# казан утлары

12
ДЕКАБРЬ-1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

**12**

ДЕКАБРЬ
1970

## Бу санда:

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

Ш. РӘКЫЙПОВ. Таңнар һаман матурмы! Повесть. 3
Г. РӘХИМ. Бәхетем сыек димим... Хыялый төбәктә. Урамнар артында яшел болын... Кыр юлларын дөбердәтеп... Ут һәм су. Бу язны... Сагышымны сөйләмим... Исемеңне бик еш кабатламыйм. Шигырьләр . . . . . . . . . . 27
Ә. ЕНИКИ. Картлар. Курай. Хикәяләр. . . . . . 31
К. БУЛАТОВА. Туган җиремә. «Кеше бул», диеп... Син юк идең... Кайчан гына әле шундый... Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . 46
Е. УТКИН. Куеп иңне иңгә. Атакага йөрде «Шүрәле». Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . 48
Н. ФӘТТАХ. Әтил суы ака торур. Роман. . . . . 49
Ә. СИНЕГУЛОВ. Кеше эзли. Яңгырда калган дарыдай... Йөрәкнең тирлесен беләм мин... Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . 91
Х. ӘЮПОВ. Урман. Карлар эреп бетә... Язгы яңгыр. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . 92

ЗАМАНДАШЛАРЫБЫЗ

М. НАСИБУЛЛИН. Фидакарь Фидан. . . . . . . 94

ХӘСӘН ТУФАНГА 70 ЯШЬ

Х. ТУФАН. Кара арыслан. Кем көчлерәк. Лирика һәм физика. Сәлам әйтегез. Яп әле, яп. Митта-а! Робагыйлар. Шигырьләр. . . . . . . 102
Г. БӘШИРОВ. Барган саен юллар күңеллерәк. . 107
Т. ГАЛИУЛЛИН. Сүз кушасы килә талларга. . . 111
Р. МОРАН. Туфан могҗизасы. . . . . . . . 119
С. ХӘКИМ. Төнге ике... Шигырь. . . . . . . 121
С. КУДАШ. Ярты гасырдан соң... Истәлек . . . 122

САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

М. НИГЪМӘТҖАНОВ. Яңа тормыш җырчысы. . . 130
Җ. ФӘЙЗИ. Онытылмас иптәш. . . . . . . . 134
З. СӘЙДӘШЕВА. Җырлар остасы. . . . . . . . 136

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Н. ӘМИНОВА. Типте йөрәк... Чәчләремдә... Керфекләрең чыланмаган... Сөйдем сине... Айлы

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

бер төн... Буй-сыннарың шул булса да... Миңа моңсу... Мин башканы сөйгән идем... Бар авыр сүз кадалганы... Җәйдә телим кояш көлүен... Зәңгәр күктә... Ерактан ук... Гөлләр башын түбән игән... Этюд. Шигырьләр. . . . . . . . 139

КЫЗЫКЛЫ БИОГРАФИЯЛӘР

П. ДЕГТЯРЕВ. Революция солдаты. . . . . . 143

ДУСЛАР ҖЫРЫ

С. АСАНОВ. Казан утлары. Шигырьләр. . . . . 152

ИРКЕН МИНЕМ ТУГАН ИЛЕМ

Н. ХӘКИМУЛЛИН. Алтай тауларында. Альпинист язмалары . . . . . . . . . . . . . . 154

СӘНГАТЬ

С. ЧЕРВОННАЯ. Сәнгатьчә нәфислек өчен. . . 163

Бәләкәй рецензияләр . . . . . . . . . . . 169

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Г. ЗӘЙНАШЕВА. Конфет. Корбан исемле малай. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . 173

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Ә. РӘШИТОВ. Шаян такмаклар. Әсмабикә «дәвасы». Шигырьләр... . . . . . . . . . . . 175
И. ЗАКОНОВ. Тәэсирле лекция. Ишәк хөкеме. Бюрократик мәзәк. Рәхәтләндерү. Битлек. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . 176

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 180

1970 елда журнал битләрендә басылган әсәрләр 184

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 3/IX-1970 ел. Басарга кул куелды 26/X-1970 ел. ПФ 09110. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 80246 экз. Заказ С-491. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1970 ел.

Шамил Рәкыйпов

# ТАҢНАР ҺАМАН МАТУРМЫ?

ПОВЕСТЬ[1]

## Гыйльфанның унберенче кыйссасы



Без, хыялымдагы Гыйльфан белән, академия бинасы янына килдек. Шома таш баскычлардан күтәрелеп, кызыл келәмнәр җәелгән киң коридорга үттек. Мәшһүр полководецларның стеналарга эленгән портретларын, каты сугышларны сурәтләгән сәнгать әсәрләрен карап әйләндек. Төрле кабинетларда булдык. Лекция залларының ишек төбендә тукталып тордык: занятиеләр барганга, эчкә керергә кыюлыгыбыз җитмәде.

Чит телләр кафедрасы янында йомшак кәнәфигә утырып, беренче геройларыбызны укыткан ханымны көткәндә Гыйльфан мөлаем йомшак тавыш белән сүзен дәвам итте:

— Ничаклы кадерле истәлекләр! Биредә мин партиягә кердем, биредә мин хәрби фәннәрнең нечкәлегенә төшендем, яшәргә, көрәшергә, сөяргә өйрәндем. Әйе, әйе, сөяргә дә мин шунда өйрәндем. Элек бу тойгы вакыт-вакыт мине шактый кыргыйландырып җибәрә иде. Мин сөйгән кешеңне чиксез хөрмәт итәргә кирәклеген аңладым. Зур иткән дә, хур иткән дә — хатын-кыз дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр.

Рәхиләне яратуымны, шуны уйлап газаплануымны Маргаритам беренче көннәрдә үк күреп алды. Ләкин тойгыларымны мыскыллап нык бер сүз әйтсен! Ягымлылыгы, кешелеклелеге, олы җанлы булуы белән һаман саен үзенә карата барды ул мине. Миңа ял да бирде, акыллы киңәшче дә була белде! Мондый кешене яратмаска, хөрмәт итмәскә мөмкин түгел.

[1] Ахыры. Башы 11 санда.

Иван Чернопятко белән бер группада укыйбыз. Застава начальнигыбыз Петр Федорович Терешкин кабат безгә башлык булып алды — арабызда ул иң өлкән кеше. Без лейтенантлар, ә аңа майор дәрәҗәсе биргән иделәр инде.

Әнә шулай бергәләп фән биеклекләренә үрмәлибез. Мин майорны ярышка чакырдым. Ул гуманитар фәннәр буенча аксый, ә миңа хәрби фәннәр авыр бирелә. Аның хәрби фәннәрне әйбәт белүе гаҗәп түгел: академиягә чаклы махсус мәктәпне тәмамлаган. Шуңа күрә аның миңа ярдәм итә алуы бәхәссез иде. Ә үзенә ни? Шуны уйлап булса кирәк ул: «Ә сез, Батыршин, миңа кайсы фәннән булышырсыз икән соң?» — ди.

— Инглизчәдән,— дим мин моңа.

— Инглизчәдән... һм... Элек берәр төрле мәктәп яки курс тәмамладыгызмы әллә? — ди бу.

— Академия тәмамлаячакмын. Курыкмагыз, бурычлы булып калмам! — дим.

Күнде теге. Ләкин бу эштән үзенә файда киләчәгенә ышанмады бугай. Әйдә, булышыйм инде, дигәндер, күрәсең. Ул элек-электән шундый күндәм һәм йомшак күңелле кеше иде бит.

Инглиз теле укытучыбыз Татьяна Алексеевнага да сүземне сүз итәчәгемне әйттем.

Майор Терешкин үзенең җегәрен беренче дәрестә үк чамалап, тәмам күңелсезләнде: «Батам мин, Гыйльфан, бу юлы, мөгаен, коткарып кала алмассың!» — ди.

— Күңелегезне төшермәгез, иптәш майор. Тәвәккәл таш яра! — дим.

Дәрестән соң класста калып диктантлар язарга, ватып-сындырып булса да үзара инглизчә сөйләшергә гадәтләнеп киттек. Бу күнегүләргә Иван Чернопятконы һәм курсташыбыз Виктор Тимаковны да тарттык.

Нәтиҗә ничекме? Сүздә тордык, әлбәттә. Миңа килгәндә, мактану булмасын, өстәмә рәвештә гарәп телен дә өйрәнә башладым. Энигә рәхмәт. Ул Донбасста чакта ук мине гарәпчә тырмаштырырга, аз-маз укыштырырга күндергән иде. Мәскәүдән хатны аңа гарәпчә генә сырлыйм, ул да шулай җавап бирә. Шытырдатып укыйм, язам. Ә гарәп телен белмим. Әшмени бу? Үз-үземә ачуым килде. Чик сакчысы ич мин. Күп телләр белергә тиеш.

Иптәшләр гаҗәпләнә: ничек өлгерәсең? диләр. Вакытыңны бүлә белсәң, һәммәсенә өлгерәсең икән ул. Ихластыр шулай.

Академиядә үзебезнең курсантлардан футбол командасы оештырып җибәрергә, гимнастика, бокс, фехтование белән шөгыльләнергә дә мөмкинлек таптык әле без. Билгеле, Чернопятко электәгечә минем уң кулым иде. Миннән башка кая барсын ул? Без гел бергә инде. Группада янәшә утырабыз, бер үк бүлмәдә яшибез. Акчаны да бергәләп тотабыз. Кызлар күзләргә дә бергә барабыз. Әйе, Маргарита Ивановнаны эзләп тапкач, очрашырга сүз куешкан җиргә икәүләп бардык без. Алдан ук килешеп куйдык: кыз кемне сайлап ала — ул шуныкы була.

Әйткән сүз — аткан ук. Киттек билгеләнгән сәгатьтә очрашу урынына. Иван да дәшми, мин дә дәшмим. Икебез дә кыз турында уйлыйбыз. Икебезнең дә аны үзенеке итәсе килә. Бикназлы, бик чибәр шул, парень. Әйбәт тәрбия алган кыз, белемле, культуралы. Әгәр сөйгән егете булса? Ул чакта... ул чакта ни дип без сызгырган җиргә килер иде әле ул? Юк, аның бернинди егете юк. Яшь, инсафлы кыз бала әле ул. Георгиевский залда утырганда күрдек ич. Аңардагы тыйнаклык, аңардагы моңсу караш!.. Сөйгән егете бар кеше үз-үзен шундый кыюсыз, шундый сак тота димени?! Адашкан яшь болан кебек ич ул! Беркеме юк — монысы хак. Кемне ошатыр — монысы язмыш кулында.

Метрода Иван да шул хакта уйлап бара икән. Ул ачыктан-ачык:

— Әгәр кыз сине ошатса һәм үзең дә аны... Рәхиләдән артык күрсәң, Рәхиләне миңа бирерсең,— диде.

— Ярар! — дидем мин. Ә үзем: «Җүләр син, Иван, Рәхилә күптән кияүдә булмаса, әлегә чаклы хат язмый түзеп торыр идемени? Кәт әйдә, кәт һавадагы кошны!» дип уйлап куйдым.

Метродан чыктык. Яз ае — март кергән булса да, төштән соң азрак салкынайтып җибәргән иде. Тротуар кырыйларына җыелган су эремчекләнеп тора, аяк астында айкалучы күгәрченнәр, чыпчыклар йоннарын кабартканнар. Шәһәр халкы барыбер сынатмый тагын: яшьләрнең күбесе яланбаш, җиңел пальтодан. Кызлар аеруча чибәрләнеп киткәннәр сыман. Гел көләләр. Битләренә яз кояшы бизәү яккан.

Маргарита Ивановнага яз ничек тәэсир итте икән? Ул тагын да чибәрләнгән булырга тиеш... Ул Белорус вокзалы янындагы күпердә көтәргә вәгъдә биргән иде. Күренми. Әллә... Юк, кайбер кызлар кебек кыланып сөйләшмәде ул бүген минем белән. Аңа ышанмаска мөмкин түгел иде. Тавышы шундый иде аның. Гадәттә күзне күңел көзгесе диләр. Күз күңел көзгесе булса, тавыш йөрәк илчесе буладыр, мөгаен.

Күперне бер әйләндек. Тәмәке көйрәтергә дә өлгердек. Кызыбыз юк та юк.

Вокзал чатында гына лоток сыман бер нәрсә бар. Анда карт бер яһүд сату итә. Янында кызлар да күренгәли. Шарлары, тасмалары, конфет-прәннеге бар. Бәлки безнең назлы кызыбыз да шунда тукталгандыр?

Ул анда юк иде. Өстәвенә, без килүгә сатучы карт әйберләрен брезент белән томалап китеп барды, бездән лотокка күз-колак булуны үтенде.

— Ярар,— дидек без. Карт күздән югалуга, брезентны тартып ачтым да: «Бала-чага, кыз-кыркын! Кемгә прәннек, кемгә шар? Акча юк дип тормагыз, бушлай сатам, алыгыз!» — дидем.

Башта Чернопятко да аптыраган иде, аннары булышырга яныма килеп басты. Икәүләшеп, бер тиен акча алмыйча, сату итепме итәбез. Әниләрен сөйрәп балалар килә, ояла-ояла яшь-яшь кызлар килә. Һәммәсенә сораган нәрсәне бирә торабыз. Ун-унбиш минут үтмәгәндер, лотоктагы әйберләрдән җилләр исте.

Менә бер заман, ах-ух дип йөрәген тотып, сатучы картыбыз йөгереп килеп җитте: «Нишләдегез, командир иптәшләр, башымны хур итәсез лабаса!» ди, кычкырып еламый гына.

— Күпмелек товарыгыз бар иде, папаша,— дим мин.

— Җиде йөз сиксән ике сум унҗиде тиенлек,— ди бу.

Стипендия алган гына идек — сигез йөз сумны санадым да бирдем картка. Ул, рәхмәтләр укый-укый, калтыранган куллары белән акчаны кесәсенә яшерде.

Нәкъ шул чакта безнең янга Маргарита Ивановна килеп чыкты. Ул сату итүебезне читтән генә күзәтеп торган, күрәсең. Елмая-елмая: «Ә безгә дигән матур шарлар очып киткәнгә охшый, кызым!» диде.

Без, корт чаккандай сискәнеп, ул җитәкләп килгән чем-кара күзле, бөдрә чәчле, өч-дүрт яшьләр чамасындагы курчак кебек бик матур кызчыкка текәлдек. Кем кызы ул? Нишләп Маргарита Ивановна аны бирегә иярте килгән? Мөгаен, безне шаяртырга уйлагандыр. Янәсе, нәрсә әйтерләр икән сюрпризны күреп...

— Менә без килдек,— диде Маргарита Ивановна, шат булырга тырышып.— Күрәсез, икәү килдек. Ул «икәү» сүзенә аеруча басым ясап әйтте. Мин Маргарита Ивановнага дикъкать иттем. Йөзе агарган, керфекләре тетрәнә иде аның.

— Без дә икәү ич,— диде Чернопятко.

— Әйе шул, менә хәзер без чибәр туташ белән танышабыз,— дидем мин, бөлокәчкә таба бөгелеп, күрешер өчен аңа кулымны суздым.

Шул чак әйтсәң адәм ышанмаслык хәл булды: әнисенең пальто итәгенә ябышып безгә башын кыңгыр салып карап торган кызчык, мәр-

җәндәй вак тешләрен күрсәтеп, чәчкә ачылгандай елмайды да минем муеныма сарылды.

— Папочка! — диде ул яңгыравык тавыш белән һәм кочагыма сеңеп бетәрлек булып, озак кайтмыйча торган өчен этисенә үпкәләвен, энисенең һаман-һаман елавын тәтелдәргә тотынды.

— Рита! Рита, нишләвең бу? — диде көтелмәгән хәлдән аптырап калган ана.

Миңа әллә нәрсә булды. Әйтерсең, хәнҗәр белән йөрәгемә чәнчеделәр. Тик сулу алуым бүленеп калса да, бу чәнчү әрнетмәде, киресенчә, мин нииндидер ләззәт кичердем. Иң әүвәл кызчыкның үзәк өзгеч моңлы бер тавышында әнкәм уйнаган кубыз чыңнарын ишеткәндәй булдым. Аннары салмак кына атлап килә-килә анасыннан аерылып калган колынның өзгәләнеп кешнәвен искә төшердем. Сандугачлы әрәмәләрдә печән чапканда, җәйге иртәнең искиткеч матурлыгына соклана-соклана тукталып чалгы янаган, җиләк җыйган чакларымны хәтерләдем. Якында гына, янымда гына Рәхиләнең эссе сулышын тойгандай булдым. Аның җиләктәй иреннәре җавап көткәндәй кысыла төшкән, тузгыган чәчләрен җил тарый...

— Юк, кызым, синең этиең...

Мин шушы сүзләрдән айнып киткәндәй булдым. Нәкъ шул мизгелдә яшь ананың озын керфекләрен сирпеп, кыюсыз гына күтәрелеп каравын, аннары өметсезләнеп, ачынып башын аска июен күреп калдым. Тәнемә гүя салкын су койдылар.

— Минем эти! Минем эти бу! — диде сабый, калтыранган кулларын сузып торган анасына барырга теләмичә, муеныма ныграк сырышып.

— Ә бәлки... аның синең кебек үз кызы бардыр? — диде Маргарита Ивановна акрын гына.

— Юк, юк, мин аның кызы булам! — диде сабый, кире какмаслык итеп.

— Әлбәттә, әлбәттә,— дидем мин. Ихластыр, әллә нишләтте бу сабый мине, әллә нишләтте.

Якында гына, янымда гына күксел томан шикелле өрфия пәрдә эченнән миңа карап, гүя барысына җавап көткән Рәхилә акрын-акрын чигенеп, эреп беткәндәй юк булды.

Миңа уңайсыз булып китте. Мин бер гөнаһсыз сабыйны кочаклаган килеш, уйларыма күмелеп, басып торам. Маргарита Ивановна да, Чернопятко да безгә хәзер нәрсә эшләргә кирәклеген хәл итә алмый торган халәттә иделәр.

— Кил, кызым, үземә,— диде, ниһаять, ана, рәнҗүле тавыш белән.

— Юк-юк, аңа миндә рәхәтрәк,— дидем мин.

Чернопяткога мондый кыюлык каян килгәндер, Маргарита Ивановнаны сул ягыннан култыклап, мине уңга калдырды да, кирәктәй кулын алга сузып, күңелле итеп: «Ә хәзер бераз йөреп алабыз, аннары мороженый ашарга керешәбез»,— диде.

Киттек.

Бу минем гаилә корып җибәрүгә таба тәүге адымнарым иде.

Урамда халык, халык... Барысы шат, барысы бәйрәмчә киенгән. Кайберәүләренең кулында чәчәкләр күренә.

Яз чәчәкләре — умырзаялар иде алар...

Рита белән без әнисенә караганда да тизрәк дуслаштык.

— Эти янына барам! — дип даулый иkән ул көн саен. Маргарита Ивановна кызының минем белән дөньясын онытып уйнавын, миннән башка ашарга да, йокларга да ятарга теләмәвен күреп, икеләнеп, газапланып йөрде-йөрде дә йокысызлыктан талчыккан ак йөзенә акрын-акрын кызыллык йөгерә башлады — минем якка борылды һәм төбе киселгән зифа аккаен төсле кочагыма сыгылып төште.

Матур айлы кичләрнең берсендә ике буйдак яшәгән бүлмә түрендә тыйнак кына бер мәҗлес үткәрдек. Безнең чәчләрне чәчкә бәйләгән туй мәҗлесе иде ул.

Алдан ук сөйләшенгәнчә, Чернопяткога үзенә аерым почмак әзләргә туры килде. Аның караватын башы күккә тигән Рита биләде.

Көннәр гаҗәеп дәрәҗәдә тиз үттеләр. Без искиткеч тату яшәдек. Күксел томан шикелле өрфия пәрдәгә төренеп юкка чыккан Рәхиләә, толымнарын кистереп, кире кайткандай булды. Вакыт-вакыт, йокы аралаш мин аңа исеме белән дә эндәшкәнмен икән. Күпне кичергән акыллы Марам рәнҗемәде. Зур түземлелек белән күңелемне акрын-акрын яулады. Мин аңа һәлакәткә очрап үлгән очучы ирен, ул миңа үлгән мәхәббәтемне беркайчан искә төшермәдек. Алар бүгенгенең кадерен белер, ләззәтен татый төшәр өчен күңегү чорыбыз, җитлегүебез генә булганнар дип нәтиҗә чыгардык.

Озакламый икенче нәни кызчыгыбыз Әлфия дөньяга килде. Үзенә охшаган кара чутыр иде ул. Барлык кызлар да шундый ут борчасы буламы икән? Вәт мәшәкатьләр тудырды ул безгә! Өйрәнмәгән эшем калмады. Ай үсәсен көн үсә дигәндәй, бик чая булып чыкты бу кыз. Укып кайтуымны гына көтеп тора, бишектән кулга ал, күтәреп йөрт, сикерт үзен. Шырк-шырк көлә. Үсә-үсә тагын шул билгеле булды: кайсы ягы беләндер бу тиктормас кыз Рәхиләне хәтерләтә иде шикелле. Аның турында уйламаска тырышам, ләкин уйлар черки кебек, күңел тәрәзәңнән кусаң, ишектән бәреп керәләр...

Ә көннәрнең берендә теп-тере Рәхилә үзе килеп керде. 1940 елның дүртенче январь иртәсе иде бу. Ишекне ачып җибәрсәм, алдымда хәрби киемле очучы басып тора. Иң әүвәл, әллә Маргаританың ире һәлак булмыйча, кайтып керде микән дип тә уйлап алдым. Ләкин күзләре, яңаклары, иреннәре таныш лабаса моның! Менә ул төз басып үкчәләрен шапылдатып честь бирде: «Хатын-кызлар эскадрильясының очучы штурманы Рәхилә Бәширова, укуын уңышлы тәмамлап, ялга кайтып бара».

Ә үзенең күзләреннән мена-менә мөлдерәп яшь тамарга тора.

Түземәдем: «Вольно!» дип кычкырып, кулыннан тотып җилтерәтеп, түргә, Кыш бабай янына китереп бастырдым.

— Марочка! Таныш булыгыз: Рәхилә бу! Раечка! — дим.

— Ул икәнен шундук абайладым,— диде хатыным. Мин аны кунакка кырын карар, үгетләргә туры килер үзен дип торам. Юк, алай итмәде. Кояштай балкып, Рәхилә янында бөтерелде! Юл килеп талчыккандырсың дип, ванна бүлмәсенә кертеп җибәрде, үзе минут эчендә өстәл хәзерләде. Миңа шыпыртлап кына: «Кызның асылы белән мәйханә булгансың икән!» — ди.

— А как же! — дигән булам. Үзем эчемнән генә: «Иванның бәхете бар икән, мөртәтнең, дим. Тизрәк үзләрен таныштырырга кирәк!»

Рәхилә ванна бүлмәсеннән пешкән әнистәй алсуланып, җыйнакланып чыкты. Кыяфәте якын килерлек түгел. Башын тавис коштай горур тота. Миңа карамый да. Бүләге дә бар икән: ике кызга ике зур курчак алып килгән. Икене... Димәк, безнең хәлләрне ишетеп торган.

Дөресен әйтергә кирәк, чәй яны күңелле булмады. Шуннан соң тиз-тиз Чернопятко765ны чакырдым. Ул ялгыз башы янәшә квартирада гына яши иде. Рәхиләне күргәч, аптырап югалып калды. Кулыннан тоттым да кыз янына утырттым. Гомергә дус булуларын теләдем. Тегеләр серле генә итеп бер-беренә карашалар.

Иван миңа гына әйтмәгән икән: алар ел буе хат язышып ятканнар. Адресны Казаннан Хафизә җибәргән. Теге чакта безнең арада килеп чыккан аңлашылмаучылыкка да шул Хафизә сәбәпче булган. Рәхиләне сынар өчен, юкны бар итеп хат язган. Монысы да сыны катса да

сыната торганнардан түгел. Училищедагы укытучысының рәсеменә жизнәң шул була инде, дип язып җибәргән.

Чәй эчкәч, җыйнаулашып елка карарга киттек. Рәхилә юрганга төрелгән Әлфияне күтәрде, Чернопятко Ританы җитәкләде. Шулай мәш килеп, бер гаилә кешеләредәй чүкердәшеп бардылар. Халык казанышлары күргәзмәсендә елка карадык. Кичке якта Иван бүлмәсенә җыелдык. Аккордеонын күтәреп, Терешкин килде. Җырладык, биедек, күңел ачтык.

Рәхилә безгә кайтмады. Икенче көнне иртән саубуллашырга керде: «Бәхет телим сезгә!» — диде, Әлфия янына килеп, мөлдерәп карап торгач, сабыйны үбеп, тиз-тиз чыгып китте. Бусагада: «Гыйльфан абый, дуслык көчендә кала!» — дип кычкырды.

Аны вокзалга Чернопятко озатты.

Мин тәрәзә янына басып карап калдым. Аннары... берне тотырып эчкән идем, яныма Мара килде, сабыр гына итеп: «Әтисе, акылыңа кил, аракы эчеп берәү дә мәртәбәгә ирешкәне юк!» — дигәч, тукталдым. Ял көне иде. Ишек алдына чыгып, барлык күрше балаларын таудан бик озак чана шудырдым, поезд ясап тартып йөрдем.

Чернопятко белән сөйләшәсем килсә дә, янына кермәдем, нигәдер ул үзе дә күренмәде.

Ә кич Мара, күңелемдәгене белгән кебек: «Берсе диванга, икенчесе караватка ятып йоклаганнар. Көзгә Жуковский исемендәге академиягә килергә ниятли. Шунсыз кияүгә чыгарга исәбе юк», — диде.

«Рәхилә, син аз гына да үзгәрмәгәнсең!» — дип уйладым мин.

## Гыйльфанның уникенче кыйссасы

1941 елның июнь башларында безне Көнбатыш Белоруссиягә стажировкага җибәрделәр. Биредә әле күптән түгел генә поляк паннары хуҗалык иткәннәр. Бичара белорус крестьяны чабагач белән ашлык суккан. Көз җиткәч, җир идәнле өендә чыра яндырып, киндер тукып көн күргән. Тәрәзәдә карындык, түрдә сәке. Кара мичләр ишекне ачык куеп ягылган, мал-туар да шунда, кешеләр дә шунда... Ачлы-туклы яшәгән халык йогышлы авырулардан кырылган. Кая монда бездәгедәй калай түбәле зур мәктәпләр, китапханәләр, уку өйләре, клублар!

Урман өскә авып тора — ындыр артында гына. Ләкин аннан чыбык сындырып алырга да рөхсәт юк. Чөнки урман панныкы, графныкы, тагын әллә кемнеке...

Җырларында сагыш, күзләрендә моң булган халыкның. Белоруссиягә азатлык килгәч кенә иркен сулаганнар бу төбәктәгеләр. Ләкин кырык бергә аяк баскач, кояшлы аяз күктә әледән-әле шомлы кара болытлар күренгәли башлагач, тынычлык югала. Европаны басып алган афәт бирегә таба борыла. Ил чикләренә гаскәр туплана, техника җыела. Җирдән һәм күктән чик бозулар ешая. Боларның һәммәсен күреп торган халык шөбһәләнә, чырайлар кырыслана, йөрәкләр кысыла...

Гыйльфан сөйләвеннән туктый, яңагына таяна һәм, черем иткәндәй, күзләрен йома. Беләм, ул йокламый, шулай уйлана гына. Нәрсә турында уйлый икән хәзер Гыйльфан? Мөгаен, сугыш башлануы турындадыр.

1941 елның 22 июнь таңы минем дә хәтеремдә яңара. Бу каһәрле көн турында ничаклы кыйссалар тыңлаганым, дәһшәтле чынбарлыкны сурәтләгән рәсемнәр, картиналар тамаша кылганым булса да, хыялымдагы Гыйльфанга: «Сездә сугыш ничек башланды?» дип сорау бирми кала алмыйм.

— Курсташың, хәзер отставкадагы генерал-майор Виктор Иосифо-

вич Тимаков бу хакта тәфсилләп сөйләде: Син дә, Гыйльфан туган, өстәп берничә сүз әйтмәссеңме икән?

Гыйльфан күзләрен ачты, чәчләрен сыпырды һәм:

— Тимаков белән очрашып сөйләшүегез яхшы булган,— диде.— Инде әкияттәге сыман итеп үткәннәргә кайтыйк... Хәер, алар әкият түгел, алар эзсез югалмаган. Ул чактагы күкрәүләр, тетен, аһ-зар — барысы-барысы галәм киңлегенә таралса да, җирдә эзләр калгандыр.

Минә Гродно шәһәре. Ямь-яшел бакча-шәһәр иде ул. Мондагы чисталык, мондагы сихәтле саф һава, мәһабәт матурлыкка сокланмаска мөмкин түгел. Урам саен, чат саен, йорт саен бакча. Чишмәләре челтерәп, сандугачлары сайрап тора. Шәһәр уртасында — зур бер парк. Шуннан ерак түгел безнең өченче армия штабы урнашкан иде... Штабны һәм шәһәрне саклап ничаклы кеше һәлак булды...

— Шушы паркта, кайчандыр өченче армия штабы урнашкан бина алдындагы туганнар каберенә татар кызы, Советлар Союзы Герое очучы Ольга Александровна Санфированың да сылу гәүдәсе күмелгән...

— Әйе, зур корбаннар бирдек, туганкай.

Дәшмибез. Гыйльфан тәмәке көйрәтә. Аннары, ирен кырыеннан гына күгелҗем төтен алкаларын җибәрә-җибәрә, сүзен дәвам итә.

— Шимбә көнне, ягъни 21 июньдә, төшкә чаклы штабта группабыз белән карталар өстендә хәрби өйрәнүләр үткәрдек. Лейтенант Чернопятко укчы полкның командиры ролендә иде. Башкаларыбыз, шул исәптән мин дә, батальон командирлары булып алдык. Алты сәгатькә сузылган бу өйрәнүдә һөҗүм итү һәм оборона тоту тактикасын үзләштердек. Чернопятко полк белән оста идарә итте.

Башкаларыбыздан да укытучылар бик канәгать булдылар.

Йокларга соң гына яттык. Мин өйгә хат яздым, нке яшьлек кечкенә кызым Әлфияне өзелеп сагынуымны әйттем, әнисеннән тизрәк фоторәсемен җибәрүен үтендем.

Кызым төнлә төшемә керде. Дулкынланып ярсып аккан зур дәрьяның икенче ягында... Рәхилә кочагында иде ул. Башында — чәчәк такыя. Өстендә — ап-ак күлмәк. Никах күлмәге... Кызым кул изи-изи мине янына чакыра. Мин, Хасан күлен тугыз тапкыр йөзеп чыккан кеше, кул-аякларымны да селкетә алмыйм. Батам, авызыма су тула...

Дежурныйның: «Подъем! Боевая тревога!» дигән тавышына уянып киттем. Еракта туктаусыз гүләп самолетлар оча, зениткалар ата, гөрселдәүләр ишетелә иде.

— Ял көнендә дә рәхәтләнеп йокларга ирек бирмиләр ичмаса! — дип сукранды кайсыдыр, киенә-киенә.

— Осоавиахим күнегүләр үткәрә, ахры,— диде икенче бер курсант.

Шул чак баш өстеннән иләмсез гүләп, һава ярып самолет очып үтте. Янәшәдә генә бакча артында бер-бер артлы көчле шартлаулар ишетелде, нәрсәдер гөрселдәп ауды, тәрәзә пыялалары коелып төште, түшәм чытырдады, өстән тузан, штукатур коелды. Бинада бүтән бер генә минутка да калырга ярамый иде.

— Сугыш бу, егетләр! — диде Чернопятко.

— Дөрес, Иван! Безгә фашист килә. Аның самолетлары, гүләүләреннән таныйм! — дидем мин. Тәрәзәгә карыйм. Анда таң шәфәгы. Дымлы җил бүлмәгә чәчәк һәм көек исе алып керә. Чәчәк исе тәрәзә төбендәге түтәлләрдән килә. Көн саен иртән күкрәк тутырып сулый идек без аны. Бүген... Бакчадагы сандугачлар да тынган.

Стенадагы сәгать чалышаеп туктап калган. Уклары иртәнге өч сәгать кырык җиде минутны күрсәтеп, шунда тынып тормышның бетүен искәртеп тора иде.

Чыгып тезелдек. Шәһәр ут, ялкын эчендә. Җир гүя мотор гүләүләре, гөрселдәүләр, шартлаулар белән тулы.

Окопларга яттык. Һава һөҗүме артыннан дошманның танклары, мото-механикалаштырылган частьлары өскә ыргылды. Сугыша-сугыша чигенәбез.

Бераздан Германиянең безнең илгә искәрмәстән һөҗүм итүен белдерделәр. Без барыбыз да өченче армия составына кушылып сугышырга ниятләгән булсак та, кайберләребезгә Гроднодан бик тиз китәргә боерык килде. Оборона Халык Комиссариаты Терешкинга, Тимаковка, миңа һәм тагын берничә иптәшкә генә штабта калырга ризалык бирде.

Чернопятко белән кочаклашып хушлаштык. Курсантлар төялгән машиналар кузгалды.

— Хуш, Гыйльфан! — дип кычкырды Чернопятко.

— Хуш, Иван! — дидем мин.

— Ул-бу була калса...— Чернопятко сүзен әйтеп бетерә алмады, сирена гүләве яңгырады.

Майор Терешкин белән мине Хәрби советның секретариатына, ә майор Тимаковны штабның разведка бүлегенә билгеләделәр.

Фронтның бу участогындагы хәлләр безгә яхшы таныш иде. Безнең гаскәрләр дошманга бик нык каршылык күрсәтәләр. Фашистлар зур югалтуларга дучар ителәә. Ләкин көчләр тигез түгел. Без һаман чигенергә мәҗбүр. Корал, сугыш кирәк-яраклары азайды, үлүчеләр, яралanучылар күп... Дошман соңгы сулышына чаклы көрәшәчәк «большефикларны» урап үтә. Дүртенче июльдә Оборона Халык Комиссариатыннан безгә Мәскәүгә кайтырга дигән боерык алынды. Бу чакта без тәмам чолганышта калган идек инде. Унбиш кеше бер төркемгә берләшеп божраны өзеп чыгарга булдык. Партия җыелышы майор Тимаковны төркемнең җитәкчесе, мине аның урынбасары итеп сайлады. Поход шартларында, утлы божрада үткәрелгән беренче җыелышыбыз иде бу. Дошманның эре берләшмәләре белән бәрелешкә кермичә, вагракларын юк итә-итә үзебезнекеләргә таба чигенергә дигән карарга килдек.

Птичь елгасына килеп тәртелгәнче юл тыныч үтте. Фашистларны шактый борчуга төшереп, берничә кыю операция ясап алдык. Утызлап фрицны дөмектердек, техникаларын юк иттек. Артиллерия атышларыннан фронтның һаман тирәнәя баруын абайламаска мөмкин түгел иде. Урман аланнары, юллар фашист листовкалары белән чуарланып ята. Бу кәгазьләрдә немец командованиесе Кызыл Армияне тәмам җимерелде дип белдерә, чолганышта калучыларның каршы торуын мәгънәсезлеккә санап, берсүзсез бирелергә тәкъдим итә. Көндезләрен без тукталган хутор, авылларда крестьяннар шушы листовкаларны тотып янызга киләләр иде. «Дөресме, туганнар, бу хәбәр?» — дип сорыйлар иде алар бездән.

Мөмкинлек булган һәр җирдә крестьяннар белән әңгәмәләр үткәрдек, Кызыл Армиянең фашистлар өеренә ныклап каршы торуын, озакламыйча һөҗүмгә күчәчәген һәм җиңү алып киләчәген аңлаттык. Тарихтан дәлилләр китердек, хәзерге чигенүнең сәбәпләрен төшендердек.

Крестьяннар безгә ашарга-эчәргә биреп, изге теләкләр теләп калдылар.

Әйткәнемчә, Птичь елгасына килеп тәртелгәнче бертөрле дә югалтуларга очрамадык. Киң сулы елганы кичәргә хәзерләнгәндә, майор Терешкин суга кермәячәген белдерде. Ул йөзә белми икән. Хасан күлендәге шикелле аркама яткырып чыгарга теләсәм дә, моңа аны һич күндерә алмадым. Исән-сау килеш ничек мин синең муенына атланыйм? Моның гарьлеген кая куйыйм? — диде дә суга керергә батырчылык итмичә, көймә эзләргә китте һәм шул китүеннән борылып кайтмады.

Ахырдан билгеле булганча, ул фашистлар засадасыннан кача-кача адашып, полковник Гришин партизаннарына юлыккан. Тәмам алҗыган

командирны бригада штабына китергәннәр. Полковник аны үз бригадасында калырга күндергән. Майор фашистлар тылында партизаннарның дистәләрчә кыю операцияләрен хәзерләгән һәм үзе дә шунда урнашкан. 1943 елның көзендә исә безнең регуляр частьлар белән очрашып, полк командиры итеп билгеләнгән.

Без майорны ике көн, ике төн эзләдек. Аның хәбәрсез юкка чыгуына мин иң беренче чиратта үземне гаепле санадым. Сөекле командир, әйбәт иптәшнең югалуы бик үкенечле иде. Авыр кичердем мин бу югалтуны.

Юан гына имән төбендә уйланып утырам.

Чернопятко хәзер кайда икән?

Ике яшь бала белән бер ялгызы калган Мара ни эшли икән?..

Күңелсез иде миңа. Мондый чакта кеше төшенкелеккә бирелә башласа, аны син беткәнгә сана. Дисциплина, үз-үзенә һәм иптәшләренә таләп нык булырга тиеш.

Кабат партия җыелышы үткәрдек. Үз фикерләремне әйттем. Майор Тимаков тышкы кыяфәтне адәмчә саклап йөртүдән башлап, чигенү, разведка ясап дошманга һөҗүм итү тактикасына кадәр һәммәсен элеккегечә җиренә җиткереп эшләргә тиешлегебезне куәтләде.

Тәүлек саен утыз-кырык чакрым юл үтәбез. Һәрберебезнең аркасында бер поттан артык йөк: гранаталар, дисклар, бүтән кораллар. Арыла. Ашарга-эчәргә дә такы-токы гына. Шуның өстенә, дошман белән очрашып чәкешкәләп тә алгалыйбыз. Менә биредә,— Гыйльфан тез өстендәге планшетына җәеп салынган картага бармагы белән төртеп күрсәтә,— Червень исемле шәһәрчектән утыз чакрымлап көнбатышта кызык бер хәл булып алды...

Мин түзмим, очучы Павел Башкиров белән урманда очрашу турында сөйләвен үтенәм.

— Әйе, булды андый хәл, булды,— ди Гыйльфан.— Унынчы июль иртәсе иде. Кояш кыздыра, бөркү. Учак кабызмыйча гына коры-сары белән тамак ялгап, карт чыршы күләгәсендә азрак черем итеп алырга хәзерләнәбез. Баш астына салыр өчен печән җыйдык. Гимнастерка якаларын ычкындырып, кошлар сайравын тыңлап чалкан ятабыз. Тыныч. Рәхәт. Мин иптәшләргә Хасан күле буенда печән чапкан чакларны сөйлим. Һәммәсе күз алдында. Ничаклы гомер үткән... Фашистлар Германиясенең союзнигы булган Япония анда безнең чиккә кабат басып керергә җай гына көтеп ятадыр. Ай-һай, тыгызга туры килердер егетләргә. Хәер, монда менә эшләр тагын да хөртирәк. Кайда хәзер фронт сызыгы — билгеле түгел.

Мин йокыга китә алмадым, постка басар чак җитте. Юкәле аланлыкта агач төбенә посып, тирә-якны күзәтеп ятам. Көтмәгәндә, әллә кайдан болыт астыннан һава ярып, әрсез карчыгалар шикелле бер төркем мессершмитлар килеп чыкты. Безнекеләр аларны эре калибрлы пулеметлардан атып каршыладылар. Әрсез истребительләр авыр кыймылдаучы бомбардировщиклар өчен бик куркыныч бит алар. Шуңа күрә бомбардировщиклар заданиегә озатучысыз йөрмиләр. Безнекеләрнең дә озатучы бер истребительләре булган икән. Менә шул кыю җан дошман очкычларына берүзе һөҗүм итте. Әле берсенә бәйләнә, әле икенчесенә. Рәтләрен болгатып, исәпләрен чуалтып бетерде тегеләрнең. Җиде самолет безнең авыр бомбардировщикларны куып әзәрлеклисе урынга, төп курстан читләшеп, бердәнбер истребитель белән сугышырга мәҗбүр булдылар. Безнең бомбардировщиклар китеп күздән югалды. Фашистларның менә җан ачулары чыкты, күрәсең. Сукыр черкидәй, өерләре белән менә ябырылдылар. Менә безнең самолетның канат астыннан төтен бөркелде, кара койрык хасил булды, янтайды һәм җиргә маталде. Аяз күктә ап-ак гөмбәзле парашют калыкты. Пилот бездән бер чакрымлап ераклыктагы ачыклыкка килеп төште.

Майор Тимаков: «Коралга!» дип төркемне аякка бастырган иде инде.

Өлкән лейтенант Котляров белән икәүләп очучыны эзләп йөгердек. Урман кырыенда ук күренеп торган кечкенә генә бер авыл ягыннан тырылдап мотоцикл килә башлады. Чокырга яттык. Фашист безнең турыга житкәч, автоматлардан кыска «чират» бирдек. Жирән чәч мәтәлеп төште. Мәетне урманга сөйрәп, үлән белән күмеп куйдык. Мотоцикл төзек булып чыкты. Моторны кабызып, агачлар арасыннан борыла-сарыла үзебезнең очучыны эзләргә керештек. Ул безне пистолетын кулына тотып, сак каршылады. Киемнәре янган, үзе пешкән булса да, дошманга ансат кына бирелә торган түгел иде аның кыяфәте.

— Сез кемнәр, кайсы частьтан? — диде ул, безгә һаман әле шикләнеп карап.

Аңлаштык. Өлкән лейтенант Павел Башкиров мине күптәннән ишетеп белә икән. Атлыгып килеп кулымны кысты. Бу кызык танышу истәлекле булсын әйдә дип, мин өлкән лейтенантка трофей автоматны бүләк иттем.

Павел безнең янда калды.

Унберенче июльдә Березина елгасын кичтек, 15 августта Сож елгасына килеп життек. Тагын бер атна үткәч, алда фашист гаскәрләре агылган Орша — Унеча шоссе юлы күренде. Безгә юлның теге ягына чыгарга кирәк иде. Ләкин ничек?

Майор Тимаков мине өч иптәш белән разведкага жибәрде. Юлдан ерак китмичә шактый ара үтеп, күзәтүләр алып баргач һәм крестьяннар белән сөйләшкәч, отрядка зур куркыныч янавын ачыкладык. Без килгәнче бередән генерал-майор Калмыковның кавалерия бригадасы үтеп киткән. Ул бригада тик кенә үтеп китмәгән, әлбәттә. Сиздерми генә шоссе юлына якынлашканнар һәм жайлы урыннар сайлап, туплардан, пулеметлардан ут ачып, йөзләрчә гитлерчыларны дөмектергәннәр, күп техника, сугыш кирәк-яраклары юк ителгән. Дошманның алга таба хәрәкәте тукталган. Кавалериячеләр шушы өзеклектән файдаланып, чолганыштан чыгып ычкынганнар. Бригаданың флангларын каплап торучы вак подразделениеләр генә өлгерми калган. Алар урманга таралырга мәжбүр булганнар. Фашистлар шушы вак подразделениеләрдән үч алмакчы икәннәр.

Үзебезнең регуляр частьларга тизрәк кушылу өчен юлның теге ягына чыгу хәстәренә керештек. Жайлы гына урын сайладык. Көтәбез. Үч иткән шикелле, юлдагы хәрәкәт кимеми дә кимеми. Бәйрәм парадындагыча, гаскәрләр өзлексез көнчыгышка таба агыла.

Көндезге икеләр тирәсендә нәкъ безнең каршыдагы аланга ниндидер бер часть тукталды. Лагерь сыман нәрсә корып жибәрделәр. Радистлар элемтәдән бушаган арада шау-шулы музыка тапшыралар. Шнапс белән сыйланып өлгергән солдатлар, музыкага кушылып, жыр башладылар. Кайберләре юына, кайберләре чишенеп ташлап кояшта кызына.

Кыланышларына гарьләнеп үләрсең. Ихластыр әгәр! Әйтерсең, үз илләрендә сәйранга чыкканнар. Йөрәктәге ачуны басып булмый, сикереп торып өсләренә ташланасы килә, автомат белән селтәнә-селтәнә кырасы, кисәсе килә үзләрен.

Фашист ахмак түгел ул. Безнең тыелып тора алмыйча, авызлык тимерен чәйнәп ятуыбызны сизенгәндәй, урманга каратып ике пулемет куйдылар, ә аз гына сулгарак минометчылар урнашты...

Менә кистек автоматлардан! Тешне кысып, агач төпләрендә ята бирәбез. Немецларның урманга керергә исәпләре күренми. Безгә каратып куелган пулеметлар, минометлар саклык чарасы гына. Курка фашист, шикләнә...

Поход кухняларыннан, борынны кытыклап, тәмле исләр тарала. Безнең ничә көн инде кайнар аш күргәнебез юк... Ачның күзе икмәктә

дип тикмәгә генә әйтмәганнәр. Кухня арбасы өстенә баскан ак калфаклы, алъяпкычлы карт немецның зур чүмечен күзәтеп, төкерек йотып яту бик ук күнелле эш түгел ул, мин сиңа әйтим.

Агач төбендә посып ятулар яраган икән әле. Менә бер заман өч автомашина шоссе юлыннан чыкты да безгә таба килә башлады. Куаклыкларга житкәч, алардан иллеләп автоматчы коелды. Рәткә тезелеп, тыртыр ата-ата киләләр. Безнең кебек посып ятучылар булган икән бу тирәдә — һәммәсе, уттан качкан боланнар кебек, янәшәдәге чытырманлыкка йөгерде.

Фашистлар килә дә килә. Алар безне күрмиләр, без күрәбез. Автоматлар әзер, гранаталар әзер. Теге чакта самурайлар да шулай күкрәк киереп килгәннәр иде.

— Арт сабакларын укытырга кирәк бу тәти егетләрнең! — дим мин майор Тимаковка.

— Әзерләнергә! — диде майор.

Фашистлар безгә унбиш-егерме метр ара калгач, майор кул селтәде һәм уналты автомат дошманга бердәм ут ачты. Тегеләрнең сафлары буталды, борылып качучыларга гранаталар ыргыттык. Куа барырга ярамый иде. Янәшәдәге урманга йөгердек. Бераздан без засадада яткан наратлыкта миналар шартлый башлады. Без йөгердек тә йөгердек...

Искә алсаң, мондый очрашулар ифрат күп булды безнең. Озын сүзнең кыскасы шул: безнең отряд дошман тылыннан мең чакрымга якын юл үтеп, йөзгә якын фрицны дөмектереп һәм әсир алып, унлап автомашинаны шартлатып, күп кенә сугыш кирәк-яракларын юк итеп, егерме сигезенче августта Брянск өлкәсенең Столбы авылы янында үзебезнекеләргә кушылды.

Мәскәүгә кайттык. Мине, ай-ваема карамыйча, дөнья түбәсенә — Памирдагы ил чикләренә билгеләделәр.

Әни, тере сөяк сыешыр дип, минекеләрне Казанга үз янына алдырган. Юл уңае белән Казанга тукталып, азрак кунак булгач, Памирга юнәлдем. Ул чакта анда дошман агентурасы үзенең активлыгын шактый көчәйткән иде. Көн саен диярлек чикне бозалар, безнең погранотрядлар белән канлы бәрелешләр булып тора, чик буендагы безнең көтүләрне, авылларны талап киткәлиләр. Көн-төн ял итмичә ышанычлы яңа секретлар ясадык, постлар билгеләдек. Егетләр белән тирләп-пешеп эшләргә туры килде. Ихластыр, җиңел нәрсә түгел бу. Әйбәт чик сакчысы булу өчен зур талант кирәк дисәм, Америка ачмам дип беләм.

Нәтиҗә шул: өч-дүрт ай дигәндә егетләр үз профессияләрен ярыйсы гына оста үзләштереп, дошман агентурасының юлын бикләделәр. Чик буена тәртип урнашты. Мин үз миссиям үтәлгәнгә санап, тизрәк фронтка җибәрүләрен сорадым. Үтенечемне канәгатьләндермәделәр. Мәскәүгә яздым, фронтта күбрәк файда китерәчәгемне расларга тырыштым. 1942 елның көзендә мин Сталинград казанында кайный идем инде. Башта рота командиры идем, аннары минем карамакка батальон бирделәр. Төрлесен күрергә, төрлесен татырга туры килде. Ләкин ни булса булды, бер адым да артка чигенмәскә дигән боерыкны намус белән үтәдек. Утыз көн уразаның бер көн бәйрәме дә була дигәндәй, тиздән безнең эшләр күңелләләнеп китте. «Казанда» калып тәмам пешкән гитлерчыларны коралсызландыра башладык, һаман әле әтәчләнгәннәрен башларына сугып кикрикләрен шиңдердек. Егерме бишенче январьда безнең егерме беренче армия көнбатыштан Сталинградка бәреп керде һәм икенче көнне Мамай курганы янында күршеләр белән кушылып, немецларның 6 нчы армиясе командующие фельдмаршал Паулюска, башында акылы булса, бирелүдән башка чара калмаганлыгын аңлаттык. Бөтенләй үк исәрләнмәгән икән әле ул: утыз беренче январьда фельдмаршал Паулюс штабы белән үзе теләп безгә әсир төште. Бу тарихи вакыйганы миңа үз күзләрем белән күрергә насыйп булды.

«Кызганыч, шундый очрашуны алданрак искәрсәм, академиядә инглиз һәм гарәп телләре белән берәттән, һич авырсынмыйча, немец телен дә өйрәнгән булыр идем!» — дидем мин иптәшләргә.

Өйдән хат килде. Һәммәсе сау-сәламәт. Терешкинның һәм Чернопятко белән Рәхиләнең генә кайда икәнлекләре билгеле түгел. Терешкин семьясына «Ирегез хәбәрсез югалды» дип язганнар...

Кайда сез, дуслар? Кәперәйгән дошманның койрыгына баса-баса куа башлаган көннәрдә үлеп ятарга яки хәбәрсез бөтенләй югалырга мөмкинмени?! Юк, сез исән-сау булырга тиеш. Сугыш мәшәкатьләре генә хатларыгызны юлда тоткарлыйдыр. Без әле очрашырбыз. Безгә җиңү көннәрен күрергә дә насыйп булыр.

Сталинградтагы хәлиткеч җиңү, Мәскәү янындагысы кебек үк, безнең һәммә сугышчының күңелен күтәреп җибәрде. Озын колактан гына Курск тирәсенә дә «казан асарга» ниятләнүебезне белгәч, мин үземне шунда җибәрүләрен сорадым. Әллә җае туры килде инде, әллә бәхет елмаеп куйдымы — миңа Курск тирәсенә күчәргә рөхсәт иттеләр.

Атаклы Курск дугасы! Бу операциягә катнашып исән-сау калган кеше ике тимер ташкын тудырган гарасатны, җирне, күкне көйдергән ут туфанын җиде буынга сөйләргә васыять әйтер. Шунда без исән калдык. Нәрсә ул исән калу — җиңдек! Җиңмәсәк, исән калмас идек. Прохоровка авылы янында безнең гаскәрләр күрсәткән батырлык турында җырлар чыгарырга, поэмалар иҗат итәргә кирәк! Нәрсә, бар алар дисезме? Яхшы... яхшы...

Курск дугасындагы атаклы бәрелешләрдән соң, дошманның тимер өемнәренә әверелгән танклар каберстаны төтенли, пыскый калды. Без алга киттек. Озакламыйча Брянск өлкәсенә килеп кердек. Минем өчен истәлекле җирләр башланды. Командованиедән рөхсәт сорап, Столбы авылын карарга бардым. Янмый калган берничә өй, көл, күмер өемнәре уртасында инде күптән суынган озын муенлы мичләр һәм кое сиртмәләре генә моңаеп тора иде монда.

Нинди матур, төзек авыл иде бу! 1941 елда үзебез чигенгән юллар, урманнар, хутор-авыллар аша Гроднога чаклы килеп, һәр җирдә дошман калдырып киткән шундый коточкыч вәхшилекне күрдем мин.

1944 елның июль аенда Молдавия җирләре өчен каты сугыш барды. Элеккеге чиккә җиткәч, тантаналы рәвештә герблы чик баганаларын утырттык, контроль пунктлар, заставалар ясадык. Тиздән мине Молдавиядәге НКВД гаскәрләренең чик буе участогы коменданты итеп билгеләделәр. Нәкъ шунда чакта — туры килүен кара син аның — күңелдә сакланган иске танышлардан берәүне очраттым...

Юк, Рәхиләне түгел. Рәхилә, күп тапкырлар талпынып караса да, фронтка эләкмәгән: Үшнә буенда авырттырган аягы аркасында хәрби самолетка утырудан бөтенләй мәхрүм калган ул. Тылда яту гарьлегеннән якыннары белән аралашмас-сөйләшмәс булган. Аннары Чернопятконың өйләнүен ишеткән... Сугыш, туганкай, кешеләрнең характерын да үзгәртте ул...

## Гыйльфанның унөченче кыйссасы

Чернопятко белән кайчан очраштыкмы? Аерылышуыбыз, хәтерегездәдер, сугышның беренче көнендә Гродно янында булды. Ә очрашуыбыз... Теләсәгез ничек хөкем итегез: сугыш беткән көнне Мәскәүдә очраштык! Дөрес, моңа чаклы бер-беребезнең исәнлеген белдереп, хатлар язышкан һәм берничә тапкыр телефон аркылы сөйләшкән идек инде. Ләкин бер-берсен зарыгып сагынган чын дуслар өчен нәрсә ул хат һәм телефон аркылы гына сөйләшү?!

Чернопятко ул чакта Ерак Көнчыгышта хезмәт итә иде. Миңа анда барырга, аңа Мәскәүгә килергә һич туры килмәде.

Ниһаять, җиңү көнен бәйрәм итү уңае белән безгә башкалада күрешергә насыйп булды.

Җиңү тантанасын, бөтен дөньяга ишетелерлек булып яңгыраган артиллерия салютларын сөйләмәсәм дә күзаллый торгансыздыр. Гаҗәеп күренешләр иде алар!

Дустым белән ни төстә очраштыкмы? Сөйлим, тыңлагыз. Ул ишекне шакып тормады. Юл чемоданын тоткан килеш атылып керде дә: «Гыйльфан, мин кайттым!» — дип кычкырып җибәрде.

Кочаклашып күрештек. Иванның коңгырт күзләрендә яшь ялтырады — йомшак табигатьле кешегә күпме генә кирәк соң?

Кояшта, җилдә йөреп бите кара-кучкылланып янган, йокысыз төннәр күп эләккәнгә, күз төпләре җилсенеп чыккан, әлек бөдрәләнеп торган чем-кара чәчләре сыекланып, чигәләренә көмеш җепләр йөгергән.

Кочаклашып коридорда басып торабыз. Сөекле Марам безне житәкләп түргә уздырмаса, без, бәлки, шулай онытылып озак торыр идек әле.

— Исәнлек-саулыкмы, Иван?! Аю, җиңү белән котлыйм үзеңне! — дидем мин, аның җилкәсенә сугып.

— Гыйльфан, сине дә котлыйм, дустым! — диде ул.

Урамда, безнең подъезд төбендә, ниндидер машина өзлексез гудок бирә. Гаҗәпләнеп тәрәзәгә килəм. Шул арада Иван учы белән маңгаена сугып ала һәм вокзалдан үзе утырып килгән таксига акча түләргә дә онытып, өйгә керүен хәтерләп, ашыгып аска төшеп китә.

Без шул арада тиз-тиз табын хәзерлибез. Шундый очрашу хөрмәтенә тамак чылатмый буламы соң?!

Төне буе сөйләшеп утырдык. Академиядә укыган чактагы иптәшләрне искә төшердек. Аларның күбесенә җиңү шатлыгын күрергә насыйп түгел икән шул. Эх, язмыш! Ничаклы кеше әрәм булды, ничаклы шәһәр, авыллар көлгә әйләнде! Мәгърүр Россия, син барыбер җиңеп чыктың. Без Антейларга тиң баһадирлар биргән, бөтен сугыш авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән совет халкы турында горурланып сөйләштек.

Эчләре мәкер белән тулган япон империалистлары Ерак Көнчыгышта ил чикләренә уннарча дивизия гаскәр туплап, басып керергә җай көтеп тормаган булсалар, аларга каршы куелган безнең ничаклы көч фашистларны кыйнауда катнашыр иде һәм без җиңү байрагын рейхстагка иртәрәк кадар идек. Алар безнең чиктә гаскәр тотып үз союзниклары — фашистик Германиягә булыштылар. Моның өчен Араки, Хасимито, Итагаки, Кимура, Нагано, Сигемицу, Умедзу кебек бер төркем сугыш чукмарлары гаепле. Аларның пычрак эшләрен чик буенда күп күргәнгә, Иван белән икебез дә нәфрәтләнүнең аргы ягына чыккан идек бүген.

Тиздән аккордеонын күтәреп, подполковник Терешкин килде. Үзебез яраткан «Раскинулось море широко» һәм «Броня крепка и танки наши быстры» җырларын җырладык. Сугыштан кайтмаган иптәшләрне кабат искә алдык. Кабат япон агрессорларын нәләтләдек.

Алгарак китеп булса да әйтим: юкка гына чәпченмәгәнбез икән без ул көнне. Тиздән үзәк матбугатта Берләшкән Милләтләр оешмасының япон хәрби җинаятьчеләрен каты җәзага тарту турындагы искәртүе белән таныштык. Дөресен әйтик, бу хәбәр безнең күңелләргә бик хуш килде. Килмичә: җир шарының теге ягыннан да гаделлек җилләре исә башлады түгелме?! Иш янына куш дигәндәй, Бөек Ватан сугышы тәмамланып ике ай үткәч, ягъни егерме алтынчы июльдә Потсдам декларациясе Япония хәрби көчләренә берсүзсез капитуляция ясарга тәкъдим итте. Дүрт илнең вәкилләре кул куйган бу тарихи документта: «Без японнарны раса буларак коллыкка төшерергә яки милләт була-

рак юк итәргә җыенмыйбыз. Әмма барлык хәрби җинаятьләргә, шул исәптән, безнең хәрби әсирләргә карата зур ерткычлык эшләгән кешеләргә дә каты гадел хөкем чыгарылырга тиеш... Япон халкын алдап, аны бөтен дөньяга хуҗа булу максаты белән канлы сугышларга этәргән власть даирәләре мәңге-мәңгегә алып ташланырга тиешләр. Чөнки дуамал милитаризм дөньядан бөтенләйгә куылмыйча торып, җирдә иминлек һәм гаделлек мөмкин түгел», диелгән иде.

Япония хөкүмәте сугышсыз гына капитуляция ясарга риза булмады. Сугыш хәрәкәтләре театры Ерак Көнчыгышка күчте. Германия фашизмын челпәрәмә китергән шанлы гаскәрләр япон милитаризмын да тиз арада тез чүктерделәр. Һәм 1945 елның икенче сентябрендә Япония капитуляция турындагы актка кул куярга мәҗбүр булды. Моны Американың «Миссури» линкорында Япония императоры илчеләре — чит ил эшләре министры Мамору Сигемицу һәм япон генеральный штабы начальнигы генерал Исидзиро Умедзу башкарды.

Сугыш хәрәкәтләре туктатылды. Японияның төп хәрби җинаятьчеләре, шул исәптән безгә күптәннән билгеле Мамору Сигемицу һәм Исидзиро Умедзу да, кулга алынды. Аларны һәммәсен Сугамо төрмәсенә илтеп яптылар.

1945 елның уналтынчы декабрендә биш дәүләт чит ил министрларының Мәскәүдә үткәрелгән киңәшмәсеннән соң, япон хәрби җинаятьчеләрен хөкем итү өчен унбер дәүләт вәкилләре катнашында Халыкара хәрби трибунал оештырылды. Аның белән Ерак Көнчыгыштагы союздаш державалар гаскәрләре башкомандующие АКШ армиясе генералы Дуглас Макартур җитәкчелек итте.

Бу вакыйгаларны без, Хасан күле бәрелешләрендә катнашучылар, зур кызыксыну белән күзәттек.

1947 елның икенче яртысында безгә, Хасан күле вакыйгаларын раслаучы шаһитлар сыйфатында, Токио процессына барырга туры киләчәген әйттеләр. Бу вакытта Америка империализмының япон хәрби җинаятьчеләрен акларга тырышу позициясе билгеле була башлаган иде инде. Матбугатта Америка дәүләт эшлеклеләре Японияның хәрби потенциал көчен коммунизм куркынычыннан, ягъни бездән саклану өчен файдаланырга кирәклеге турында ачыктан-ачык яздылар, дәлилләр китерергә, шул ялганга киң җәмәгатьчелекне ышандырырга тырыштылар. Генерал Макартур да сүздән эшкә күчте: гаепләре расланмады дигән сылтау белән егерме сигез япон хәрби җинаятьчесен сак астыннан азат итте. Алар арасында Азия илләре өстеннән Японияның хакимлек итәргә тиешлеген гамәлгә ашыру өчен төрле агрессив планнар төзетеп, аларга фатиха биреп утыручы император Хирохито да бар иде. Канга сусаган шушы галиҗәнап, япон хөкүмәте башлыгы, беренче номерлы җинаятьче 1945 елның көзендә үз-үзен үтергән принц Коноэ Фумимаро белән берлектә 1938 елның егерме беренче июлендә хәрби министр Итагаки һәм япон генеральный штабы начальнигы Тодзионы үз сараена кабул итеп, Хасан күле районында СССР чикләренә гаскәр белән басып керергә ризалыгын биргән иде бит инде. Чик буенда япон башкисәрләре оештырган провокацияләрне, үч алырга, сизгер булырга чакырган шаһитләрне ничек онытмак кирәк?! Эшләр болай барса, Токиодагы тикшерүче һәм яклаучы әфәнделәр (ә аларның күбесе америкалылар) караны ак, акны кара дип расларга да күп сорамаслар.

Хакыйкатьне өстен чыгарырга, илебез мәнфәгатен, аның керсез абруен сакларга кирәк. Моны барысын да үз күзләребез белән күргән, авырлыкларны үз җилкәбездә татып, кайнар каныбыз белән түләгән кешеләр эшләмичә кем эшләсен тагын?!

Кыскасы, Токио процессына Чернопятко белән икебез дә ныклап хәзерләндек. Шахта электровозы зарядныйга кертелеп аккумуляторларына энергия туплаган шикелле, без дә әйләнә-тирәбездә кайнап-

гөрләп торган тормыштан үзебезгә кирәкнең һәммәсен таптык. Башкалабыз үзенең сигез йөз еллыгын бәйрәм итәргә хәзерләнә. Урамнарда кояш, кешеләр йөзендә кояш. Нәни кызым Әлфия беренче класска мәктәпкә китте. Шатлыгының иге-чиге юк. Кулыннан җитәкләп, үзем озата бардым. Туктаусыз бытылдый да бытылдый. Кем булыр ул? Врачмы, инженермы? Үзе доктор булам, ди. Апасы Рита быел бишенче класста. Ул укытучы булырга хыяллана. Икесенә дә юллар ачык. Теләкләре тормышка ашачагына һич шигем юк. Чөнки алар өчен Туган ил кайгырта. Шундый бәхетле илнең тулы хокуклы гражданы булу үзе бер бәхет түгелмени?

Уйланып йөрим, дошман белән йөзгә-йөз очрашкач югалып калмас өчен фикер туплыйм.

Сеңелем Әминә бездә тора. Ул быел башкала педагогия институтын тәмамлаячак. Вакыты кысан булса да, минем хәлне аңлап, әллә кайлардан инглизчә кызыклы китаплар алып кайта. Токиода суд процессы инглиз һәм япон телләрендә алып барыла. Мин Хасан күле районында булган вакыйгалар турындагы шаһитлык күрсәтмәләремне инглиз телендә сөйләргә тиешмен.

Эшебез хак булса да, күңел тыныч түгел.

Ерак юлга сәфәр чыгасымны ишетеп, Голубовкадан җиңги белән Хәлиулла абзый, Казаннан әти-әни, Гайшә апа, Кәлимулла агай килде. Гөр килеп сыйланып утырдык. Сырадан бүтәнне авызына якын да китермәгән әти һәм Хәлиулла абзый, ялгыз башыбыз ерак китүгә шөбһәләнеп, сак булырга, күзне ачыбрак йөрергә киңәш иттеләр. Әллә күңелләре сиздеме икән җанкисәккәйләремнең! Эх, Токиодан очып киткән көнне кире кайтарып булса!..

«Безне озатырга кил, көтәбез»,— дип Рәхиләне чакырып телеграмма суктык. Аның хәзер Казанда яшәвен, ире дә, үзе дә җаваплы урында эшләп, малай үстерүләрен ишеткән идек инде.

— Килмәс, ахры,— дибез.— Борчып юкка гына телеграмма суктык!— дибез.— Яшь чакта кем кыз белән йөрмәгән дә, кайсы кыз кочтырмаган?! Инде кияүгә чыгып бала анасы булгач, сызгырган җиргә атлыгып килеп җитәргә димени?

Анпары ире бар, улы бар... Нәрсә әйтер ул аларга?

Миңа, ниһаять, иртәгә сәфәр. Бүген башкалада соңгы төнебезне кунабыз. Соңгы төн... Чыннан да соңгы төнебез булган икән ул.

Һәммәсе күз алдында, һәммәсе кичә генә булган кебек, ә бит егерме өч ел вакыт үтте инде! Авыр миңа, бик авыр, туганнар!

Күзләремә яшь тулганмы? Кулларым төйнәлгәнме? Тешләремне чытырдатып кысып түзәм. Безне йоткан океан упкынындай, күңелем шашынса да, мескенләнеп илермәм, сыкранмам.

Әйе, мәңге онытылмас соңгы кич турында сөйли идем мин.

Хатыны Александра Григорьевнаны ияртеп, Чернопятко безгә керде. Аз гына күңелләнеп, чәйләп утырабыз. Әлфия миңа Токиодан «әни» дип әйтә белә торган курчак алып кайтырга куша. Рита да, муенымнан кочаклап, колагыма үз йомышын пышылдый.

Сабыйларым! Шифалы җылы сулышыгызны һаман үз битемдә тоям, күзләрегездә җемелдәгән шатлык, сөенеч нурларын һаман хәтеремдә саклыйм мин. Сез хәзер зурлардыр инде. Ләкин минем өчен икегез дә мәңгегә сабыйлар булып калдыгыз сез.

Рита кызым, кояш күңелле әткәңне озатырга вокзалга төшмичә, мәктәпкә китүең өчен син һаман үз-үзеңне гафу итә алмыйча өзгәләнеп яшисең икән. Үтенеп сорыйм: тынычлана күр. Син берниндн акылсызлык эшләмәдең. Шулай кирәк иде, җаным. Мин барыбер киттем. Барыбер...

Киткәнче булган истәлекле бер вакыйга турында сөйләргә кирәк икән әле. Мәскәүдәге соңгы кич ул.

Хатыннарыбызны яныбызга утыртып, парлашып-гөрләшеп чәй эчәбез дигән идем бит. Ишек шакыдылар. «Әйе, керегез!» дибез. Карасак — Рәхилә. Керде дә, мин сиңа әйтим, коридор стенасына сөялде. Тазарган, тагын да чибәрләнгән бу. Толымнарын кистереп, чәчләрен бөдрәләткәнгә шома ак йөзе түгәрәкләнгән шикелле.

Чернопятко белән икебез дә сикереп торып, Рәхилә янына йөгердек. Ул еш-еш сулый иде. Икебезгә берьюлы ике кулын сузды. Эндәшмәде. Керфекләрен сирпеп карады гына. «Килмичә кала алмадым шул!» — диләр иде аның җете кара күзләре.

Төлке якалы пальтосын салдырып, чәчәкле яшел яулыгын, өрсәң очып китәрлек күгелҗем шарфын үзебезнең киемнәр янына элдек. Рәхилә тиз-тиз кулларын юып, айдай балкып, өстәл тирәсендәгеләр белән күрешеп чыкты, балаларга кучтәнәчләр өләште. Тәмләп чәй эчтек, шәрап-виносыннан авыз иттек. Рәхилә сакланып кына эчсә дә, йөзе бик тиз алсуланып чыкты, гадәттәгедән күбрәк көлде, шаярып сөйләште.

Менә ул бөдрәләрен селкеп, кинәт урыныннан күтәрелде һәм: «Дуслар, бер тәкъдим бар. Әйдәгез, пилмән пешерик. Пилмәнсез нинди озату кичәсе булсын ул!» — диде. Биленә Маргаританың ак алъяпкычын бәйләде, камыр изде. Без ит тападык, күзләрдән яшь агыза-агыза суган әрчедек.

Рәхилә Казанда чакта да безгә килеп бик еш пилмән ясаша иде. Аның кулларына күз иярми: елт-елт йөреп тора һәм яшь гөмбә шикелле түм-түгәрәк матур пилмән әзер. Без берне ясаганчы ул өчне-дүртне бөгә. Шулпа кайнап чыкканчы кухня өстәле өсте аның пилмәннәре белән тулды, куна тактасына тезә башлады.

— Туйганчы ашарсыз, Токиода да искә төшерерсез! — диде ул.

— Теш казыган саен искә төшерермен, Рәхилә! — диде Иван.

Рәхилә шаяртып, үткен теллеләнеп:

— Пилмәнне генәме? — дип сорады.

Хатыны алдында нәрсә әйтсен инде Иван, югалды да калды. Мин ана ярдәмгә ашыктым:

— Пилмәнне дә, сине дә искә төшерербез. Ләкин, дөресен әйтик, тамак туйганчы беренче планда пилмән булыр. Монысына инде үпкәләмәссең! — дидем.

Рәхилә көлә-көлә бармак янады.

Аш пешкәнче һавада йөреп керергә булдык. Балаларны ияртеп ишегалдына бакчага чыгып киттек. Шау-гөр килеп таудан чана шудык. Яшь чакларны искә төшердек.

— Гыйльфан абый, хәтерлисезме Эт тыкрыгында ат чанасына төялешеп таудан шуганны? — дип сорады Рәхилә.

Кая инде ул хәтерләмәгән! Үтте яшьлек, йөрәкне көйдерә торган хатирәләр генә калды аңардан...

Нигә болай икән соң бу тормыш? Яшьли сөйгән кешең белән очрашканчы һәммәсе үз урынында була, яшисең, дөнья куасың — гомер үткәне сизелми дә. Зарланмыйсың да. Очрашкач... Утлы күзләре белән багыренне көйдереп, бүгенгедәй серле итеп карап та куйсалар... Дөньяны тылсымга күмеп энҗедәй кар бөртекләре дә төшкәләп торса?

Югалыгыз, моңсу хисләр! Без тормыштан канәгать, без алсу яңаклы, төймә борынлы кызчыкларыбызны чырылдатып, көлә-көлә таудан чана шуабыз, чаналардан поезд ясап аларны тартып йөрибез. Утырыгыз: сезне тартырга да көч ташып тора бездә!

Чаналар шыгырдый, балалар чыр-чу килә, балалар, тәгәрмәчләр тавышы чыгарып, тукылдап баралар. Әлфия паровоз булып кычкыра. Рәхилә, вокзалдагыча кул болгап, моңсу гына озатып карап кала.

Иртәгә — аерылышу, иртәгә поезд безне Владивостокка алып китәчәк.

Пилмән искиткеч тәмле булды. Кабат музыка тыңладык, кабат вальс әйләндек. Без, Иван белән, әледән-әле Рәхиләне биергә чакырдык. Бу хәл, билгеле, хатыннарыбызга ошамады, ахры. Ләкин Рәхилә аларга игътибар итмәде, бөтерелеп-бөтерелеп биюендә булды. Без аның чиктән тыш тәэсирләнүен күрдек.

— Татарча җырла әле, Раечка, зинһар, җырла! — диде Иван. Рәхилә күңелендә кайнаган тойгыларга кирәкле юнәлеш бирергә теләп.

— Җырламас дидегезме әллә? Җырлыйм! Әлбәттә, җырлыйм! — диде Рәхилә һәм матур яңгыравык тавыш белән җырлап та җибәрде:

Нинди җилләр, нинди куллар аны
Өй түрендә китереп утырткан?
Кубыз кебек пар каен төбендә
Хәзер көн дә
Сагыш көен тынлап ут йотам,
Бер ялгызым калып утырам...
Эх!
Берсен киссәм, берсе җәл —
Бигрәк авыр,
Бигрәк авыр минем хәл!

Без Иван белән күзгә-күз караштык. Тынып, моңаеп калган җырчыны тәбрикләдек.

Хатыннарыбыз да җырны ошаттылар һәм җыр сүзләрен тәрҗемә итүне сорадылар.

Иван белән кабат күзгә-күз караштык.

Мин, «Иске карурман»ны хәтерләп, караңгы төндә яшь егетнең яхшы атлар белән карурманны кичүен, пар каен кисеп алуын сөйли башлаган идем, Рәхилә: «Не совсем так»,— дип, үз җырының сүзләрен тиешенчә тәрҗемә итте дә бирде.

Хәзер инде хатыннарыбыз күзгә-күз караштылар.

Рәхилә белән сүзләр бетмәгән, дөресрәге, үзсенеп сөйләшүебез башланмаган иде әле. Рәхилә ничек яши, кияве кем, ул ни исемле? Иң мөһиме: бәхетлеме ул?

Җырына карaганда...

Балаларны йокларга яткыргач, үз бүлмәбезгә кереп утырдык. Маргарита Иван хатыны Александра белән янәшә, без Рәхиләнең ике ягында. Азрак сөйләшеп утыргач, Маргаритага: «Марочка, калдырыгыз безне, зинһар, өчебезне генә. Безнең монда ирләрчә сөйләшү!» — дидем мин.

Хатыннар, бик үк риза булмаганга акрын гына кузгалып, безне Рәхилә янында калдырдылар. Рәхиләнең ике ягына утырдык. Күзләренә карадык. Учыбыз белән йомшак ак кулларын сөйдек. Безнең арада шундый эчтәлекле сөйләшү булып алды.

— Раечка, Иванга нишләп хат язмадың?

— Чолганышта калган иде ич ул...

— Ул түгел, мин чолганышта калган идем.

— Шулаймыни? Мин тагын икегез дә бергә дип уйладым.— Рәхилә күзләрен идәнгә текәп, иңбашына төшеп торган яшел яулыгының чукларын саный башлады. Озын керфекләрен сирпеп, миңа карап куйды.— Аннары синең исән икәнлегеңне белдем.

— Мин исән булганга Иванга хат язмадыңмы? Кызык...

— Дөресен әйткәндә, шулай.

— Мин бернәрсә дә аңламыйм! — диде Иван, гаҗәпләнеп.— Дустымның исән булуы өчен шатланырга кирәк чакта дистәләгән хатларыма җавап язмыйлар.

— Мин... аның исән булуы өчен шатландым,— диде Рәхилә, акрын гына.

— Ә нишләп җавап язмадың?

Бүлмәдә кабер тынлыгы урнашты. Без җавап көттек.

Рәхилә иреннәрен тешләп, тирән итеп сулу алды һәм ярыйсы ук кырыс тавыш белән:

— Бая сез хатыннарыгызга ирләрчә сөйләшәсебез бар, дидегез. Ирләрчә сөйләшсәк, шул: Иванның хатларына җавап язган булсам, ул, сугыш вакыты дип тормастан, Казанга кайтып килү әмәленә керешер иде. Кайткач... үзе белән китәргә күндерер иде. Нигә бу? Күк белән саубуллашкач... Гомумән, нигә миннән допрос аласыз әле сез? Бәлки, минем берегезнеке дә буласым килмәгәндер? — диде.

Без гафу үтендек. Әңгәмәбезнең җебе өзелде. Ә сөйләшәсебез килә, бик килә! Мин акрын гына:

— Улыңның исеме ничек? — дим.

— Рафаил,— ди хәзер инде чит ханым, үз уйларына күмелгән килеш.

— Ирегез кем? — дим мин, Рәхиләне йокысыннан уятырга теләмәгән кебек акрын итеп.

— Рәссам,— ди ул, башын күтәрмичә генә.

— Сез бәхетлеме? — дип сорыйм мин, тәмам пышылдап. Һәм үз соравымнан үзем үк куркып киттем. Нәрсә әйтер Рәхилә, ни дип җавап бирер?

Менә ул, бөдрәләрен селкеп, башын күтәрде, яшьле күзләрен сөртте һәм:

— Вино бирегез миңа! — диде.

Иртән безне озатырга вокзалга килмәде.

Владивостокта без аңардан: «Дуслык көчендә кала. Сезне өзелеп сөюче Рәхилә»,— дигән телеграмма алдык.

## Гыйльфанның соңгы кыйссасы

Мондый телеграмма белән нәрсә әйтергә тели иде Рәхилә? Башыбызга китерә алмадык. Ерак юлга сәфәр чыгалар, башкарасы эшләре тау кадәр, күңелләре күтәренке булсын, дигәндер, мөгаен.

Шулай икән, моңысы өчен дә зур рәхмәт аңа.

Башкарасы эшләребез чыннан да зур иде шул безнең.

Махсус самолетка утырып, Токиога очтык. Бездә һава тыныч, җылы иде. Ә Японияга якынлашып килгәндә көчле җил күтәрелде, бозлы яңгыр ява башлады. Иван белән янәшә утырып сөйләшеп барабыз. Кулда Япония турында белешмә мәгълүматлар.

Табигать каршылыкларына карамыйча, куәтле очкыч хәвеф-хәтәрсез юлын дәвам иттерде. Япониянең баш утрауларын — Сикоку, Кюсю, Хонсю, Хоккайдоны очып уздык. Шундый эреле-ваклы дүрт меңгә якын утрау ярларын Тын океанның ярсулы дулкыннары юа. Горизонтта тропик кояшы көйдергән тутыккан бакыр сыман таулар, таулар. Арада атаклы Фудзияма вулканы мәһабәт булып өскә башын калкыткан. Тау итәкләрендә, иңкүлекләрдә чәй, цитрус плантацияләре яшелләнеп тора. Дөгесе җыеп алынган чуар басуларны челтерләп су баскан.

Килеп төштек. Җилле яңгыр сибәләп торса да, ярыйсы каршыладылар.

Иң яхшы отельләрнең берсенә урнаштык. Аннары үзебезнең илчелектә биредәге хәлләр белән таныштырдылар.

Подгорная заставасының элеккеге начальнигы подполковник Терешкинны, майор Чернопятконы һәм мине (минем дә званием майор) Хасан күле вакыйгаларын ачыклау өчен, шаһит буларак, киләсе атналарда гына судка чакыруларын белгәч, иптәшләр безне шәһәр күрергә димләделәр.

Токио — чын мәгънәсендәге гигант шәһәр — үзенең зур-зур отельләре, дүртәр-бишәр яруслы храмнары, универсаль кибетләре, ресторан-нары, кышын да яшеллеген саклый торган агачлар арасына салынган матур-матур йортлары белән кешене гаҗәпкә калдырырлык. Урамнары төз, андагы хәрәкәткә башың әйләнерлек. Нинди генә кәяз җинел автомобильләр юк монда... Өч көпчәклеләре дә бар! Хәер, автомобильләр генә түгел, кешене кеше тартып йөргән нужа арбасы — рикша, велорикша, педикеб һәм тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр күп очрый бу шәһәрдә.

Америкалылар 1945 елда Токионы ярыйсы гына пешекләгәннәр. Бомбага тоту нәтиҗәләре завод-фабрикалар урнашкан кварталларда аеруча күзгә ташлана. Ләкин шунысын әйтергә кирәк: хәрабәләр җимерелеп ята бирә, завод-фабрикасы исә гөрләп, төтенләп эшли бирә. Кай арада яңа корпуслар салып өлгерткәннәр дә кай арада стенасы исән калганнарын төзәткәннәр?! Гомумән, японнар искиткеч тырыш һәм пөхтә халык икән...

Гыйльфан сөйләүдән тукталды. Зәңгәр күккә күзләрен төбәп, бик бирелеп тыңлый башлады. Шылт иткән тавыш та юк. Нәрсә тыңлый чик сакчысы, ни ишетә аның сизгер колаклары?

— Самолет килә,— диде Гыйльфан.

Чынлап та бераздан биектә-биектә һава ярып килүче реактив самолет күренде. Аяз күк йөзендә озынча күксел тасма хасил булды.

Авыр тынлыкны бүлеп, мин:

— Гыйльфан, әйтегезче, Хиросиманы барып карадыгызмы? — дип сорадым.

— Әйе,— диде Гыйльфан,— гөл-бакча шәһәр күз ачып йомганчы көлгә әйләнгән, анда ун меңнәрчә кешеләр янып үлгән.

Мондый вәхшилек кирәк идеме? Юк, мең кабат юк! Иерәкләр шулай дип тибә, аек акыл шундый нәтиҗә чыгара. Хиросиманы карарга баручылар һәммәбез хәрби кешеләр без. Сугышта төрлесен күрдек. Әмма мондый варварлыкка һичкайчан кул куя алмыйбыз. Кешелек дөньясы алдында коточкыч җинаять бу! Өчебез дә дәшмибез. Аяклар җансыз шәһәр уртасындагы мәйданга атлыйлар. Анда — һәйкәл. Эллипс сыман өч аяклы постаментта кулларын күккә таба сузган нәни кызчык сыны. Ул япон халкы легендасы буенча, кешеләргә бәхет китерергә тиешле кәгазь торналарны күккә очырып җибәреп тора. Бу һәйкәлне бирегә — нәкъ атом бомбасы шартлаган җиргә — нур авыруы белән газапланып үлгән нәни кызчык истәлегенә япон балалары куйганнар. Шушы мәйданга килеп чыккан һәр япон һәйкәл янына тукталып, тын кала. Күзләрендә ачу, куллары үч белән йодрыклана. Без японнарны аңлыйбыз: бер гаепсез сабыйларны, картларны һәлак итүчеләрне дошман итеп күрмәскә мөмкин түгел.

Америка генералы Маршаллның Япониядә шартлатылган атом бомбалары чирек миллион америкалыны һәм миллионнан артык японны үлемнән саклап калды дип лаф орып, үзләре эшләгән җинаятьне акларга маташуын без дә бүген нәфрәтләнеп искә алдык.

Авыр тойгылар белән Токиога кайттык. Пыяла стеналы кунак бүлмәләребез кысан, җайсыз тоелды. Урамда малахай-малахай җепшек кар ява...

Ниһаять, безне судка чакырдылар. Элек Япония хәрби министрлыгы

урнашкан зур соры йортка киттек. Әйткәнемчә, биредә унбер ил — АКШ, Кытай, Англия һәм Төньяк Ирландия, СССР, Австралия, Канада, Франция, Нидерланд, Яна Зеландия, Һиндстан һәм Филиппин республикасы вәкилләре катнашында Халыкара хәрби трибунал суды бара. Миңа ул язмыш дигәнең ничек шаяра бит: шушы соры бинада, шушы тыныч кабинетларда еллар дәвамында ничәмә-ничә төрле явыз эшләр уйланылган, мәкерле планнар төзелгән. Ә бүген шул ерткычларның үзләрен үз өннәрендә үк хөкем итәбез. Конференц-залга кердек. Аның бер як стенасы янындагы күперчеккә судьялар өчен озынча өстәл, өстәл янына унбер урындык куелган. Урындыклар артына стенага трибуналны оештыруда катнашкан унбер илнең төрле төстәге флаглары эленгән.

Залга керүгә түрдәге шушы флагларга күз төшә. Сине тантаналы, кырыс күренеш биләп ала.

Судьялар күперчегенең алдында гаепләнүчеләр һәм яклаучылар чыгыш ясар өчен микрофонлы пульт урнаштырылган. Пультның уң ягында яклаучылар президиумы өстәле, ә сулда гаепләүчеләр утыра. Судьялар күперчегенең сулъяк кырыена шаһитлар өчен урындыклар куелып, ул да микрофон белән җиһазландырылган иде. Моның өстенә шаһитлар урыны да, пульт та яктылык сигналлары белән дә тәэмин ителгән. Төрле ил вәкилләре чыгыш ясаганда һәм шаһитлар күрсәтмә биргәндә әлеге яктылык сигналлары ярдәмендә паузалар көйләнә икән. Паузалар шундагы тәрҗемәчеләр өчен кирәк. Тәрҗемәчеләр шаһитлар һәм гаепләүчеләр арасына урнашканнар. Алар артында исә — стенографистлар. Янәшәдә үк аерым сүзләрне, тәгъбирләрне тәрҗемә иткәндә килеп туа торган бәхәсләрне хәл кылучы башлык-монитор дигәннәре утырган.

Судьялар өстәле алдына килеп бастым. Дөресен әйтим, дулкынланам. Җиңелчә генә тетрәнәм. Шундый халәтне мин беренче тапкыр шахтага төшкәндә кичергән идем. Клеть кузгалып китте. Дөм карангы. Клеть, корыч арканнан менә-менә өзелеп китәм дигән сыман, тибрәнә-тибрәнә гүя упкынга төшә...

Инглизчә:

— Шаһит Батыршин әфәнде, сез чын хакыйкатьне, фәкать чын хакыйкатьне генә сөйләргә тиеш. Шуның өчен Халыкара хәрби трибунал алдында ант итегез! — дигән сүзләрдән айнып киткәндәй булам.

СССР вәкиленең шаһитлек күрсәтмәләре бирергә тиешлеген белеп, тәрҗемәче миңа баш судьяның сүзләрен ашыга-ашыга русчага тәрҗемә итә. Яныма библиясен тотып, кара киемле кеше килә. Алдыма куелган библияне әдәпле генә этәреп, инглизчә:

— Мин дингә ышанмыйм. Совет Социалистик Республикалар Союзы гражданины буларак, судка үз илемдә кабул ителгәнчә тантаналы сүз бирергә әзермен. Һәм шулай ук миңа тәрҗемәче кирәк булмаячагын да белдерергә рөхсәт итегез! — дидем.

Судьялар күзгә-күз карашып, үзара пышылдашып алдылар. Безнең ил вәкиле, шундый ук рухта дәвам ит дигәндәй, чак кына елмаеп куйды.

Татар милләтеннән булуым да гаҗәпсендерде, ахры, хөкемче әфәнделәрне. Бер-бер артлы сораулар бирергә керештеләр. Судка бирәчәк шаһитлык күрсәтмәләремә күләгә төшерергә чамалаучылар да юк түгел. Һәрбер сорауга чатылдатып җавап бирәм: «Милләтем татар, Казан заводында, Донбасс шахталарында эшләдем»,— дим. Аннары 1938 елда булып үткән Хасан күле вакыйгаларына күчтем. Һәммәсен төкми-чәчми сөйләп бирдем. Япония хәрби министры Итагакиның яклаучысы, күзлекле, озын буйлы, чандыр америкалы һәм гаепләүчеләрдән берәү, фикеремне чуалтырга теләп, ике яклап сорау бирәләр. Бу — аларча кистерешле сорау алу икән. СССР чик сакчылары, янәсе, Хомуку

авылы янында төнлә адашып шау-шу тудырмаганнармы? Кара-каршы атышларга шул адашу сәбәпче түгелме?

Итагакига шул гына кирәк икән. Залга, яклаучы соравы буенча, күзлекле бер шадра японны чакырып керттеләр. Ант иттерделәр. Бу кеше 1938 елда Хасан күле районында чик сакчысы булган, имеш. Утыз беренче июльдә иртән томан төшү аркасында...

— Тукта, тукта! — дим үз-үземә, бу шадра японны кайдадыр күргәнем бар ич минем. Шуның куен кесәсеннән хәрби таныклыгын алган идем бит теге чакта. Әх, ул сакланса...

Судка мөрәҗәгать итәм. Бу кеше чыннан да Хасан күле вакыйгаларында катнашты, дим. Һәм соңгы фугасны шартлатып контузия алуын, үтермәгез дип ялваруын һәммәсен сөйләп бирәм.

— Кызганыч, хәрби билетын алып килмәгәнбез аның! — дим.

Шул чак нәрсә булды диярсез. Безнең ил гаепләүчесе сүз сорады һәм Танаки Рюкачиның хәрби билетын судьялар алдына китереп салды. Илебез чикләрен бозып, ике атна буе дәвам иткән бәрелешләрнең гади инциденттан башланып китмәвен, Япония генеральный штабының агрессив планы һәм аны үтәүчеләр — бүген гаепләләр эскәмиясендә утыручы җинаятьче әфәнделәр сәбәпче икәнен раслады.

Итагаки Сейсираның башы аска иелгәннән-иелә барды.

Аның янында гына, як-ягына ялт-йолт каранып, Доихара Кендзи утыра. Монысы инде бик хәтәр разведчик, штабта планлаштырылган барлык провокацияләрне җиренә житкерүче. 1931 елдан алып югары хәрби хезмәттә.

Генерал Араки Садао — СССРга каршы заговор коручыларның иң өлкәне, иң тәҗрибәлесе. Ул Ерак Көнчыгышта японнар интервенциясен оештыручыларның һәм Колчакка булышучыларның башында торган. Мәкерле эшчәнлеген 1938—1941 елларда да ташламаган. Фашистлар Германиясенә булышлык йөзеннән, СССРга һөҗүм итү планнары төзүдә актив катнашкан. Мондыйлар биредә егерме сигез кеше. Һәммәсенең намусы керле, кулы канлы.

Миңа Япониянең 1938 елда Мәскәүдәге илчесе Сигемицу Маморуны да күрергә насыйп булды. Илче әфәнде шулай ук хәрби җинаятьчеләр эскәмиясендә утыра иде.

Хөкем процессы инглиз һәм япон телләрендә алып барылганга, минем һәр сүземне японча тәрҗемә итә тордылар. Япон теленең бер үзенчәлеге бар икән: җөмләнең соңгы сүзе әйтелми торып, төгәл мәгънәне аңларга мөмкин түгел. Шуңа күрә паузалар ясау зарури күренешкә әйләнә. Мин шул арада тагын нәрсәләр сөйләргә тиешлегемне искә төшереп куям, залны күзәтәм. Хөкем залының сулъяк канатында партер һәм галерея бар. Биек булмаган барьер белән бүленгән бу партерда журналистлар кәгазь кыштырдата. Ничәмә-ничә илдән килгәннәр алар. Дус бар, дошман бар дигәндәй, авызыннан нинди сүз чыгуын көтеп кенә торалар. Хасан күле вакыйгалары уңае белән безнең илнең хаклыгы, гаделлеге шик астына алына торган мәкерле сораулар бирелгәндә, журналистларның күбесе җанланып китә, тиз-тиз каләмен кыштырдата. Тере шаһит авызыннан тешләрепә килешмәгән чын дөреслек чыккач, аларның чырайлары сурәнләнә, күзләрендәге очкыннар сүнә.

Икегә бүленгән галереядагы халыкка карыйм. Бер якта японнар, икенче якта америкалылар утыра. Америкалылар үз-үзләрен горур тоталар. Японнар боек. Вакыт-вакыт әсәрләнү билгеләре күрсәтәләр, пышылдашып алалар. Күрәсең, әлегә чаклы билгеле булмаган кайбер мәгълүматлар аларның күзләрен ачкандыр.

Япония хәрби эшлеклеләре, мәсәлән, Маньчжурия җирләрен (Япония бу илне 1931 елда басып алды) совет чик сакчылары үз билгеләре

белән законсыз тестә билэп алганнар дип халыкны алдап ятканнар, солдатларны чик бозуга хәзерләгәндә гадел эшкә барасыз дип котырткаңнар. Бу ялганны фаш итеп, шаһит Терешкин элек үз житәкчелегендә булган Подгорная заставасының чик сызыкларын картада күрсәтте. Кире какмаслык дәлил сыйфатында 1886 елда Россия һәм Кытай хөкүмәтләре (ул чакта Маньчжурия Кытай составына кергән) арасында Хунчунда үткәрелгән килешү беркетмәсе карталарын бирде.

Иван Чернопятко күрсәтмәләре дә булды. Шулай итеп без япон хәрби җинаятьчеләренең мәкерле чын йөзләрен ачтык, ул башкисәрләрне якларга да, акларга да урын юклыгын исбатладык. Нәтиҗә бер генә булырга тиеш: Нюрнберг процессындагы шикелле, иң каты җәзаны бирергә. Үлем, фәкать үлем сугыш чукмарларына!

Токиода без ике айдан артык яшәдек. Унберенче декабрьда үз илчелегебездә иптәшләр белән саубуллаштык. Иң күңеллесе тагын шул булды: мина, сигез елдан соң, Рәхиләнең истәлек кулъяулыгы әйләнеп кайтты. Яшьлегемне күргәндәй әсәрләндем, дулкынландым. Һәммәсе искә төшә. Җырлыйсым, биисем килде.

Ул көнне Токиодан Владивостокка безнең ике самолет очарга тиеш иде. Терешкин икенче рейска калды. Мине дә сабыр итәргә димләгән иде, мин, елмаеп, Чернопятко иңенә кулымны салып:

— Бергә тудык, бергә үстек, аерылмыйча бергә очтык! — дигәч кенә кыставыннан туктады.

Ул безне аэродромга озата барды. Нинди детальләр истә калган соң? Гадәттәгечә үзара шаярта-шаярта сөйләштек. Самолет очарга әзер түгел иде әле. Аның тирәсендә тыз-быз килеп механиклар кайнаша, өлкәнрәге аларны ашыктыра, күккә ымлый.

Күк йөзе болытлы, һава ярыйсы ук җилле иде. Ләкин очышны кичектермәделәр.

Багаж бүлегендә әйберләребезне тапшырганда бер кызык хәл булды. Өйдәгеләргә күп итеп бүләкләр алган идем. Буш кул белән кайтып булмый ич семьяга. Бу юлы әниләренә алтынлап бизәкләр төшерелгән япон чынаяклары, бик матур башмаклар, Ритага ефәк кимоно, ә Әлфиягә үзе сораган зур курчак сатып алдым...

Самолетка күтәрелдек. Чернопятко, күңелемдә ташыган уйларымны белгән кебек, ишектә тукталды. Минем аяклар безне ышанычлы тестә күтәреп торган җирдә, дөресрәге, трапның соңгы басмасында әле. Күккә, һавага, кешеләргә әйтеп калдырасы сүзләрем бар сыман. Анда, диңгез артында, туган җир, өй, дуслар, иптәшләр... Алар, ашкындырып, үзләренә тарталар, тизрәк кайт, бик сагындык, диләр сыман.

Озатучыларга кул изәдек.

— Хушыгыз, иптәшләр! Хуш, Токио! Хуш, күпне күргән, күпне кичергән Япония!

Күтәрелеп киттек. Йомшак кәнәфидә Чернопятко белән янәшә утырып кайтабыз. Ул тәрәзә янында, диңгезне, күп сандагы утрауларны карап бара. Фудзияма вулканы күренә башлагач, Иван мине дә тәрәзәгә чакырды.

Аста искиткеч күренеш ачылды. Тирә-якта диңгез зәңгәрләнеп ята. Төрле кызык сурәтләрне хәтерләткән эреле-ваклы утраулар аккош мамыгыдай ап-ак кар белән капланганнар. Утрауларның берсендә Фудзияманың түбәсе ялтырап күренә. Өстә ап-ак кар. Фудзияма хәзер башына чалма ураган ком гарәбен хәтерләтә. Дүрт мең метрга якын биеклектәге бу сүнгән вулканның әйләнә-тирәсендә, итәкләрендә пальма, банан, чәй плантацияләре, эреле-ваклы хисапсыз күп авыллар таралып ята.

— Фудзияма шахта терриконына бик охшаган иң! — диде Чернопятко.— Кара, кара, нәкъ Голубовка!

Без шахтер чакларыбызны, андагы дусларны искә төшерәбез, җаен туры китереп, кунакка кайтып килергә план корабыз.

— Иң әүвәл үзебезнең заставага сугылырбыз. Владивосток аркылы кайтып, Подгорнаяга керми китү килешә торган эш түгел,— дим.

Юлның яртысын узгач, һава шактый начарланды. Көчле җил самолетны, әйтерсең, тотып селки. Дулкыннар арасында тирбәлгәндәй, бер күтәреләбез, бер төшәбез.

Инде Владивостокка ерак калмады. Радист: аэропортка кайтып җитәбез, каршылагыз,— дип хәбәр дә салды.

Нәкъ шул чакта әллә нәрсә булды. Көек исе чыкты, колакны тондырып бик яман шартлау яңгырады. Иван белән икебез дә, бүтәннәр дә аяк өскә бастык. Самолет аска мәтәлде. Иванның: «Һәлакәт!» — дигән әрнүле кычкыруын хәтерлим, иңемә куйган кул җылысын сиземлим. Аңымны яшен кебек бер уй яктыртып үтте: «Бу — үлем! Ниләр генә эшләргә өлгердек соң әле?»

Дулкыннарга кергәчме, кергәнчедерме, самолет челпәрәмә килеп таралды. Тын алудан туктаган идек инде. Иванның кулы иңбашымда калды, мин аның биленнән кочакладым. Котылырга теләп, җан ачысы белән ары-бире сугыла алмадык — көчле шартлау икебезне дә мингерәүләткән иде. Су... Һаман аска таба төшәбез... Анда җылырак булыр сыман... Мамык мендәрләргә яткандай, тирән йокыга талдык... Караңгы... Караңгы...

Кайдадыр еракта кыңгыраулар шалтырый...

Кайдадыр еракта кубыз чыңнары яңгырый...

«Бергә тудык, бергә үстек...»

«Россия, без синең турылыклы улларың идек!..»

«Без...»

Мәңгелек караңгылык...

Менә шулай тәмамланды безнең тормыш юлы.

Күзләрем моңсу карыйлармы? Үкенечле төстә үлгән кешеләрнең күз карашы шундый була. Бу карашта өмет, ышаныч яши, яхшылыкны хуплау, кылган яманлык өчен каты хөкем, мәкерлеккә нәфрәт тулып ята.

Үлгәннәр турында күбрәк уйлагыз, рәсемнәренә ешрак карагыз. Пакь намуслылар моңардан чирканмыйлар, үлгәннәр алдында бурычлы икәнлекләрен исләреннән чыгармыйлар.

Әйе, моңсу мин хәзер. Утыз өч яшендә, гомернең чәчәк аткан чагында юкка чыгу бик үкенечле бит. Ничаклы эшлисе эшләр калды!..

Әйтегезче, әйтегезче миңа: алсу таңнар һаман шундый матурмы? Тук башаклы басулар өстендә элеккечә җилкенеп тургайлар сайрыймы, бакчаларда җимешләр кызарып пешәме, көн-төн гөрләп-гүләп торган шахталар, завод-фабрикалар янынннан ыжгырып поездлар үтәме — тормыш шулай дәвам итсен өчен кызлар элеккечә үк сөйкемле, киленнәр уңганмы, егетләр хәзер дә батыр, ирләр хәзер дә гайрәтлеме?

Шулайдыр, шулай булмаска мөмкин түгел!

Ашаган ризыкның чын тәмен, чиста-пакь өй эченең ямен, мәхәббәтнең гүзәллеген, дуслыкның әчкерсезлеген, бирелгән антның какшамаслыгын — тормышның чиксез матурлыгын өстән-өстән генә аңлаучылар булса, андыйларга минем хакта сөйләгез, мин җырлый алмый калган җырны җырлагыз!

* * *

Мин хыялымдагы Гыйльфан белән саубуллаштым.

Каршымда очсыз-кырыйсыз диңгез зәңгәрләнеп ята. Тузгак яллы чал дулкыннар бер-берләрен ашыктырып миңа таба тәгәриләр, авыр ыңгырашып үзара пышылдашалар да, бәйдән ычкынгандай ярсып, кинәт ярга ташланалар.

Диңгез! Диңгез! Нигә болай һаман ярсу син?

Мин сиңа горурланып әйтә алам бүген: Гыйльфан да, аның дусты Иван да җирдә икенче яшәүне — үлемсез тормышларын башладылар. Безнең белән бергә яшиләр, көрәшәләр, җиңәләр алар!

Гыйльфанның кызлары әтиләренә турылыклы: Рита да, Әлфия дә башкала вузларын уңышлы тәмамлап, хәзер аспирантурада укыйлар. Эшлиләр. Рита — вуз укытучысы, Әлфия — инженер. Аның кияве Рафаил космонавт-лачыннарыбызны ерак очышка хәзерләүчеләрнең берсе. Өч яшьлек уллары бар. Ул — Гыйльфан исемле.

Гыйльфан Батыршинның балачак дусты Галимҗан Камалиев та, каһарман абыйсы кебек үк, Алтын Йолдыз кавалеры.

Болар нәрсә, могҗизамы?

Җирдә могҗизалар күп.

Җирдә могҗизаларны кешеләр тудыра.

Менә мин, ярсулы дулкыннарыңа карап, яңа могҗиза көтәм: озакламас, горизонтта бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаш ап-ак ике игезәк лайнер күренер. Берсе аның «Гыйльфан Батыршин» исемле, икенчесе — «Иван Чернопятко».

Алар хәзер юлда. Алар, җир кешеләрен сагынып, туган илгә кайтып киләләр!

## Гәрәй Рәхим

•

Бәхетем сыек димим,
Күңелем боек димим.
Тик әле нидер көтәм,
Кайчак моңаеп китәм.

Кайгыларым зур димим,
Үземне ким-хур димим.
Ләкин нидәндер туям,
Кайчак кимсенеп куям.

Елар сәбәпләрем күп,
Көләр сәбәпләрем юк.
Ләкин көләм, еламыйм,
Еларга һич уйламыйм.

Берәүләрдән көнләшәм,
Күпләргә гөл өләшәм.
Берәүләрне орышам —
Мин яшәргә тырышам.

## Хыялый төбәктә

Бу төбәктә талгын жилләр исә,
Иренеп кенә шаулый тирәкләр.
Давыл монда килеп житә алмый,—
Тотып кала таулар-терәкләр.
Монда шундый тын елгалар ага —
Ник бер дулкын каксын ярларга!
Тузганаклар ап-ак мамыкларын
Очырталмый бөтен яланга.
Еланнар бар монда, тик агусыз,
Сандугачлар сайрый белмиләр.
Кешеләре тик картлыктан үлә,
Бәхетсезлек белән үлмиләр.
Монда солых та юк, сугышлар да,
Сөю дә юк монда, нәфрәт тә.
Киләчәккә бөек өмет тә юк,
Һәм кителми һичбер дәһшәт тә.
Үзгәрүчән мизгелләр юк монда,
Монда — көннәр, еллар, гасырлар.
Шагыйрь монда шигырь яза алмый,
Һәм көнозын йоклый батырлар.
Әгәр ялгыш монда килеп чыксаң,
Катып калыр иде йөрәкләр.
Ярый әле хыял жимеше бу,
Ярый жирдә юк бу төбәкләр.

●

Урамнар артында яшел болын.
*Аяз Гыйләҗев*

Урамнар артында яшел болын.
Улакны кимерә яшь колын.
Аранда тилмерә яшь колын:
«Урамнар артында яшел болын...
Урамнар артында яшел болын...»

Авылда көнозын бер аваз:
Тук та тук гел чалгы чүкиләр.
Абзыйлар, колынны онытып,
Көнкүреш бурычын үтиләр.

Яшь кызлар июньдәй көләчләр,
Урамнан узалар фырт кына.
Кызларга июньнән дәрт кирәк,
Колынын кирәкме чуртыма.

Чирәмдә чал чәчле бер бабай
Колынын, болынын онытып,
Тагын бер өч елга җитсен, дип,
Нур җыя кояшка йөз тотып.

Авылда көләч бер көй йөри —
Кешеләр җырлыйлар җәй җырын.
Кешеләр өзәләр җәй җырын:
«Урамнар ар-тында я-шел,
бо-о-о-лын...»

Җыр тынган арада каяндыр
Дөп тә дөп бер аваз ишетелә.
Бу шулай аранда яшь колын
Аягын канатып тибенә.

Тибенә, әйтергә теле юк,
Улакны кимерә яшь колын.
Нишләсен, әйтергә теле юк:
«Урамнар артында яшел болын,
Урамнар артында яшел болын...»

●

Кыр юлларын дөбердәтеп
Ак толпарлар чабып узды.
Юл читендә моңсу гына
Карап калды ялан кызы.
Ерак китте ак толпарлар,
Юлда ташлар аунап калды.
Һәм ташларга тып-тып итеп
Ике бөртек тамчы тамды.

# Ут һәм су

Беребезне күбәүләр ут диделәр,
Беребезне күбәүләр су диделәр.
Ләкин җирнең ике якын юлдашы —
Ут белән су мәңгелеккә дуслашты.

Кайберәүләр бу дуслыктан көнләшә.
(Тик куркалар бугай бераз гөнаһтан).
«Бу бит,— диләр,— сыймый физик законга,
Ничек инде ут белән су дуслашкан?!»

Кайберәүләр бу дуслыкка ышанмый.
«Ут белән су мәңге дошман ич!» — диләр.
Тик үзләре сусаганда шигырьгә
Ут белән су җырын кушып эчтеләр.

Кайберәүләр бу дуслыктан куркалар.
Курка алар дөньяны су басудан,
Курка алар без тудырган җырлардан
Бу дөньяга дуслык уты кабудан.

Кайберәүләр бу дуслыктан көлделәр.
«Ут кабынса, су сүндерер»,— диделәр.
Берәүләре батыраеп киттеләр —
Ут белән су арасына керделәр.

Тик алары бик тиз һәлак булдылар —
Утта янып, суга батып үлделәр.
Шунда гына бик күбәүләр бу җирдә
Бөек Дуслык бар икәнен белделәр.

●

Бу язны мин бик нык көтеп алдым,
Ә ул миңа сагыш китерде.
Мин тамчылар белән мизгел саен
Кабатлаган идем исемеңне.

Урам ташларында тамчы тишкән
Исемнәрең генә калдылар.
Кайтуыңа тәмам өмет өзеп,
Тамчылар да салмакландылар.

Гөрләвекләр белән агып килде
Кавышырбыз дигән өметләр.
Тик алар да бик тиз агып китте,
Аһ, алар да
Синең вәгъдәләрең кебекләр.

Яшеннәрне инде каршы алам.
(Уңышсыз яз, тизрәк үт инде!)
Әй син, яшен, өмет учагыма
Тик бер очкын бүләк ит инде.

Тик бер очкын...

●

Сагышымны сөйләмим мин сиңа,
Син бит артык сизгер кыз, җаным.
Бу ят хистән синең нәфислеккә
Зыян килер диеп куркамын.

Табигатьнең синдәй камиллеген
Минем тәмам чуалтуым бар.
Бәхет юрап куйган йолдызыңны
Офыгыңнан югалтуым бар.

Өметләрең шаулап чәчәк аткан
Бакчаларга ят җил кермәсен.
Бер кеше дә сине, сагышлардан
Саргаядыр бу кыз, димәсен.

Картаймас бер сабые бул җирнең,
Мәңге бәхет көен көйлә син.
Юк, сөйлә, дип, күзләремә бакма,
Сагышымны сиңа сөйләмим.

●

Исемеңне бик еш кабатламыйм.
Ул миңа бер изге, йола сүз.
Мәхәббәттә шунсыз яши алмыйм,
Яши алмыйм монда алласыз.
Юк, сөюдә мин атеист түгел —
Аллам да бар, җан саклаучым да,
Фәрештәм дә, газраилем дә бар,
Кыяматтә бар яклаучым да.
Газраилләр белән сугышканда
Мин пышылдыйм синең исемне —
Шундый чакта мин көрәшкә дәшәм
Материя — әйбер — җисемне.
Йолдызларны, кояшларны дәшәм,
Киберын да, лазерларын да.
Бит җирдәге бөек сөю өчен
Уйлап таптык анын барын да.
Шуңа күрә синең исемеңне
Бик еш кабатламыйм — йола сүз.
Мәхәббәттә шунсыз яши алмыйм,
Яши алмыйм синсез — алласыз.

Әмирхан Еники

# КАРТЛАР

хикәя



Бүген таң алдыннан Рамазан бабайның карчыгы Әсмабикә әби үлгән дип әйттеләр... Авылда үлем-бетем сирәк булганга күрә, бу хәбәр бик тиз таралып өлгерде. Күпләр өчен ул хәтта көтелмәгәнрәк хәбәр дә булды, чөнки әби атна-ун көн генә ятып, ничектер тиз генә үлеп тә киткән. «Һай алла, кай арада гына булды соң әле бу, күптән түгел генә әбиебез кәҗәсен куып йөри иде бит!» дип гаҗәпләнделәр... Ләкин үлемгә, бигрәк тә карчык кешенең үлеменә, хәзер берәүнең дә артык исе китми. Була торган эш... Аның караввы, исән калучыны күбрәк кызганалар. Менә сиксәннән узган Рамазан картның хәле чынлап та мөшкел инде. Көтмәгәндә генә алтмыш ел гомер иткән карчыгыннан аерылды да куйды. Нишләр ул, бахыркай?.. Кем карар, түшәген кем җыяр, кем җылы сүз дәшер?.. Көчсез, хәлсез — ятим бала белән бер бит инде ул хәзер!

Ул көнне карт өенә килүчеләр күп булды. Карт-корыны әйткән дә юк, эштәге ирләр дә, авылның икенче очындагы хатыннар да, хәтта яшь-җилкәннәр дә килеп, бабайга күренеп кенә булса да чыгарга тырыштылар. Авыл советы председателе белән колхоз председателе дә килеп киттеләр. Үлгәнне күму эшләренә һәрвакытта бик күңел биреп йөрүче идарә члены Әзһәл абзыйга колхоз председателе әйтте: «Белегез, нәрсәләр кирәк? Кәфенлеге булмаса, хәзер сельподан ак материя җибәртермен. Тагын нәрсә?.. Акча?.. Тиздән хисапчы бер утыз сум китереп бирер... Ат җибәртермен, машина кирәксә, машина да җибәртермен... Карт сораганны көтмәгез, үзегез белеп эшләгез!» диде. Бу бик урынлы боерык иде, чөнки картның үзенең ни дә булса уйларлык, хәрәкәт итәрлек чамасы калмаган. Фани дөнья белән алыш-биреше беткәндәй ул иртә таңнан бирле карчыгының аягы очында бөкрәеп утыра — һич кемне күрми дә, ишетми дә. Мәетне юарга кирәк булгач та аны иплән-юатып кына урыннан кузгата алдылар. Хәсрәттән генә түгелдер инде бу, күрәсең, картлыгы да бик житкән бабайның!

Безнең халыкта мәетне озак яткырмыйлар, бигрәк тә җәйнең менә мондый эссе көннәрендә. Әле иртәнге якта ук өч-дүрт кеше, көрәкләрен иңбашларына салып, зиратка кабер казырга киткәннәр иде... Зират авылдан өстәрәк, тигез чирәмлектә. Моннан биш-алты ел элек зиратны

әйләндереп киртәләгәч һәм терлек кереп таптамый башлагач, андагы агачлар бик тиз куерып үсеп киттеләр. Хәзер ул кечкенә бер урман булып утыра, җәй башларында аннан өзлексез кошлар сайравы ишетелеп тора...

Төш җиткәндә инде Әсмабикә әбине әзерләп тә өлгерттеләр. Монысы өчен берни дә кирәк булмады — карчыкның күптән әзерләп куйган кәфенлеге дә, кабергә төшерүчеләргә дип саклаган сөлгеләре дә, тагын нәрсә өчендер җыйган таңкаләре дә бар икән... Колхоздан ике ат килде, озатырга шактый гына халык та җыелды. Башта бер арбага палас җәйделәр, мендәр куйдылар, аннары әбинең иске юрганга ураган гәүдәсен өч кеше ипләп кенә күтәреп чыгарып салдылар. Карчыгы артыннан өстенә озын җилән, башына бүрек кигән Рамазан бабай үзе дә күренде. Ул, бусагадан атлап чыккач та тукталып, зәгыйфь тавышын күтәрә төшеп, көтеп торучыларга эндәште:

— Оланнар, Әсмабикә әбиегез, мәрхүмә, әйбәт кеше иде бит!

— Әйбәт кеше иде, Рамазан бабай, бик әйбәт кеше иде! — диделәр аңа каршы төрле яктан.

Шуннан соң гына Рамазан бабай болдырдан төшеп, ике егет ярдәмендә карчыгының аяк очына менеп утырды. Башка картлар икенче арбага тезелештеләр. Атлар кузгалды. Ирләрнең бер өлеше мәет артыннан иярде, ә күп кенә өлеше атларның бераз ераклашканын көтеп тордылар да үз юллары белән китеп бардылар. Капка төбендә исә хатын-кызлар гына, күзләрен сөрткәләп, торып калдылар.

Атлар һәм озата баручылар тыкрыктан авыл читенә чыгып, зиратка таба күтәрелделәр. Зират янына җиткәч, туктап, мәетне арбадан, паласының дүрт почмагыннан тотып кына, яшел чирәмгә төшерделәр. Авылда, билгеле, күптән инде мулла юк, ләкин шәригать гамәлләрен аз-маз белүче Яхъя исемле чатан бер карт бар, менә шул бабай үлгән кешенең якыннары сораган чакта, кышын өйдә генә, җәен яшел чирәмдә җиназа да укый иде. Хәзер дә шул ук бабай, үзе кебек берничә карт белән сафка басып, мәет өстенә кычкырып җиназа укыды. Башкалар исә читтән тын гына карап тордылар... Мәет әйләнәсендәге үләндә «ак тәтәйләр» хәйран күп иде (бездә ромашка чәчәген шулай дип атыйлар), ак тәтәйләр өстендә ак күбәләкләр оча, киртә буендагы агачлардан әрсез кошларның чыр-чу килеп тавышлануы ишетелеп тора, ә якында гына чирәмгә чөй кагып, шуңа озын бау белән бәйләп җибәргән бер кызыл бозау, «Кешеләр монда нишлиләр?» дигән шикелле, башын гына борып, җиназа укучыларга карап тора. Һәм шушы тереклек эчендә Әсмабикә әби үзе дә юри генә үлгән булып ята кебек... Бер уйласаң, бик гади нәрсәгә охшый бу үлем дигәнең!..

Кыска гына җиназа укыганнан соң, мәетне кире арбага салмыйча, паласы белән генә күтәреп, зират эченә, кабергә алып киттеләр. Кабер әзер, бер читтә тәмәке тартып утырган кабер казучылар, сукмак буйлап килүчеләрне күргәч, кагынып урыннарыннан тордылар. Монда тагын Яхъя карт җитәкчелек итә башлады. Аның кушуы буенча өч кеше мәетне ләхеткә куяр өчен кабергә сикереп төштеләр. Әсмабикә әбинең ак кәфенгә төргән гәүдәсен юрганнан чыгардылар, астыннан өч тастымал үткәреп, шуларның башларын кабердәге әлеге кешеләргә бирделәр. Алар мәетне иплән кенә кабергә төшерә башладылар Шул чакта Рамазан бабай, тураеп, халыкка нидер әйтергә теләде:

— Оланнар, Әсмабикә әбиегез...— Ләкин кинәт тавышы өзелде, бөгелеп төште һәм иңбашлары калтыранып китте. Кабер әйләнәсендәгеләр аның ни әйтергә теләгәнен аңлагандай:

— Әйбәт карчык иде Әсмабикә әбиебез, бик тә әйбәт карчык иде, мәрхүмә! — диештеләр.

Ун-унбиш минут та үтмәгәндер, таза егетләр әбине күмеп тә куйдылар. Башкалар шул чакта иелеп я кәрәк, я кулы белән генә кабергә

туфрак ташладылар. Шуннан соң картлар кабернең ике ягына тезелеп утырдылар, Яхья карт моңсу гына итеп коръән укыды (хәер, аның нәрсә укыганын хәзер белүче дә юк), аннары Рамазан бабай җилән чабуына баса-баса сәдака өләшеп маташты. Дога кылдылар, шуның белән эш бетте һәм халык ашыгып тарала да башлады. Рамазан бабайны, атка утыртып, күршеләре алып китте, кабер казучылар, Әзһәл абзыйга ияреп, сельпога таба киттеләр... Кабер очында, ниндидер бер фәрештәнең Әсмабикә әби белән сөйләшергә килүен ишетер өчен, Яхья карт ялгыз үзе генә утырып калды.

Гаҗәп, безнең зират буенда ак тәтәйләр быел нигә бу хәтле күп икән?

* * *

Рамазан бабай хәзер көн дә иртә-кич зиратка, карчыгы янына барып йөри. Без моны һәркөн диярлек күреп торабыз. Эш шунда: әлеге зиратка илтә торган тыкрык каршында гына, Ясәвиләр коймасы буенда өелеп яткан бүрәнәләр бар — менә без, бу тирәдә торучылар, эштән бушагач, кичләрен шул бүрәнәләр өстендә тәмәке тартып, гәп сугып утыргалыйбыз. Шулай булгач, Рамазан бабай да зираттан кайтышлый гел безнең каршыдан узып китә. Без аны, күреп алсак, сүздән туктап, артыннан гына карап калабыз. Аның зиратка йөрүенә артык исебез дә китми, хәлен аңлыйбыз да кебек, чөнки карчыгы янына бару карт өчен хәзер бердәнбер юаныч булса кирәк... Ләкин шулай да аны күргән саен күңелне ничектер тырнабрак торган шундыйрак уй туа: картның ходай бирмеш һәр көнне иртә-кичен зиратка йөрүе бары үзенә юаныч табар өчен генәме, әллә моның бүтән берәр тирәнрәк сәбәбе дә бар микән?

Бер кичне шулай түбән очның Лотфи карт узып барышлый безнең янда туктап, бераз утырып торды. Шул чакта тыкрыктан Рамазан бабай да килеп чыкты: ул гадәтенчә таягына таянып, бөкрәя төшеп, зираттан кайтып килә иде. Без аның каршы яклап үтеп киткәнен сүзсез генә карап калдык. Бабай ераклаша төшкәч, кемдер җиңел генә сулап:

— Йөри карт, йөри! — дип куйды.

— Юксына инде, мескен, юксына! — диде аңа каршы икенче берәү.

Безнең Лотфи карттан ни дә булса ишетәсебез килә иде. Лотфи карт, Рамазан бабайдан бер ун яшькә кечерәк булса да, аның егет чагын, ир чагын күргән кеше. Аннары үзе дә карт булгач, ялгыз калган бабайның эчке хәлен дә дөресрәк аңлыйдыр инде, билгеле. Ләкин картыбыз таш сын шикелле бер сүз дәшмичә, хәтта чыраен да үзгәртмичә тик кенә утыра. Шуннан соң безнең күрше Казбек, шәһәрдән кайткан студент, үзе башлап Лотфи карттан сорады:

— Лотфулла бабай, әйтегез әле, Рамазан бабай, имеш, яшь чагында бик таза, бик чибәр егет булган, диләр, дөресме шул?

— Нигә, Рамазан бабаегызның яшь чагында ниндирәк егет булганын хәзер дә чамалап була торгандыр,— диде Лотфи карт, чак кына елмая биреп.

— Чамалап булса да, күз алдына китерүе читен. Сиксәннән узган карт бит... Ә сез аның яшь чагын үзегез күргәнсез. Я, ничегрәк иде соң?

Лотфи карт, күзләрен кыса төшеп, нидер уйлагандай, бераз дәшми торды. Аннары ашыкмыйча гына әйтте:

— Рамазан карт егет чагында мин малай гына идем әле, шулай да яхшы хәтерлим: өрлектәй төз гәүдәле, таза егет иде ул, төскә дә чибәр иде, борыны пычак сыртыдай туры, күзләре шомырттай кара, ә кашлары карлыгач канатыдай кыйгачланып тора иде... Авылда бер егет иде бабагыз!

— Энә ничек икән?! — дидек без, гаҗәпләнеп.— Күз алдына китереп кара син аны хәзер!.. Сөйләп бирсәң үзе дә ышанмас!

— Ә менә Әсмабикә әбине ямьсез кыз булган диләр, дөресме шул? — диде Казбек, бер дә тыйнакланып тормыйча.

— Ансы инде сорамасаң да билгеле,— диде кемдер шунда.— Картлык ямьсезлекне бетерә алмый икән... Мәрхүм әбинең авызы зур, борыны ямьшәк, шадрасы да бар иде — кая куясың?

— Юк, менә Лотфулла бабай әйтсен әле,— диде Казбек, һаман картны кыстап.

— Ни әйтәсең инде,— диде карт, авыр гына сулап.— Ходай Әсмабикә әбиегездән матурлыкны кызганган шул.

— Алайса, шундый чибәр егет ничек итеп шундый ямьсез кызга өйләнде икән, ә?.. Лотфулла бабай, сез беләсездер?..

— Беләм?.. Каян?.. Мин үзем дә ул заманда малай гына идем бит әле...

— Юк, шулай да?.. Ну ничек булырга мөмкин бу?..

— Дөресе аның шул,— диде Лотфи карт, бераз көттереп.— Рамазан бабагыз Әсмабикәсенә күрми өйләнгән.

— Күрмичә?.. Ничек ул алай? Күрмичә кеше өйләнәмени?..

— Сез, оланнар, ул заманны белмисез... Рамазан бабагыз яшь чакта әле күрмичә өйләнү, күрмичә кияүгә чыгу булгалый торган иде. Исегез китмәсен!

— Ну бит, күрмәсә дә ишеткәндер... Бөтенләй белмичә алмагандыр инде.

Лотфи карт башын әзрәк кагып торды да аннары әйтеп куйды:

— Аны алдаганнар.

— Алдаганнар?.. Ничек итеп?.. Кызык бу, кызык!

Лотфи карт җавап бирергә ашыкмады, нидер күңелен борчыгандай, ул уйга калыбрак утыра иде. Ләкин аны төрле яктан: «Сөйләгез инде, Лотфулла бабай, сөйләгез» дип, бик нык кыстарга тотындылар. Бары шуннан соң гына картыбыз эчке икеләнүен җиңгәндәй бер сулап:

— Ярый алайса,— диде.— Үлгән кешенең йөгенә керү килешми килешүен, күңел дә тартып бетерми, әмма мин сезгә, оланнар, үзем ишеткән кадәресен генә сөйлим. Гайбәт түгел, ходай кичерсен!.. Иң элек шуны әйтим: Әсмабикә әбиегез безнең авылдан түгел бит, Такта-Алачыктан, шуннан безгә килен булып төшкән кыз. Такта-Алачык, үзегез беләсез, бездән унсигез чакрымда, кайчандыр зур базарлы, биш мәхәлләле бер авыл иде. Анда байлар да күп булган, хәер, сез аның ул чагын белмисез инде — ә соңыннан бу авыл яртылаш диярлек таралып бетте... Менә шул Такта-Алачыкта Гобәйдулла исемле бер бай була. Ходай аңа кызларны күп биргән икән, бер-бер артлы житеп килгән дүртме-бишме кызы булган, имеш. Арада иң өлкәне менә шушы Әсмабикә әбиегез булган инде... Ишле кызга кияү табып бетерү ансат эш түгел, хәтта бай кешегә дә... Шуның өстенә, ул чактагы гадәт буенча, башта иң өлкәнен бирергә тырышканнар, өлкәнен бирмичә торып, кечерәкләрен бирә башлауны килештермәгәннәр, теге беренче кызлары утырып калыр дип курыкканнар. Бу урында шуны да әйтергә кирәк: байның кече кызлары барсы да бик чибәр булганнар, имеш, тик Әсмабикә бичара гына матурлыктан мәхрүм булып калган... Шулай да атасы, Гобәйдулла бай, өлкән кызына ничек тә кияү табарга тырышкан. Бай кешенең, мәгълүм инде, тирә якта таныш-белешләре күп була, безнең авылда да аның кемдер бер якын танышы булган, менә шул кеше Ризван картка, дөресрәге, Ризван картның малаена, байның кызын димләргә тотынган. Шәт, аңлыйсыздыр, Ризван карт ул Рамазан бабагызның атасы — мин дә аны яхшы хәтерлим әле... Юаш кына, әдәмчелекле бер кеше иде, мәрхүм!.. Җирдән башын күтәрмәгән гади бер мажик... Бай кеше белән туганлашып китү картның күңеленә, билгеле, хуш

килә — соң шулай булмыйча, заманасы шундый бит аның... Тик ышанып кына бетми, булмас, бай кеше кызын безнең ише мужикка бирмәс, ди. Ә димләп йөрүче ышандыра, яучы гына җибәр, Гобәйдулла бай кызын бирәүгә бирмәсә дә синең малаеңа бирәчәк, ди, ант итеп ышандыра. Шуннан соң Ризван карт мәсьәләне улына чишә: менә, ди, шундый җирдән, шундый кешенең кызын сиңа димлиләр, ни уйлыйсың, соратып карыйбызмы әллә? — ди. Рамазан бабагыз да моңа риза була (булмыйча, бай кызына кем өйләнмәс!), ләкин бер шартын куя: кызны күрмичә алмыйм, ди... Инде теге димләүче ике арада йөри бит, менә шул — егетнең теләген байга җиткерә. Бай моңа каршы әйткән, имеш: кызны никахка чаклы егеткә күрсәтергә шәригать кушмый, атасы килсен, атасы күреп китәр дигән, имеш... Шуннан нишләргә кала?.. Киңәшәләр дә, әлеге димләүче белән Ризван карт, ат җигеп, Такта-Алачыкка китеп тә баралар. Анда баргач, Гобәйдулла байның үзенә төшмиләр, ярамый, бай бер нәрсә дә белмәскә тиеш, янәсе... Каршыдарак торган бер йортка керәләр. Ризван картны урам тәрәзәсенә утырталар һәм көтәргә кушалар. Менә бер заман, күпмедер вакыт узгач, бай капкасыннан купшы гына киенгән, көянтә-чиләк аскан бер кыз килеп чыга... Картка әйтәләр: әнә кара инде, синең улыңа буласы кыз шул үзе, диләр... Кыз чынлап та бик сылу, бик чибәр була. Карт аның вак-вак кына атлап чишмәгә киткәнен дә, чишмәдән кайтканын да карап тора... Әлхасил, кыздан бик канәгать булып калган Ризван карт... Кайткач улына да кызны бик мактап сөйләгән: «Улым, үз күзем белән күрдем, кызның килмәгән җире юк, алсаң — уңарсың!» дигән.

Шуннан эш җайлана инде. Тәвәккәлләп яучы җибәрәләр (шул ук димләп йөрүчене), бай кызын бирергә риза була, аннары озакка сузмыйча туен да итәләр. Ике авыл арасы якын җир түгел, моннан Такта-Алачыкка туй барып җиткәнче дә никах укылганчы, көзге көн үтеп тә китә. Рамазан бабагыз инде ак келәткә, кәләш куйнына күз бәйләнгәч кенә барып керә... Оланнар, мин сезгә ишеткәнемне генә сөйлим, чын дөресен инде аның Рамазан бабагыз үзе генә белә торгандыр... Кыскасы, зифаф төне узгач, икенче көнне генә ул янында яткан Әсмабикәсен ачык күргән, диләр. Бик гаҗәпләнгән, имеш, ни уйларга да белмәгән, әмма кызның үзенә берни дә сиздермәгән. Тик җаен туры китереп атасыннан: «Әткәй, киленеңә бер күз сал әле, шунымы син миңа димләдең?» дип сораган. Ризван карт киленне күргәч бик аптыраган: «Юк, дигән, минем моны күргәнем юк, миңа бөтенләй башка кыз күрсәттеләр», дигән. (Әлеге чибәр сеңелләреннән берсе булган икән ул). Моны белгәч, Рамазан бабагыз башта бик яман дуламакчы, туйны ташлап китмәкче булган. Ләкин атасы, әйткәнемчә, сабыр, әдәмчелекле кеше, малаен ул эштән тыйган: «Кыз хәзер синең никахлы хатының, дигән, эт баласы түгел, эт баласын да ташлап китмиләр, кара аны, җылатасы булма!» — дигән... Дөрес тә инде, никах укылган, бер кич янында кунган, ничек итеп, нинди җан белән кыз баланы ташлап китмәк кирәк?!. Ямьсез дигәч тә гарип түгел бит ул, кул-аягы, бөтен җире тап-таза. Озын сүзнең кыскасы, Рамазан бабагыз, өлешемә чыккан көмешем шушы икән дигән дә Әсмабикәсен әйбәтләп-түйлап өенә алып кайткан... Менә шул аның тарихы, оланнар!

Лотфи карт сөйләп бетерде дә җиң очы белән нечкә мыекларын сыпырып куйды. Ләкин аның бик гади генә итеп сөйләгән бу сүзләрендә нидер җитми иде әле. Ярый, алдап булса да егетне өйләндергәннәр, ди, әмма өйләнгәч бергә торасы бар бит. Соңыннан ничегрәк яшәгәннәр алар?..

— Алтмыш ел гомер иттеләр,— ди Лотфи карт, тыныч кына.

— Ләкин гомер итү төрлечә була бит, Лотфулла бабай!

— Булмыйча... Гомер юлы бик озын, чокырлы да чакырлы, шома гына бармый ул... Шуны да әйтергә кирәк, Рамазан бабагыз яшь

чагында шактый кызу канлы кеше иде, юктан да дулап китә торган гадәте бар иде. Әмма ләкин Әсмабикә әбиегезгә ходай матурлык бирмәсә дә, күркәм холык биргән. Сабыр, чыдам, артыгын әйтмәс, яшен йота белер... Хәзерге кайбер яшь киленнәр төсле тавыш чыккан саен тырт итеп әтиләренә йөгермәгән.

— Ансы инде үзен гаепле дип белгәнгә күрәдер...

— Ә нинди гаебе бар аның?.. Ризван картка сеңелесен күрсәткән чакта аңа әллә әйтеп торганнар дисезме? Юк, булмас, андый нәрсә бик яшерен эшләнә ул, хәтта суга барырга чыккан сеңелесе дә белмичә калгандыр әле.

— Ә ярату? — диде Казбек, егетләнеп.— Ярату булганмы соң алар арасында?

— Сезгә тагын нинди ярату кирәк? — диде Лотфи карт, бик гаҗәпләнеп.— Әнә Рамазан бабагыз карчыгының кабере өстеннән кайтып та керми, ә сез монда ярату дип, оялмыйча, лыгырдап утырасыз!..

Без дәшмәдек, хәтта нигәктер уңайсызланып та калдык, гүя без бик гади бер хакыйкатьне аңламый идек. Дөресен генә әйткәндә, картларны тыңлап утыру яхшы, әмма аларны аңлап бетү, бигрәк тә алар белән бәхәскә керү һич тә мөмкин түгел. Әнә «ярату» дигән бер сүздән картыбыз кызды да китте. Ни өчен, бик гаеп сүзмени ул?.. Әллә яратуны картлар бөтенләй башкача аңлыймы?

Ә Рамазан бабай карчыгы янына һаман йөри дә йөри. Һәр кичне диярлек без аның зираттан кайтканын күрәбез һәм сүзсез генә артыннан карап калабыз. Мескен бабай!.. Хәер, ни өчен мескен, бәлки бер дә мескен түгелдер? Бәлки аның гомере буена әкренләп төшенгән һәм үзе генә белгән зур бер хакыйкате бардыр, ихтимал, шуңардан аңа ялгызлыгын җиңеләйткән чын юаныч килә дә торгандыр. Серле-тирән булса кирәк картларның җаны, тик безгә генә ни өчендер караңгы ул!

# КУРАЙ



Күптән түгел Сәгыйть[1] дус миңа курай турында шушы легенданы сөйләде:

«...Бик борын заманда безнең җирләрдәге бер хан үсмер малайларны берәм-берәм чакыртып, шулардан чәчен кырдыра торган булган. Әмма чәч кырган малайларның берсен дә хан кире кайтарып җибәрмәгән — һәркайсын шунда ук үтертә икән. Шулай итеп, ханның чәчен кырган күп кенә малайлар һәлак булганнар. Ни өчен хан аларны үтерткән соң? — моның сәбәбен берәү дә белмәгән... Менә көннәрдән бер көнне бер ялгыз хатынның бердәнбер малаена да чират җиткән: хан чәчен кырдырырга аны да чакырткан. Малай хан сараена китәр алдыннан әнисе аңа төче икмәк пешереп биргән: мә, улым, тамагың ачкач, утырып ашарсың, дигән.

Малай төче икмәкне кыстырып сарайга киткән, хан янына барып кергән һәм күп сөйләшеп тормастан ханның башын бик әйбәт юешләп, үткен пәке белән чәчен кыркып төшергән. Менә шул чакта ул гаҗәеп

[1] Сәгыйть Агиш — күренекле башкорт язучысы.

бер нәрсә күргән: ханның башында имән бармак чаклы мөгезе бар, имеш!.. Хан да шүрәле сыман мөгезле, имеш!..

Малай эшен бетергәч, хан аңа әйткән: «Син инде минем мөгезне күрдең, ханның мөгезе бар икән дип сөйләп йөрерсең, шуңа күрә мин сине үтертәм», дигән. «Ярый,— дигән малай, бер дә каушап тормыйча,— тик син миңа шушы икмәгемне генә ашап алырга рөхсәт ит»,— дигән. Хан рөхсәт иткән. Малай түче икмәген иплэп кенә ашарга тотынган. Ул ашыкмыйча, авызын чәпелдәткәләп, бик тә тәмле итеп ашый икән. Хан да моның ашаганын карап тора-торгач, кызыгып киткән: «Икмәгең бик тәмле күренә, кая, миңа да әзрәк сындырып бир әле»,— дигән. Малай чамалап кына сындырып биргән. Хан ашый башлаган һәм исе китеп малайдан: «Нигә бу икмәк шул хәтле тәмле?» — дип сораган. Малай: «Әнием аны үзенең күкрәк сөтенә изеп пешерде шул!» — дип җавап биргән. Моны ишеткәч, хан шактый аптырап калган: «Алайса без синең белән бер ананың сөтен капкан булып чыктык, без хәзер бер туганнар булабыз бит!» — дигән. Малай дәшмәгән. Ә хан уйланып: «Бер туганны үтерергә ярамый бит әле, менә хикмәт нәрсәдә! — ди икән.— Ләкин үтертмичә дә булмый, чөнки син минем мөгезне күрдең, халыкка сөйләп йөрерсең... Инде нишләтергә сине?..»

Малай бу юлы да дәшмәгән, һаман тәмләп кенә түче икмәген ашый биргән. Шуннан соң хан, бераз икеләнеп торгач, малайга әйткән: «Ярар, мин сине үтертмим,— дигән.— Ләкин бер шартым бар. Кырда кура дигән бер көпшә үсә, син аның кипкәнен чокыр башыннан табарсың. Менә шул көпшәне кисеп ал да минем мөгез турында сөйлисең килгән саен шуңа гына өреп йөр. Аңладыңмы?.. Мөгез турында — ләм-мим!.. Телең кычыта башлады исә, көпшәне генә сызгыртырга тотын!.. Килештекме?»

Малай: «Ярый, риза»,— дигән, шуннан хан аны өенә кайтарып җибәргән.

Малайның вакыт-вакыт мөгез турында бик сөйлисе килеп китсә дә, вәгъдәсен бозмаган. Сөйлисе килгән саен, әлеге шул кырдан кисеп алган көпшәсен «гү... гү» өрергә тотына икән. Тора-бара ул көпшәнең түбән очына тишекләр дә ясаган. Тишекләргә баскалап, көпшәдән нечкә-калын тавышлар да чыгара башлаган. Шулай итеп, малай төрле көйләр уйнарга өйрәнеп киткән. Хәзер инде ул ханның мөгезен сөйлисе килгәндә генә түгел, ә телдән әйтә алмаган берәр уе, хәсрәте бар чакта көпшәсен алып уйный икән. Искиткеч моңлы-матур уйнаган ул, кешеләр аны таң калып тыңлаганнар. Кеше теле әйтеп бирүдән гаҗиз хисләрне кузгатучы курай дигән гаҗәеп нәрсә әнә шулай туган!»

* * *

Бу легенданы яңарак ишетсәм дә, курайның үзен миңа бик яшьли күрергә һәм тыңларга туры килде. Безнең Дәүләкәнгә терәлеп кенә торган Яңа Керманкәйдә курай уйнаучы бер карт бар иде — менә шул картны хәтерлим әле мин... Тик минем балалык хәтеремдә аның кураеннан бигрәк башка ягы ачык сакланган. Хикмәт шунда, Тимербай карт курайчы гына түгел, балыкчы да иде. Һәм без, Дәүләкән малайлары, Дим тугаена барган чакта Тимербай картның шундагы күлләрдә тар гына бүрәнә каекка утырып, сыңар ишкәге белән камышларны ера-ера нәрәтә куеп йөргәнен гел күрә торган идек. Ул кояштан, җилдән бакырга әйләнеп, какланып беткән, бик чандыр бер кеше иде. Балакларын тезенә чаклы сызганган, күлмәгенең алдын ыштан бөрмәсенә кыстырган, изүе һәрвакытта ачык, ә башында беләүләнеп каткан түбәтәй... Аннары тагын шул ук ыштан бөрмәсенә бәйләп, ул иске кын кынында кечкенә үткен пычак та йөртә иде. Менә шул пычакка безнең күзебез

яна иде һәм, әйтергә кирәк, бу пычаклы бабайдан без әзрәк кенә курка да торган идек.

Соңыннан Тимербай карт нәрәтәгә кергән бик шәп табан һәм кара балыкларны иске кәрзингә тутырып, өстен яшел үлән белән каплап, Дәүләкән урамында, ыштан балакларын да төшермәгән килеш, сатып йөри иде.

Аннары инде, үсә төшкәч, мин аның курайда уйнавын да хәтерли башладым. Әйбәт, оста уйный идеме ул? — мин әле белми идем, әмма өч-дүрт тишегеннән башка бер нәрсәсе дә булмаган, эче куыш, җип-җиңел, кибеп беткән көпшәдән шундый гаҗәеп озын көйләр чыгара алуына хәйран кала торган идем. Бер могҗиза булып тоела иде ул миңа, һәм мин, кем өрсә дә курайдан шулай көй-моң чыгара аламы икән, дип, баш вата идем. Билгеле инде, минем курай дигән шул җип-җиңел көпшәне тотып, өреп карыйсым да килә иде... Ләкин Тимербай карт кураен юри генә, карар өчен генә дә һич кемгә тоттырмый иде. Уйнап беткәч, ул кураеның башын ни өчендер ялаштырып ала да, аннары күлмәк изүеннән каядыр эчкә үк тыгып куя. Бу да мине бик гаҗәпләндерә иде.

Әмма минем курай белән чынлап торып сихерләнүем тагы да үсә төшкәч, унөч-ундүрт яшьлек чагымда булды. Беләсез, бу шундый вакыт инде — күңел кыллары үзеннән-үзе тибрәнеп, йөрәктә җыр-моң туарга гына тора!.. Хыялның да бик җилкенгән, эзләнгән, очынган чагы!.. Нәкъ менә шушы чакларда миңа курайны еш кына ишетергә туры килде.

Безнең күршедә генә Миңнегәрәй исемле башкорт тора иде. Аның ике аты бар. Шул атларын тәңкәле камыт-эшлияләр белән читән тарантаска җигеп, поезд килүгә Дәүләкән станциясенә чыга һәм поездан төшкән кымызчыларны утыртып, Дим буе авылларына илтеп куя торган иде. Бу аның төп кәсебе, атларын һәрвакыт таза, көр тота, ә көз җитеп, беренче кар төшкәч, шул атларның берәрсен иярләп, төлке, бүре сугарга да чыга. Шуның өчен генә ул ике бурзай да асрый иде. Кыскасы, бик егет кеше иде безнең күрше Миңнегәрәй агай.

Менә шул Миңнегәрәй агайга базар көннәрендә Дим буеның берничә мулласы, әйтик, Шәрип авылыннан Котлыяр мулла, Казанголдан — Исхак мулла, Япардан — Сафуан мулла гел килә торганнар иде. Бу өч мулла бик дуслар иде, ахрысы, чөнки кайчан карама, алар һәрвакыт бергә булалар иде.

Аларның базарда бернинди сату-алу эшләре юк, иртәнге якта чыгып, базарны бер әйләнәләр дә үзләре кебек тагын берничә мулланы яки бай башкортны ияртеп кайталар һәм Миңнегәрәй агайның түр сәкесендә көне буе диярлек ашап-эчеп, курай тартып, җырлашып утыралар... Ике ихата арасында тәбәнәк читән генә, ә күрше өйнең тәрәзәләре киңенчә ачык, шунлыктан барысы да — сәкедәге чирек-чирек кымызлары да, табак тулы итләре дә һәм кунаклар үзләре дә ап-ачык күренеп тора. Гомумән башкорт муллалары ашап-эчеп утыруларын берәүдән дә яшермиләр иде. Исерә калсалар да гаеп итүче юк — мулла да кеше!

Менә шул ачык тәрәзәләрдән инде бер вакыт, абзыкаем, курай белән җыр агыла башлый!.. Һәм мин шуны ишетүгә, барган җиремнән капкынга эләккәндәй, шып тукталып кала идем. Һич ычкына алмый идем мин бу татлы әсирлектән... Бөтен дөньямны онытып, ләззәтеннән, сызландыруыннан жыларга җитешеп тыңлыйм да тыңлыйм... Күз алдымда үзәнең якты киңлекләре, тын түбәләре, ак тирмәләре, утлауда йөргән җылкылары белән кылганлы дала әкрен генә җәелә дә җәелә... Бик биектә бөркет салмак кына йөзә. Еракта ялгыз җайдак шәүләсе күренә, әллә кайдан гына әрләп сызгыруы ишетелгән кебек була... Һәм иң гаҗәбе, шул далада ак тастарлы җиңгәнең муенына корык салган бияне савып утырганын бик ачык итеп күрә торган идем. Бу шул хәтле ачыкҗанлы булып күз алдына килә, мин хәтта җиңгәнең ике тез арасына янтайтыбрак кыстырган агач чиләген дә, шул чиләккә биянең ике им-

чәгеннән алмаш-тилмәш бәреп төшкән нечкә генә сөтне дә күргәндәй була идем... Әнә шулай әллә кайларга алып китә, хыялый итә иде мине бу башкорт курае, башкорт җыры!..

Курайчыны берничә мәртәбәләр күрсәм дә, мин аның кайсы авылдан, кем икәнен белә алмадым. Аны шул муллалар үзләре базардан ияртеп кайталар иде. Аз гына кылый, аз гына шадра, озын буйлы бу агай, минемчә, бик шәп курайчы булгандыр. Бик дәртләнеп, бик рәхәтләнеп, ничектер җиңел итеп, гүя уйнап кына тарта иде ул үзенең кураен! (Аның сирәк кенә төкле ирене кураен китереп терәмәс борын ук үзен-нән-үзе селкенә башлый иде инде.) Әмма шул ук вакытта ул кураеннан гаҗәп саф, гаҗәп иркен тавышлар чыгара белә һәм шуны искиткеч озын итеп, бормаландырып суза да ала иде. Кыскасы, тәмам җилеккә үтәрлек итеп уйный иде агаебыз!

Ә курайга кушылып һәрвакыт Котлыяр мулла җырлый торган иде. Һичшиксез, курайчыга тиң җырчы иде ул... Авызын ачар-ачмас, ирен-нәре арасыннан гына бер суза башласа, тавышы киң далага да сыймас кебек... Шуның өстенә гаҗәеп моңлы-матур җырлый иде бу мулла!.. Мин аны яхшы беләм, бездә дә аның булганы бар иде. Озын кара казаки кигән мәһабәт-таза гәүдәле, елтырап торган кызгылт-шома битле, сирәк кенә кара сакаллы бер кеше иде ул. Базардан базарга, кунактан кунак-ка гел бал, кымыз эчеп тә кызык сөйләп, җыр җырлап йөргән бу кешенең мулла булуына ышануы да читен иде. Елына ике килә торган гаеттән башка ул үзенең мәчетенә йөрде микән?.. Һәрхәлдә, мин аның чалма кигән чагын күрмәдем.

Озын сүзнең кыскасы, күрше Миңнегәрәй агай өенә җыелып, сәрхүш булып утыручы муллаларның җыр-курайларын миңа бер-ике җәй буена еш кына ишетергә туры килде. Нәкъ менә шул чакта башкортның тиңсез бай, гүзәл, сихри җыр-моңнары минем кайрыланып өлгермәгән күңелемә гомерлеккә диярлек сеңеп калды да булса кирәк. Аннары озак та үтми мин, шактый яшь башымны алып, туган-үскән оядан, якты Дим буйларыннан, ерак калага чыгып киттем. Ә бер өч-дүрт елдан соң теге муллалар да кайсы кая таралып, югалып беттеләр шикелле..

* * *

Шактый күп еллар узгач, мин үзебезнең радиокомитетта (фронттан кайтып шунда эшли башлаган чагым) тагын бер курайчы белән таныштым. Бу инде татар курайчысы иде. Шуның өстенә радиода уйнаштыра, димәк, аны күпмедер дәрәҗәдә профессиональ курайчы да диярга була. Ләкин якынрак танышкач, мин аның кайчандыр хуҗалык эшләрендә эшләп йөргәнен, тик соңгы вакытларда гына курайчы булып танылып киткәнен белдем. Әлбәттә, музыкага бик сәләтле кеше иде ул, кулына ни тотса, шуны уйный ала, курайга да яшьтән үк өйрәнгән, әмма болар берсе дә аның өчен төп кәсеп була алмаган. Инде аны радиога чакырып уйната башлаганнар икән, моның сәбәбе бик ачык: шәһәрдә ул бердәнбер курайчы.

Исеме аның Исмәгыйль иде. «Исмәгыйль абзый» дип эндәшә идек без аңа. Җыйнак-җиңел гәүдәле, җирән сакаллы, зур коңгырт күзле бу чибәр абзый телгә дә бик җор иде, гел уен-көлке сөйләргә ярата торган иде. Шуңадыр инде ул безнең радиокомитетка йөрүче күп кенә артистлар, җырчылар, композиторлар белән дә якыннан аралашып, ничектер җиңел генә дуслашып өлгергән иде.

Мин үзем дә Исмәгыйль абзыйны ярата идем, алюмин кураен да рәхәтләнеп тыңлый идем, ләкин ни өчендер шул чакта еш кына: «Нигә бу абзый табигый курайда уйнамый икән?» дип, ихтыярсыздан уйлана да идем. Белмим, яшьтән үк тыңлап өйрәнгәнгә күрәме, миңа ясалма курайга караганда кырда үскән табигый курай якынрак та һәм

тансыграк та иде. Дөресен генә әйткәндә, күптән инде мине бер нәрсә гаҗәпләндерә: ни өчен табигый курай бездә юк, ни өчен ул, әйтик, башкортларда сакланган да бездә сакланмаган?.. Бик сирәк кенә очраган безнең курайчылар я тимер, я җиз курайда уйныйлар. Бәлки кеше кулы белән ясалган бу курайлар теге ялан кураена караганда әйбәтрәктер, курай сәнгатендә үзенә күрә бер алга китештер?.. Ихтимал, шуның өчен дә ясалма курай табигый курайны гамәлдән кысып чыгаргандыр?.. Бу хакта мин Исмәгыйль абзыйның үзеннән дә сораган идем. Аның әйтүенә караганда, табигый курай, билгеле, безнең татарларда да булган, хәзер дә әле кайбер җирләрдә, мәсәлән, Ык буенда ялан кураенда уйнаучылар очрыйлар, ләкин татар халкы кырда үскән курай белән генә чикләнмичә, шуның төсле итеп тимердән, җиздән дә ясарга өйрәнгән. Моның сәбәбе, бәлки, безнең дымсурак, салкынчарак җирләрдә уйнарга яраклы курайны табуга караганда, аны кулдан ясау ансатрак булгандыр. Аннары тагын ясалма курайның тавышы да безнең татар колагына нәфисрәк ишетелсә кирәк... Бу сүзләрдә, һичшиксез, дөреслек булырга тиеш.

Шуннан соң мин бер сөйләшүдә Исмәгыйль абзыйдан туп-туры сорадым:

— Ни өчен сез ялан кураенда уйнамыйсыз?

Моңа каршы ул көрсенә биреп:

— Их, Әмирхан туган, уйнамас идеммени мин, ләкин юк бит ул, ялан курае, юк,— диде.

— Ә сез дөресен генә әйтегез әле: ялан кураен үзегез яратасызмы?

— Һе, яратмыйча, әлбәттә, яратам.

— Алайса, табарга кирәк аны.

— Ә кайдан?.. Акчага сатылмый, Арчада үсми ул... Аның өчен генә Урал тауларына барыргамы?

— Бик кирәксә, барасың да аны...

— Мин әзер,— ди Исмәгыйль абзый, шунда ук сүзне уенга борып.— Әйдә, командировочный яздыр, иртәгә үк китәм.

— Курай сиңа кирәк бит.

— Нишләп миңа, халыкка кирәк ул... Ә халыкка кирәкне табу сезнең эш... Чын, комитет алдында мәсьәләне күтәр, курай җыеп кайтыр өчен Уралга экспедиция җибәрик, диген.

Безнең сөйләшү әнә шулай ярым уен-көлкегә әйләнеп бетә торган иде. Әлбәттә, миңа тансык курай турында бүтән уйлаучы да юк, аннары Исмәгыйль абзыйның алюмин курайлары бар чагында башкасын кирәк дип белүче дә юк иде.

Ул шулай кысыр хыял булып калган да булыр иде, ләкин бер җәйне минем үземә Оренбург өлкәсенә, Куандык дигән җиргә кайтырга туры килде. Юлга чыгар алдыннан мин бу сәфәремне Исмәгыйль абзыйга да әйттем.

Абзый кызыксынып:

— Куандык?.. Нинди җир, кайда ул? — дип сорады.

— Сакмар буенда,— дидем мин.

— Сакмар буенда!.. Бик тә ямьле якларга китәсең икән, туган! — диде ул сөенеп һәм әз генә көнләшкәндәй дә булып. Аннары нидер исенә төшкәндәй ачылып өстәде: — Карале, син шуннан миңа әлеге үзең мактаган ялан кураен табып кайтмассыңмы?.. Сакмар буенда үсәргә тиеш ул!

Аның бу үтенече миңа да ошап куйды.

— Ярар, абзый, эзләп карармын! — дидем мин ихлас кына.

— Зинһар, туган!.. Син үзең кырда үскән курайны таныйсыңдыр бит?

— Танымасам, мин аны шундагы агайлардан эзләтермен.

— Бигрәк тә яхшы!.. Тик син берничәне табарга куш инде... Түләргә туры килсә, алып кайткач, исәпләшербез.

— Анысы өчен борчылмагыз, Исмәгыйль абзый,— дидем мин, сүзне шуның белән өзеп.

Куандык!.. Кайдан бу шигъри матур исем?.. Минем сугышка чаклы да бу тирәләрдә булганым бар иде. Беренче күргәч, үзем дә куанугa охшаш хис кичергән идем. Табигатьнең гаҗәеп бай, матур җирендә утыра ул Куандык!.. Кайсы ягына карама, ямь-яшел йомры түбәле биек-биек таулар... Шул таулар арасыннан бормаланып көмештәй ак, чиста Сакмар агып килә. Таулар читенгән җирләрдә күкрәк авызыннан куе үлән үскән тип-тигез тугай җәелеп китә. Ә таулар китереп кыскан урыннарда текә кыялар бөтерелеп аккан Сакмар өстендә таш стенадай басып торалар... Билгеле инде, бу гүзәллекне, бу байлыкны беренче килеп күргән кешеләрнең чынлап куанулары да һәм ак тирмәләрен корып утырган шушы урынга «Куандык» дип исем бирүләре дә бик табигый, бик аңлашылса кирәк. Шигъри исем үзе үк шуны әйтеп тора!

Куандыкка мин кыз туганнарыма кунак булып кайткан идем. Аларда хәзер ир заты юк, икесенең ире һәм бердәнбер энеләре сугышта һәлак булдылар. Шуңа күрә мин, фронттан исән-имин кайткан ага тиешле кешеләре, алар өчен бик кадерле кунак идем. Сый-хөрмәтне әйткән дә юк, ашап-эчеп кенә өлгер, шуның өстенә ике-өч көн саен эссе мунча, яткан урыным да ак өйнең түрендә, сиртмәле караватта гына...

...Бу сый-хөрмәттән бик тиз маемларга да мөмкин иде, ләкин мин ходай бирмеш һәр көн я Сакмар буена, я тауларга чыгып китә идем. Таулар!.. Малай чактан ук калган бер комарлыгым бар — кайда гына берәр биеклек күрмим, шуңа үрмәләп булса да менәргә тырыша идем. Менә Куандык әйләнәсендәге тауларга да мин тырыша-тырмаша мендем, ниһаять!

Тау биекме? Син менәмсең?
Мен, менә алсаң, таугa мен!
Таугa мен, күр дөньяны син,
Күр бу дөньяның ямен!

Әйе, дөньяның хәйран ямьнәре, хәйран киңлекләре ачыла икән бу таулардан!.. Әкрен генә җил уйнаган биек түбәдән мин, үземчә чамалап, әле Орск, әле Җилаир якларына озак кына карап тора идем. Аннары...

Төш түбән, йөр син түбәндә,
Күр чәчәкләр, чишмәләр.
Күр игеннәр, күр җимешләр.
Хәсрәтеңне бер китәр!

Әйе, Сакмар буена төшкәч, хәсрәт-уйлар чынлап та каядыр ага да китә. Назлы-шаян кызлар кебек бит ул җыр булып аккан Сакмар!.. Бер карасаң, чуер ташлар өстеннән, ак тәпиләрен елтыратып, көлә-көлә йөгерә, икенче карасаң, озын толымнарын сүткән шикелле, зәңгәрләнеп-уйчанланып тын гына агып ята.

Нигә сугa сузыласың,
Тал чыбыккай, интегеп;
Ялварасың, борыласың,
Тилмерәсең, өзеләсең,
Аккан сугa күз текеп?

. . . . . . . . . . .

Әнә шулай иске шигырь өзекләрен искә төшереп, мин Куандык әйләнәсендә күп йөрдем. Әлбәттә, Исмәгыйль абзыйның курай табып кайтырга кушкан үтенечен дә хәтеремнән чыгармый идем, киресенчә, күңелгә килгән җыр, шигырьләр курайны гел искә төшереп кенә тора

иде. Әмма мин үзем Сакмар тугаенда да, тау битләрендә дә, күпме караның йөрсәм дә, аны очрата алмадым. Әллә юк, әллә эзли белмим?.. Ахрысы, танып та житкерми торганмындыр. Иллә мәгәр бөтен нәрсә күкрәп үскән бу җылы-якты җирләрдә курай булырга тиеш бит, булмыйча мөмкин түгел!

Ахырда бу эшне, башта уйлаганча, бер агайдан үтенергә туры килде. Кешесе дә табылды. Базар көн саен Сакмар үрендәге бер авылдан килеп, минем кыз туганнарда атын тугарып торучы Хажиәхмәт исемле бер агай иде ул. Үзе урман каравылчысы икән... Менә бер килүендә мин шул агайдан, «базар чәен», клиндер манып, эчеп утырган чагында, иплэп кенә сорадым:

— Әйт әле, Хажиәхмәт агай, сездә курай бармы?

— Курай? Нинди курай? — диде ул, аңлап бетермичә.

— Соң, уйный торган курай.

— Бар бугай бер-ике кешедә. Уйнаштыралар.

— Менә миңа да кирәк иде шул курай.

— Тарта беләсеңмени? — диде ул, елмаеп кына.

— Үзем өчен түгел. Бездә бер курайчы бар, шул кушкан иде. Табып китермәссеңме?.. Буш итмәм.

— Курайны бит аны, туган, сатар өчен ясамыйлар.

— Миңа ясаганы кирәкми. Кырда үскәне булса ярый... Үсәме ул сездә?..

— Үсә, күп үсә, бер колач кыркып китерергә була,— диде ул, кәефле генә көлеп.

Аның болай җиңел генә әйтеп ташлавы мине бераз пошындырып куйды. Колачы белән кыркып китергән курай нинди булачак ул?.. Эшкә ярый торганмы, түгелме?..

— Син, Хажиәхмәт агай,— дидем мин, шигемне сиздермәскә тырышып,— курайның уйнарга ярый торганын гына табып китер инде. Колачлап кирәкми, берничәү булса, шул җитәр... Сине өйрәтәсе юк, үзең дә беләсеңдер?!.

— Ярар, синең өчен сагылда үскәнен генә табып китерермен,— диде Хажиәхмәт агай, пинжәк чабуы белән шабыр тир битен сөртә-сөртә. Аннары сыңар кулы белән генә ияген сыпырып куйды: «Аллаһеәкбәр!».

Әлбәттә, белә ул, белмиме соң!.. «Сагылда үскәнен» ди бит! Ягъни кояшка каршы тау битендә үскән курай була инде ул... Мин чамалыйм, бу курайның иң эгъләсе, өрмәс борын «Буранбай»ны суза башлый торганы булырга тиеш. Ишеткәнем дә бар, җылы туфрактан һәм эссе кояштан ярала икән ул чын курай! Шуңа күрә төпченеп тормадым, хәтта кайчан китерәсең дип тә сорамадым — Хажиәхмәт агай, барыбер, клиндерләп чәй эчәр өчен генә булса да, алдагы базарга килеп җитәчәк.

Ләкин атна арасында бер көнне Сакмардан су кереп кайтсам, өйнең тышкы бусагасында әлсерәп бер карчык утыра. Ерактан килгәнгә охшый, җирдә таягы да ята, үзе янып-көеп, тәмам бакыр төсенә кергән. Көннәре дә бу арада бик эссе тора, пешеп үләрлек... Мин ихтыярсыздан: «Кем бу әби, ни өчен мондый чакта йөри, саилче микән әллә?» дип тә уйлап куйдым. Шул чакта кар базыннан салкын катык күтәреп, минем кече сеңел Һәммәюн килеп чыкты. Мин, аңа таба атлап, әкрен генә:

— Бу әби кем була? — дип сорадым.

— Хажиәхмәт агайның әсәе, Миңзифа әби,— диде Һәммәюн.

— Шулаймыни? — дидем мин аптырап, аннары, карчык янына барып, исәнләштем: — Исәнме, әби!

— Саумы, улым! — диде әби ачык кына.

— Кем белән килдегез?

— Үзем генә.

— Әллә җәяү?

— Җәяү шул,— диде әби, елмаерга тырышып. Мин гаҗәпләнеп торган арада һәммәюн әйтеп куйды:

— Әнә ул сиңа курайлар китергән.

Курайлар китергән?!. Шушындый эсседә, унбиш чакрым җирдән, җәяүләп?!. Бер мизгел ни әйтергә дә белмичә торгач, мин, ниһаять:

— Их, әбекәем! — дидем, ачынып.— Нигә болай азапланып йөрисен, ашыгыч нәрсә түгел иде бит ул. Хаҗиәхмәт агай үзе дә базар көнне китергән булыр иде!

— Улым килә алмый, печәнгә төштеләр...

— Шулаймыни?.. Җайсызрак килеп чыккан икән. Сезгә, карчык кешегә, бу эсседә йөрүләре бик авырдыр бит?

Әби бер дә исе китмичә генә:

— Һи, йөрүмени бу! — диде.— Көн өстенә килеп китәбез без Куандыкка... Әле индә йөк тә була, буш кул белән килүнең бер азабы да юк. Менә әзрәк кенә хәл алам да кире китәм.

— Кире?.. Юк инде, әбекәем, бүген мин сезне җибәрмим. Хәзер менә чәй эчәрбез, аннары аш та өлгерер.

— Юк, булмый, миңа эчәргә ярамый әле,— диде карчык, кипкән иреннәрен ялап.

— Нишләп?

— Мин — ураза.

— Ураза?

— Әйе, алла кабул итсен!

Тагын шул гына җитмәгән иде! Их, әби, әби, болай да әлеп киптергән кебек булгансың бит, дидем мин эчемнән тенә, ләкин үзенә әйтеп тормадым, чөнки әйтүдән мәгънә юк, һәм килешмәс тә иде ул. Кешенең гомере буе тоткан уразасын бозып буламы соң?!.

Минем карчык китергән курайларны тизрәк күрәсем килде. Аның артындарак чүпрәккә төрелгән озын бер нәрсә стенага сөялеп тора иде, шуңа ымлап сорадым:

— Шулмы инде сез китергән курайлар?

— Ийе,— диде карчык һәм борылып озын төргәкне алды.— Мә, үзең сүтеп кара.

Мин, чүгәләп, баш-башыннан бәйләгән бауларны чиштем дә чүпрәкне сүттем. Менә сиңа курайлар!.. Дөресрәге, курай булачак куралар... Җидәү икән үзләре, кайсы озын, кайсы кыскарак. Бик үткен пәке белән киселгән булса кирәк, очларында бернинди янчелгән яки ярылган җире юк... Һәм шушы эче куыш, җип-җиңел, үтә кипкән үсемлек сабагы, кемдер иренена тидереп, өрә башлагач та, үзенә сихри җан кергәндәй, өзгереп уйнап җибәрергә тиеш!.. Гаҗәп, гаҗәп!.. Бәлки безнең иң ерак бабаларыбыз әле үлән-тамыр җыеп туена башлаган чакларында ук бу үсемлекне өреп карарга, сызгыртырга өйрәнгәннәрдер. Бәлки шул заманнардан ук инде сакланып килә торгандыр бу курай дигән иң табигый, иң кадерле уен коралы?!. Ләкин менә хәзер аны ничек бәяләргә? Баһасы бармы аның? Һәрхәлдә, бушка гына бирелми һәм алынмый торгандыр инде.

— Хаҗиәхмәт агай нәрсә әйтте соң? — дип сорадым мин карчыктан. Ул, билгеле, минем тел төбемне аңламады.

— Нәрсә әйтсен. Куралар әйбәт, диде, үзе дә ике көн эзләп йөрде.

— Рәхмәт инде аңа, бик рәхмәт!.. Тик, әби, мин боларның бәясен белмим бит әле... Күпме тора икән үзләре?..

— Хода белсен! — дип кенә куйды карчык. Ул һаман да әле сүзнең нәрсә турында баруын аңлап бетерми иде, ахрысы. Шуннан соң мин торып, кесәмнән утыз сумлык[1] чыгарып суздым.

---

[1] Иске акча вакытта.

— Аз булмасмы, әби?
Карчык сискәнгәндәй кинәт минә ике кулын селтәде:
— Куй, кирәкми!
— Ничек инде кирәкми?.. Бушка гына булмый бит.
— Кирәкми, кирәкми! — диде карчык, кат-кат башын, кулын селкеп.— Кырда үскән кура өчен кеше акча аламыни, ошамаганны!..
— Кура өчен булмаса, хезмәтегез өчен алырга тиешсез. Хәжиәхмәт агай вакытын әрәм итеп эзләп йөргән, сез менә җәяүләп китерә килгәнсез... Шуның өчен түлим мин, алыгыз!
— Юк, алмыйм! — диде карчык, кырт кисеп.
Мин шактый кыен хәлдә калдым. Кулымдагы акчаны карчыкка көчләп бирә дә алмыйм, кире кесәмә салсам да бик уңайсыз. Нишләргә соң?.. Карчыкны болай бер нәрсәсез җибәрү һич тә ярый торган эш түгел, ничек кенә булса да аны бәхилләтергә кирәк. Ләкин ничек итеп?.. Ахырда без, җыйнаулашып дигәндәй, карчыкны бүген китмәскә, авыз ачып, куна калырга кыстый башладык. Карчык моңа да бик авырлык белән генә күнде. Балалар көтә, килен ачуланыр дип, һаман карышып маташты.
Балалар дигәннән, мин Хәжиәхмәт агайның вак кына балалары күп булуын ишетеп белә идем. Шуннан күңелгә бер әйбәт уй килде: әлеге карчык баш тарткан акчаны һәммәсенә биреп, шул балаларга тәмле-төмледән ни дә булса, ә карчыкның үзенә чәй-шикәр алып, шуларның һәммәсен киткән чагында гына кулына тоттырырга куштым. Күчтәнәчтән инде әбиебез баш тартмас, шаять!
Кояш баегач, әби тоз тәмләп кенә авыз ачты, безнең белән утырып аш ашады, аннары бик күп итеп чәй эчте. Икенче көнне таң беленгәч үк торып, яңадан уразага керер өчен сәхәрен ашап, Сакмар үрендәге авылына кайтып киткән иде инде ул...
Санаулы көннәр тиз үтте. Минем дә китәр вакыт җитте. Юлга әзерләнгән чакта гына көтелмәгән бер мәшәкать чыкты: куралар минем чемоданга сыймый икән. Бөкләп сала торган әйбер түгел, нишләтергә үзләрен?.. Болай төреп, бәйләп кенә алсаң, юлда я сынар, я изелер дип тә курыктым. Шуннан соң кыз туганнарның киңәше белән, мин май заводында әрҗә ясаучылардан тиз генә озын футляр сыман бер нәрсә эшләтеп алдым. Куралар шуңа шып кына кереп утырдылар.
Өйгә кайткач, Исмәгыйль абзыйны чакырып алып, тантаналы рәвештә дигәндәй, кураларны футлярыние белән аңа тапшырдым. Абзый, үзе кушып җибәрсә дә, ышанып көтмәгән икән, күргәч бик куанды.
— Валлаһи газим, чын куралар бит болар, башкорт менә шулардан курай ясап тарта да инде! — диде ул, һәркайсын бик җентекләп карый-карый.
— Хәзер, Исмәгыйль абзый, син «тартканны» ишетәсе калды безгә,— дидем мин.
Ул әзрәк уйланып торды да ни өчендер башын кагып куйды:
— Белмим шул, белмим шул!..
Шактый гаҗәп тоелды миңа аның бу уйчан-сәер җавабы. Ничек юрарга моны дип торган арада, ул миннән кинәт кенә сорады:
— Ә күпме түләргә үзләренә?
Тагын каһәр суккан акча мәсьәләсе!.. Теге әби шикелле кырт кисеп кенә: «Юк, бер тиен дә кирәкми!» дип әйтмәкче булган идем дә, кинәт Исмәгыйль абзыйны бераз шаяртасым килеп китте. Авыр гына сулаган булып:
— Кыйбатка төште бу куралар, Исмәгыйль абзый, һәркайсы утызар сум тора,— дидем.
Ләкин Исмәгыйль абзыйның моңа бер дә исе китмәде:
— Булыр, булыр!.. Сакмар кадәр җирдән кайткан ич алар! Нәрсә, хәзер үк түләргәме?

Мин ирексездән көлеп җибәрдем һәм теге әбинең бу кураларны ин эссе көндә, ураза килеш, унбиш чакрым җирдән җәяү китерә килеп тә бер тиен акча алмавын сөйләп бирдем. Ахырдан, шул әби шикелле, мин дә бер тиен дә алмыйм дидем. Кечкенә бу вакыйга Исмәгыйль абзыйга шактый нык тәэсир итте булса кирәк, ул сүз таба алмагандай бераз дәшми торды, аннары башын кагып: «Кара син, ә, изге бәндәләр дә бар икән!» дип куйды. Шуннан соң кураларны, дөньяның иң кадерле бер нәрсәсе шикелле, култык астына сак кына кыстырып, кат-кат рәхмәтен әйтеп китеп барды.

Әмма ни кызганыч, Исмәгыйль абзыйның ялан кураенда уйнаганын миңа ишетергә туры килмәде... «Белмим шул» дигән иде ул, курайларны миннән алып киткән чагында. Нидер сизенгән шикелле әйткән икән абзый кеше!.. Башта аның өен, урыны яңа төзелешкә кирәк булгач, шәһәрдән шактый еракка, каядыр Чыңгыз тирәсенә күчерделәр. Исмәгыйль абзый шуның мәшәкатенә кереп батты, ахрысы, бөтенләй күзгә күренми башлады. Аннары күпмедер вакыттан соң үзе дә каты авырып, көтмәгәндә генә үлеп киткән... Мин хәтта аның үлемен ишетми дә калдым. Кем әйтмешли, дөнья бу!..

Ләкин соңыннан инде, Исмәгыйль абзыйны искә төшергән чакта, теге курайларны ул нишләтте икән дип уйлап куйгалый идем. Бары күптән түгел генә ишетеп белдем: Исмәгыйль абзыйдан калган барлык курайлар да Тел, әдәбият институтының музыка кабинетында саклана икән... Юри кызыксынып, барып карадым. Моннан күп еллар элек Хаҗиәхмәт агай Сакмар буеның тау битләреннән кыркып алган, әнисе Минзифа карчык җәяүләп Куандыкка китерә килгән, мин исә махсус футлярга салып алып кайткан курайлар кабинет шүрлегендә, иске газеталарга төрелгән килеш яталар. Сүтеп карагач, мин аларны таныдым. Исмәгыйль абзый һәр кайсына өстән дүрт, астан бер тишек ясаган (нәкъ башкорт курае төсле итеп), кулыңа ал да сыздырып, сузып җибәр!.. Әмма алар өнсезләр, сыздырып-сузып җибәрердәй кешесе юк — әкияттәге теге малай кебек кешесен, кешесен кайдан табарга?!.

IIIIIIIIIIIIII

## Клара Булатова

### Туган җиремә

Агым суларыңның ярсулыгы
Йөрәгемә күчкән.
Авыл таңнарының алсулыгы
Йөзләремә төшкән.

Якты кояшымның алтын нуры
Иңнәремә төшкән.
Биек таулар юлы, юллар җыры
Телләремә күчкән.

Аяз күкләреңнең зәңгәрлеге
Күзләремә җыелган.
Басу кырларыңның иркенлеге
Күңелемә сыйган.

Януларым, эзләү, табуларым
Синнән килгән минем.
Җимешләрем, иҗат җимешләрем
Синдә, сөйгән илем.

### «Кеше бул», диеп

Беренче тапкыр кузгала бала,
Уяна бала бишектә көлеп.
Кулына ала анасы сөеп:
«Үс, улым,— диеп,
«Кеше бул»,— диеп.

Беренче тапкыр сабакка бара,
Сумкасын асып, формасын киеп.
Каршылый мәктәп, каршылый сөеп:
«Кеше бул»,— диеп,
«Кеше бул»,— диеп.

Өлгереп, эшкә юл ала бала,
Озата мәктәп:
«Якты юл»,— диеп.
Каршылый юллар, каршылый кырлар,
«Кеше бул»,— диеп,
«Кеше бул»,— диеп.

●

Син юк иден —
    синнән башка әйбәт иде.
Син бар булдың —
    синең белән әйбәт иде.
Син юк хәзер —
    синнән башка әйбәт түгел.
Синсез ничек яшәп булган?
    аңлый алмыйм.
Синсез ничек әйбәт булган?
    аңлый алмыйм.
Шунысын аңлыйм:
    хәзер синсез әйбәт түгел,
Шунысын аңлыйм:
    хәзер синсез яши алмыйм.
Син бар иден —
    синең белән бәхетле идем,
Бәхет шундый —
    аннан кем дә туя белми, арый белми.
Чөнки бәхет —
    туйдыра торган,
    ардыра торган,
    күнегә торган гадәт түгел.
Син барында әйбәт иде —
    бәхетле идем,
Син кил инде,—
    синнән башка әйбәт түгел.

●

Кайчан гына әле шундый
Кайгысыз, моңсыз идем.
Гел ялан тәпи йөгергән
Ваемсыз бер кыз идем.

Өстә бер чуар сарафан,
Чәчтә күбәләк иде.
Сулыш кин, кая карасаң
Дөнья түгәрәк иде.

Алдында үсмер күңелнең
Гел зәңгәр иртә иде.
Гел таңнар көтә иде ул,
Гел бәйрәм итә иде.

Җәй чыксам — җирем ямь-яшел,
Кыш керсәм карлы иде.
Ул чак гаҗәп бай идем мин,
...Һәм үтә ярлы идем.

Чалт аяз якты күңелемнең
Юк иде болытлары.
Юк иде җанда сөюнең
Бу давыл, бу утлары.

Әле кул тимәгән сазның
Төз иде кыллары да,
Юк иде ярасы аның,
Юк иде җырлары да.

Ах, әгәр язмыш борылса,
Шул үткән матур заманга
Мин кире барыр идем;
Тик үзем белән ул якка
Үтә бай бер фәкыйрь чакка,
Үтелгән юллардан сырган,
Катлаулы еллардан торган,
Өзелгән кыллардан туган,
Өзелмәс моңнардан торган
Байлыгым алыр идем —
Җырларым алыр идем.

## Егор Уткин

### Куеп иңне иңгә

Салкын окопларда эткәйләрнең
Без канында,
Хыялында булдык.
Алар белән бергә яраландык,
Ятып калдык,
Бураннарда тундык.
Ә дөньяга бераз соңлабрак,
Давыл тынгач тудык.
Без дөньяга килдек давыл тынгач,
Яшәр өчен көлеп,
Яшәр өчен янып.
Якты күнебезне,
Якты илебезне
Бар бит торучылар мушкаларга алып.
Дары исе безгә туганда ук сеңгән.
Тик без төзүчеләр —
Сугыш безгә нигә?
Ләкин Ватан дәшсә — миллион Матросовлар,
Газинурлар басар куеп инне иңгә.

### Атакага йөрде «Шүрәле»

*Ф. Яруллинның якты истәлегенә*

Яхшы белә идем
Батырлыгын,
Рухын,
Моңын татар халкының.
Шүрәлесе хәтта сүндереште
Илгә килгән афәт ялкынын.
Землянкада,
Окопларда булды
Үзәк өзгеч салкын кышларда.
Сугышчылар белән алгы сафта
Ут яудырды яуда дошманга.

Нурихан Фәттах

# ӘТИЛ СУЫ АКА ТОРУР

ТАРИХИ РОМАН[1]

III



Коточкыч яңалыкны иң элек кодалар белде.

Кайгылы хан, эндәшмичә, кешеләргә күтәрелеп карамыйча, бик озак утырды.

— Аппак юк...— диде ул ниндидер чит кеше тавышы белән.— Юк... Китте... бетте...

Аның ике як бите буйлап кайнар яшь тамчылары тәгәрәп төште.

Акбүре ыруыннан килгән кодаларга хан Аппакның кайчан, ничек, нишләп «юк» булуын аңлатып тормады. Анысын башкалар аңлатты. Тотыш би кодаларны бер үзе бер өйдә көтеп утыра иде. Аңа турысын гына әйтергә беркемнең дә батырчылыгы җитмәде.

Шулай да барыбер белде. Белде, тик ышанмады, ышана алмады. Үзе исән чакта, үзенең күзләре кешеләрне, күкне, кояшны күргән чакта... өйләр, агачлар аумыйча-авышмыйча торган чакта... әҗүндәгы барлык нәрсә элеккечә исән-сау калган чакта ул аның гына... бары Аппакның гына шушы мәңгелек күк, кояш астында булмавына, шушы өйләр, каралтылар арасында булмавына ышана алмады. Капка төбендәге сакчылар, беркемгә кирәксез ниндидер хатыннар, балалар, усалланып безелдәгән чебеннәр, этләр, терлекләр шушында... шушы җирдә, шушы илдә иркенләп яшәп ятканда аның гына... бары бер Аппакның гына монда була алмавына ул берничек тә ышана алмады.

Юк, юк! Ышанмагач ышанмады!

Тәңрем! Туган җирем, туган күгем! Олуг кояш! Әйтегезче, күрдегезме сез дә аның юк булуын? Күрдегезме җөфүт каган кешеләре аны

¹ Ахыры. Башы 8, 9, 10, 11 саннарда.

көчләп, тартып алып киткәннәрен? Өйләр, капкалар, тузанлы юл, сез ул чакта монда булгансыз. Күрдегезме аның кан-яшь түгеп, чит якларга, чит җирләргә киткәнен?

Әй болгарлар, әй кешеләр! Шуны күреп ничек сезнең йөрәгегез ярылмады, ничек сезнең ярсуыгыз кузгалмады?! Урман-таулар, кырбасулар! Бөек Әтил! Ак болытлар! Ник сез шуңа юл куйдыгыз?! Ник сез шуны тыныч кына карап калдыгыз? Сез Тотышны... үзегезнең юлдашыгызны оныттыгызмыни? Аның бары аны гына — бары Аппакны гына сөйгәнлеген оныттыгызмыни? Әллә сез дә көнләштегез?! Әйтче, язмыш, көнләштеме алар минем сөюемнән?!

Үзенең йөрәк төреннән чыккан иң усал сүзләрен ул, сөңге аткан кебек, хан йөзенә атты.

— Син — ялганчы! — диде.

Башка авык булса, башка кеше булса, мондый сүзгә Алмыш хан чыдап тормас иде. Мең батманлы авыр башын, кайгылы зур башын көчкә күтәреп утырган ата кеше урыныннан да кузгала алмады. Ул бары күз кабакларын гына калкытты да, ачусыз гына:

— Мин ялганчы түгел, Тотыш... углан,— диде.— Язык миндә түгел.

Ул үзе янындагы хан-агасына ым какты. Хан-агасы каядыр китеп барды. Күп тә үтмәде, кулыннан җитәкләп ул хан катына яшь кенә бер кызны алып килде. Аңа, күп булса, ундүрт-унбиш яшьләр булыр иде. Оялудан аның сылу бит очлары пешкән чиядәй алсуланып тора. Аның елтыр-кара күзләре тынгысыз. Бу авыкта ул куркытылган болан баласына охшап калган иде.

— Менә минем кызым Айтулды... Аппакның бертуган сеңелесе,— диде Алмыш хан, авыр гыжылдап.— Мин аны сиңа хатынлыкка бирәм, Тотыш би.

— Мин ат түгел, бога түгел,— диде Тотыш би, усалланып.— Мин синең бу кызыңны яратмыйм, тегесен яратам... Аппакны! Шуны бир син миңа, Алмыш хан!

Мондый сүзләр ишетеп, хан көлемсерәгәндәй итеп куйды.

— Иң элек син миңа аны алып кайтып бир... каганны җиңеп...

— Җиңәрмен! — диде Тотыш би, тиле кеше сыман, тыела алмыйча.— Каганның астын өскә китерермен, Аппагымны тартып алырмын!

Хан янындагы кешеләр, бу кеше чыннан да тилергән ахрысы дигән шикелле, сүзсез генә бер-берсенә карашып алдылар, тамак кыргалап куйдылар.

— Сиңа кыен миңа да кыен, углан,— диде ата кеше авыр гына.— Мин сүземне әйттем: Айтулды синеке. Теләмисең икән, көчләмим. Үйла, тынычлан. Ике көннән килерсең. Син, Тотыш углан, миңа үз углым кебек якынсың. Мин сине яраттым. Күңел яраңны төзәтү өчен мин сиңа тагын бер изгелек эшләмәкче булам.

Алмыш хан чибәр, шома йөзле, тук, таза битекчегә кул изәде. Битекче алгарак чыкты, таяк сыман итеп төрелгән юка күнне сүтте дә, калын, матур тавыш белән кычкырып укый башлады:

— «Мин, изге Болгар йортның башы Шилке углы Алмыш хан ошбу ярлыкны Акбүренең Күрән би углы Тотыш бигә ирекле тархан булсын дип бирдем. Миңа буйсынган карачылар, хан-агасы, биләр, ыру башлары, субашлары, тарханнар, угланнар, туган-тумачалар, ил агалары, илчеләр, каравыл башлары, базар башлары, тамга башлары, агычылар, ясакчылар, салымчылар, авыл башлары, Болгар йортның барлык аксөякләре, каралары белсеннәр: чибәрлеге тиңсез кызым Аппакны явыз җөфүт каган тартып алганга, Аппакның кияве буласы Тотыш бинең кайгысын уртаклашып, күз яшьләре түгеп, мин Алмыш хан,

Күрән би углы Тотыш бине, аның угылларын, угылларының угылларын, барлык токымын киләчәктә мина, миннән соң утырачак ханнарга калан түләмәсен дидем. Көчләп аннан яу өчен ир-ат алмасыннар, караларын тартып алмасыннар. Ясак, салым, түләү салмасыннар. Ыругына, катавына, авылларына, байлыгына, терлек-туарына талау китермәсеннәр. Җиренә-суына, урманнарына, болыннарына басып кермәсеннәр. Тыңламаучыларга алланың каргышы, ханның ачуы төшәр. Тотыш би үзе, күче, ырудашлары, токымнары Болгар ханнарының якыны, ышанычлы таянычы булсын, мине агылардан көч белән, байлык белән якласын, алладан миңа, минем йортыма, улусыма, ыруларыма тәлим байлык, иминлек, озын яшь теләп, изгелектә булсын...»

Ханның якыннары, Акбүре илчеләре — тирмәдәге барлык кешеләр тын да алмый тыңлап тордылар. Укып бетергәч, битекче ярлыкны ханга бирде, хан — Тотыш бигә сузды.

Тотыш би кузгалды, ашыкмыйча, нык-нык басып, хан катына килде. Бер сүз әйтмичә, ярлыкны алды да, учында йомарлап... идәнгә ыргытты.

— Мин синең ярлыгыңа өйләнергә килмәдем, хан! — диде, усал итеп.

Кешеләр тетрәнеп киттеләр, куркынган тавышлар, аһылдаулар ишетелде. Кайберәүләр, исән чакта чыгып таярга кирәк дигән сыман, ишек ягына караштырып алдылар. Котлары алынып, ыңгырашып Акбүре илчеләре-кодалары Алмыш ханның аягы астына егылдылар.

Тирмәдәге кешеләр генә түгел, хан үзе дә, сулуы кабып, агарынып, өнсез калды. Нәрсә бу? Шулай аның йөзенә төкерергә... аңа каршы кул күтәрергә... кем ул? Кем!

Аның ярым йомык күз кабаклары киерелеп ачылды. Күкрәгендә котырынган ярсуын тотып тыя алмыйча ул, йодрыкларын нык кысып, бөтен буе белән калтыранырга тотынды. Шулай да ул нишләптер утырган урыныннан тора алмады.

— Моның өчен сине агач башына асып куярга тиешләр,— диде ул бераздан, авыр тын алып.— Буйсынмавың белексезлегең аркасында, күзең сукыраю... кайгы-сагыш аркасында, кызым Аппакны яратуың аркасында булганга, мин сине кичердем, Тотыш би. Мин Акбүре белән татулыкта яшәргә телим, Акбүренең Чулман буенда минем тәрәгем, уң кулым булуын телим. Әйткән сүзем көчендә: ике көннән килерсең.

## IV

Кодалар-илчеләр, аякларына тимер таккан кебек авыр атлап, әкрен генә кире борылдылар. Байраклар түбән иелде, башлар салынып төште. Килгәндә шундый куанып кычкырган быргылар, күк күкрәтеп дөпелдәгән дөңгерләр мыштым гына тынып калдылар. Урамда, юлда очраган кешеләр, Тотыш бинең, Тотыш алыпның кайгылы йөзен күрмәскә тырышып, күзләрен читкә бордылар. Ага-базар шулай ук аларны тавыш-тынсыз каршы алды. Чыр-чу килеп арттан балалар да иярмәде, капка төпләрендә авызларын ачып карап торучылар да күренмәде. Кешеләр, шулай булачагын алдан ук белгәнгә күрә, таракан-нар кебек каядыр качышып беттеләр.

Әллә качмаганнар иде микән соң? Әллә тирә-якта шаулап, ыгы-зыгы килеп тордылар микән соң алар? Тотыш күрмәде, ишетмәде. Ул берни тоймады. Ул, алтынлы, бизәкле иңр өстендә утырган килеш, иксез-чиксез Әтил дулкыннарында тирбәлеп барган кебек, әкрен генә тирбәлеп барды да барды. Ул бик озак барды. Болгар-тора белән

Ага-базар арасындагы ике-өч чакрымлык юлны ул, әйтерсең, айлар, еллар барды. Аның күзләреннән чишмә булып яшьләр акты, аның күкрәгендә тотенсез ут-ялкын дөрләде. Аның кайгылы йөзен күреп яшь кызлар яулык очларын чәйнәделәр, аның күз яшьләрен күреп яшь егетләр үзләре дә үкереп еладылар. Болгар илен тагын кайгы басты.

Тотыш алып кайгысыннан Болгар илен кара болыт басты...

Бигеш аларга күп итеп ит суйдырды, күп итеп сычук, буза куйды. Ачыккан акбүреләр ашау ягын кайгырттылар. Тотыш ашарга утырмады. Шулай ук ул ятып та, басып та тормады. Ул ничектер барлык кешеләрдән, тормыштан, аҗуннан аерылып калган кебек булды. Ул, әйтерсең, әле дә атына атланган килеш, җир белән күк арасында әкрен генә тирбәлеп барды.

Яшь бинең, белексез, тиле бинең кыланышына ачулары килгән кодаларның, ашап-эчеп алгач, телләре чишелде. Беренче булып Майчан аксакал телгә килде.

— Синең аркада, кем... Тотыш углым, кхм, кхм... без дә башсыз кала яздык. Инде син би булгансың икән, Акбүренең баш кешесе икәнсең, уйлап эшләргә... адымыңны уйлап атларга кирәк.

— Балаларча булды!

— Шундый ярлык биргәндә, алырга да ычкыныргае! Кызы үзенә булсын!

— Әйтмә! Нинди сөю, нинди ярату ул? Кыз беткәндер би кешегә!

— Кочакларга, төн кунарга кем дә ярый,— диештеләр кодалар, берсеннән берсе уздырып.

— Сеңелесе соң, сеңелесе! — диде үги ата Котан, кычкырып.— Тагын ни кирәк? Алмыш ханның кызын алам диден — ал! Шуңа килдек түгелмени? Шуның өчен йолабыздан, ата-бабалардан баш тарттык түгелмени? Бу, Тотыш би... углан, энем... синең эш кенә түгел, бөтен ыру эше. Менә без, Акбүренең аксакаллары, җыелдык та сиңа әйтәбез: Айтулдыдан син баш тартырга тиеш түгел. Калымны бирәбез дә, кызны алабыз да кайтып китәбез.

— Әйе, әйе, шулай!

— Әле берсеннән баш тарт, әле икенчесеннән! Ни дигән сүз бу?

— Ямгырчы би кебек, Алмыш хан да барыбызны да тотып япканчы, эшне тизрәк җайларга кирәк,— диештеләр башкалар да, шаулашып.

Тотыш би, телдән язган кеше сыман, беркем белән карулашмады. Күрмәс күзләре белән ул ырудашларының әле берсенә, әле икенчесенә карап алды. Күңеле белән ул барысын да сизеп, тоеп торды: аксакаллар ничек тә аның йөрәгендәге ялкынны сүндерергә, ничек тә аның уйларын, теләкләрен үзгәртергә, кирегә — үзләре теләгән якка борып җибәрергә тырыштылар. Сөю юк, ярату юк... кем дә ярый... Каланны түлик тә кире борылыйк... Ямгырчы бигә барып әлеккәч тә шуны сөйләделәр түгелме соң алар?

Аларга нәрсә! Тамаклары тук булсын да, кочаклашып төн кунарга, бала табарга, кием-салым юарга, ямарга, аш пешерергә ишләре булсын. Күңелләре теләгән сөекле, күрекле кызмы ул, карабашмы — алар өчен барыбер. Төннәрен аларның ялт-йолт килеп янган якты йолдызларга караганнары бар микән? Уйланып, таң калып аларның төпсез, киң Әтилгә — бертуктаусыз агып яткан бөек көч чыганагына карап утырганнары бар микән? Тирә-якта ут-үләннәр шау чәчәккә күмелгәндә, чикерткәләр сайраганда, бал кортлары бал җыйганда, аларның болын уртасына сузылып ятып, баш очында эленеп торган ак

болытларны күзәткәннәре бар микән? Сөекле кызлары турында уйлап, төннәрен йокысыз уздырган чаклары булды микән аларның?

Сөю юк, ярату юк, имеш! Шуннан башка тагын ни бар соң ажунда, тәңрем?!

Әллә соң туганда ук алар шулай бөкшәйгән, ямьшәйгән, уршыган картлар булып, чытык йөзле, черек тешле, сирәк-мирәк кәҗә сакаллы картлар булып туганнармы?

Сөю юк, ярату юк... Кочакларга кем дә ярый, имеш! Киекләр дә, ерткычлар да... барлык кошлар, кортлар яратыша бelә. Кеше генә шундый түбәнмени, тәңрем?!

— Сез миннән көләсез, минем яратуымнан, минем кайгымнан көләсез, аксакаллар,— диде ул эчке бер ачыну белән.— Туганымнан бирле, аягыма басып йөри башлаганнан бирле сез, сезнең балаларыгыз миңа ят итеп карадылар. Минем кыюлык, минем батырлык сезгә кыргыйлык булып, йолага каршы килү булып тоелды. Мин кылычым белән, сөңгем белән... каным беләныруымны яудан, үлемнән саклап калдым. Мин бары ыруның ирегең, бәйсезлеген генә саклый алмадым. Минем аңа көчем җитмәде. Алмыш ханның алыплары белән орышып мин бер дә кыргый түгеллегемне, туган җирем, туган ыруым, атам-анам өчен утка-суга керә алуымны күрсәттем. Минем батырлыкка сокланып сез минем «явызлыклар»ны, «кыргыйлык»ны, «башбаштаклык»ны онытып тордыгыз. Инде килеп ханның кызын ятаткамын икән, чынлап торып... йөрәгемә тәңре салган барлык ут-ялкыным белән, бөтен күңелем белән ятаткамын икән, бу тагын да сезгә тилелек булып, балалык, кыргыйлык булып тоела. Сез тагын да миңа ышанмыйсыз, ырудашлар. Минем яшьлегемә, минем сөя алуыма ышанмыйсыз! Күкрәгемдә утлы куздай дөрләп янган йөрәгем булуына, башымда уем, кулымда көчем барлыгына ышанмыйсыз! Тәңре мине яратканда матурлыкны, гүзәллекне күрә торган күзләр биргән, тәмлене, татлыны аерырга сизгер тойгы биргән. Үзем теләгәнчә сөяргә миңа канатлы күңел биргән. Сез, ырудашлар, шуңа ышанмыйсыз. Барлык кешеләр, барлык тереклек ияләре сезгә үзегез кебек картайган-муртайган булып, телсез-күзсез бүкән булып тоела. Әйе, ырудашлар, мин бары Аппакны гына яратам! Тәңре алдында, бөек Әтил, Чулман алдында, изге ияләр алдында мин ант итәм: аннан башка мин беркемгә өйләнмәячәкмен!

— А-а! — диделәр аксакаллар беравыздан, котлары алынып.

— Курыкмагыз, ырудашлар,— диде Тотыш би.— Сез исән калырсыз. Минем бу антым өчен... Айтулдыга өйләнмәгән өчен Алмыш хан сезгә бармак белән дә чиртмәс. Акбүре ыруына бернинди талау кылмәс. Мин, ырудашлар... аксакаллар... үз теләгем белән биләкне үги атам, үги агам Котанга тапшырам.

— А-а! — диделәр тагын да аксакаллар, утырган урыннарында кузгалышып.

— Айтулдыга Котан би өйләнер, тарханлык ярлыгын да ул алыр... хан бирсә, билгеле. Бу минем боерыгым... соңгы боерыгым.

Ул, башка берни әйтмичә, Багдад тегүчесе теккән бай тунын, алтын-көмешле киң билбавын, башындагы биек, очлы бүреген салып, үги атасына тоттырды. Шуннан соң үзенең билен таррак, төссезрәк икенче бер каеш белән буды да, кылычын, бөктәсен җайлады да, яланбаш көе ырудашлары янынннан чыгып китте.

Алмыш хан каршында Тотыш би тарханлык ярлыгын йомарлап ыргыткач, ал тамгалы күн кисәге Котанның аяк астына туры килде. Котан шундый зур ирек, байлык бирә торган әлеге күн кисәген, киек тоткан ерткыч кебек, шундук эләктереп алды, шундук тун җиңе эченә

яшерде. Ыгы-зыгы арасында аны беркем күрмәде. Инде менә аның кулына бай кием-салым, билбау, бүрек тоттырып чыгып киттеләр. Ыруның аксакаллары алдында аны, субашы Котанны би ясадылар!

Аның күз аллары әлҗе-мәлҗе килде, буыннары камыр кебек йомшап калды. Аның авызы үзеннән-үзе ерыла башлады. Ул, тыела алмыйча, көлеп үк җибәрде, кулындагы алтын-көмешле бай киемнәргә — билек билгеләренә исе китеп карап торды да аннары ырудашларына күтәрелеп карады, бала-чага сыман:

— Киим микән? — дип куйды.

— Ки, ки! — диде аксакалларның берсе.— Үзе салгач, ки!

— Башкача булмас, ахрысы,— диде Майчан аксакал да, пошынып.

Майчан аксакал ыруда белекле, турылыклы карт санала иде. Яшь егетнең сүзләре аның күңелен шактый яралады, шулай да ул аңа ачулана алмады. Киресенчә, ул үзен аның алдында уңайсыз сизә иде, ахрысы.

— Үзе теләмәгәч, кхм...— диде ул, Котанга туры карамыйча.— Яшь шул, яшь. Яраткан, берни эшләп булмый. Яратудан да зур көч юк ажунда, оланнар. Без дә уйламыйчарак сөйләндек, кхм... Бераз тынычлансын, ашыкмыйк әле булмаса.

— Юк, юк, билекне Котанга тапшырабыз!

— Котанга, Котанга!

— Тотышның авызыннан ана сөте кипмәгән. Би андый булмый! — диделәр аксакалларның күпчелеге, ачулы шаулашып.

Котан үзенең киемнәрен салып ташлады да, берәрсе тартып ала күрмәсен, дигән сыман, кабаланып-калтыранып, би киемнәрен кияргә тотынды. Ырудашлары сүзсез генә аны күзәтеп тордылар. Киемнәр яңа бигә бераз гына киңрәк, иркенрәк иде, шулай да бик килешле иде. Субашы Котан күз алдында үзгәреп китте.

— Котан — би! Сез мине... чынлапмы? Беравызданмы? Антмы? — дип сөйләнде каушап калган Котан би, як-ягына каранып.

— Чынлап, чынлап! Ант, ант! — диделәр ырудашлары, аны тынычландырып.

— Хи-хи... ышанычыгызны аклармын. Бай булыгыз, сау булыгыз. Тәңре... алла сезгә мең яшь бирсен! Хи-хи!

Куанычыннан тынычлыгын җуйган би ул көнне үзен исерек кебек тойды. Аның үзен чыннан да би итеп, көчле итеп күрсәтәсе килде, бу турыда аның барлык кешеләргә, барлык Болгар йортка белдерәсе килде. Шул ук мәлдә аның күңеленә: «Тотыш углан сүзен кире алса?» — дигән бер куркыныч уй да килде. Бу аны бик каты кайгыга салды. Тыелгысыз куаныч каядыр юк булды. Билектән чын-чынлап колак каккан кебек, яңа бинең чын-чынлап йөрәге яна башлады. Аксакаллар ант итү белән генә чын би түгел ич әле ул! Би итеп аны ыру башы танырга, корылтай танырга тиеш. Аннары Алмыш хан да аңа Айтулдыны бирәме, юкмы әле, ярлыгын таныймы, юкмы әле. Әйе, нишләргә уйлый Тотыш билектән баш тартып? Кире ыруга кайтачакмы, монда торып калачакмы ул? Ыруга кайтса, аның белән беркемгә тынгы булмаячак. Анасы Койтым бикә барыбер аның яклы булачак. Шулай булгач, димәк... шулай булгач...

Шулай! Монда Утташ кам кебек эшләргә ярамый. Монда уйлап, киңәшеп эшләргә кирәк.

Котан би үзенең уйларын башкаларга да сөйләп бирде: без аннан беркайчан да игелек күрмәдек, моннан соң да күрмәбез, диде. Аны нидер эшләтергә кирәк. Нишләтергә — үземнең генә башым җитми — сез ни әйтсәгез, мин шуңа килешермен, диде.

Аксакалларга яна бинең сүзләре төпле тоелды. Әй, Тотышны ырудан куарга, я булмаса бөтенләй юкка чыгарырга кирәк. Тик менә шунысы куркыта: ыру башының углын юкка чыгару алай бик җиңел эш түгел шул. Углы белән икесен бергә йолкып атар идең, кемне куярга ыру башы итеп? Шул ук Котан бине, Акбоганымы? Монысы инде бөтенләй ярамаган нәрсә булачак. Ана корт көчле булса, корт күче дә көчле була. Ыруның анасы көчле. Аңа тияргә ярамый, тисәң, ыру таркалачак. Шулай ук Тотышны да исән калдырырга ярамый — алай да ыру таркалачак. Таркалмаса да, яңадан башбаштаклык китәчәк.

Акбүренең илчеләре, аксакаллары шулайрак уй йөрттеләр. Шулай да беркемнең дә тотып кына: аны шулай итәргә, болай итәргә кирәк дип әйтергә теле бармады. Би киемнәрен кисә дә, билек тә, көч тә Котанда түгел, Тотышта иде.

— Ике көн үтсен, ханга үзенең соңгы сүзен әйтсен,— диде Майчан аксакал үзенең аптырашкан ырудашларына.

— Юк! — диде Котан би, каршы төшеп.— Ике көн узгач соң була. Сез миңа ант иттегез, инде кирегә чабасызмы? Тотыш ике тәүлек эчендә юк булырга тиеш. Хан катына ул түгел, мин барачакмын!

Котан би беренче тапкыр ныклык күрсәтте, ырудашлар да яна биненң яңача сөйләшүен сизми калмадылар. Бу аларга ошады да, ошамады да. Алар күнделәр. Тотыш угланны юк итүне ырудашлар үги атаның үзенә тапшырдылар.

Үги ата үзе берни уйлап таба алмады. Караңгы төшкәч ул базар башы Бигеш янына китте. Аңа ул үзенең үтенечен сөйләп бирде. Төрле кеше белән эш итеп шомарып беткән Бигеш, эре тешләрен ыржайтып, ат кешнәгәндәй көлеп куйды.

— Аннан да җиңел эш юк,— диде.— Калымга алып килгән байлыгыңның яртысын бирсәң...

Котан би ык-мык итте.

— Алайса, бөтенләй бирерсең! — диде Бигеш, зур корсагын тотып көлә-көлә.

— Күбрәк. Аның башы аңа торырлык түгел,— диде үги ата.

— Аның башы синеке ишеләрнең меңенә тора! — диде Бигеш, күрәләтә мыскыл белән.

Кеше киеме киеп кенә би булган субашы Котан, агарынып, бөктәсенә тотынды.

— Тсс! — диде Бигеш, бармак янап, бала-чаганы тыйган сыман.— Юкса менә моннан типкәләп чыгарырмын да ханга барып әйтермен, барлык байлыгыңны басып калырмын. Тотыштан котылмакчы булалар! Кара син аларны! Тотышны бөтен Болгар белә. Тотышны бөтен Болгар ярата. Тотыш углан Алмыш ханның иң көчле, иң күркәм алыбы, беләсең килсә. Суарларны Тотыш тез чүктерде, ягыларның котын алды. Алмыш ханга ул әйткән сүзләрне син әйткән булсаң, бүген сине каргалар чукыган булырые. Синең ише тавык башларның меңе түгел, ун меңе дә Тотыш алып башына тормый!

Котан би тирләп чыкты. Бу куркыныч, юан кешегә күтәрелеп карарга да батырчылыгы җитмичә, ул урынында таптанып тик торды. Куркудан озак кына аның авызы ачылмады.

— Калым миңа кирәк булачак,— диде ул бераздан, исенә килә башлап.— Калымны мин ханга бирәчәкмен.

— Хан сиңа ни бирер? — диде Бигеш, тычкан күзен кысып.

— Айтулдыны...

— Айтулдыны?! — дип кычкырды Бигеш.— Айтулдыны ул сиңа

түгел, Тотышка бирмәкче була! Син соң кем — танымый тораммыни соң әле мин сине?

— Житте! — диде би, барлык батырлыгын жыеп.

— Я, килештекме? — диде Бигеш, Котан бинең изүеннән эләктереп алып.

— Килештек,— диде үги ата.— Калымның яртысы... Тик анда бүләккә дигәннәре дә бар.

— Нәрсә? — диде Бигеш, Котан бине кабып йотардай булып.— Мин берни белмим. Минем таварлыктагы байлыгымның яртысы — минеке. Калымны, бүләкме, минем өчен барыбер.

Котан би, авызын ачып, лып иттереп артына утырды. Нинди кеше бу?! Нинди оятсыз бу?!

Шундый көчсез, таркау күренгән юан, симез кеше, бине кинәт якасыннан эләктереп алды да, ишеккә таба төрткәләп:

— Әнә бара юлың! — диде.— Кеше үтерүчеләр! Иртәгә байлыгыңнан гына түгел, башыңнан да колак кагарсың әле!

— Ярар, килештек. Барлык байлыкның яртысы сиңа,— диде Котан би, маңгай тирләрен сөртеп.

## VI

Караңгыда песи кебек сак кына атлап Бигеш акбүреләр «урада»сына килде. Тотышның тирмәсе аерым утыра иде. Бигеш ишек бавын тарткалады да, эчтән тавыш килгәч, ишекне ачты. Тирмәдә бөтенләй дип әйтерлек караңгы иде. Учактагы кузлар сүнә язып, көл белән капланган иде. Шулай да көл катламы аша кызгылт ут жемелди иде. Шуңа күрә тирмә эчен әзме-күпме шәйләргә дә була иде.

— Тотыш, йоклыйсыңмы? — диде Бигеш, тамак кырып.

— Йокламыйм,— диде урында яткан кеше ачык бер тавыш белән.— Бу кем? Бигешме? Әйдә, түрдән уз.

Ул урыныннан торды, учактагы утны көйрәтеп жибәрде. Бигеш тә учак янынарак килде. Икесе дә, аякларын бөкләп, киез өстенә утырдылар.

— Төнлә борчуым өчен ачуланма,— диде Бигеш, кайгылы йөз белән сүзгә башлап.— Мин барысын да ишеттем. Менә кайгыңны уртаклашырга килдем.

— Бүген генә ишеттеңмени? — диде Тотыш, базар башының жирәнгеч-ягымлы йөзенә карап алып.

— Соңгысын — бүген генә,— диде Бигеш, авызын очлайтып.— Мин аны да әйтмим... Хан янында булган күңелсезлекне әйтәм.

— Һы,— дип куйды Тотыш коры гына.— Аның өчен мин кайгырмыйм. Үкенмим дә. Мин бернәрсәгә үкенмим. Төн уртасында килгәнсең икән монда, юкка түгелдер. Турысын гына әйтә алмассыңмы?

Аның күз карашы очлы, үткен иде. Ул чамадан тыш тыныч. Үз-үзен ул чамадан тыш иркен, ышанычлы тота. Аның тавышы корыч тимер чыңыдай чыңлап, яңгырап чыга. Элеккедән дә кырысрак, ныграк, усалрак алыпны күреп Бигеш, кирәкле сүзен башлый алмыйча, чак-чак кына төртелгәндәй итеп торды.

— Турысын гына әйткәндә,— диде ул, иреннәрен бөрештереп,— мин сиңа изгелек эшләмәкче булып килдем, сине коткармакчы булып...

— Кемнән, нәрсәдән?

— Үлемнән, Тотыш алып,— диде Бигеш, көрсенеп.— Хан ярлыгын ташлап син бер ялгышкансың, билегенне ташлап ике ялгышкансың. Ике ялгышың өчен дә сине үлем көтә. Менә мин сине шул ике үлемнән коткармакчы булып килдем дә!

Бигеш, нидер көткән сыман, тынып калды. Тотыш аның сөйләвен көтте. Базар башы, тычкан күзен челт-мелт йомгалап, аның йөзенә карап утыруында булды. Тотыш аңлап алды, куеныннан калтасын чыгарды да, юан, комсыз кеше алдына ташлады. Калтадагы көмеш акчалар, шыңшыган сыман, тонык кына чыңлап куйдылар. Бигеш берьюлы ачылып китте.

— Мин сине бик яхшы беләм, Тотыш алып,— диде ул, шундук сүзгә башлап.— Мин сиңа булышмакчы булам. Син инде би түгел. Хан, теләсә дә, теләмәсә дә, сиңа инде Айтулдыны бирә алмаячак. Шулай булгач, ике тәүлектән, юк, тәүлек ярымнан ул сине тотып алып ябып куячак. Билегеңнән баш тартып син үги атаңны көчәйттең. Ул сине бүген таңда...

— Бүген таңда?! — диде Тотыш, чак-чак кына кашларын җыерып.— Мин аның үзен таң атканчы!..

— Юк, юк! — диде Бигеш, кулын селтәп.— Алай булмый! Берүк аны уйлама. Үз утарымда, үз җиремдә мин кеше каны коелуын теләмим. Миңа читтән кеше күп килә. Бер яманатың чыкса, борылып та карамаячаклар. Алай-болай син ялгышлык эшләсәң, ул чагында мин үзем сине ханга тотып бирергә тиеш булачакмын. Синең ырудашларына да мин шулай дидем: минем җиремдә кеше каны коярга ярамый, дидем. Алар сине, Тотыш алып...— диде ул, тавышын әкренәйтеп,— алар сине яргуламакчы булалар. Аксакаллар барысы бер сүздә. Син аларның да кытыгына кагылгансың, яман сүзләр әйткәнсең.

Тотыш, йөрәгенә чыдый алмыйча, сикереп урыныннан торды, киенә башлады. Бигеш тә аягына басты.

— Син кая барасың? — диде ул, Тотышның юлына аркылы төшеп.

— Мин аларны!..— диде Тотыш, тешләрен шыгырдатып.

— Син тагын өченче ялгыш ясамакчы буласыңмы? — диде Бигеш, кызу канлы егетнең беләгеннән тотып алып.— Мин барында син ул ялгышны эшләмәячәксең! Сиңа котылу юлы бер генә — син качарга тиеш!

— Ничек итеп? — диде Тотыш.

— Үзем булышырмын,— диде Бигеш.— Шуның өчен дә килдем... булышырга, коткарырга.

— Койма аша чыгу угрылык санала,— диде Тотыш.— Димәк, син мине капкадан чыгарачаксың? Таң атмыйча капка ачылырга тиеш түгел. Шулай булгач...

— Син капкадан да чыкмассың, койма аша да чыкмассың,— диде базар башы.— Мин синең янга үземнең кешене җибәрермен. Ул сиңа каян чыгарга икәнен күрсәтер. Онытма: мин берни белмәдем, күрмәдем! Син койма артына чыккач та мин берни белмим, берни күрмим! Кая китәсең килә, шунда китәрсең — анда синең ирек.

Бигеш, үз сүзен әйткәч тә, тизрәк чыгып китү ягын карады. Үз тирмәсендә Тотыш бер үзе генә торып калды. Бик азга гына кабынып киткән ярсу шундук юкка чыкты. Аны тагын да ниндидер торгынлык, искитмәүчәнлек биләп алды. Ул әле үзенең иң зур кайгысыннан арына алмаган иде, арыну түгел — ул әле үзенең буталган уйларын-теләкләрен җайга да сала алмаган иде. Ул әле үзенең киләчәктә нишләргә тиешлеген бөтенләй белми иде. Бигеш килеп аның күзен ачты.

Чыннан да, нишләргә, ни кылырга, кая барырга тиеш соң ул? Алмыш ханнан ярлыкау үтенергәме? Ул ярлыкаган очракта да, кем булыр иде икән соң ул? Ул инде би дә түгел, тотык та түгел. Кем соң ул? Йолкыш, сукбай? Алмыш хан ап-ачык итеп әйтте түгелмени: йол-

кышка мин кызымны бирмим дип? Билекне кире сорап алыргамы? Кулдан очкан кошны инде ничек тотып алмак кирәк! Әйе, аның инде берние юк: киеме дә, калтасы да, калымы да... ярлыгы да! Кылычыннан башка, бөктәсеннән башка аның кулында берние юк. Аңа инде беркем буйсынмый, аны инде беркем тыңламый. Шулай ук хан да тыңламас. Үзенә күпме җирләр-сулар яулап алган, үзенә күпме байлык алып кайткан Тотыш алыпны инде ул да тыңламас. Атлас тун, ак бүрек, алтынлы киң билбау ажундагы бар нәрсәдән көчлерәк. Менә ул йола!

Күрәсең, җирәнгеч кеше ялганламыйдыр. Шулай булгач, тагын качаргамыни? Кая? Ырудашлар сине читкә типкәч, кая булса да барыбер түгелмени? Шулай итеп, үги ата, үги агай үч алмакчы була... Булыр. Базар башы ялганламый, ахрысы. Көч анда, үги агайда. Көчсез кеше көчкә ия булса, иң беренче эше — үч алу.

Димәк, барысы да бетте. Бетсен. Аппак булмагач, сөю, ярату булмагач, бетсен. Шулай да үләсе килми. Үләргә әле иртә!

Бигешнең кешесе озак көттермәде. Нишләптер үсми калган, кыска гына буйлы, аксак, өтәләнгән кеше артыннан Тотыш, кылычын җайлап тоткан килеш, сак кына атлап тышка чыкты.

Тышта караңгы иде. Күктә берән-сәрән йолдызлар җемелдәшә, капка ягына кызгылт яктылык чайкала — учак яна иде. Өйдән чыккач та Тотыш, күзе иләшсен өчен, беравык туктап торды, ырудашлары йоклый торган тирмә ягына карап алды. Анда шылт иткән тавыш та ишетелми иде. Анда гына түгел, бөтен угарда, бөтен тирә-якта тирән, караңгы тынлык саклана иде.

Шулай күпмедер тыңлап, карангалап торгач, ул кечкенә кешенең иңбашына орынып алды. Кеше еракта караеп күренгән коймага таба кузгалып китте. Койма янына килеп җиткәч, Тотышның нишләптер күңеле тырнала башлады. Әллә ничек кисәк кенә булды бу. Ныклап уйламыйча... «Нәрсәсен уйлыйсың инде?» — диде ул шундук, үз-үзенә каршы килеп.

— Менә бу яркак кузгала. Читкә этәсең дә... Тышта — урман...— дип пышылдады кечкенә кеше.

— Башта син үзең! — диде Тотыш аңа.

Кеше карышмады, кузгала торган ярканы көчәнеп читкә этәрде дә, кысылыштырып икенче якка чыкты. Аның артыннан Тотыш та чыкты. Койма тышында ул тиз генә як-ягына каранып алды, калтасында торып калган ике ярмакның берсен кылавызның[1] учына салды:

— Бай бул,— диде.

— Бай бул, Тот-тыш,— диде кылавыз, этенеп.

Ул бизгәк тоткандагы кебек калтырана башлады. Тотыш аны-моны абайлап өлгергәнче, ул кире утар ягына кереп юк та булды. Шул чакны аның койма артында, яркакны үз урынына җайлап куймакчы булып, нидер эшләгәне ишетелде. Агачка агач тиеп шакылдаган тавыш төнге тынлыкта куркыныч булып яңгырады. Шул ук мәлдә, Тотышның колак төбендә генә диярлек, койма өстеннән калкып торган биек сыргаң башыннан төнге каравылчының:

— Кем ул анда? — дигән йокылы тавышы ишетелеп китте.

Бөтен койма өсте, бөтен тирә-як берьюлы кыймылдашып куйды. Әле анда, әле монда: «Тотыгыз, тот!» — дигән сүзләр яңгырады. Ул да булмады, баш очыннан гына нидер сызгырып үтте, шык итеп каты җиргә ук килеп төште. Сызгырып үткән, шык та шык иткән тавышлар күбәйгәннән-күбәя барды. Шул ук мәлдә дип әйтерлек, ур артында караңгыда ашыгып, ябырылып килүче җәяүле карачкылар күренде.

---

[1] Кылавыз — юл күрсәтүче.

Димәк, барысы да алдан уйланылган булган! Ах, ялганчы! Ах, эттән туган симез үләксә!

Тотыш өчен билгесезлек, торгынлык юкка чыкты. Бөтен нәрсә, ачыкланып, үз урынына утырды. Алда — ягы. Димәк, орышырга кирәк, үз-үзеңне сакларга кирәк!

Ул койма буйлап йөгерә башлады. Койма өстендәге каравыл өйләренең ничек корылганын ул бик яхшы белә иде — өстән аткан уклар аңа тимәячәк. Аның өчен иң куркынычы — каршыга килүче җәяүле каравылчылар иде. Янында гына ышанычлы калкан — биек койма булуы аны тынычландыра төште. Ул аек баш белән бөтенесен күз алдыннан кичереп алды.

Төнге сакчылар, ашык-пошык кыланып, койманың әлерәк кенә Тотыш чыккан турысына атуларында булдылар. Урман ягыннан килеп чыккан карачкылар да, шаулап, ук ата-ата, шул турыга якынлаштылар. Караңгы коймага сыена-сыена болын ягына, Әтил ягына йөгергән кешене алар абайламыйчарак калдылар, ахрысы.

Тотыш койма буенча йөгерүендә булды. Тавышларның артта кала баруы аның күңелен тынычландыра төште. Шулай ук котылды микәнни? Шулай җиңел генә... Туктале, бу урны ничек чыгарга соң? Алда тагын сакчылар юк микән?

Ул шулай дип уйларга да өлгермәде, койма почмагында, ачыграк җирдә төркемләшеп торган өч-дүрт сакчы өстенә килеп чыкты.

Койма почмагында тирән ур аша тар гына күпер салынган иде. Сакчылар әлеге шул тар гына күпердә басып торалар. Аларның берсе сөңге белән, икенчесе кылыч, өченчесе ук-җәя белән коралланган Әйе, монда барысы да алдан уйлап эшләнелгән иде. Бу инде сиңа Ямгырчы би тәбесе түгел — монда сине коткарырга Тәңкә юк иде!

Тотыш эсселе-суыклы булып китте. Арттан да, алдан да, уңнан да, сулдан да аңа бернинди котылу юлы юк. Берәр ничек кош булып күккә очса да, барыбер аны ук белән атып төшерерләр иде. Бары җир убылса гына...

Ярның якасына килеп җиткән алып ярсып кинәт бар көченә кычкырып җибәрде. Кычкырып җибәрде дә, котырынган барыс кебек, карачкылар өстенә ташланды.

Алар да, ахрысы, аның коймага ышыклана-ышыклана килүен сизмичәрәк калдылар. Алар да, ахрысы, аны әле булса шау-шу ишетелгән төштә дип уйладылар. Әллә соң алар аның ныклап торып якынлашуын көттеләр микән, я булмаса, аны тере килеш алмакчы булдылар микән?

Ни генә булмасын, алар өчен бу тамак ярып кычкыру бөтенләй көтелмәгәндә яңгырап китте. Базар башы Бигешнең яу күрмәгән, орыш күрмәгән тук, симез сакчылары каушап калдылар. Шулай да берсе сөңгесен ыргытты — сөңге коймага кадалды. Укчы ук атты — угы каядыр ур төбенә барып төште. Сакчылар яңадан коралларына тотынганчы, Тотыш аларның каршысына барып та басты, каты селтәнеп, кылычы белән берсенең аякларын чабып өзде, икенчесен күпердән төртеп төшерде дә, качып киткән өченчесен куа-куа, болын ягына ыргылды.

Аның артыннан уклар очты, куркынган өзек-өзек тавышлар ишетелде. Өченче сакчы да ерак кача алмады — урталай чабылып җиргә ятып калды. Тотыш, алдын-артын карамыйча, тигез җирдән ерактагы ниндидер киртәләргә, каралтыларга карап йөгерде. Аны инде берни дә куып җитәрлек түгел иде.

Ул, ниндидер каралтыларга сыенып, кача-поса, бертуктамый чабуында булды. Менә каралтылар, киртәләр дә артта калды, ул тагын иркен, буш җиргә килеп чыкты. Монда кипкән сазлык иде, ахрысы,—

аяк астында ниндидер түмгәкләр, агач кисәкләре калкып чыкты. Бер-ике тапкыр ул егылып алды. Егылганда ул артына карарга да өлгерде. Сыеклана башлаган караңгылыкта, Бигеш утары ягында ул болын өстенә сибелгән бик күп карачкылар күрде. Алар, ахрысы, аны куа киләләр иде.

Ул уңга — Ага-базарның ярга якынрак урнашкан тирмәләре, чатырлары, агач өйләре арасына борылды. Монда аңа беркем очрамады. Бөтен яр буе таң алды йокысына чумган иде.

Таң беленә башлаганда ул, Ага-базарны артта калдырып, Этилнең буш, аулак яр буена килеп житте. Бу тирәдә аста да, өстә дә беркем күренми иде. Монда тыныч, искиткеч тыныч иде. Ул бөтенләй туктап калды, курыкмыйча артына борылып карады: куа килүчеләр инде күренми иде.

Ул текә ярдан шуышып аска төште, чабыш аты кебек тиз генә туктый алмыйча, яр буеннан җиңелчә генә йөгереп барды да барды. Ул берничек тә туктый алмады. Ул туктарга тиеш түгел иде. Ул ничек тә бу төштән, бу җирдән ераграк китәргә тиеш иде. Ул ничек тә котылырга, исән калырга тиеш иде.

Әле комлыктан, әле ташлыктан сикереп атлый-атлый ул шулай туктаусыз йөгерүендә булды. Аның яныннан гына, аның аяк астында гына пышылдап, тирбәлеп-чайкалып Этил йөгерде. Алар, әйтерсең, бер-берсен узарга тырыштылар.

Юк, алар узышмадылар. Бөек, тирән, көчле Этилне ничек узмак кирәк?! Ул бары Этилдән калышмаска гына тырышты. Ул аңа иярергә, аның җаена ятарга гына тырышты.

Этил исә акты да акты. Менә шулай ул көн-төн ага, еллар, йөз еллар, мең еллар ага. Кешеләрнең орышында, үлемендә, кайгысында аның уе да юк. Сөяләрме алар, сөймиләрме, елыйлармы, көләләрме — уйламый да, үз көенчә ага да ага. Ул шундый тыныч, ул шундый олы!

Ах, булыргае Этил кебек көчле, Этил кебек олуг! Булыргае Этил кебек житез, күрергәе ерактагы сөйгәнеңне! Җитәргәе Итил торасына, сөйләргәе аңа йөрәк сагышыңны, моңнарыңны, кайгыларны!

Бөек Этил, туган Этил, күрдеңме син бүген мине? Мин тагын да бер үлемнән... мең үлемнән исән калдым. Аңлыйсыңмы, беләсеңме шуны: сөеклемнән аерылып калдым... Мин кайгылы, мин сагышлы... Мин тагын да мең үлемнән исән калдым. Җиткер шуны минем сөйгәнемә, тиңсез Этил, бөек үзән! Җиткер аңа минем уйларымны, җиткер аңа кайнар каным катыш аккан тозлы яшьләремне!

Туган Этилгә кайгыларын, әрнүләрен сөйләп ул яр читеннән барды да барды.

## VIII

Якында, яр өстендә тояк тавышлары ишетеп ул кисәк кенә туктап калды, башын калкытты. Артта, текә яр читендә, сындай катып, атлы җайдак тора иде. Ул, ахрысы, Этил өстен, яр буйларын күзәтә. Ул, билгеле, аны күрмәкче булып карана иде!

Әйе, әйе, кораллы ир-атлар бөтен Этил буен бетереп аны эзлиләр! Әнә якында гына ачулы ирләр тавышы ишетелде, ат авызлыгы чыңлады...

Ул ачыккан иде, арыган, йончылган иде. Аның инде беркем белән орышасы да, сугышасы да килми. Аның бары менә шулай дәү Этил белән житәкләшеп, серләшеп-сөйләшеп бертуктаусыз барасы да барасы килә.

— Үлеме, тереме — табарга! — диде баш өстендәге ачулы кеше, кемгәдер аңлатып.— Боерык шундый!

Каландырук! Алмыш ханның бурзае... Ышанычлы сакчысы, шымчысы, кан эчкече.

— Тирә-якны айкап чыктык,— диде чәрелдәп яшь бер ир.— Юк булгач, юк! Тамгадагы каекларны карадык, Ага-базарның астын өскә китердек.

— Ул Әтил ягына киткән. Күреп торганнар,— диде Каландырук.— Теге якка гына таймаса, ул бу якта булырга тиеш. Тагын бер карап чыгыгыз. Алай да табылмаса, яр буена ут төртәбез! Мин аны табарга тиешмен, мин аның канлы башынмы, янган сөякләренме, Алмыш ханга илтеп тоттырырга тиешмен. Боерык шундый. Андый качаклар Болгарга талау китерә. Корыч-Тимер өчен әләгә язды инде. Монысын да ычкындырсак, эләкми калмас.

Шулай кычкырышып алар китеп бардылар.

Ул кар-янгыр сулары ерган ниндидер тар гына ур-чокыр турысында туктап тора иде. Чокырның тирә-ягын юкә, чикләвек куаклары каплап алган иде. Әйе, алар аны күрми китеп бардылар.

Агач ботакларын селкетмәскә, кыштырдатмаска тырышып, саклаunion кына ул яңадан кузгалып китте, комлы яр читенә төште. Коткарса аны бары Әтил генә коткара алыр, ахрысы. Төпсез Әтил, иксез-чиксез, тынгысыз Әтил... Тәңредән дә, алладан да бөегрәк Әтил генә коткара алыр, ахрысы, аны.

Яр буе шәп-шәрә, ап-ачык. Тотынып йөзәрдәй берни күренми иде.

Бер кулына йөрәген, икенче кулына кылычын кысып тоткан килеш, ул Әтил белән, дулкыннар белән янәшә атлап барды да барды. Көтмәгәндә ул ауган агач өстенә барып чыкты. Су буенча агып килә-килә, бәрелә-сугыла шомарып, муртаеп беткән үле агач аның юлына аркылы төшеп ята иде. Колач житмәслек юан, озын бер тирәк иде бу. Яртылаш ул комга баткан, яртылаш жир өстеннән күтәрелеп калган иде. Бер кеше түгел, ун кеше дә, йөз кеше дә кузгатырлык түгел иде аны!

Шулай да аны кузгатырга, суга төшерергә кирәк иде. Шушы иләмсез зур, юан, авыр тирәктән башка тирә-якта берни юк иде.

Олуг Әтил чыгарып ташлаган олуг тирәк аңа юлдаш булды. Үле тирәк аны үлемнән коткарды.

Ул өс киемнәрен, коралларын бер жиргә салып куйды да башындагы алпагын кулына алды. Алпакны чүмеч кебек итеп яр читеннән — су янынннан агачка таба ермак казырга тотынды. Алпагы белән каерып авыр, юеш комны алды да читкә ташлады, алды да читкә ташлады. Ермакны ул бер колач киңлегендә итеп, тирән итеп казыды. Ул казыган ермакка су тула барды. Соңга таба сулы комны жиңел генә ишеп төшерде. Уйлаган уенның барып чыгачагына нык ышанып, сөенеп ул баш калкытмый эшләде. Ул, аз гына да туктап тормыйча, аз гына да ял итмичә эшләде — куллары арыса, комны аяклары белән ните, аяклары арыса, куллары белән ните. Ул баш калкытмый эшләде. Үле тирәккә ул кот бирде, көч бирде.

Каландырук чакырткан ике йөз кешелек яңа алай Ага-базар ягындагы болынга таралып, барлык чокыр-чакырларны, куакларны, камыш-түмгәк араларын тоташтан айкап килә башлаганда, ерактa, яр өстендә киек аулаучы сунарчылар сыман һай-һулап кычкырган куркыныч тавышлар яңадан ишетелә башлаганда, ул мең батманлык муртайган агачны ермактагы су өстеннән Әтилгә этеп чыгара алды. Тирәкнең нечкә башына, киселгән ботак янына ул үзенең киемнәрен, коралларын бәйләде. Үзе, анадан тума шәрә калып, ике кулы белән дә агачка тотынып, кыйгачлап, агым белән йөзеп китте.

Көзге су инде суынган иде. Балалар да, өлкәннәр дә бу көннәрдә су керүдән туктаганнар иде. Тотыш суның суыклыгын бөтенләй диярлек

сизмәде. Ул, әйтерсең, суны тоймады да. Ул бары үзенең ярдан тизрәк читләшергә, елга уртасына чыгарга, аннары каядыр еракка, икенче якка барып җитәргә тиешлеген генә аңлады. Инде ул үзе калдырып киткән ярга да борылып карамады, ул яктагы тавышларга да колак салмады. Якында гына аларның каеклары да, көймәләре дә юк. Яр буйлап куа килүләре дә ишетелми. Алар әле булса өстә, болында — куаклар, чокыр-чакырлар арасында кычкырыналар иде бугай.

Туган Этил! Олуг Этил! Агыз тизрәк! Коткар мине ягылардан! Исендәме, күптән түгел калан бирдем мин сиңарга? Ачуланма миңа, үпкәләмә миңа. Алып чык син мине дулкынында ирек ярына.

Тәңрем! Баш тартып мин синнән бик языклы булдым. Акбүренең изге ияләре, сезне онытып мин игелексез булдым. Туган җирем, туганыру! Изге анам Койтым бикә! Кичерегез, ярлыкагыз мине. Миңа сезнең каргыш төште. Ана кендегеннән аерылган бала кебек, мин дә аерылдым сездән. Кичерегез, ярлыкагыз мине! Мин сезнеке түгел инде. Мин бер ялгыз. Мин — йорт-җирсез, мин — ырусыз, мин — тәңресез. Беркемем юк минем. Мине Этил алып китте, аерып китте. Сау булыгыз, бай булыгыз, туган җирем, туган илем!

Тик шулай да минем кендек өзелмәгән сездән. Минем күнел аерылмаган сездән. Ерагая барган саен, минем арттан сез киләсез, туган җирем, олуг Чулман, изге анам Койтым бикә!

Кичерегез, ярлыкагыз мине!

Тиңсез Этил! Илт син мине каган торасына, илт син мине сөйгәнемнең канлы-яшьле эзе буйлап. Мин табарга тиеш аны, мин күрергә тиеш аны.

Мин барыбер йоларга тиеш үземә дигән өлешемне — Аппагымны!

Каландырукның кешеләре ал-ял белми аны эзләделәр. Яр буйларын, якындагы урманнары, чокыр-чакыр араларын — барлык шикле урыннарны тентеп, актарып йөрделәр. Алмыш ханга ярарга теләп, Каландыруктан бигрәк Котан би тырышты. Ул үзенең барлык ирләрен үги угылын, үги энесен эзләргә җибәрде. Базар башы Бигеш кайгысыннан кара күмер кебек янды. Тотыш аны утыртты төп башына! Бөлдерде, акыртып талады! Өч сакчысы юкка чыкты. Чит ил сатучылары курыкышып юлга җыена башладылар. Ага-базарда сату-алу бозылды. Шуның өстәвенә, аның якасыннан алып, хан әйтте: Тотыш алып табылмаса, мин синең барлык байлыгыңны тартып алам, үзеңне утлы табага бастырам! — диде.

Каландырукка хан әйтте: тапсаң, мин сине субашы ясыйм, диде.

Котан бигә хан әйтте: тапсаң, мин сине киявем итәм, диде.

Шуңа күрә дә алар кара тиргә батып, телләрен салындырып, бөтен җирдән аны эзләделәр.

Ул, юан, кара агачка тотынып, агымга кыйгачлый-кыйгачлый, елга уртасына таба йөзде дә йөзде. Этил уртасыннан агып барган ташландык агачны күрмәделәр түгел — күрделәр. Тик шул агачка тотынып, муеныннан көзге салкын суга чумып, Тотыш йөзеп барадыр, дип уйларга беркемнең дә башына килмәде. Әзмени суда агып барган ялгыз агач! Аны суда никтер барысы да көймәгә, улакка утырган килеш күрергә телиләр иде. Яр буенда ул казыган ермакны да күрмәделәр түгел — күрделәр. Тик алар күргәндә ермакка инде күптән су тулган иде, ком өстендәге эзләр юылган, ермак ярлары тигезләнгән иде. Азмыни яр буенда андый ермаклар!

Ул түбәнгә таба акты да акты. Туган Этил, көчле Этил, иркәләп, тирбәлдереп, яман күзләргә күрсәтмичә аны алып китте. Ага-базар, Каландырук, кораллы ирләр — барысы да бик еракта, артта калды. Инде шактый ара үтелде. Инде икенче якка да чыгарга булыр иде. Тик әлегә аның чыгасы килмәде. Бу тирәдә уң якта да аны ханга тотып бирүләре бар иде.

Ул арада көн дә кичегә башлады. Су өстеннән салкынча җил исәргә тотынды. Тотыш агачка йөзтүбән капланып бара иде. Ул туңа башлады. «Ярга чыкмый булмас», дип уйлады ул. Текә яр башындагы кечкенә авылдан, таш кыя астына посып утырган ялгыз алачыктан башка бу тирәдә кеше-кара булуы турында сөйли торган берни күренми иде. Ул кечкенә авылны да, ялгыз куышны да узып китәргә булды.

Җил арттан исә иде, шуңа күрә агачны ярга таба алып баруы аңа бик үк авыр булмады. Шулай да ул күңеленнән чамалаган төштән шактый еракка барып чыкты. Су эчкән, муртайган авыр агач, яр читендәге вак ташларга килеп төртелү белән, ул суга басты, коры җиргә чыкты. Шуннан соң ул агачка бәйләнгән коры киемнәрен чишеп алды, тирәкнең нечкәрәк башын коры җиргә тартып куйды. Агачның әле кирәге булуы бар иде, аны әле кулдан ычкындырырга ярамый иде.

Ул коры киемнәрен киде, күнчегендәге ку белән чакма ташын, тун якасына эләктерелгән кармагын капшап карады. Барысы да үз урынында иде. Болай булгач, яшәргә була! Тик ул бүгенгә балык каптыру белән булашмаска булды: аяк астындагы коры-сарыларны җыештырды да, беренче эше итеп ут ягып җибәрде. Ут янында аның күңеле күтәрелеп китте. Аңа искиткеч күңелле булып китте.

Утка ул әле бер ягын, әле икенче ягын куйды, җылынды, кибенде. Яр астында ышыкланыр өчен җайлы урын юк иде. Ул куыш ясап тормады. Инде бик нык арыган иде. Баш астына корыган үлән йолыккалап салды да, кылычын, бөктәсен тун астына яшерде дә, җайлап җир өстенә сузылып ятты.

## IX

Бер мәлне ул йокы аралаш үзенең янбашы бик нык җылынганлыгын тоеп, кабаланып аягына торып басты. «Ут капкан, ахрысы», дип уйлады ул, куркып. Күзен ныклап торып ачып җибәргән иде, су өстенә балкып кояш чыккан, көн яктырган... учак сүнгән... якында гына, яр буенда, караеп, ямьле көннең ямен җибәреп, очлы борынлы бик зур каек калкып тора! Арттарак, яр буенда тагын берничә каек күренә...

Якында гына, аның колак төбендә генә тыелып көлгән тавыш ишетелеп китте. Тотыш сискәнеп артына борылды. Аның каршысында биленә таянып, ят бер кара кеше басып тора иде. Ят кешенең ике ягында тагын берничә кеше бар. Аларның кулында үткер кылычлар ялтырап китте.

— Фатих! — диде Тотыш, кара кешене танып алып.

— Тотыш! — диде Фатих, ак тешләрен елтыратып, көтелмәгән бу очрашуга чиксез куанычын белдереп.— Сине анда эзлиләр. Минем арттан куа киләләр. Әйдә, утыр тизрәк. Кунагым булырсың.

— Син... нишләп монда? — диде Тотыш, кораллы ирләргә каранып.

— Мин илемә кайтып барам,— диде гарәп сатучысы.— Синең җирдә — мин кунак, минем каекта — син кунак. Кайда телисең, шунда төшереп калдырам.

Тотыш утырды. Ул утырмыйча булдыра алмады. Ул монда сөенергә дә, сөенмәскә дә белмәде. Чит каекка атлаганда аның йөрәге өзелеп төшкән кебек булды. Ул, нәрсәсендер калдырган сыман, үзе яткан учак ягына соңгы кат күз төшереп алды.

Аңа ашарга, эчәргә китерделәр. Ул бар нәрсәсен онытып ашаганэчкән арада, Фатих ибн Әхмәтнең яр буена туктаган каеклары берәмберәм кузгалып киттеләр дә, Этил уртасына каердылар. Алар түбәнгә, көн ягына карап бардылар.

Гарәп сатучысы Фатих ибн Әхмәт, көн-төн байлык артыннан куса да, алай бик үк ашыгырга да яратмый иде. Ул барысын да уйлап, белеп, үлчәп эшләргә күнеккән. Ел тәүлегенең күбрәк өлешен юлда, чит-

тә үткәрергә туры килгәнгә, ул кайда да үзен өендәге кебек тотуны яхшы дип саный. Намаз укырга кирәкме — кырык эше кырылып ятса да, кичекмичә ул үзенең намазын укый, ашар чак җиттеме, шулай ук, бернигә карамыйча, тамак ялгау ягын карый. Бары тик Болгар җирендә генә, көньякның кайнар кояшы, ком-бураннары белән чагыштырганда, кеше яши алмаслык салкынлык иле булып та, тоташ яшеллеккә күмелгән оҗмах булып та тоелган бу искиткеч бай җирдә ул, үзе дә сизмәстән, иркенләп, туарылып китә торган иде. Монда тормыш талгын гына, ашыкмыйча гына ага иде. Шау-шулы, кызу канлы Багдадлар, Бохара, Сәмәркандлар, Хәрәзем, Кустантиннар, Итил-торалар янында Болгар-торалар, Суарлар, Шураннар яңа гына туган балалар сыман тоела иде. Монда инде ялкауланырга теләмәсәң дә ялкауланырга туры килә иде! Шулай да эчкерсез, беркатлы сабый торалар, эчкерсез, беркатлы кешеләр аңа ныграк ошый иде — аларны алдавы җиңелрәк.

«Сабый» Болгарда гарәп сатучысы бигрәк тә җирне-суны, аеруча шушы Әтилне ярата иде. Үзенең ташкынлыгы белән, ярларының гүзәллеге, суының арыклыгы[1] белән Әтил җир йөзендәге Фатих ибн Әхмәт белгән бер генә елгага да охшамаган иде. Анда, төрек халкындагы кебек, сокландыргыч батырлык та, тыелгысыз кыргыйлык та, төрек кызларыныкы кебек күреп туймаслык күркәмлек тә, тыйнак юашлык та бар. Гарәп базаргагы, су өстеннән искән салкынча җилгә битен куеп, яр читләрендәге кыяларга, кара урманнарга, яшел болыннарга карый-карый, көннәр буена үзенең каегында, борындагы йомшак урынында тын гына утырып барырга ярата иде. Шулай таң калып, исе китеп күпме генә карап бармасын, беркайчан да ул үзендә ялыгу, йончылу шикелле нәрсә тоймый иде. Көнозын талгын гына тирбәлеп йөзгәннән соң ул кичкә таба, яр буенда берәр җайлы, матур урын сайлап туктый да, төнен шунда куна — ашый-эчә, күңел ача иде. Әтил буйлап кайтканда ул бөтен бер ел өчен, киләчәк өчен үзендә яңа көч туплый иде.

Башка елларны шулай иде. Тик бу юлы Фатих ибн Әхмәт ашыгырга кирәк тапты. Каеклар бик кызу бардылар. Алар, караңгы төшү белән, элеккечә ярга борылмадылар, очлы борыннары белән дулкыннарны ярып, туктаусыз алга баруларында булдылар.

Гарәп сатучысы Тотышка юри генә, куркыту өчен генә: сине куа киләләр дип әйтсә дә, бу юри әйтелгән сүз аның үзенә бераздан чын булып тоела башлады. Кем белә аларны, чыннан да берәр нәрсә сизенеп, Каландырук арттан кешеләр җибәрсә! Сизенмәсә дә, болай гына да ул яр буйларын тикшерү өчен каеклар җибәрә ала ич. Аннары яр буендагы сакчыларны алдан кисәтеп куюлары да бар.

Менә шуңа күрә дә гарәп сатучысы бу юлы, бөтенләй тукталып тормыйча, барды да барды. Хан кешеләренә тоттырмаган качакның җиңел генә, бөтенләй көтмәгәндә үз кулына төшүенә ул чиксез куанса да, соңга таба бу куаныч тойгысына курку-куру[2] тойгысы кушылды. Ул, качакның үзендә иканлеген белгертмичә, ничек итеп болгарлар җиреннән ычкынырга икән, дип борчылды. Болгарларның яшерен илчесе Баштый углы Габдулланы Багдадка илтеп җиткерү бурычына караганда, Тотышны Болгардан алып чыгу бурычы аңа кыенрак тоелды. Алмыш ханга ул берьюлы изгелек тә, явызлык та эшли иде. Тик тузандай явызлык та тубалдай изгелектән яманрак саналганга, Фатих ибн Әхмәт: эшләгән изгелегем өчен хан минем явызлыгымны кичерер, дип үз-үзен юата алмады. Ни генә булмасын, Алмыш хан күзе алдында аның яманатлы булып каласы килмәде, аннан да бигрәк, аның атак-

[1] Арык — саф, таза.
[2] Куру — алай-болай булмасын дип борчылу.

лы болгар тирәләреннән, бал-балавыздан, ак буйлы коллардан — үз илендә унар тапкыр кыйбатрак сатыла торган товарлардан колак кагасы килмәде.

Тотылган очракта ул Тотышны болгарлар кулына бирә ала иде, билгеле. Тик аның алай итәсе килмәде. Аның өчен Тотыш элекке таныш-белеш кенә түгел, аның өчен Тотыш — байлык та иде.

Тотышка ул гарәп ишкәкчеләренең киемен бирде, аны ишкәк төбенә утыртты. Качак, бернинди каршылык күрсәтмичә, берни сорашмыйча, ишәргә тотынды. Ул каекларның тизрәк Болгар җиреннән чыгып китәргә тиешлекләрен дә, үзенең гарәп сатучысына көченнән килгәнчә булышырга тиешлеген дә бик яхшы аңлады. Шуңа күрә дә ул берни эндәшмәде.

Шулай да телсез кеше кебек, чылбырга бәйләп куелган кол кебек, бер урыннан кузгалмыйча, тукталмыйча ишеп бару аны озакламый ялыктыра башлады. Фатих ибн Әхмәт нишләптер аның янына килеп тә әйләнмәде. Ишкәкчеләр сөйләшмәделәр. Бу кара кешеләр арасында ул үзен чит, ят итеп тойды. Бу аның саруын кайнатты. Ник сөйләшми гарәп сатучысы? Кая алып бармакчы була ул аны? Кунак булган кешене шулай көн-төн ишкәк төбендә утырталармыни?

Менә алар, биш тәүлек буена туктаусыз барганнан соң, болгарларның калку яр башына урнашкан чик буе катаулары яныннан узып киттеләр. Аларны туктатып тикшерүче булмады. Бары катаудагы каргудан озын кулын болгап, ак юл теләп, сыек зәңгәр төтен генә озатып калды.

Фатихның караңгы йөзе яктырып китте, ишкәкчеләр үзара шаулашып алдылар, төрек сүзләрен вата-җимерә, саргая башлаган тал куаклары белән капланган яр буена күрсәтә-күрсәтә, Тотышка тиздән ярга туктау, ял итү турында аңлатырга тотындылар.

Чик буендагы катауны узып, бер дүрт-биш чакрым түбән төшкәч тә, каеклар сул як ярга борылдылар.

## X

Тирә-ягын таллыклар, камышлыклар, вак-вак күлләр әйләндереп алган бу утрау сыман җирне гарәпләр электән үк беләләр иде, ахрысы. Ярга төшү белән алар беренче адымнарыннан ук үзләрен үз җирләрендәге, үз өйләрендәге кебек тота башладылар: шундук чатырлар кордылар, учаклар яктылар, кечке ашка суярга дип, каеклардан куйлар төшерделәр, азык-төлек, әчемлек, савыт-саба ташыдылар. Берничә кеше таллар, камышлар арасына ауга китте: бу тирәдә, күрәсең, җәйрәннәр, сайгаклар бар иде.

Чатырлар корылып, казаннар асылгач, утрауга агарынган, курыкынган кол кызларны төшерә башладылар. Гарәп сатучысы аларны Ага-базарда алган иде. Алар барысы да чибәрләр, оялчаннар иде. Кызларның күбесе болгарлар иде, арада ерактан китерелгән урыслар, уйсулар [1], ар, чирмеш, мукшылар да бар иде. Кара сакал-мыек баскан кара гарәпләр янында алар үзләренең ак киемнәре, ак битләре, ак кул-аяклары белән әллә каян аерылып торалар иде.

Озын басмадан ярга кызлар төзелеп чыга башлагач та, утраудагы шау-шу кинәт тынып калды. Учаклар, чатырлар тирәсендә булашкан ишкәкчеләр тынып, эшләрен ташлап, кызларга карап тордылар. Телсез-өнсез калып соклану шулай да озакка бармады — оятсызраклары кызларга якынрак килделәр, авызларын ерып, телләрен шартлатып, үзләренчә берәр сүз әйтеп куйдылар. Аларга башкалар кушылды. Богадай таза, яшь ирләр, кыргый бер куаныч белән, тыелгысыз бер шашы-

[1] Уйсу — монда: Төньяк диңгезе буенда яшәгән халык.

ну белән шауларга, гөрелдәргә тотындылар. Кайберәүләр, чамадан тыш батыраеп, кызларның беләкләренә, түшләренә үрелделәр. Печтерелгән ирләр — сакал-мыеклы ишкәкчеләрдән дә тазарак, озынрак сакчылар, бәйләнчек чебеннәрне куган сыман, аларга юан таяклары белән селтәнеп-селтәнеп алдылар.

Печтерелгән сакчылар кызларны утрауның аргы башынарак алып киттеләр. Үзләренә карап торган аттай ирләр өереннән тартынып, качып-посып кызлар үз йомышларын йомышладылар. Шуннан соң аларны яңадан су янына, яр буена алып килделәр. Казлар кебек каңгылдашып алар су керделәр, юындылар, керле киемнәрен юдылар.

Тотыш, айгыр кебек кешнәгән, шаркылдашкан гарәпләргә катнашмыйча, аптырап, тынын кысып, бер читтәрәк басып торды. Аның инде шәрә кол кызларны гына күргәне бар иде. Тик аның беркайчан да, беркайчан да мондый кыргыйлыкны, мондый оятсызлыкны күргәне юк иде. Аның ыруында, аның улусында хатын-кызга — колмы, иреклеме ул — кайчан да кеше итеп карыйлар иде. Кыргый урманнар арасында, аюлар, бүреләр янәшәсендә яшәгән «сабый» кешеләр өчен хатын-кызның кешелек тойгыларын кимсетү, аны түбәнсетү үзе иң зур кыргыйлык саналыр иде. Телсез-өнсез, үксез яшь кызларны кызганудан аның йөрәге кысылып-кысылып куйды. Чит, ят токым, чит, ят тел ирләре арасында калган үз туганнары, үзенең кан-кардәшләре аңа бүреләр өере арасындагы куйлар шикелле тоелды. Кайсыдыр ягы белән аның үз язмышы да, Аппак язмышы да шушы кол кызлар язмышы белән бер тоелды. Сакаллы айгырларның бөтенләй кирәкмәгәнгә, авыз кутәреп, оялчан, тыйнак кызлардан көлүләре аңа үзеннән көлү булып, үзенең күңелендәге иң нечкә кылларны аяк астына салып таптау булып тоелды.

Кемдер арттан килеп аның иңбашына кулын салды. Ул тиз генә артына борылып карады.

— Чибәрләрме? — диде гарәп сатучысы, су коенучы кызларга ымлап.

Ул, күрәсең, Тотышны кызларга ымсынып карый дип уйлаган иде. Ул, күзгә бәрелеп торган эре, ак тешләрен елтыратып, зур эш башкарганнан соң гына була торган бер куаныч белән, тыелып кына кеткелди иде.

— Чибәрләр,— диде Тотыш, аның кара йөзеннән тизрәк күзен читкә борып.— Болгар кызлары ямьсез булмас.

— Кайтканда мин гел шушында туктыйм,— диде гарәп сатучысы.— Ике-өч көн туй ясап, күңел ачып алам. Кешеләргә дә ял бирәм. Гүзәлләрнең тәмен иң элек шушында татып карыймыз. Шуңа кызлар утравы димез бу җирне. Болгарда түрә каты — гарәп ишкәкчесе кызларга якын да бара алмый. Сатып алырга аның акчасы юк. Монда мин аларга тулы ирек бирәм. Моннан ары юлда кызлар да, ирләр дә үзләрен тынычрак тотачаклар. Юкса, кыен мондый тавар белән. Сакчылар гына тыя алмый. Былтыр шулай Муса атлы яһүдинең ишкәкчеләре сакчыларны кырып, Мусаның үзен таш белән суга бәйләп ташлаганнар. Кызларны алып качканнар. Тот син аннан соң аларны. Мин алай итмим. Этне озак бәйдә тотсаң, тилерә башлый. Бүген туй ясыйбыз. Син минем кунагым. Башта син сайла. Кайсы ошый... Үзеңә бер чатыр бирәм. Оҗмах менә шушында инде, Тотыш алып, хе-хе!..

— Миңа барысы да ошый,— диде Тотыш, караңгы чырай белән.

— Барысы да ярамый,— диде гарәп, шаркылдап.— Барысы да! Ха-ха! Ха-ха! Берне генә, Тотыш алып, берне генә! Ирләр күп. Кызлар болай да җитәрлек түгел.

— Алайса, миңа бөтенләй кирәкми,— диде Тотыш.

— Кирәкми?!

— Кирәкми.

— А-а! Аңлыйм! Йөрәк яна? Хан кызын онытмаган? Аппакны? Гүзәл кыз. Тиңсез йолдыз. Сокланам да, аптырыйм да мин сезгә, болгарлар. Сез... мәдәниятсез... артта калган... кыргый... Шулай да сезнең күңелегез бөек! Хан кызын син оныт, Тотыш алып. Хан кызы юк! Ул инде каган куенында, хе-хе... Ир кешегә төн кунарга кыз булсын. Гыйшык, ярату ир кеше эше түгел. Ир кешенең эше — байлык җыю.

— Фатих! — диде Тотыш, калтыранып.— Мин синең кунагың. Мыскыллама! Кызларың миңа кирәкми.

— Туктале, кызмале,— диде гарәп сатучысы, аның беләгеннән тотмакчы булып.— Миндә әле иң сылулары бар. Мин аларны бик нык саклыйм. Алары беркемгә дә бирелми. Мин аларны сатам гына. Синең өчен, Тотыш алып...

— Юк! — диде Тотыш, кискен итеп.

Борылды да, гарәп сатучысын аптыраштa калдырып, читкә китеп барды.

## XI

Ул утрауның иң аулак урынына, каеклардан читкә, яр буена килеп утырды. Аның беркемне дә күрәсе килмәде. Аңа бөтенесе җирәнгеч, әшәке булып тоелды. Монда, үзен коткаручылар арасында, ул үзен теле, токымы белән генә түгел, үзенең күңеле, үзенең уйлары-теләкләре белән дә чит-ят итеп тойды. Аппакны исенә төшереп гарәп сатучысы аның күңел яраларына, әйтерсең, учлап тоз сипте, әйтерсең, аның йөрәген очлы пычак тыгып айкады. Аның елыйсы килде, җиргә ятып ауныйсы, я булмаса, бар нәрсәне кырып-җимереп бетерәсе килде.

Ул, күтәреп булмаслык авыр төшенкелеккә бирелеп, шактый озак утырды. Түбә өстен инде караңгылык каплап алды, ашаучы-эчүче ирләр ямьсез итеп җырлар җырладылар, яр буендагы талларны калтыратырлык итеп, ямьсез тавышлар белән шаркылдап көлделәр. Аяк астында исә, яр читләренә кагылып, пышылдап су акты да акты... Шул ук Әтил. Нинди зур ул, иксез-чиксез, очсыз-кырыйсыз ул Әтил!

Ул ачыга башлады. Аны беркем дә ашарга да чакырмады, эзләп тә килмәде. «Мин кем? Мин нишләргә тиеш, ничек яшәргә тиеш киләчәктә?» дип уйлады ул, тирән бер борчылу белән. Кая бара соң ул? Ник аңа ачык кына беркем берни әйтми? Колмы ул, ишкәкчеме, әллә кунак кынамы? Исән-имин барып җитә алырмы ул Итил-торага?

Аның исерек ишкәкчеләр янына барасы килмәде. Ул утырды да утырды. Көтмәгәндә артта ниндидер аяк тавышы ишетелде. Ул сагаеп көтә башлады. «Фатих микәнни?» дип уйлады иренеп кенә. Ул инде тынычланган, юашланган иде. Күңелендә ташыган ярсу уйлар-сораулар инде онытылган, төссезләнгән иде. «Сак булырга кирәк аның белән»,— дип уйлады ул гарәп сатучысы турында.

— Тотыш, син мондамы? — диде арттан килгән кемдер, аның янында гына туктап.

Ул моны ап-ачык итеп Тотышның туган телендә әйтте. Тотыш аягына басты. Бу Фатих түгел иде. Бу ниндидер үз кеше иде!

— Син кем? — диде Тотыш, дулкынланып, карачкының йөзен күрергә тырышып.

Бу Алмыш ханның яшерен илчесе Габдулла иде. Ул үзенең кем икәнлеген әйтмәде, бары:

— Мин синең юлдашың,— дип кенә куйды.

— Син безнеңчә яхшы сөйләшәсең,— диде Тотыш.

— Синең телең — минем туган телем,— диде Габдулла.

— Син кем? — диде тагын да Тотыш, кызыксынып.— Ничек бу болай? Кол түгелсеңдер ич син?

— Түгел,— диде Габдулла, Тотышның кулыннан алып.— Мин сине ашарга чакыра килдем, Тотыш. Болай үпкәләп утыру килешми. Кем

арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың. Берни эшләп булмый. Фатих миңа әйтте. Аның ачуы килгән.

Тотыш берни эндәшмәде. Шулай ук ул аңа карышып та тормады. Алар икәүләп учак янына бардылар. Ул анда ашады, эчте. Шуннан соң алар яңадан икәүләп яр буена килделәр дә, төнге Әтилгә — елк-елк килеп аккан каралҗым су өстенә карап сүзсез генә утырдылар.

— Минем инде күптән синең белән сөйләшәсем килә, Тотыш,— дип, әкрен генә сүзгә башлады Габдулла.— Минем туган җирем — Итилтора. Синең кебек, мин дә туган илемнән качып киттем. Минем барлык байлыгым, көчем, терлек-туарым Итилдә торып калды. Синең кайгыңны мин аңлыйм. Шуңа да минә сөйләшәсем килде.

— Син ник качтың? — диде Тотыш.

— Сөйләсәң, күп инде,— диде Габдулла көттеребрәк.— Мин — мөселман. Җөфүтләр белән килешә алмадым. Кыскасы шул. Мин үземнең йолам-динем аркасында талау күрдем.

— Син мулламы әллә? — диде Тотыш.

Габдулла эндәшмәде.

— Мин менә сөюем, яратуым аркасында качак булып йөрим,— диде Тотыш, көлгәндәй итеп.— Синең сөйгәнең, алайса, йола... чумаклар йоласы булып чыга?

— Шулай дисәң дә ярый,— диде Габдулла, килешеп.— Тик монда эш коры йолада гына түгел, эш монда тирәнрәк.

— Минем өчен барыбер: йола булгач йола! — диде Тотыш.— Минем дә менә берәр белгән кеше белән сөйләшәсем киләдерие. Аңлатып бир әле миңа... нишләп шулай табына кеше йолага? Ата-баба йоласына да түгел — гарәпләр, татлар йоласына табына! Ник кирәк ул сиңа? Әнә шулай безнең кызларны тире кебек, агач, терлек кебек итеп сатып алып китсеннәр өченме, теләсә кайда теләсә ничек мыскыллассыннар өченме?! Шулар арасында синең сөйгәнең булса... сеңелең, кызың, апаң, анаң булса, нишләриең син?! Ничек карарыең, ничек түзәриең шунда?! Әнә алар, яхшы йолалы, алдынгы, белекле кешеләр минем сеңелләрне... Йола! Шул турыда ишеттемме, минем каным кайный башлый, кемнеңдер бугазын чәйнәп өзәсем килә! Мин туганнан бирле ата-баба йоласын тоттым. Сөйгәнемә өйләнү өчен мин бернигә карамый чумак йоласына күчтем. Мулла әйтте: алладан көчле беркем, берни юк диде. Җөфүт каган минем сөйгәнемне тартып алып киткән. Инде әйтеп кара: кем көчлерәк — алламы, каганмы?

— Син языклы сүзләр сөйлисең, Тотыш! — диде Габдулла, куркып, төкеренеп.— Сине иблис буташтырган!

— Мине беркем буташтырмады,— диде Тотыш.— Мин сиңа туры сорау бирәм, син шуңа туры җавап бир. Кемгә, нәрсәгә инанырга?

— Бер аллага инанырга! — диде Габдулла, нык итеп.— Минем дә йөрәгем әрни, минем дә каным бозга әйләнә. Ел саен безнең кызлар, безнең ирләр чит илләргә күпме озатыла! Ата-аналар, терлек саткан кебек, комсыз сартларга, татларга үз балаларын сатып җибәрәләр. Ата-баба йоласы моңа каршы килми. Ханнар, биләр моңа чик куя алмыйлар. Кайчан безнең олуг Әтилгә кардәшләребезнең кан-яшьләре акмый башлар?! Мин дә уйлыйм, мин дә янам, Тотыш! Бу оятлы, түбән эштән безне тәңре коткармады. Алла коткарачак! Мөселман йоласы мөселманны тавар итеп, кол итеп сатуны тыя. Төрекләр мөселман булсалар, аларны беркем сата да, сатып та ала алмаячак. Котылу юлы менә шунда, Тотыш.

— Алай икән,— дип куйды Тотыш, килешкән сыман итеп.— Шулай да мин аңлап җитмәдем әле: төрек йоласында булганда да ник бу эшкә чик куеп булмый? Төрек йоласындагы кеше кеше түгел, мөселман йоласындагы кеше генә кешемени? Алла шуңа юл куямыни? Нишләп соң гарәп ишкәкчесе төрек йоласындагы кол кызга бүген терлеккә

караган кебек карый да, ни өчен иртәгә... кол кыз чумакка әйләнсә, аңа кеше итеп карый башлый? Гарәп йоласына күчү белән мин... син... ул кол кызлар әллә икенче төрле кешегә әйләнәбезме? Ни өчен чумаклар чын кеше дә, башкалар чын кеше түгел?!

— Алла каршында бары аның коллары гына... чын кешеләр, белекле, саф кешеләр,— диде Габдулла.

— Юк, барыбер аңламыйм! — диде Тотыш.— Мин моны беркайчан да аңламадым. Үз ыруымнан Болгарга килеп яши башлагач та аңламадым. Мин анда төрле йоладагы кешеләрне күрдем. Юк, мин аңлыйм да аны. Тик үземчә аңлыйм. Барлык йолалар да бер төсле. Алар бары төрлечә атала гына. Минем үзем өчен инде барыбер. Кем йоласына табынсам да — барыбер. Мин — йортсыз-җирсез, ырусыз...

— Менә шул турыда сөйләшмәкче булганыем да мин синең белән,— диде Габдулла.— Мин сиңа әйтмәдем... мин... Багдадка барам. Җөфүтләрдән качып. Миңа ышанычлы юлдаш кирәк. Синең кебек таза, яшь... Мине синең язмышың да борчый. Күрмәгән-белмәгән булып мин болай гына синең яннан узып китә алмыйм. Кире Болгарга кайтсаң, сине анда үлем көтә. Фатих белән китсәң, сине анда нәрсә көтәдер, ансын әйтүе кыен. Ул ачык кына берни әйтми. Син үзең ничек уйлыйсың? Нишләмәкче буласың син?

— Белмим,— диде Тотыш төшенкелек белән.— Минем әлегә юлым билгеле түгел. Барлык уйларым-теләкләрем юкка чыкты. Мин әлегә берни уйлый алмыйм. Сөйгәнемнән башка миңа кызык та, ямь дә юк. Миндә бары үч тойгысы гына ялкын булып дөрли. Туң ташны да эретердәй үч, ярсу гына бар миндә. Бир миңа мең кешелек чирү — бүгеннән барып каганның йортын туздырам, сөйгәнемне йолып алам! Бармы синдә андый чирү? Булса, бүгеннән мин синең колың, юлдашың.

— Күреп торасың — миндә чирү юк,— диде Габдулла, тавышын әкренәйтеп.— Мин менә шундый чирү, көч эзләп барам. Багдадта бар андый көч! Мөселманнарның баш кешесендә. Мин менә шунда барам. Безгә ничек тә шунда барып җитәргә кирәк! Синнән дә яхшы юлдашны мин эзләсәм дә табалмам. Ашыкма, уйла. Иртәгә әйтерсең.

## XII

Габдулла саубуллашып урыныннан торды. Тик ул кузгалып китә алмады, җир астыннан чыккан кебек, аның каршысына Фатих ибн Әхмәт калкып чыкты.

— Тукта! — диде ул, яшерен илченең күкрәгенә бөктә терәп.— Алла белән ант итәм: мин барысын да ишетеп тордым! Икәүләп сез яманлык уйладыгыз.

Тотыш, гарәпнең ачулы сүзләрен ишетеп, тиз генә урыныннан сикереп торды.

— Кузгалма! — диде сатучы аңа да.

Таллар арасында кыштырдык ишетеп, Тотыш як-ягына каранып алды. Аларны төрле яктан коралллы ирләр уратып алган иде. Бары су ягында гына беркем юк иде. Юк, әнә анда да ирләр тулы көймә шуышып чыкты!

Гарәп базаргалы коралллы ирләргә үз телендә нидер әйтте. Тотыш исенә килеп өлгергәнче, ике яктан ике таза ир аның беләкләреннән эләктереп тә алдылар, каердылар, кыл аркан белән бәйләп тә ташладылар.

— Карышма, курыкма, Тотыш алып,— диде Фатих ибн Әхмәт.— Сиңа берни булмас — син минем кулда.

— Сиңа ни булды, алла колы? — диде Габдулла, аптырап, шаккатып.— Ни эшең бу?

— Миңа булмады — сезгә булган! — диде гарәп.

НУРИХАН ФӘТТАХ ◆ ӘТИЛ СУЫ АКА ТОРУР ◆

Ул исерек иде, аның сүзләрендә ниндидер кыргый куаныч бар иде, сычкан эләктергән мәче мырылдавына охшаш бер куаныч бар иде.

— Исерек башыңа... язык сыз мөселманга кул күтәрергә ничек батырчылык итәсең? — диде Габдулла, кычкырына башлап.

— Хе-хе,— дип көлемсерәде гарәп сатучысы, биленә таянып.— Сез, төрекләр, барыгыз да ярым мөселманнар. Бозык мөселманнар. Аллага тел тидерәсез. Мин ишеттем. Сез миңа яманлык кыласыз. Икегезне дә сатлык дип ханга озатсам?!

— Хәмер синең акылыңны алган! — диде Габдулла.

— Алла белән ант итеп әйтәм, юк! — диде Фатих ибн Әхмәт.— Әйдә минем чатырга, шунда сөйләшербез.

Алар җилләнеп китеп бардылар.

— Башту ибн Габдулла! — диде гарәп, үз чатырына кереп, зур сандыгы өстенә утыргач.— Мин синең белән турысын сөйләшмәкче булам. Мине юлбасар дип уйласаң, син ялыклы булырсың. Мин сине тиешле җиргә илтеп җиткерергә ханга сүз бирдем — сүземне үтәрмен. Син минем эшемә кысылма. Тотыш белән син нәрсә сөйләштең яшерен?

— Анда синең эшең юк! — диде Габдулла кискен генә.

— Мин ишеттем. Син минем колымны...

— Колымны?! — диде Габдулла, күзләрен зур ачып.

— Минем колым Тотышны...— дип төзәтте гарәп сатучысы.— Тотышны мин таптым. Шулай булгач, ул минем колым, ул минем тавар.

— Син аны кунак итеп алдың,— диде Габдулла.— Юлбасар булдыңмыни?! Ханбалыкка җиткәч мин сине...

— Барып җитә алсаң!..— диде сатучы, янап.— Сез икегез дә минем кулда. Нишләмәкче буласыз сез?

— Син нишләмәкче буласың? — диде Габдулла, ярсуына буылып.— Берәр нәрсә эшләп кенә кара! Минем сиңа утырып юлга чыкканны Итил-торадагы мөселманнар белеп, көтеп торалар. Миннән башка барып керсәң, ни диярсең аларга?

Гарәп сатучысының елтыр ак тешләре шундук эчкә йомылды. Бу турыда ул, күрәсең, уйлап җиткермәгән иде.

— Колымны мин сиңа бушлай бирмәячәкмен,— диде ул, йомшый төшеп.— Син котыртып аны үзеңә алмакчысың.

— Син аны миңа сатып бирмәкче буласыңмыни?! — диде Габдулла, шаккатып.

— Әйе! — диде сатучы.— Йөз динар![1] Алмыш хан миңа биш йөзне бирәчәк.

— Я алла! — диде Габдулла, күкрәгенә тотынып.

Ул куеныннан калтасын чыгарды, йөз динар санады да, акчаларны гарәпнең сузылган учына салды. Бу аның юлга дип алып чыккан акчасының чиреге чамасы иде. Әле балта сабыдай җир китмәделәр, болай булса, ничек барып җитәр ул барасы җиренә, ничек эзләп табар ул Тәкин углан белән Барыс угланны? Я алла, үз мөселманың терелэй тотып тунагач, башкалар ничек тунамасын? Чыннан да, кемгә ышанырга, кемгә таянырга бу аҗунда? Нишләп соң, аллам, кешеләр сүздә сине олылыйлар, чынында исә сиңа түгел — көчкә, алтынга табыналар?!

Кара гарәпнең кара йөзе, акча күргәч, яктырып китте.

— Моннан соң Тотыш тулысынча минеке,— диде Габдулла.

— Синеке,— диде сатучы, елмаеп, ялагайланып.

Икәүләп алар янадан тыш якка чыктылар. Төн уртасы инде узган, җир өсте яктыра башлаган иде. Куллары артка каерып бәйләнгән

---

[1] Динар — алтын акча берәмлеге.

Тотыш җирдә утырып тора иде. Үз кешеләренә гарәп сатучысы аны чишәргә кушты.

— Син тагын ирекле,— диде Габдулла моңсу гына, аның кулын кысып.

— Түләдеңмени? — диде Тотыш.

— Түләдем,— диде Габдулла, көрсенеп.

— Алайса, мин синең... колың? — диде Тотыш.

— Син минем кардәшем, юлдашым,— диде Габдулла.

...Ике төн, ике көн җүнел ачканнан соң, гарәпләр ярдан кузгалып киттеләр. Ишкәкчеләр баш калкытмый иштеләр. Каеклар агым уңаена бик тиз бардылар.

Текә ярлар, калын урманнар күптән инде артта калды. Ярлар тәбәнәкләнде, ерагайды. Этил тагын да ныграк киңәеп, җәелеп китте. Күрер күзгә шундый күңелле булган яшеллек кайдадыр артта калды. Тирәякта ат кылыдай каты, коры үләннәр генә тырпаеп утырган иксез-чиксез далалар, тигез, шәрә далалар башланды. Аның урынына монда кояш ягымлырак карый башлады. Яр өстендә анда-монда ак тирмәләр күренде, берәр яшел уйсулыкта утлап йөргән куй, җылкы, сыер көтүләре күренде. Я булмаса кайнар рәшә дулкыны тирбәлгән берәр тәбәнәк калкулык артыннан, озын муеннарын сузып, әкрен генә кыймылдап барган озын торыклы дөяләр тезмәсе килеп чыкты.

Каеклар ханбалыкка — Хазар йортның изге каганы яши торган Итил-торага якынлашып киләләр иде.

Менә шул чагында, үзенең туган якларыннан инде бөтенләй аерылгач, үзенең кайдыр читкә китеп баруы, кайдыр икенче илләргә баруы ачыклана төшкәч, Тотышның күңелендә кискен бер үзгәреш барлыкка килде. Моңарчы күңелендә әле тулысынча ачыкланып җитмәгән бер уй, яман чир кебек, аны тынычсызлый башлады. Шул ук мәлдә аның өчен бөтен нәрсә ап-ачык булып, кояшлы көндәй яп-якты булып калды. Барлык сораулар, барлык кайгы-борчулар, каршылыклы уй-тойгылар аның күңелен балкытып җибәргән әлеге яктылыкта кинәт юкка чыктылар.

— Юлдаш! — диде ул бер көнне Габдуллага.— Син миңа ачулана күрмә. Мин синең акчаңны тулысы белән кайтарырмын.

Габдулла күңелсез иде, уйчан иде. Тотыш аны суга салынган йөз динары өчен кайгыра, дип уйлады. Габдулла исә бөтенләй икенче нәрсә турында: гарәп сатучысының ышанычсыз булуы, Итил-торада, күрәсең, аннан аерылып калырга кирәк булачагы турында уйлана иде.

— Мин аны оныттым. Икенче ул турыда минем исемә төшермә, Тотыш алып,— диде Габдулла, үзенең юлдашын тынычландырып.

— Мин сиңа шуны әйтмәкче булам,— диде Тотыш Габдуллага.— Мин синең белән китәм! Кая алып барсаң да, нишләтсәң дә, мин синең юлдашың булырмын. Тик минем бер үтенечем бар. Бер генә үтенечем!

Ул, иелеп, аның колагына:

— Мин... Аппакны коткарырга тиешмен! — дип пышылдады.

Габдулла, ярым ачылган авызын күтәреп, аңа саңгырау кеше сыман карап торды.

— Әйе! — диде Тотыш, елмаеп, чиксез бер күтәренкелек белән.— Шунсыз миңа тормыш юк. Бу минем сиңа, язмышка... аллага... тәңрегә бердәнбер үтенечем. Ирек бир миңа, булыш миңа, чын юлдаш булсаң, кардәш булсаң.

Габдулланың ярым ачык авызыннан бер сүз дә чыкмады.

## XIII

Ханбалыкка җитәбез дигән көннең салкынча таңында гарәп базарганы Фатих ибн Әхмәт каеклары Этилнең төп юлыннан аерылган бер

тармакка килеп керделәр. Тармак буйлап бер чакрым чамасы түбән төшкәч, биек, куе камышлар арасында баш каек туктап калды. Каекның борынына баскан килеш тирә-якны күзәтеп барган Габдулла, бармакларын авызына куйды да, ачы итеп сызгырып җибәрде. Йокымсырап утырган камышлар калтыранып киттеләр, камышлар арасыннан, куркып, пырылдап, авыр чүрәкәйләр очышып чыкты. Күз алдында гына очкан үрдәкләрне күреп беркемнең дә исе китмәде. Барысы да, тыптын калып, камышлар аша еракка карап, нидер көтеп тордылар. Габдулла, колакларны ярырлык итеп, тагын бер сызгырып җибәрде. Күпмедер көтеп торганнан соң, камышлар артында, бераз сулдарак, күккә ак койрыклы ук атылды. Күп тә үтмәде, шул турыдан камыш ерып көймә килгәне күренде.

Көймәгә яшь кенә бер егет утырган иде. Аның дала кояшында кара янган киң яңагы, су өсте сыман шоп-шома булып, ялт итеп тора. Аның шулай ук кыска туны да, энҗе-ташлар белән бизәлгән сыман, иртәнге кояшта елкылдап күренә. Тик аның шомарып, каешланып беткән кисменә энҗеләр түгел, балык тәңкәләре ябышкан. Кыска ишкәге белән ул бик җиңел генә, иркен генә ишә. Ачык күкрәкле, кыскарак муенлы бу таза егетнең су буенда туган, су буенда үскән кеше икәнлеге әллә каян сизелеп тора иде.

— Хода юлыгызны уң кылсын, юлчылар! — диде ул, каектагыларга сынаулы күз карашы ташлап.

— Шулай булсын, амин! — диде Габдулла, эчке бер дулкынлану белән.

Бу аларның ымнары — алдан үзара килешеп куелган сүзләре иде. Бу — тирә-якта тыныч, имин, ярга чыгарга була, дигәнне аңлата иде. Габдулла ашыгып койрыкка таба атлады. Көймәгә аның зур гына ике төргәген төшерделәр. Шуннан соң Габдулла Тотышка төшәргә кушты. Бары шуннан соң гына ул көймәгә үзе дә аяк басты. Аннары ул баш очында, каек читендә бөеренә таянып торган гарәп сатучысына күтәрелеп карады.

— Сау бул. Алла сиңа исән-имин кайтып җитәргә язсын,— диде ул гарәп сатучысына.

— Мин сине алдан килешенгән җирдә ун көнгәчә көтәм,— диде караңгы чырайлы сатучы.

— Ярый, ярый,— диде Габдулла, кузгалып китәргә ашыгып.— Ун көннән килеп җитмәсәм, сау бул. Мин башкаларны белешермен.

Көймә, куе камышлыкта тар гына эз калдырып, ярга таба шуышты. Ике юлчысыннан арынган каек та, су өстендә зур дулкыннар ясап, әкрен генә кузгалып китте.

Куе камыш арасыннан көймә авырлык белән барды. Комлы калку яр буена барып чыкканчы беркем берни сөйләшмәде. Көймәне яр читендә калдырып, комлы сукмактан югары менгәндә дә шулай ук эндәшүче булмады.

Яр өстендә искиткеч күренеш ачылды. Кая карама — киңлек-иркенлек... Ерактагы соргылт далалар арасында аеруча күркәм булып тоелган яшел камышлы ярлар. Ярлар арасындагы Әтил тармаклары. Шул тармаклар арасында — яшел камыш урманнары уртасында — соргылт тауачыклар, калкулыклар... Утрауларның кайберләрендә камыштан корылган ниндидер куралар, киез өйләр күренә, пәрәвездәй булып, кибәргә эленгән балык аулары челтәрләнеп тора; кешеләр, терлекләр кыймылдаша. Иртәнге чалт аяз тынлыкны бозып, әле уңда, әле сулда ниндидер тавышлар ишетелеп китә.

Камыш белән кызыл балчык катыштырып ясалган ялгыз куыш янында аларны чәчләре агарган, урта яшьләрдән өлкәнрәк бер ир кеше каршылады. Көймәче егет кебек, ул да кыскачарак муенлы, киң яңаклы иде. Сирәк сакал-мыегы аның кыска итеп, түгәрәкләп алынган. Аның да

өсте-башы, гел балык белән булашканга, шомарып, каешланып беткән. Аларның икесеннән дә балык исе аңкып тора. Алардан гына түгел, мондагы куыштан, камышлардан, җирдән, көймәдән — барлык нәрсәдән балык исе килә иде.

Туган җиренә аяк басу белән Габдулла, өстендәге тунын җиргә җәеп, намаз укырга кереште. Башкалар, изге бер тынлык саклап, читтән генә карап тордылар. Габдулла, намаз укыганда үз-үзен күпме генә тыныч тотарга тырышмасын, булдыра алмады — үзе белгән бернечә гарәп сүзен авыз эченнән генә мыгырданды да, кызарынган, яшьләнгән күзләрен көнчыгышка текәп, елмаеп, туган җиренә, тәңрегә, чыгып килгән кояшка изге келәүләрен юллады. Тотыш аны шаккатып тыңлап торды. «Әллә чумаклардан баш тарткан-мы?» дип уйлады ул үзалдына. Габдулла, ахрысы, аны бөтенләй исеннән чыгарып ташлаган иде.

— Иминлекме, Мәмәт? — диде ул, өлкән ир кешегә карап.

— Иминлек,— диде Мәмәт, Тотыштан күзен алмыйча.

— Ишем, балаларым? — диде Габдулла, тынын кысып, сагаеп.

— Алар да исән-имин,— диде Мәмәт, ашыкмыйча гына.— Бары да исән.

Габдулла җиңеләеп, шаулатып бер тын алды, елмайгандай итте, юешләнгән борынын тарткалады.

— Шулай да сиңа күзгергә ярамас,— диде Мәмәт, көттеребрәк.— Кирәк кешеләрне үзебез табарбыз, алып килербез.

— Без әле сезне көтмәгәниек,— диде яшь егет, сүзгә катышып.— Каган яучылары Болгардан кичә генә кайтып төштеләр.

— Кичә генә?! Болгардан?! — диде Тотыш.

Ул моны шундый кычкырып, шундый куркыныч итеп әйтте,— барысы да, ни булды дигән сыман, аптырашып, тынып калдылар, бер-берсенә карашып алдылар.

— Бүген каганның туе була,— диде балыкчы егет, Тотышның соравыннан берни аңламыйча.

Ул боларны Тотыш өчен түгел, Габдулла өчен — Итил-тора яңалыкларыннан бик нык артта калган якын кешесе өчен сөйләде. Тик аның сүзләре Габдулладан бигрәк иң элек Тотышка барып җитте. Аның йөзе тартышып куйды. Ул, балта белән чабылган агач кебек, кинәт җиргә ауды, йөзтүбән капланды да үксеп-үксеп еларга тотынды.

## XIV

— Тор! — диде кинәт Габдулла, боерып.— Болай җебегән булсаң, берни эшли алмассың. Тор, тыңла сүземне.

Тотыш башын калкытты, торып утырды.

— Минем әле сиңа үз сүземне әйткәнем юк,— диде Габдулла.— Инде тыңла. Сез дә тыңлагыз,— диде ул, балыкчыларга эндәшеп.— Мин әле сезне таныштырмадым да бугай? Бу — Болгардан, Тотыш алып. Җөфүт каганына аның сөйгән кызын алып килделәр. Болары — Мәмәт ага белән аның улы Әмин. Минем иң ышанычлы кешеләрем. Монда без барыбыз да өлешсезләр, барыбыз да бер теләк белән янучы, аллага табынучы кешеләр. Без болай итәрбез... Фатих ибн Әхмәткә... юлбасарга ышанып мин ерак юлга чыга алмыйм. Бер ярты ай чамасы миңа монда булырга туры килә. Миңа әле кайбер кешеләрне күрергә, үз эшләремне җайларга кирәк. Ишемне, балаларымны мин Болгарга күчерәм. Мин алардан башка яши алмыйм. Барысы да сөйләшенгән-килешенгән — аларны юлда болгарлар каршы алачаклар. Тик моннан исән-имин алып чыгарга гына кирәк. Бу эштә безгә Мәмәт ага булышыр. Аннары шул: Багдадка без су юлы белән түгел, коры юл-

дан Хәрәзем аша үтәрбез. Итилдән аркышлар[1] йөреп тора. Миңа инде элек Тәкин углан белән Барыс угланны эзләп табарга кирәк... Болары аның болай гына. Инде сиңа килгәндә, Тотыш... Мин үз эшләремне кайгырткан арада, син дә үз эшеңне кайгыртырсың. Сиңа Әмин булышыр.

— Бай бул, Габдулла ага! — диде Тотыш, күз яшьләре аша елмаеп.

— Мин үз ишемнән, балаларымнан башка тора алмаган кебек, син дә үзеңнең сөйгәнеңнән башка тора алмыйсың,— диде Габдулла.— Монда бер дә искитәрлек нәрсә юк. Аллаһе тәгалә үзенең колларын сөю, сөелү өчен яраткан. Каган синең сөйгәнеңне көч белән тартып алган. Син шуны үзеңә кайтарасың. Монда угрылык юк. Монда язык юк. Түрә безнең якта, алла безнең якта!

Габдулла үзенең якташларына карап алды. Мәмәт төсе уңган күзләрен читкә борды, яшь Әмин, башын иеп, аяк очы белән җирне тырнаштырды. Аларның мондый нәрсәне яклыйсылары килмәве әллә каян күренеп тора иде.

— Ник эндәшмисез, Мәмәт ага, Әмин? — диде Габдулла.— Куркып калдыгызмы?

— Куркуын курыкмадык та,— диде Мәмәт, башын кашып.— Кызны ничек алырга? Барып сорасак, бирмәс ич ул аны?

— Көлмә, Мәмәт ага,— диде Габдулла.— Каганда — көч, бездә — кыюлык. Кызны синең белән мин түгел, менә яшьләр коткарырга тиеш. Ничек итеп коткарырга кирәген башта алар үзләре бергәләп киңәшерләр. Кирәк икән, без дә әйтербез.

— Шулаен шулай да,— диде Мәмәт ага.— Хазар каганына... изге каганга, бөек каганга кул күтәрергә! Белмим, кемнең генә йөрәге житәр икән моңа?

— Каганның безгә каршы кул күтәрергә йөрәге житә ич! — диде Габдулла.— Мөселманнарны кысарга, күршеләрне таларга йөрәге житә ич!

— Мин үзем кул күтәрермен! — диде Тотыш.— Сез миңа әйтегез генә. Барысын да мин үзем башкарырмын. Үлсәм дә, калсам да, нишләсәм дә — үзем языклы. Мин бернәрсәдән курыкмыйм.

— Син бик батыр күренәсең, углан,— диде Мәмәт Тотышка, яратмыйча.— Каган — изге. Ул җөфүт кенә түгел. Бер көнне ул җөфүт кәнәсәсенә барса, икенче көнне мәчеткә бара, өченче көнне ата-баба келәүлегенә, дүртенче көнне рум чиркәвенә бара. Аның каргышы төшсә, бик каты төшәр. Аның сараен, урдасын дүрт мөңлек чиру саклый. Аның хатыннары, кырнаклары яши торган җир биек таш койма белән уратып алынган. Хатыннары — аерым-аерым өйләрдә, өйләренең ишек төпләрендә — печтерелгән сакчылар. Ничек үтәрсең коймалар, сакчылар аша?

— Кирәк икән, кош булып очармын, җылан булып шуышырмын, йомран булып җирне тишеп керермен! — диде Тотыш.

— Иң кыены — таш койма,— диде Әмин, Тотыш ягына авышканлыгын сиздереп.— Эчкә кергәч, анда — бакчалар, агач өйләр... Анда җиңелрәк.

— Карале, син дә батыр икәнсең! — диде ата кеше үзенең углына.— Сез үләрсез дә котылырсыз. Каганның каргышы безгә — Итил мөселманнарына төшәр.

— Кызны кем урлаганын каян белерләр соң? — диде Әмин.

— Тотылсагыз? — диде ата кеше.

— Тотылсам, мине монда беркем белми,— диде Тотыш.

---

[1] Аркыш — кәрван.

— Мин каршы,— диде Мәмәт, беркемгә карамыйча.— Каган изге. Каганга кул күтәрергә... юк! Теләсәгез нишләгез — мин каршы.

— Син безне сатмассың ич, Мәмәт ага? — диде Габдулла.

— Минем әле беркемне дә сатканым юк,— диде Мәмәт ага, үпкәләп.

— Болай булгач, без үзебез генә эшләрбез,— диде Габдулла, яшьләргә карап.— Сез бүген үк торага барырсыз, карарсыз, күрерсез. Безгә барысын да уйлап, җайлап эшләргә кирәк. Ашыгырга, кабаланырга ярамый. Аппакны коткарсак, Хәрәземгә без бергәләп китәрбез. Изге иялэр, фәрештәләр юлдашыбыз булсын. Без әле каганның яңагына шундый иттереп тондырырбыз — күзеннән утлар күренер!

## XV

Алар көймәгә эре балыклар сайлап салдылар. Кояшта исләнмәсен өчен балыкны камыш белән капладылар, өлкәннәр белән саубуллаштылар да ярдан кузгалып киттеләр. Көймәне Әмин башта яр буйлап, камыш үсмәгән тар аралыктан алып барды. Шуннан соң алар, сирәк камышлыкларны үтеп, ачык су өстенә килеп чыктылар. Күз алдында икенче төрле күренешләр ачылды. Алар бара торган тармакка каяндыр икенче тармак килеп кушылды. Биек камышлар читкә тайпылды, тирә-як тагын да ныграк яктырып китте. Арттан кетмәгәндә аларны ниндидер җитез көймә куып житте. Көймәгә эрдәнәләп утын төягәннәр иде. Утынлы көймә узып киткәннән соң арттан тагын бер көймә күренде. Монысына капчыклап ашлык төялгән иде.

Алар, ахрысы, зур юлга килеп чыкканнар иде. Монда аларга әле алдан, әле арттан килүче көймәләр, улаклар очрап кына торды. Агым белән алга барган саен, як-якта ниндидер ят тавышлар, ниндидер басынкы гына шау-шу, гөрелдек ишетелә башлады. Яр өсләрендә тирмәләр, куышлар күбәйде. Ул да булмады, еракта, күк белән җир-су өсте бергә тоташкан турыда, караеп, урман кебек булып, бик күп өйләр, каралты-куралар калкып чыкты. Озын баганалар кебек күккә сузылып, тырпаеп утырган сырганнар, манаралар күренде.

Тотыш, исе китеп, күз алдында җәелгән иксез-чиксез Ханбалыкка карап барды.

Бөек Хазар йортның баш торасы Этил тамагыннан алтмыш-житмеш чакрым чамасы югары урнашкан иде. Ханбалык, «Итил» дигән бер генә сүз белән аталып йөртелсә дә, чынында ул өчкә бүленгән яисә өч кисәктән тора иде. Ханбалыкның Хазаран дип аталган иң зур кисәге Этил суының сул ягына урнашкан иде. Ун меңнән артыграк кеше яшәгән Хазаранда күпчелек мөселманнар иде. Хазар төрекләреннән, болгарлардан, тәжик, гарәпләрдән тыш монда төрле яклардан килеп утракланган күп төрле башка токым, башка тел кешеләре дә житәрлек иде. Хазаран ул бөтен Хазар йортның үзәк базары иде. Сату-алу, алыш-биреш монда беркайчан да тукталып тормый иде. Монда күбесенчә сатучылар — базарганнар, сартлар, сәүдәгәрләр яши иде. Алардан тыш монда балыкчылар, терлекчеләр, шулай ук төрле кылчылар:[1] чүлмәкче-тиречеләр, тимерче-бакырчылар, җимешчеләр яши иде. Хазаран — агач, камыш, балчык өйләрдән, киез тирмәләрдән торган сатучылар, кылчылар, каралар торасы[2] иде.

Итил-тораның уң як ярга урнашкан кисәген «Ханбалык» дип йөртәләр иде. Монда инде тулысынча аксөякләр — каган-бик үзе, каганның[3], каган-бикнең[4] туганнары, якыннары, биләре, субашлары,

[1] Кылчы — һөнәрче.
[2] Тора — шәһәр.
[3] Каган — Хазар дәүләтенең башы.
[4] Каган-бик — каганның урынбасары.

жавышгарлар[1], йола башлыклары, билгәләр, битекчеләр яши иде. Шунда ук, дүрткел биек койма белән әйләндереп алынган иркен бер җирдә бөек каганның хатыннары, кырнаклары да көн күреп яталар иде.

Әтил уртасындагы зур утрауда, Хазаран белән Ханбалык арасында Итил-тораның өченче кисәге урнашкан иде. Монда, таудай биек итеп, сырлап-бизәп, кызыл кирпечтән салынган гүзәл сарайда, таш коймалар эчендә, җимешлекләр, карт тирәкләр арасында Хазар йортның башы бөек каган, изге каган яши иде. Бу утрау «Урда» дип атала иде.

Каган, күктәге алла кебек, тәңре кебек, теос[2] кебек, аденой[3] кебек берни эшләми, бернигә катышмый иде. Бөек Хазар йортны исә каган түгел, аның урынбасары каган-бик үз кулында тота иде. Каган-бик йорттагы эчке-тышкы эшләрне алып бара, сайлап алынган унике меңлек чиругә башлык итә иде. Алай гына да түгел, каганның үзен дә ул уч төбендә биетә иде. Каган исә Хазар йортындагы барлык улусларны, ыруларны, барлык кешеләрне бары үзенең бөеклеге, изгелеге белән генә куркытып, буйсындырып тора иде. Аннары ул, күктәге аденойдан, теостан, тәңредән, алладан аермалы буларак, ике аяклы, ике куллы кешеләрнең барысы кебек, ашый-эчә, уйный-көлә иде. Аннан да бигрәк, ир кеше булганга, ул үз йортындагы теләсә кайсы чибәр кызны коча ала иде. Монда инде ул чынлап та бөек иде. Бу эштә җир йөзендә аның белән бик аз кешеләр тиңләшә ала иде. Каганның кемне дә булса кочарга теләк белдерүе белән, аның барлык ялчылары аякка баса. Эчкәреләр каганның теләге турында иң элек өй-агасына белдерәләр, өй-агасы йомышчыга белдерә, йомышчы исә урда белән уң як яр арасындагы Әтил тармагы аша каеклар өстенә салынган йөзмә күпердән яшен ташыдай йөгереп үтеп, Ханбалыкның койма белән әйләндереп алынган хатыннар катавына керә, тиешле өй янына барып, печтерелгән сакчыга каганның теләген белдерә. Сакчы бөек каганның хатынын яисә кырнагын күтәреп ала да күз ачып йомганчы аны тиешле җиргә илтеп тә тапшыра.

Җәйләүдә булмаганда каган үзенең урдасыннан кеше арасына бары дүрт айга бер генә тапкыр чыга. Аннары ул үзенең утравыннан тагын илгә яу килгәндә, я булмаса Итил-торада зур ызгыш булганда да чыга иде. Изге каганның урдадан чыгуын ишетеп, ягылар шундук куркып качалар, талашучы-ызгышучылар шундук татулашалар иде. Менә шундый көчле, менә шундый бөек, изге иде Хазар йортның башы каган!

Бүген илгә яу да килмәгән иде, берәрсенең кем белән дә булса талашканы-ызгышканы да ишетелми иде. Шулай ук бүген дүртенче айның соңгы көне дә түгел. Шулай да каган бүген утраудан чыгачак, үзенең иленә-көненә күренәчәк. Бүген бөек каган Болгар йортның башы Алмыш ханның гүзәл кызы Аппакка өйләнә. Төш уртасында, күктәге кояш түбә өстендә асылынып торганда, җирдәге кояш үзенең яңа кәләше белән Ханбалыкның үзәк урамыннан узып китәчәк!

Бу турыда инде Ханбалык кешеләренә белдерелгән иде. Шуңа күрә бүген Хазаранда торучы каралар да, сатучылар да, якындагы далаларда күченеп йөрүче күчмәләр дә, Әтил буе авыллары кешеләре дә, Итил-торадагы күп санлы кунаклар да — барысы да, барысы да таң атмас борын Ханбалык ягына агыла башладылар. Елга аша бер яктан икенче якка туктаусыз каеклар йөреп торды. Каекчылар уң як ярга төзәнгән, бизәнгән ирләрне, хатын-кызларны, бала-чагаларны ташып

---

[1] Җавышгар — Хазарда хөкем итүче, яргучы.
[2] Теос — монда: румнар, ягъни христианнар алласы.
[3] Аденой — яһүд динендәгеләр алласы.

тордылар. Бүген базарлар ябылды, кибетләр эшләмәде. Каекларга төялгән кешеләр җырлар җырладылар, төрле уен коралларында күңелле көйләр уйнадылар. Кешеләрнең күңеле күтәренке, йөзләре көләч иде. Бүген алар, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә көләргә-елмаерга тиешләр.

Үзләренең юлларын аркылы кисеп, әледән-әле уң якка ашыккан, чыр-чу килгән каекларга Тотыш аптырабрак карады. Аның беркайчан да су өстендә берьюлы бу тикле күп каеклар да, күп кешеләр дә күргәне юк иде. Ул аларның нигә шулай бары бер якка гына ашыгуларын да, нилектән шулай күңелләре чамадан тыш күтәренке булуын да аңламады. Ул алай бик үк аңларга да тырышмады. Аның күңеле бөтенләй икенче нәрсәдә иде. Ул үзенең Аппагын уйлады. Юк, ул аны уйламады да, ул аны кайдадыр якында гына итеп тойды. Аңа үзе белән аның арасында ниндидер күзгә күренмәгән койма бар шикелле булып, тагын бераз бардың исә, яр читендә күренгән серле корылмалар, коймалар, сырганнар янына ук барып җиттең исә, шул күзгә күренмәгән койманы үтеп чыгарга, аны күрергә, аның белән кавышырга булыр шикелле булып тоелды. Ул ике арада яткан чын кирткоймаларны әлегә берничек тә күз алдына китерә алмады.

## XVI

Алар бераз соңгарак калдылар: яр буена инде көймә туктар урын да калмаган иде. Ханбалыкның биек коймасы яныннан ук бөтен яр буен — тамгаларны, басмаларны, күперләрне, комлыкларны көймәләр, каеклар, улаклар сарып алган иде, әйтерсең, Хазаранның барлык кешеләре бу якка күченгән. Көймә-каекларның барысы да кешесез, бары тик зуррак каекларда гына берән-сәрән сакчылар күренгәли.

Әмин, каек-көймәләр арасыннан буш урын карый-карый, үргә ишә башлады. Алар бер ярты чакрым чамасы кире менделәр дә комлы ярга туктадылар. Көймәне алар яртылаш ком өстенә тартып чыгардылар, киемнәрен, коралларын караштырдылар да, тар сукмактан яр өстенә менеп, барлык кешеләр юнәлгән якка — Ханбалыкның Киң урам дип аталган үзәк урамына карап киттеләр. Әмин Тотышны башта каган карарга алып барырга, аннан соң, кешеләр төркеме таралгач, урамнар, тыкрыклар бушап калгач, Ханбалык белән, дүрткел койма белән таныштырырга булды. Юлда ук ул аны: кеше арасында юк-бар сөйләшмәскә, кычкырып теләсә нинди сорау бирмәскә дип, кисәтеп куйган иде. Шуңа күрә алар юлда бөтенләй диярлек сөйләшмәделәр. Тотыш тулысынча Әмингә ышанды.

Ханбалык җиренә аяк баскач, беренче булып Әмин үзе сүз башлады.

— Әнә каган тирмәсе! — диде ул, сул якта, утрау уртасында калкып күренгән кызыл кирпеч сарайга күрсәтеп.

Тотыш барган җиреннән туктап калды, авызын ачып, каушап, таң калып каган сараена карарга тотынды. Ул аны баштарак утраудагы ниндидер таш кыя дип уйлаган иде.

— Ул да... андамы? — диде ул, пышылдап.

— Белмим,— диде Әмин, аның кем турында соравын аңлап.— Кашыңны җыерма! Әнә юл буенда чавышлар [1] карап тора!

— Белмисең?! — дип пышылдады Тотыш, аның кисәтүен тыңламыйча.— Белмәгәч... ничек соң... без аны каян табарбыз?

— Бүген тапмасак, иртәгә... Иртәгә тапмасак, берсе көнгә,— диде Әмин, шулай ук пышылдап, елмаеп.

---

[1] Чавыш — тәртип саклаучы.

Тотышка ул ничектер үз-үзенә ышанмыйчамы, теләмичәме сөйләшә шикелле тоелды.

— Син... ялганламыйсыңмы? — диде ул, балыкчының күзләренә карап.— Үзең булышмакчы булдың, үзең койрык болгыйсың түгелме?

— Юк, болгамыйм,— диде Әмин, чавышларга арты белән борылып.— Минә бу мәлдә аның кайда икәнлеген беркем белми. Күрәсең, шул кызыл өйдәдер.

— Алайса, кая барабыз соң без? Ник шул утрау ягына бармыйбыз? — диде Тотыш, тагын да ныграк аптырап.

— Син ычкынгансың, ахрысы, юлдаш! — диде Әмин, усал пышылдап.— Миңа бер генә сорау да бирмә. Үзем аңлатырмын. Кел, елмай!

— Ярар, синеңчә булсын...— диде Тотыш юаш кына.

Алар каган үтеп китәчәк Киң урам башына килеп җиттеләр. Тик монда да алар соңга калган булып чыктылар: урамның ике ягын да, тыгызлап тутыргандай, кешеләр сырып алган иде. Алар, ырып-ерып, уртадагы ачыграк урынга үтмәкче булдылар. Тик аларны беркем дә үз алдына уздырмады. Аларның тыкшынуын, ыгы-зыгы тудыруын күреп, шундук атлы чавыш килеп җитте. Егетләргә ул артка, буш урынга барып басарга боерды.

Күпмедер көтеп торганнан соң, урда ягында быргы тавышлары ишетелеп китте. Киң, тигез урамның ике ягын да тутырып торган, түземсез гөрләшкән кешеләр, быргы тавышына колак салып, тып-тын калдылар. Урамның Төньяк капкага — каган чыгачак капкага якынрак башында басып торган кешеләр, киселгән камыш кебек, барысы берьюлы җиргә аудылар. Бары тик урам читләрендә бер-берсеннән билгеле ара калдырып торган атлы чавышлар гына урыннарыннан кузгалмадылар да, аргы баштагы кешеләр генә баскан килеш тора бирделәр.

Төньяк капка ягыннан ишетелгән быргы тавышы якынайганнан-якыная барды. Җиргә йөзтүбән капланып яткан кешеләрнең барысы кебек, Тотыш белән Әмин дә, кызыксынуларын җиңә алмыйча, башларын калкытып, тавыш килгән якка карадылар. Болай карау бик уңайсыз иде, болай күбесенчә алдагы кешеләрнең арт саннары, янбашлары гына күренә иде. Тотышка бу аеруча кыен булды. Ул, терсәкләренә таянып, калкынгандай итте дә көтә башлады.

Менә уртадагы ачыклыкта ашыкмыйча гына атлап килгән яхшы ат күренде. Атны яхшы итеп бизәгәннәр, өстенә ефәк бөркәнчекләр япканнар. Атка атланган кораллы яшь ирнең дә өсте-башы ялт итеп тора. Ике куллап ул озын сапка беркетелгән ал байрак тоткан. Озын койрыклы байрак, җилсез көндә әлсерәп, яшь ирнең иңбашына салынып төшкән. Беренче байракчы узып китү белән, аның артыннан тагын унлап байракчы күренде. Алар барысы да яшьләр, чибәрләр иде. Байракчылардан бераз калышып, быргычылар, доңгерчеләр килеп чыкты. Алар якыная барган саен, быргы кычкырткан, дөпелдәгән тавышлар да көчәя барды. Тотыш, онытылып, шау-шу арасында башын тагын да ныграк күтәрмәкче булды. Шул чакны искәрмәстән аның аркасына авыр, тупас нәрсә килеп төште. Авыртудан ул чак кына кычкырып җибәрмәде — Әмин ачу белән кулыннан тотып алмаса, күрәсең, кычкырып та җибәргән булыр иде.

— Билсез каласың киләмени?! — дип пышылдады Әмин аның колак төбендә генә.

Тотыш исенә килеп күзләрен ачып җибәргәндә, урам уртасын инде ир-атлар каплап алган иде. Алар, быргы, доңгер тавышларына җайлашып, тигез, нык адымнар белән киләләр. Тотыш каганны никтер менә шул атлылар арасындадыр дип уйлады — алар шундый бай, матур киенгәннәр, шундый тазалар, кырыслар иде! Быргы тавышлары аның йөрәген телеп-телеп алды. Атларның таш җәелгән урамга дөп-дөп

басулары аның җукрәген таптаган кебек тоелды. Менә шулай, башын да калкыта алмыйча, тузан иснәп, күршеләренең табаннарын иснәп, җиргә капланып ятарга тиеш булуы, шул ук мәлдә якыннан гына Аппак узып китәргә тиешлеге турында уйлап, үзенең көчсезлеге, кечкенәлеге турында уйлап ул нишләргә дә белмәде.

Шул чакны җиргә ауган кешеләр өстеннән, күктәге кояш яктысыннан да көчлерәк булып, ниндидер яктылык шуып үтте. Тотыш, аңлаешсыз бер курку белән, каушап кинәт күзләрен йомды. Яңадан күзләрен ачып караса, урамнан, атлы ирләр барган яктан ниндидер зур, түгәрәк нәрсәнең кояшта чагылып-чагылып китүен күреп алды. Нәрсәнең шулай бик көчле булып чагылуын ул тиз генә төшенә дә алмады. Алпак дисәң, алпак түгел, калкан дисәң, калкан түгел... Үзе, ахрысы, алтыннан — сап-сары. Баш очына күтәргәннәр. Күктән кояш төшкән дә, шуны шулай күтәреп баралар дип торырсың!

Кинәт Әмин каты гына итеп аның янбашына төртеп алды.

— Әнә! — диде ул, пышылдап.

Тотыш, күзләрен зур ачып, бөтен күңеле белән алга омтылып, урам якка текәлде. Әле генә кораллы ир-атлар тулып килгән урам уртасы бушап калган иде. Алтын «кояш» тоткан кеше дә алгарак узып киткән иде. Бушап калган урам уртасыннан, таза атларга атланып, кечкенә төркем булып, ниндидер ирләр килә. Аларның икесе, алтын төсендәге сары байрак күтәреп, башкалардан берничә адым алдарак баралар. Байрак күтәргән ирләр артыннан тагын дүрт ир килә. Кулларына алар ниндидер озын колгалар күтәргәннәр. Колга башларына күк төстәге киң ефәк чыбылдык беркетелгән. Менә шул чыбылдык астында, акбүз атка атланып, ниндидер кеше килә. Җиргә ятып караганда да аның йөзен бик үк аерырлык түгел иде. Бары тик дүрт колга башындагы чыбылдык итәкләре чайкалып, ачылып киткәндә генә, ул кешенең башындагы алтын алпагы, сирәк сакалы, озынча чандыр йөзе күренепкүренеп кала иде.

— Каган! — диде Әмин, пышылдап.

Тотышның никтер моңа әз генә дә исе китмәде. Әллә аның күзен будылар, әллә анда ниндидер эчке үзгәреш барлыкка килде — үз-үзен ул бик тыныч тотты. Күтәрмә җаваҗ астында акбүз атта барган ул чандыр кешегә карата ул ачу да, көнләшү дә, курку да, олылау да тоймады. Аның турында шул тикле күп сүзләр, куркыныч сүзләр ишетеп тә, үзен шундый якыннан күргәч, Тотышны күңел кайту шикелле бернәрсә биләп алды. «Нәрсәсе изге икән соң аның?» дип уйлады ул үзалдына. Бу исә аның бердәнбер теләгән — үзенең Аппагын коткару теләген тагын да ныграк көчәйтә төште.

Чыбылдык астындагы каган узып күп тә үтмәде, шундый ук колгаларга беркетелгән ак чыбылдык-чатыр күтәргән башка ирләр төркеме күренде. Чатыр астында, баштанаяк ефәк киемнәргә киенеп, алтынкөмешләрен, чын ташларын елкылдатып, атка атланган хатын-кыз килә иде. Аның да аты акбүз иде. Атның ике ягыннан да, иярдәге кыз егылып китә күрмәсен дигән сыман, җәяүле яшь ирләр атлый иде.

Бу — ул иде. Аппак иде. Аның башы түбән иелгән, куллары салынып төшкән иде.

## XVII

Каган белән яшь каләштән бер чакрым чамасы артка калып, урам уртасыннан кораллы ир-атлар узды. Алар бик күп иде. Алар узганда урамда җиңелчә тузан болыты күтәрелде, тавыш күтәрелде.

Хазар каганының уникe меңлек атлы чирүе узып киткәч, йөзтүбән капланып яткан кешеләр кузгалыша башладылар.

Тотышны Әмин тарткалап торгызды. Ул исерек кеше кебек иде.

Әмин аны култыклап кайдыр читкә алып китте. Бераздан алар яр буена, үзләренең көймәләре янына килеп чыктылар.

— Инде ашап алсак та ярый — ачыктырды,— диде Әмин, көймә төбеннән ниндидер төенчек табып алып.

Шул ук мәлдә ул, коры камыш, тизәк җыеп, яр буенда ут тергезеп җибәрде. Монда аулак иде. Кешеләр барысы да диярлек, көймәләренә утырып, китеп беттеләр. Бөтен су буенда алар икесе дә, тагын берән-сәрән балыкчылар гына торып калды.

Әмин көймәдә алып килгән балыкларны кыздырды, бертуктаусыз ут-учак белән булашты. Тотыш, әлерәк кенә урамда яткан сыман, ком өстенә сузылып ятып, суны күзәтте. Беркем берни сөйләшмәде. Сөйләшмәсәң дә, барысы да аңлашыла иде, барысы да көн кебек ачык иде.

Аппак монда. Ул кайдадыр якында гына. Өстенә ул ят киемнәр кигән, аның янында — ят ирләр. Алар аның белән янәшә генә атлыйлар, алар аның киемнәренә орыналар, курыкмыйча, тартынмыйча алар аның йөзенә-күзенә карыйлар! Бары тик ул гына — Тотыш кына тотарга тиеш булган кулларын тоталар, бары тик ул гына сыйпарга тиеш булган чәчләрен сыйпыйлар! Чит ирләр. Белмәгән-күрмәгән ирләр. Гарәп ишкәкчеләре болгар кызларын мыскыллаган кебек, алар, тартынмыйча, курыкмыйча, аны мыскыллыйлар! Синең күз алдында... Тегендә Кызлар утравында ул кардәшләрен яклап берни эшли алмаган кебек, монда да ул үзенең сөйгәнен яклап берни эшли алмады. Шуннан да зур оят, шуннан да зур көчсезлек бармы, тәңрем, җирдә?!

Туган Әтил, олуг Әтил, кеше баласына үз-үзен, үз якынын яклый алмаудан да зуррак оят бармы, булганмы?! Күпне күргәнсең син, күпне ишеткәнсең, изге елга. Нигә эндәшмисең син дә, батыр үзән? Әллә син дә куркасыңмы, әллә син дә качасыңмы аннан... бөек каганнан?

Әтил ага да ага. Еракта, Кызыл яр турысында Чулман ничек аккан булса, ул да шулай ага да ага. Кыймылдап, ухылдап, нидер пышылдап ага... яр читләрен ялап, көймә-каек төпләрен сыйпап ага да ага.

Чулман ярында аның изге анасы Койтым бикә дә менә шулай игелексез улгы кебек карап сагышлана микән шушы мәлдә? Аппак өчен аның йөрәге ничек өзгәләнсә, аның да йөрәге шулай өзгәләнә микән үзенең югалган улгы өчен?

Шуран катаудагы ише Тәңкә уйлый микән аны шушы мәлдә? Кетә микән аны Күке улгы белән бергә яр башына чыгып?

Әйтче, Әтил,— күрдеңме син минем анамны, күрдеңме син минем Тәңкәмне? Күрдеңме син минем каным нәни улгымны? Уйлыйлармы алар мине, көтәләрме алар мине, туганым Әтил?

Әтил ага да ага... Алар монда икәү. Әтилнең яртысы — Чулман. Алар кавышканнар, алар табышканнар. Башкаларда аларның эше юк. Юк, анасы да, Тәңкәсе дә, улгы да аның турында берни белмиләр булыр. Юкса, Әтил ни дә булса әйтер иде, сөйләр иде. Алайса син, Әтил, аларга әйт минем турыда. Ярга ташланган балык кебек, кирәксез бер агач кебек комда аунап ята, диген. Якында гына, берничә адым читтә генә аның сөеклесе кан-яшь түгә, үзен беркем йолып ала алмаганга үпкәсеннән, ачуыннан өзгәләнә, диген.

Юк шул, Әтил кире акмый. Әтил бары бер генә якка ага.

Ичмасам җил дә исми бу якларда. Нинди бөркү, нинди авыр монда! Нинди кысан, нинди кыен монда! Үзе шундый якты, шундый аяз, тик шулай да берни күреп булмый монда. Ничек кеше яши монда?

Аппак, иркәм, канатым, күзем явы, кызалагым [1], ничек яшисең син монда?! Мин барыбер сине йоларга тиеш, мин барыбер сине тартып,

[1] Кызалак — тюльпан.

йолкып алырга тиеш бүре базыннан! Әтил, әйт син ана, еламасын, кайгырмасын — мин барыбер коткарырмын аны!

Ашагач Әмин аны Ханбалыкта йөртте. Ул аны нииндидер тар гына тыкрыклардан алып китте, ниндидер киң язуларга, җимешлекләр янына алып чыкты. Ул аңа үзе белгән бөтенесен сөйләде, үзе белгән бөтенесен күрсәтте. Алар икәүләп читтән генә койманы карап йөрделәр. Койманың бер төше тәбәнәк иде, ярым җимерек иде. Тотыш берни сорашмады. Ул бары тыңлады да үз уйларын уйлады, барысын да исендә калдырды. Кич була башлагач, алар яңадан көймәләре янына килделәр.

— Бүгенгә җитәр,— диде Әмин, көймәне суга тартып.— Әйдә, утыр, киттек.

— Кая? — диде Тотыш.

— Кая булсын — үзебезгә, утрауга. Безне инде болай да югалтып яталардыр,— диде Әмин.

— Мин беркая китмим,— диде Тотыш искиткеч бер тынычлык белән. Яшь балыкчы, аның мондый сүзләрен ишетеп, каушый калды.

— Карале, юлдаш, син чынлап сөйлисеңме? — диде ул, пошынып.

— Чынлап,— диде Тотыш.

— Безне Габдулла ага югалтып ятадыр, борчылып...

— Борчылсын. Мин аңа кайтырга дип сүз бирмәдем.

— Мин китәм! Кал үзең генә! — диде Әмин, ачуланасы килеп, кулын селтәп.

— Бар, китә бир,— диде Тотыш.— Сау бул. Изгелегеңне онытмам.

— Туктале, нишләмәкче буласың соң син? — диде Әмин.— Монда калып нишләмәкче буласың? Без соң барысын да уйлап, җайлап эшләргә дип сөйләшмәдекмени?

— Мин беркая китмим! — диде Тотыш, нык итеп, кабатлап.— Теләгемә ирешмичә, мин моннан аяк та атламаячакмын! Мин инде барысын да уйладым да, җайладым да. Яр буенда көймәләр җитәрлек, Әтил кая да булса алып чыгар әле.

— Мин сине беркая җибәрмим! Син болай бөтен эшне бозачаксың! — диде Әмин, чын-чынлап куркуга төшеп.

— Синнән сорап тормаслар! — диде Тотыш.

Әмин, әйтер сүз таба алмыйча, тынып калды. Көймәсен ярга кире чыгарды да, тезләрен кочаклап, комлы яр читенә утырды.

— Болай булгач, мин беркая китмим,— диде ул, үзалдына сөйләнеп.

Алар, бер-берсенә карамыйча, бер-берсенә якынлашмыйча, ком өстендә шулай утырдылар да утырдылар. Яр буенда якында гына беркем калмаган иде. Алар, нидер көткән кебек, Әтилгә карап утырдылар да утырдылар...

Сиздермичә генә көн сүрелде. Су өстеннән салкынча җил исә башлады. Әмин, юлдашын кайтырга күндерә алмаячагына ышангач, яңадан учак ягып җибәрде, балык кыздыра башлады.

Тотыш бернигә катнашмады, бернигә борчылмады, кайгырмады — таштан уеп ясалган сын шикелле, тезләренә таянып утырды да утырды. Ул караңгы төшүен, койма эчендәге ялгыз өйләр ягында утлар кабынуын көтте. Көн яктысында ул анык булырга тиешле өйне күреп, күңеленә беркетеп куйды. Анда, ул өй тирәсендә, озын колгаларда байраклар җилферди иде. Койманың ярым җимерек төшеннән ул ерак түгел. Барысы да күңелдә, барысы да күз алдында. Караңгы төшкәч ул турыда утлар яктырак янса, Әмин ялгышмаган булыр.

Әтил ага да ага... Әле кайчан гына аксыл-яшькелт иде, инде әнә кара төскә керде. Елкылдап, тере кебек кыймылдап, ыңгырашып ага да ага. Кайчаннан бирле агасың син шулай, Әтил? Моннан йөз ел элек, мең ел элек әлегәчә туктамыйча шулай актыңмы син? Күптән,

бик күптәннән синең яр буеңда әлегедәй берәр егет утырдымы шулай сагышланып?

Нинди көч бу, нинди иксез-чиксез көч, тереклек синдә, Әтил?! Каян килә бу тикле көч, бу тикле су, Әтил? Мин очармын... тузан булып, томан, төтен булып мин очармын күккә, Әтил. Уйларсыңмы мине шунда, сагынырсыңмы моңсу бер тамчыңны, бер тузанны, чиксез Әтил?!

Ах, нинди тереклек бу синдә, олуг үзән! Көч бир миңа, ныклык-корычлык бир миңа, бер углыңа... бер тамчыңа, анам Әтил! Йөрәк түзми. Мин кузгалдым, сау бул, Әтил!

Әйе, Әмин алдамаган. Әнә шул турыда бик күп булып утлар янды... бик күп утлар, якты, куркыныч утлар...

Ул изге суда битен юды, кулын юды. Тун чабуы астындагы бөктәсен изге суга манчып алды. Ул кузгалды. Ут күбәләге утсыз тора алмаган кебек, ул да ут-ялкынга карап китте.

## XIX

Төн урталарында ул исән-имин аның өенә барып җитте. Аны беркем сизмәде, беркем күрмәде. Кирәк җирдә ул песи булып посып торды, кирәк җирдә җылан булып җирдән шуышты. Юлына аркылы төшеп, йокымсырап яткан симез сакчыларны ул бернинди тавыш-тынсыз юкка чыгарды.

Багана башларында чытырдап кара май яна иде. Шуңа күрә тирә-якта көндезгедәй яп-якты иде. Шулай да ул сиздермичә, күренмичә анда барып җитте.

Ишек төбенә үк килеп җиткәч, аның авызлыкланган ярсу йөрәге ашкынып тыпырчына башлады. «Тыныч бул! Тыныч бул!» — диде ул үзенең йөрәгенә, тешләрен кысып, утлы күмердәй очкынланган күзләре белән тирә-якны капшап.

Ул ишекне эчтән бикледер дип уйлады. Бауны тиз генә тартып җибәрде дә, күзен йомып упкынга ташлангандай, өй эченә атылып барып керде. Өйдә караңгы иде. Баздагы кебек, төнге су төбендәге кебек караңгы иде. Юк, алай ук түгел иде бугай. Яктыдан кергәнгә генә шулай иде, ахрысы. Тыштан түбәдәге түгәрәк төнлектән өй эченә кызгылт ут шәүләсе төшә иде.

Ул капшанып диярлек түргә узды. Агачтан сырлап ясалган биек ятакта кемдер йоклап ята иде. Юк, ятактагы кеше йокламый иде, ахрысы: үлгән сыман ул йөзтүбән капланган иде. Өйдә кемдер барлыгын сизепме, югарыдан төшкән яктылыкны күрепме, ул башын калкытты.

Менә ул кыймылдап куйды, кулын күтәреп, яктылыктан күзен каплады. Шуннан соң ул никтер торып, яланаяк килеш, идәндәге йомшак келәмгә басты.

Тотыш, ярсу йөрәген әле булса ычкындырмыйча, өстән төшкән тоныкк яктылыкта аның таныш йөзенә — сулыккан, агарынган йөзенә, елый-елый шешенеп беткән күзләренә карап торды.

Ул әле бөтенләй үк уянып җитмәгән иде бугай. Аягына басканда да әле ул каршысындагы кешене абайлап җиткермәде, ахрысы.

Менә ул аны күреп алды. Сискәнеп, калтыранып китте. Авызы ачылып калды. Йөзенә коточкыч курку билгесе чыкты. Ап-ак кулы битен каплау өчен югары күтәрелде. Шул ук мәлдә ул, бөтен өйне, бөтен урданы, бөтен аҗунны куркытып: «а!» дип кычкырып җибәрде. Артына чигенде, ятагына менде дә, юкка кыйналган көчек сыман шыңшып-ыңгырашып, мендәрләр арасына сыенды.

— Бу мин... курыкма...— диде Тотыш тамак төбеннән чыккан бер өн белән.

Ул ятакка таба бер адым атлап куйды.

— Килмә, килмә! — дип кычкырды Аппак, чырылдап.
— Бу мин... Тотыш,— диде егет.— Мин сине эзләп килдем. Мин сине алырга килдем. Тынычлан. Мин...
Ул, әйтәсе сүзен әйтеп бетермичә, ятак янына ук килде. Бүре күргән куй кебек, Аппак аңа коты алынып карады. Ул аякларын кочаклап, өстенә ябынгычын каплады. Ул, ахрысы, аның чыннан да Тотыш булуына әле булса ышанып житмәгән иде.
— Аппак! Сөеклем! — диде егет, ачыргаланып.— Курыкма! Бу — мин... Тотыш. Карама миңа шулай итеп.
— Юк, юк! — диде Аппак, башын чайкап.
Тотыш нәрсә уйларга да белмәде. Алар, бер-берсенә якын килергә куркып, бер-берсенә карашып, беравык тынып тордылар.
Кинәт Аппак үксергә тотынды. Битен куллары белән каплап, йомгактай бөгәрләнеп елады ул. Ике арадагы киртә юкка чыкты. Тотыш, үзенең кайдалыгын, нишләргә тиешлеген исенә төшереп, кискен бер омтылыш белән аны тотып алды, күкрәгенә кысты.
— Тиз бул, киен! — диде ул, ашыгып.— Сакчылар сизгәнче, безгә моннан чыгып китәргә кирәк. Аңлыйсыңмы, тиз бул, тиз!
Аппак, яшьле күзләре белән аңа карап, башын чайкады.
— Юк,— диде.— Син бар. Син кит. Мин... калам.
Тотышны кинәт яшен суккан кебек булды.
— Каласың?! — диде ул, шаккатып.— Бу — мин, Тотыш! Ышанмыйсыңмыни? Төш түгел бу, өн. Менә минем сул як беләктәге ярам, менә минем ияк астындагы миңем.
— Син — Тотыш... ышанам,— диде Аппак, чит-ят бер тавыш белән.
— Ышангач?! Онытмадыңмы?
— Онытмадым. Бары да истә,— диде Аппак, пышылдап, салкын гына!
— Шулай булгач?! Ни булды сиңа? Аппагым, ни булды?! Юк, мин сине алмый китмим. Безне көймә белән көтеп торалар. Таң атканчы тиңгезгә чыгарбыз. Угызларга качарбыз... Хәрәземгә... Багдадка — кая телисең! Икәү мәңге бергә булырбыз... Әтил белән Чулман кебек. Бергә, бергә! Мин синең өчен килдем, аңлыйсыңмы шуны, Аппагым? Синсез миңа яшәү юк. Мин сине шушы көе алып китәм — тавышланма гына!
Ул аны юрганына төреп, сабый бала кебек итеп күтәрде дә, ишеккә борылды. Аппак, карышып, кычкыра башлады.
— Ник, ни булды?! — диде егет, еларга житешеп, өзгәләнеп.
— Мин... каган хатыны,— диде Аппак.— Иола... тәңре... Мин каргыштан куркам, Тотыш.
Егетнең искәрмәстән тез астына суккан кебек булды. Ул, тыны бетеп, көче бетеп, аны кулыннан ычкындырып жибәрде. Каган хатыны Аппак идәнгә басты. Тотыш аңа куркып, чиркәнеп карады.
— Син ничек?..— диде ул, гыжылдап.
Ул аны яңадан эләктереп алды, ашардай булып аның агарынган, төссез-яруксыз йөзенә, күзләренә карады.
— Мин сине... үз кулларым белән... буып үтерәм! — диде ул.
— Үтер,— диде Аппак, елмаеп.
Тилергән, үз-үзен белештермәгән егет аның сүзләрен ишетмәде. Ул бары аның елмаюын гына күреп калды. Шул чакны, әйтерсең, кинәт кояш балкыды, әйтерсең, ажунда булмастай искиткеч нәрсә булды. Тотыш яңадан аны кочып алды, шашкын бер кайнарлык белән, ярату белән кочып алды.
— Юк, юк! — диде ул, кабаланып, аның йомшак чәчләрен, кайнар битен, иңбашларын сыйпап-үбеп.— Юк! Киттек... Тиз бул, киттек! Мин сине кичерәм. Син — минеке... Киттек!
Ул яңадан аны иңбашына салды, яңадан ишеккә борылды.

Сөекле табышын күтәреп ул койманың ярым җимерек турысына йөгерде.

Тирә-якта ниндидер тавышлар ишетелде, күз алдында — әле анда, әле сулда озын колгалар башына утыртылган ниндидер утлар биеште. Күпмедер җир киткәч, йөзем куаклары янында, ачык урында, үз каршысында гына очлы сөңгеләр, ачулы йөзләр, бик күп утлар күреп, ул ирексездән туктап калды. Ул моннан алай җиңел генә үтеп китеп булмаячагын аңлады. Ул, табышын җиргә куеп, шундук кылычына тотынды, сөңгедән дә очлырак, як-яктагы утлардан да ялкынлырак күз карашы белән үз тирәсен ялмап алды: алар күп иде, чиксез күп иде!

Ул ягы алдында каушап калырга, кемнең дә булса китереп органын көтеп торырга күнекмәгән иде. Ул, куркусыз барыс кебек, таш кыядан ыргылган болан кебек, чәнечкеле сөңге чытырына ташланды. Берсенең утлы колгасын кыеп төшерде, икенчесенең кулындагы калканын йолкып алды, өченчесенең аягын чапты.

Сөңге урманы кысылганнан-кысыла барды. Җирдә яткан Аппакның әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, уңга-сулга селтәнеп, тар гына аралыкта ул ары-бире сугылды.

— А-а! Менә кем икән! — дип кычкырды кинәт аның колак төбендә генә таныш тавышлы бер кораллы сакчы.

Тотыш, күзләрен ачыбрак караса, үзенең күкрәк турысына очлы сөңгесен терәп, коточкыч елмаеп Корыч-Тимер басып торганлыгын күреп алды. Аның чак-чак кына башы әйләнеп китте. Ул орырга дип ярсып кылычын күтәрде.

— Булмады! Син җиңелдең! — дип кычкырды Корыч-Тимер, тыелгысыз бер куаныч белән.

Шул ук мәлдә очлы, үткер тимер, киемнәр аша, сөякләр аша чыгып, Тотышны җиргә екты. Бер уңайдан озын сөңге аны мәңге үзенең сөеклесе белән кавыштырды.

Каргалган, тапланган өйгә сакчылар төрле яктан ут төрттеләр. Төн карасын ярып күккә төтен, ялкын күтәрелде. Ялкын белән бергә ике яшьнең коты тәңре катына очты.

## Соңгы бүлек

### I

Менә тагын яз житте. Кышкы озын төннәрдән соң, каты салкыннардан, ачы бураннардан соң тагын яз килде... Тагын Чулманда боз кузгалды, җылы яктан кояш белән бергә кошлар килде... Балыкчылар ауга чыктылар. Бозын ватып шаулап-җәелеп аккан елга кебек, тормыш тагын ярларына сыеша алмыйча гөрләп ага башлады.

Тәңкә быел бернәрсәгә дә катнашмады — башка еллардагы кебек, җир ачылу белән, тау кашына кызлар уенына да йөрмәде, балыкчылар белән ауга да чыкмады, шулай ук өй эчендәге эшләргә дә күз салмады. Ул, үзенең койма өстендәге җылы, аулак урынына чыгып утырды да, суны күзәтте. Моннан берничә ел электәге кебек, ул әле булса аны көтте. Алмыш ханның Аппагын каган алып киткән. Айтулдыдан ул баш тарткан. Шулай булгач, ул барыбер кайтырга тиеш түгелмени? Ул әйтте: мин сезне ташламам, көтеп торыгыз, диде. Шул ук сүзләрне ул Торымтайга да әйткән: кайтырмын, алып китәрмен, дигән. Шулай булгач, ул үз сүзен үтәми калмас. Шундый сагынып, саргаеп, шундый өзелеп көтеп торучылар булганда, ул берничек тә кайтмый кала алмаячак!

Язгы салкын җилдән бөрешеп, әле шулай моңаеп, әле үткәннәрне күз алдына китереп утырганда, артта кемнеңдер аяк тавышлары ише-

телде. Тәнкә артына борылып карады. «Атаммы әлләә?» дип уйлады ул. Ярый әле ул түгел икән! Ул булса, тиргәп, куалап төшерер иде. Аның белән ара бөтенләй бозылды. Ул аңа үз кызы булган өчен генә, кайчандыр яраткан кызы булган өчен генә түзеп тора. Аннары ул Күкене дә ярата бугай.

— Безнең әннә монда икән! — диде Торымтай, Тәнкә янына килеп.— Без сине эзлибез дә эзлибез. Салкын түгелме сиңа, әннә? Монда жил. Без сиңа менә жылы толып китердек! Төренеп кенә утыр әле шуна.

Торымтай бер кулына зур толып тоткан, икенче кулы белән Күкене житәкләгән иде.

— Әннә, мин балыкка балам! — диде Күке, Торымтай кулыннан ычкынмакчы булып.— Толымтай жибәлми. Мин балыкка балам!

— Атаң кебек зу-ул булгач барырсың,— диде Тәнкә, урыныннан торып, Күкене кулына алып.

Торымтай ул утырган аркылы агачка толыбын жайлап жәеп куйды.

— Бүген жиллерәк, әллә аска төшәбезме? — диде ул.— Төсең качкан. Терелеп тә житмәгәнсең. Төшик, булмаса.

— Утырыйк әле бераз,— диде Тәнкә.

Углын ул үзенең тезенә утыртты, тезләрен дә, углын да толыпка төрде дә, күрми калдым, ахрысы, дигән сыман, янадан су өстенә текәлде. Кинәт ул йөткерә башлады. Ул инде былтырдан бирле йөткерә. Кыш көне бераз тынып торгандай итте дә, яз житү белән әнә тагын көчәеп китте.

— Әйдә, төшәбез! Монда жил,— диде Торымтай тагын да.

— Утырыйк әле,— диде Тәнкә йөткерүдән туктаган арада.— Баланы ал. Аңа салкын.

— Миңа салкын түгел, әннә! — диде Күке.— Мин балыкка балам.

Анасы кулыннан ычкындыргач та ул шуышып аның тезеннән төште, йөгереп китмәкче булды. Торымтай аны шундук эләктереп алды.

— Сез төшегез, сез...— диде Тәнкә, учы белән авызын каплап, йөткерә-йөткерә.

— Ярамый, төшәбез. Үзем менәрмен карарга,— диде Торымтай, чарага куймыйча.

Ул Күкене кулыннан ычкындырды да Тәнкәне көчләп диярлек урыныннан торгызды, әле генә жайлап куйган толыбын кире алды.

— Ул миңа сине карап-саклап торырга кушты. Ныклап торып аяктан егылсаң, ни диярмен мин аңа? — диде Торымтай, бала-чаганы юаткан сыман сөйләнеп.

Тәнкә килешкәндәй булды. Әкрен генә атлап, өчәүләп алар баскычтан төштеләр. Күке, үскән углан буларак, барысыннан да алданрак төште, йөгергәләп каядыр китеп тә барды. Ялгыз өенә кайтып учакка ягып жибәргәч кенә Тәнкә аның юклыгын күреп алды.

— Яшь колын кебек. Атасына охшаган,— диде ул, елмаеп.

Соңгы көннәрдә ул шундый сүзләрне бик еш әйтә башлады. Ул беркайчан да «Тотыш» димәде, аны сагынып көтүе турында да беркайчан да кычкырып әйтмәде. Ул бары үзенең Күкесен мактады да, бары аның «атасын» гына исенә төшерде. Торымтай белән алар бер-берсен бик яхшы аңладылар. Торымтай да беркайчан да үзенен әлекке иясен кычкырып телгә алмады. Ул бары көрсенеп кенә куйды. Ул инде, Тотыш өчен көрсенүдән бигрәк, Тәнкә өчен көрсенә иде. Тәнкә аның күз алдында сыза барды, юкка чыга барды. Торымтай, кулыннан килгәнчә, ничек тә аңа булышырга тырышты — үзе белгән имнәр белән имләде, белекле имчеләр белән киңәште, кирәкле им сулары, им тамырлары алып кайту өчен, берничә тапкыр Ага-базарга барды. Тәнкә үзе, әйтерсең, берни сизмәде. Ул, ахрысы, әле булса үзен әлеккечә таза-сау дип белә иде.

Учак янында алар сүзсез генә җылынып утырдылар. Утыра торгач, Таңкә кинәт әйтеп куйды:

— Торымтай... ул кайтканчы үлмәм микән мин? — диде.

— Ни сөйлисең син? — диде Торымтай, тыныч булырга тырышып.— Авызыңнан җил алсын!

— Тын җитми. Әйдә ирекка, әйдә койма өстенә,— диде Таңкә, ялынып.

— Әйдә алайса,— диде Торымтай көрсенеп, теләмичә генә.

Ул аны яңадан толыбына төрде, сабый бала кебек күтәрде дә урамга чыкты.

— Сизгер син, Торымтай. Бай бул,— диде авыру хатын, пышылдап.— Аякның көче юк. Әллә нәрсә булды.

— Ашамыйсың. Ашарга кирәк,— диде Торымтай, шелтәләп. Аннары йомшак кына өстәп куйды: — Көннәр җылынсын әле менә — җүнәрсең,— диде.

## II

Алар койма өстенә менеп җайлап утырырга да өлгермәделәр, яр астында ниндидер ыгы-зыгы ишетелде. Таңкә үрелеп аска карады. Кинәт аның йөзе балкып китте: яр буена Акбүре каеклары килеп туктаган иде!

Тамга сакчылары исә акбүреләрне бик үк теләмичә генә каршыладылар. Моннан ике-өч ел элек килеп киткән Акбүре кунакларын алар әле онытып бетермәгәннәр иде. Шул игелексезләр, шул башкисәрләр аркасында күпме талау килде аларга! Шулар аркасында, шуларның Тотыш атлы юлбасарлары аркасында би кызы әнә чиргә сабышты, атасы белән икесенең арасына кара мәче ятты. Би тыныч булмаса, каралар да тыныч түгел. Барысы да шул акбүреләр аркасында!

Акбүреләр турында ишетеп, Ямгырчы биның дә чырае сытылды.

— Башлары кем? — диде би яр астыннан менгән сакчыга.

— Хатын кеше. Койтым бикә,— диде сакчы.

Мондый сүз ишетеп, Ямгырчы би җиңел сулап куйды. Койтым бикә! Ул да исән икән. Юк инде, акбүре булмагае, әллә кем булсын, Койтым бикәгә караңгы йөз күрсәтү килешмәс.

Ул яхшы киемнәрен киде, яхшы атын иярләргә кушты. Акбүреләрне каршыларга аның яшь хатыны да, Таңкә белән Торымтай да, тугантумачалары да төште. Койтым бикәне Ямгырчы би элеккечә яшь, чибәр итеп күрермен дип уйлаган иде. Күргәч исе китте. Аның каршысында ул белгән, ул күңелендә йөрткән Койтым бикә түгел, бөтенләй икенче Койтым бикә басып тора иде. Өч-дүрт ел эчендә ул танымаслык булып үзгәргән иде. Баштанаяк ул ирләрчә киенгән иде. Көмеш алпагы астыннан аның иртә көмешләнгән чәчләре күренеп тора. Күләгәле, яруклы күз төпләренә аның нечкә генә булып җыерчыклар сузылып яткан. Кайчандыр тулы, сусыл иреннәре аның кысылган, кипшереп калган. Күз карашында ныклык, кырыслык билгесе, аннан да бигрәк — әчкә, тирәнгә яшерелгән кайгы-сагыш билгесе күренә.

— Язмыш мине синең җиреңә китерде, Ямгырчы би,— диде Койтым бикә, исәнлек-саулык сорашканнан соң.— Углым Тотышка күрсәткән явызлыкларыңны уйлаганда, синең җиреңә кунак булып аяк басу түгел, синең ягыңа әйләнеп тә карый торган кеше түгел мин. Тик шулай да, күктән тәңре күреп тора, мин синең кебек әчкерле, үчлекле түгел, Ямгырчы би! Минем кайгым зур. Минем кайгым сине куралмаудан да, үчтән дә, кеше әшли ала торган барлык явызлыклардан да зуррак, көчлерәк, би. Син Кызыл Ярга килеп киткәннән бирле мин ике иремне югалттым. Ишеткәнсеңдер: Күрән би егылып үлде, Котанны Алмыш хан үтертте. Мин, Ямгырчы би, Күрәннән дә, Котаннан да сөек-

ләрәк өченче кешемне югалттым. Мин углымны... Тотышымны югалттым, би! Мин колынын корт ашаган бия кебек, мин бозавын аю капкан болан кебек. Мин кузысы тирән ярга төшкән куй кебек. Минем йөрәк маем, бавыр итем... бердәнберем... Тотыш углым юк булды, би! Синдә минем туруным [1] бар, киленем бар. Мин синен барлык явызлыкларыңны оныттым, Ямгырчы би! Мин яңадан синен белән туганлашырга килдем... туруным Күке, киленем Тәңкә янына килдем. Җиреңә аяк бастырасыңмы, Ямгырчы би?

Ул, башын югары тотып, Ямгырчы биненң күзенә туры карап сөйләде, бераз гына үртәлеп, бераз гына өстен торып сөйләде.

— Мин сине җиремнән, катавымнан кире борып җибәрә алмыйм, Койтым бикә,— диде Ямгырчы би.— Сүзең чын: миндә синең туруның бар, килениң бар. Ант итеп әйтәм: мин дә синен белән татулашуга каршы түгел. Түрдән уз минем изге җиремә, Койтым бикә! Түрдән узыгыз, Акбүренең кыю ирләре!

— Бай бул, Ямгырчы би,— диде Койтым бикә.— Җирен-суың тыныч булсын, илен-көнең имин булсын. Минем әле сүзем бетмәде. Синең җиреңә аяк басканчы мин шуны да әйтергә тиешмен: мин синдә күп тормам. Мин Алмыш ханга юл тотам. Мин аннан углымны таптырырга барам. Уең үзгәрмәдеме, сүзеңне бозмассыңмы, би?

— Юк, үзгәрмәде, Койтым бикә,— диде Ямгырчы би.— Мин синең юлыңа киртә булмам. Түрдән уз, кайгылы ана.

Ямгырчы би сүзен бозмады. Ничек тә ул бикәнең күңелен күрергә тырышты: шундук казаннар асылды, сарыклар суелды, базлардан ачы бал тулы чапчаклар, кисмәкләр чыгарылды. Тик Койтым бикәнең ашауэчүдә аз гына да кайгысы булмады. Ул күбрәк килене Тәңкә белән, туруны Күке белән юанды.

Төнне Койтым бикә килене белән бер өйдә кунарга теләвен белдерде. Була алмаган биана белән була алмаган килен төне буе сөйләшеп, серләшеп чыктылар. Бер-берсенә карата алар моңарчы булмаган бер туганлык, якынлык тойгысы кичерделәр.

— Үле булса, ишетелерие,— диде Койтым бикә югалган улы турында.— Кем белә аны, әллә хан берәр җиргә озаткандыр, я булмаса ябып тотадыр, кол итеп саткандыр... Кайда гына булмасын, мин аны барыбер табарга тиешмен!

Мондый сүзләрдән соң Тәңкә бөтенләй үзгәреп китте, терелеп, яшәреп китте. Ул инде аны чынлап торып, ышанып көтә башлады.

III

Шуран катауда ике кич кунганнан соң акбүреләр Болгар-торага юл тоттылар.

Алар китеп күп тә үтмәде, Ямгырчы бигә Алмыш ханнан тартык килеп төште. Тартык Ямгырчы бигә ханның кичекмичә бөтен ыруы белән Өчкүл янына килеп җитәргә дигән боерыгын тапшырды.

— Ни булды? — диде би, сагая калып.

— Болгарга ерактан, Багдадтан илчеләр килде! — диде тартык, күтәренкелек белән.— Барлык чумакларның башы Әл-Моктадир Алмыш ханга үзенең ышанычлы кешеләрен җибәргән. Ханга буйсынган барлык улуслар, барлык ырулар, ислам йоласына күчкәнлекләрен танып, хәлифә илчесе алдында ант бирәчәкләр. Кем дә кем каршы килә, аларга хәлифәнең каргышы төшәчәк. Алар алла колы Алмыш ханның үткер кылычын татыячаклар. Ханның боерыгы шундый.

Ямгырчы би карышып тормады. Ул үзенең бөтен ыруына Чулман аръягына чыгарга, Өчкүл ягына юнәлергә боерды. Казаяк ыруы тиз

[1] Турун — баланың баласы.

арада аякка басты. Булган барлык каекларга, көймәләргә утырып кешеләр Болгар ягына агылдылар.

Алмыш хан урдасына, Өчкүл янындагы болыннарга башка яклардан да төркем-төркем булып кешеләр килделәр. Оя-оя булып тирмәләр корылды. Барлык болыннарны, басу-кырларны, урман буйларын, аланнарны атлар, кешеләр каплап алды. Кеше күплектән атлап йөрер урын да калмады.

Дүрт көн, дүрт төн буена кешеләр шулай килә тордылар, бер тирәгә җыела тордылар. Якын-тирәдәге барлык ырулар, ыру башлары, биләр, тарханнар җыелып беткәч, кояшлы бер иртәдә кешеләр Өчкүл янындагы иң зур бер болынны бал кортыдай сарып алдылар.

Менә кешеләрне тын калырга өндәп быргылар кычкырды. Чит илләрдән килгән илчеләр хәлифә җибәргән ике кара байракны югары күтәрделәр, Алмыш ханның өстенә кара чапан, башына ак чалма кидерделәр. Хәлифә илчесе Сүсән әр-Рассиның битекчесе Әхмәт ибн Фадлан — озын борынлы, озынча битле, җирән сакал-мыеклы таза гына бер гарәп бөтәрләнгән битекне җиң очыннан алды да укырга җыенды. Шунда ул үзе янында торган Баштый углы Габдуллага үз телендә нидер әйтте дә, Габдулла Алмыш ханга борылды, аңа битекченең сүзләрен җиткерде. Әхмәт ибн Фадлан: хәлифәнең битеген укыганда аяк өсте басып тыңларга кирәк, дигән икән. Берничә ел эчендә картаеп, юанаеп калган Алмыш хан аягүрә басты. Аннан күрмәкче карачылар да, биләр дә, тарханнар да, барлык кешеләр аякларына бастылар.

Бер-берсенә сыенып басып торган кешеләр урманы тынып калгач, калку урынга менеп баскан, шуңа күрә барлык тирә-якка күренеп торган битекче көр, ягымлы тавыш белән кычкырып укырга кереште. Баштый углы Габдулла шундук аның сүзләрен болгар теленә әйләндереп барды. Габдулланың сүзләрен башка тылмачлар үзләре янындагы кешеләргә җиткерделәр. Йөз меңләгән кеше урманы өстеннән төрле якка, дулкын-дулкын булып, бер үк сүзләр тарала торды.

Хәлифә битеген укып бетергәч, бөтен киң болынны тутырып торган кешеләр, җирне-күкне дер селкетеп, бер авыздан «Алла!» дип кычкырдылар. Казаяклар да, Койтым бикә белән юлдашлары да, биләр, суарлар да, бәрәнҗәрләр дә — барысы да, барысы да төп болгарлар белән шул үк сүзне кабатладылар.

Әхмәт ибн Фадлан укып бетергәч, Алмыш хан үзенең атына атланып, уртадагы түгәрәк ачыклыкны бер әйләнеп чыкты. Ул үзенә буйсынган кешеләргә — ирләргә, хатыннарга, бала-чагаларга күз йөртеп чыкты. Аларның башы өстеннән ул еракка — Этил буе киңлекләренә, Чулман буйларына, Ука ярларына, Урал итәкләренә, Җаек далаларына күңеленнән күз йөртеп чыкты. Күз алдына килгән шул биләмәләрен, җир-суларын бергә туплаган сыман, ул зур авыр йодрыгын йомарлады да кулын күтәрде.

— Болгарлар! Болгар җиренең барлык улуслары [1], ырулары! — дип кычкырды Алмыш хан көчле, күтәренке бер тавыш белән.— Моңарчы таркау булган, бер-берсе белән ызгышып, бер-берсенең канын коеп яшәгән... миңа калан түләгән улуслар, ырулар бүген бер байрак астына берләште. Шушы язгы кояшлы көндә, барлык үләннәр, агачлар... барлык тереклек иясе куанып башларын калкытканда, бөек Этил, Чулман җирендә безнең изге йортыбыз — Болгар йорт та яңадан туды! Болгар, яшь булса да, өлкән алыплар тезмәсенә басты. Безне изге хәлифә үзе таный, безгә үзенең изге теләкләрен юллый. Бүгеннән башлап мин, Алмыш хан, Болгар йортның башы, үземнең Хазар каганына бәйсез икәнлегемне белдерәм. Бүгеннән башлап Болгар йорт

---

[1] Улус — халык, ырулар берләшмәсе.

жирдә үзенә ирек даулаячак, үз көнен үзе күрәчәк, үз язмышын үзе сайлаячак. Күктә кояш сүнми торып, Болгар йорт сүнмәячәк. Әтил суы корымый торып, Болгар йортның тамыры корымаячак!

## IV

Шулай итеп, Алмыш хан теләгенә иреште: Багдадтан биш мең кеше белән илчеләр килде, изге хәлифә аны үз канаты астына алды. Моннан соң инде ул барлык эшендә аңа таяначак. Моннан соң инде аның теләсә нинди яуларга, давылларга каршы корыч калканы булачак.

Әйе, илчеләр килде. Алар аңа хәлифәнең байракларын алып килделәр, бүләкләр, күчтәнәчләр, им-том үләннәре алып килделәр. Илчеләр белән бергә аның угыллары, ышанычлы кешесе Габдулла исән-имин әйләнеп кайтты. Шулай да барысы да ул уйлаганча ук барып чыкмады. Ислам йоласына өйрәтергә тиеш булган укытучылар — мөгаллимнәр, суыктан, ераклыктан, авыр юлдан куркып, Хәрәземдә үк илчеләрдән аерылып калдылар — илчеләр исә таныш су юлы белән түгел, адым саен куркыныч сагалап торган коры җирдән килгәннәр иде. Болгарга шулай ук соратылган ташчылар да килеп җитмәде. Алмыш ханга элеккечә үз көченә, үзе корган агач коймага гына сыенырга калды. Бигрәк тә үкенечлесе шул булды: хәлифә җибәргән дүрт мең динар акча шулай ук хан калтасына эләкмәде. Хәлифәнең изге динарларын аның кулына тапшырырга тиеш булган Әхмәт ибн Фадлан ул акчаларны юлда ук әллә үзенә үзләштергән, әллә берәр ничек юкка чыгарган иде. Алмыш хан, гарәп битекчесен күпме генә кысмасын, берни барып чыкмады. Ул, теләсә дә, теләмәсә дә, кул селтәргә, үпкәсен эченә йотарга тиеш булды. Аның урынына ырудашлары күзе алдында, күршеләре күзе алдында ханның атагы бермә-бер үсеп китте. Төптән уйлап карaганда, монысы инде дүрт мең динардан да артыграк иде. Үзенчә ул шулай дип уйлады, шуның белән күңелен юатты.

Шулай итеп, илчеләр аңа сөенечләр дә, көенечләр дә алып килделәр. Тик алар алып килгән көенеч Хәрәземдә торып калган мөгаллимнәр дә, ташчылар да, дүрт мең динар акча да түгел иде. Алар алып килгән көенеч-кайгы Аппак белән Тотышның үлеме иде. Моны ханга Габдулла сөйләде. Бу турыда ишеткәч, ата кеше Габдуллага берни әйтмәде — сорау да бирмәде, ышану-ышанмау да белдермәде. Ул әлегә моны ничек итеп аңларга да, моның белән үз-үзен ничек итеп килештерергә дә белмәде. Айкын хатынның тазалыгы болай да чамалы иде. Кызының үлеме турында ишетсә, аның бөтенләй үк аяктан егылуы бар. Шуңа күрә ул бары Габдуллага бу турыда башка беркемгә дә сөйләмәскә генә кушты.

Шундый көннәрнең берсендә Алмыш хан янына Койтым бикәнең керергә теләвен белдерделәр. Алмыш ханның йөрәге кузгалып куйды. Койтым бикә... Тотыш... Алар турында ул беркайчан да тыныч кына уйлый алмады.

— Минем углымны кая куйдың? — диде аңа Койтым бикә, сорау алган яргучы сыман.

— Ул качты. Син ул турыда беләсең булыр,— диде хан.

— Мин ышанмыйм,— диде Койтым бикә.

— Шуннан башка мин берни белмим,— диде аңа хан.

Койтым бикә икенче көнне дә килде. Ул аңа шул ук соравын бирде:

— Кая куйдың минем углымны? — диде.

Чәчләре агара башлаган, кырысланган, усалланган бу хатынга ханның ачуы килде. Шулай да ул аны җиңел генә куалап чыгара алмады.

— Алайса, тыңла,— диде ул аңа, йомшарып.

Ул үзе бер сүз дә әйтмәде. Койтым бикәгә барысын да Габдулла сөйләде. Үзе белгән, үзе ишеткәннең барысын да төкми-чәчми сөйләп бирде.

Алмыш хан, Тотышка ни булганын белгәч, Койтым бикә аңын җуяр, егылыр, я булмаса тилереп, чәчен-башын тырнап еларга тотыныр дип уйлады. Кайгы күреп йөрәге тимергә әйләнгән ананың ичмасам ыңгырашкан тавышы да ишетелмәде, күзләренә бер бөртек яшь килмәде. Аның нык кысылган иреннәре генә тагын да ныграк кысыла төште дә, авыз читләрендәге, күз төпләрендәге җыерчыклары гына кызганыч булып тартышып-тартышып куйды.

Габдуллага хан чыгарга кушты. Койтым бикә белән генә калгач ул, авыр көрсенеп:

— Язмыш...— дип куйды.— Язмыштан узмыш юк. Син — углыңны, мин — кызымны югалттым.

— Әйе, язмыштан узмыш юк, ханым,— диде Койтым бикә, каядыр читкә, еракка карап.— Син минем туган ыруымны тар-мар иттең, син минем атамның башын чаптың... ата-баба йоласын аяк астына салып таптадың. Барысы өчен сиңа тәңренең авыр каргышы төшкән, Алмыш хан... көч, байлык иясе... хәлифә ялчысы! Шуны бел, ханым, син кызыңны гына түгел... углыңны да югалттың!

— Ә?! — диде хан, аягүрә басып.

— Әйе, углыңны да! — диде Койтым бикә, ишеккә таба борылып.

## V

Кызыл Ярга кайтканда Койтым бикә тагын Шуран катауга туктады.

Ямгырчы би белән аның арасында зур гына сөйләшү булды. Койтым бикә Тотыштан туган Күкене үзенә биреп җибәрүне сорады. Тотыш инде юк, диде, аның кайдалыгын беркем белми, диде. Күке минем бердәнбер юанычым, диде. Ямгырчы би ике арада мондый сөйләшү буласын, күрәсең, алдан ук көтеп торган иде.

— Күкенең анасы бар,— диде ул.— Мин дә, син дә — яңа йоладагы кешеләр. Чумак йоласы яшь баланы ата-анадан аерырга кушмый. Күке сиңа юаныч булган кебек, анасына да юаныч. Кая куярмын мин аның баласыз анасын?

— Чакырт кызыңны! — диде Койтым бикә.

Тотышның инде бөтенләйгә, мәңгегә юкка чыгуын белгәч, Тәңкә тынычланып калгандай булды. Койтым бикә, кызганып, аңа углының кайда, ничек үлүен әйтмәде. Ул аңа: Тотыш Әтил аръягында юлбасарлар белән сугышта үлгән, ахрысы, дип ялганлады.

— Нишлисең, бирәсеңме балаңны? — диде ата кеше үзенең кызына.

— Мин углымны беркемгә бирмим,— диде Тәңкә, каны качкан иреннәрен чәйнәп.— Анам каршы килмәсә, мин аның белән китәрием... углымны алып.

— Мин синнән шуны гына көттем дә, кызым! — диде Койтым бикә, елмаеп, Тәңкәне кочагына алып.— Берегез дә артык түгел, икегезне дә алып китәм. Икегез дә балаларым булырсыз.

— Минем тагын бер кешем бар,— диде Тәңкә оялчан гына. Аның бит очларына көчсез генә кызыллык йөгерде.— Торымтайны да... каршы килмәссезме, анам?

— Торымтай? — диде Койтым бикә аңлап җитмичә.— Ә-ә, Торымтай! Аңа да каршылыгым юк. Тагын кемнәрең бар — әйдәгез барыгыз да. Кайгылы ана күңеле өч кешене түгел, йөз кешене, мең кешене сыйдыра ала! Баласын югалткан ана өчен барлык үксезләр — бала! Күкем минем... Куаныч-Бога, атла алдан. Барлык йортым — сиңа, җирем-суым, күгем — сиңа... бар байлыгым, көчем — сиңа. Атла, углым... Күке балам!

1969 ел, Казан.

## Әдхәт Синегулов

### Кеше эзли

Кеше эзли...
Җир астына төшә,
алтын эзли,
Су астына төшә,
алкын эзли,
Галәм киңлегеннән
яңа җисем эзли,
Ачылмаган шахталарга
яңа ишек эзли...
Һәрбер таштан, һәр агачтан
үзе корган бу тормышның
яңа якты төсен эзли.
Арый-тала, гел тырыша —
Янар, кайнар эшен эзли.
Язын эзли, җәен эзли,
Көзен эзли, кышын эзли,
Очып эзли, йөзеп эзли,
Язып эзли — казып эзли...
Дусларына әйтер өчен
иң кадерле сүзен эзли,
Дошманына кадар өчен
иң зәһәрле угын эзли.
Бар итим дип, югын эзли,
Дөреслекнең юлын эзли.
Кеше эзли-эзли генә
Үз җиренең йөзен бизи.

●

Янгырда калган дарыдай,
Янмаган чакларым булса,
Тик торганда дөрләп китеп,
Кабынган чакларым була.

Башыма кайгылар килеп,
Җырлаган чакларым булса,
Күңелем шатлык белән тулып,
Җылаган чакларым була.

●

Нәрәкнең төрлесен беләм мин:
Кыюын, куркагын, сафларын...
Нәрәгем, белмим, син ниндидер,
Тик беләм: мин сине сатмамын.

## Харрас Әюпов

### Урман

Давылларга куеп киң күкрәген,
Күтәрелгән шушы җирдән ул
Шаулый-шаулый гасырларны кичкән,
Бөгалмаган аны җил-давыл.

Эченәрәк үт син, түренәрәк,
Авазларын тыңла, күр ямен,
Тартынмый ул синнән, ятсынмый ул,
Ачып сала җанын, йөрәген...

Тармакларын салмак тибрәндереп,
Чайкала да бераз бу җилдән,
Тынып кала,
Гүя үткәннәрне
хәтерләргә тырышып, карт имән.

Качкыннарның йөрәгеннән кабынып,
Аланнарда күпме ут янган,
Туңган чакта кеше монда килгән,
Шул урманны ябынып йоклаган.

Янәшәдә кәкре усак тора,
Ничек аны күрми узасың —
Авыр чакта, ахры, кешеләргә
Күтәрешкән дөнья нужасын...

Агачларның монда үз моңы бар,
Җырга алар иртә өйрәнгән,
Һәрбер чыбык үз авазын сала,
Шаулашалар сабыр имәннәр.

...Эченәрәк үт син, түренәрәк,
Авазларын тыңла, күр ямен.
Тартынмый ул синнән, ятсынмый ул,
Ачып сала җанын, йөрәген...

●

Карлар эреп бетә бугай инде,

Эх, җанымда бозлар кузгала!
Торналарга зәңгәр яулык болгый,
Йөрәгемә басып, кыз бала...

Зәңгәр күктә уйный зәңгәр яулык,
Зәңгәрлектә торна тавышы.
Сине сагынып кышны үткәргән ул,
Сине эзләп килә яз кошы.

Зәңгәр юлдан килгән мәхәббәткә
Сузылып-сузылып яулык болгама,
Китәр өчен түгел бу килүе,
Озатырмын диеп уйлама.

Бу күңелнең актарылган чагы,
Эх, җанымда бозлар кузгала!
Торналарга зәңгәр яулык болгый,
Йөрәгемә басып, кыз бала...

## Язгы яңгыр

Шомыртларга ике ак шәл кирәк,
Язгы яңгыр ява — гел ләйсән.
Җаннарыма шифа булыр кебек,
Яңгырларга чыгып әйләнсәм.

Синең гомер — язгы яңгыр минә,
Толымнарың — кара гөрләвек:
Иңнәреңнән агып төшә дә ул,
Хыялыма килә юл ярып.

Үзең беләң бергә агызмасаң,
Йөрәгемә әгәр таммасаң,
Гөлләр бу яз чәчәкләнмәс төсле
Яңгырларга кушылып яумасаң.

Яланнарга чыгып бер әйләним,
Юк, теләмим яңгыр узганны:
Елатыр да, юатыр да кебек
Яңгырларга куйсаң бу җанны...

**Мәгъсүм Насибуллин,**
юстиция советнигы

# ФИДАКАРЬ ФИДАИ

Кайбер кеше белән бер коллективта эшлисең, көн саен очрашып торасың, исәнлек-саулык сорашасың, ә аның тормышын, эчке дөньясын бөтенләй белмисең. Киресенчә дә була: кешене бер тапкыр да очратмагансың да, күрмәгәнсең дә, ә синә аның турында күп нәрсә билгеле. Казанда яшәүче бер танышымны мин башта шулай күрмичә генә белә идем. Хәер, бер мин генә дә түгел. Безнең илебездә дә, хәтта чит илдә дә аны белмәгән юрист сирәктер. Ул — Фидаи Нургали улы Фәтхуллин, юридик фәннәр докторы, Казан дәүләт университетының җинаять процесслары кафедрасы профессоры.

Фидаи Фәтхуллин белән беренче танышуым — әгәр моны танышу дип әйтергә яраса — бик сәер булды. Ул чакта мин Башкортстан АССР прокуратурасында эшли идем. Гафури районы прокуратурасы тикшерүчесе Шәйхисламовның эш тәҗрибәсен өйрәнергә туры килде. Тикшерүче буларак, ул әле яшь, Казан дәүләт университетын тәмамлап, икенче ел гына эшли иде. Шуңа карамастан, эшендә ник бер генә кимчелек булсын! Дөресен әйтим, башта үзем дә ышанмый тордым. Бер-бер хәл турында хәбәр булдымы — тикшерүче инде анда. Тәҗрибәле рецидивист йомгакның очын ничек кенә оста яшермәсен, яшь белгеч аны сүтми калмый. Җинаять нилектән, нинди сәбәпләр аркасында килеп чыккан, нинди шартларда эшләнгән, нәтиҗәләре нинди — барысын да энәсеннән җебенә кадәр ачып сала. Тикшерүче кичләрен клубта, халык арасында, гыйльми лекцияләр укый, җанлы әңгәмәләр үткәрә. Нәтиҗәләр ярылып ята: җәмәгать тәртибен бозучылар сирәкләнә бара, ачылмый калган җинаятьләр юк.

Шәйхисламовның эш тәҗрибәсе барлык республикага таратылды.

Очрашуларыбызның берсендә Шәйхисламов ризасызлык белдерде.

— Шау-шу күтәрү кирәкмәс иде.

— Ничек инде ул?

— Укыганда авыр булса, эшләгәндә җиңел була.

— Дөрес сүзләр, ләкин...

— Безнең укытучыбыз Фәтхуллин шулай әйтергә ярата иде. Тәҗрибә дә менә түгел, анык.

Казан дәүләт университетындагы хокук белгеченең фамилиясе ул чакта минем



өчен әллә ни күп нәрсә аңлатмый иде әле. Кызыксынмый булдыра алмадым. Сүзгә сүз ялганды, бер хәтирә икенчесен алмаштырды... Без Фәтхуллинның элекке шәкерте белән берничә сәгатьтән соң гына саубуллаштык.

...Шәйхисламов — Фәтхуллин. Агачны җимешенә, останы өйрәнчегенә карап беләләр.

Озакламый Фәтхуллин белән икенче тапкыр «танышырга» туры килде.

Районнарның берсеннән хат килеп төште. Анда җинаять эшләнгән булган: бер комбайнчыны үтергәннәр. Үтерүчеләр, имештер, күрше шәһәрнекеләр, берсе завод директоры, икенчесе аның шоферы. Тикшерүче белән прокурор ни өчендер аларны яклыйлар, кулга алырга теләмиләр.

— Барырга, тикшерергә туры килер,— диде республика прокуроры.

Һәм менә урында ныклап тикшерү башланды.

* * *

Колхоз көтүчесе Һадиев малларны таң белән урманга алып китә. Озакламый авыл күздән югала. Ләкин бу ни эш? Кинәт маллар барган җирләреннән туктап калалар. Бер урынга өелешеп, тояклары белән җирне казый-казый, үкерешергә тотыналар. Көтүче маллар җыелышкан урынга ашыга. Янып бетмәгән агач ботаклары һәм кием кисәкләре арасында үле гәүдә ята икән. Авыл кешеләре мәетнең комбайнчы Зариф Галиев булуын танйилар.

Шул ук көнне районнан прокурор һәм тикшерүче килеп төшәләр. Вакыйга булган урында кечкенә калибрлы гильза табыла. Юлда автомобиль эзләре ярылып ята, ГАЗ-69 машинасыныкы. Алгы тәгәрмәчләренең уңы шомарып беткән булырга тиеш. Мәетне юлдан сөйрәп алып кергәннәр.

Машина эзе тикшерүчене күрше шәһәргә алып килә. ГАЗ-69 автомобиле завод гаражында табыла. Арткы ишекне ачып, тикшерүче машина эченә күз сала: кош каурыйлары, кипкән ал таплар.

Шоферның путевкасында күрсәтелгән авыл исеме дә шул, числосы да туры килә.

— Рәхим итегез,— дип, директор тикшерүчегә 12 нче калибрлы ИЖ мылтыгын китереп бирә.

— Ә кечкенә калибрлысы кайда?

— Анысы шоферда.

Әмма шоферда мылтык табылмый. Ул күпме сорасаң да, бер сүзне кабатлый: «Бар иде, югалттым».

Тикшерүчене тагын бер нәрсә шикләндерә. Шоферның сөйләвенә караганда, алар мәет табылган урыннан үтмәгәннәр, ә директорның әйтүе буенча үткәннәр булып чыга. Шик үскәннән үсә бара. Гаражда табылган машинаның вакыйга булган урындагы эзләр белән туры килүе, шофер белән директорның каршылыклы күрсәтмәләре, кечкенә калибрлы винтовканың юкка чыгуы, тәгәрмәчкә ябышып кипкән чәчләрнең мәетнеке төсле булуы — болар барысы да шикләнергә мәҗбүр итә.

Ләкин, икенче яктан, директор ихтирамлы кешеләрнең берсе. Элекке фронтовик. Партиянең шәһәр комитеты члены, шәһәр Советы депутаты. Шоферның да биографиясенә тел-теш тидерерлек түгел. Унҗидә яшеннән эшләп килә, кичке мәктәптә укый, бер тапкыр да җәмәгать тәртибен бозган кеше түгел. Шулай булуына карамастан, үтерелгән кешенең туганнары директор белән шоферны кулга алу ягында. Башканы иштерергә дә теләмиләр.

Ләкин тикшерүче катгый карарга килергә ашыкмый. Авыл халкы моны йомшаклык дип бәяли һәм тикшерүче белән прокурор өстенә жалоба языла.

— Шикле кешеләрне ни өчен кулга алмадыгыз? — дип сорыйм тикшерүчедән.

— Вөжданым җитмәде,— диде ул кыска гына итеп һәм, бераз уйланып торгач, өстәп куйды: — Безнең профессор Фәтхуллин булса, моның өчен: «Молодец, энем!» — дияр иде. Мин сезгә бер вакыйга сөйлисем килә. Ачыграк аңлашылсын өчен...

* * *

Таң беленеп килә. Идел ягыннан искән җил шәһәр урамнары буйлап томан таратып йөри. Казан йоклый. Шәһәр читендәге өйләрнең берсендә Гомәровлар гаиләсе дә йоклый. Тынлыкны бозып, өч тапкыр стена сәгате суга.

Тирә-якта хәвеф юклыгына ышангач, билгесез кеше, кесәсеннән ниндидер металл нәрсә чыгарып, җитез хәрәкәтләр белән, тәрәзәне каера башлый. Бер минуттан ул өй эченә керә. Сандыктан алган әйберләрен төенчеккә төйнәп, карак тәрәзәгә табан юнәлә. Аның аяк астында идән тактасы шыгырдый. Шул тавышка уянган әби бөтен көченә кычкырып җибәрә. Уллары һәм киленнәре, сикереп торып, аның янына ташланалар.

— Нәрсә булды, әни?

Карчык тәрәзәгә төртеп күрсәтә.

Уллары һәм киленнәре тышка атылып чыгалар. Бераз йөгергәч тә төенчек күтәргән кеше күренә. Ләкин ул иртәнге томан эчендә күздән югала. Куу дәвам итә. Ниһаять, кеше тагы да күренә. Ул трамвай тукталышына таба йөгерә. Әмма бу юлы төенчеге юк аның.

Олы улы, аны куып җитәрәк, нәфрәтенә буылып, кычкырып җибәрә:

— Тукта, әшәке җан! Кузгаласы булма!

Кеше көтелмәгән хәлдән сискәнеп китә һәм тукталырга мәҗбүр була.

— Әйберләр кайда? — дип кычкыра карчыкның икенче улы, тешләрен кысып.

— Сез ни турында? Аңлап җиткермим,— ди әлеге кеше, тыныч кына.

— Ах, оятсыз! Гаепсез булып кылана бит әле! Әйт, башыңны урталай ярмас борын, әйберләр кайда?

Башкалар да нәфрәт, янау сүзләре яудыралар. Берсенең кулында лом күренә. Теге егет читкә тайпыла: ачуның чигенә җиткән кешеләрнең теләсә нәрсә эшләве бар.

— Акыллырак булуыгызны сорар идем,— дип кыю гына сөйли башлый егет.— Лом белән сугып бөтен нәрсәне бозып куюыгыз мөмкин. Беренчедән, кеше үтереп, әйберләрегезне таба алмавыгыз бар. Икенчедән, мине үтерү — самосуд диган сүз. Ә ул, ялгышмасам, җинаять була.

Шундый тыныч, юмор катыш акыллы сүзләр боларның ярсуын бераз баса төшә. Егетне таланган йортка алып китәләр. Тавышка йөгереп килгән күршеләр, кызыксынуларын яшермичә, сандык өстенә утырган «каракны» күзәтәләр. Әби, бармагы белән егетнең күкрәгенә төртә-төртә, кычкыра:

— Ах, иблис! Тәрәзәдән менгәнеңне үзем күрдем. Син идең ул, кара йөз! Кешенең хәләл малына кул сузарга?! Шушы гәүдәң белән. Каһәр суккыры!

Тиздән йорт янына милиция машинасы килеп туктый. Машинада эт тә бар. Тәрәзә төбеннән эз алган эт өрә-өрә егеткә ташлана. Сержант аны тынычландырырга ашыга. Җыелган кешеләрнең кайсыдыр сокланып кычкырып җибәрә:

— Акыллы хайван! Эләкте егетең!

Егетне тентеп, милиция бүлегенә озаталар.

Эш бик катлаулы күренмәгәнлектән, аны тикшерүне күптән түгел милиция кадрлары әзерләү мәктәбен тәмамлаган лейтенантка тапшыралар. Яшь лейтенант, мәктәптә өйрәткәнчә, эшне кызу тотарга уйлый. Иң мөһиме: каракка фикер тупларга вакыт бирмәскә. Эзләр суынмас борын, җинаятьчене дәлилләр белән стенага терәп, гаебен танытырга, иптәшләре кем булуын әйттерергә һәм урланган әйберләрнең кайдалыгын күрсәтергә мәҗбүр итәргә кирәк. Каршысында утырган егетнең «тәҗрибәле җинаятьче» булуын сизсә дә, лейтенант эшнең уңышлы тәмамлануына шикләнми.

Икенче көнне лейтенант егетне кулга алу өчен санкция сорап прокурорга бара.

— Сөйләгез, нәрсәгә нигезләнеп кулга алырга булдыгыз?

Лейтенант барын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирә.

— Әйе-е...— ди прокурор, мәгънәле итеп.— Кызык. Димәк, ул студент, җитмәсә булачак юрист. Ә вакыйганың кайсы бер детальләрен, әйтик, үзенең шулай иртә торып урамга чыгуын ничек аңлата ул?

— Имтихан бирер алдыннан чират алу өчен беренче трамвайга өлгергә теләгән леген әйтә,— ди лейтенант, мыскыллы тавыш белән.— Ышандырырлык түгел.

Кыска гына тынлыктан соң прокурор чал башын күтәреп:

— Егетне минем янга алып килегез,— ди,— университеттан комсомол оешмасы секретарен, факультетның деканын чакыртыгыз. Миңа кайсы бер нәрсәләрне ачыкларга кирәк.

Гаҗәпләнүен җиңеп, профессор студентка характеристика бирә. Аның еш кына я пристаньга, я төзелеш объектларына эшкә йөрүләрен искә ала һәм:

— Ә сез студентның гаепле булуына ышанасызмы? — дип сорау бирә.

— Әлбәттә, ышанам, йөз проценты белән!

— Ә мин аның йөз проценты белән гаепсез булуын исбат итә алам. Юридик факультетның кешеләре белән сөйләшмәдегезме? Юкка. Бик кирәк иде. Материаллардан күренүенчә, студент белән җинаятьченең юллары туры килә бит. Иртә томанлы булган. Урамда агачлар да күп, тыкрыклар да җитәрлек. Студентның юлга чыгу вакыты белән җинаятьченең качу вакыты да туры килә. Ниндидер тыкрыкка китеп югалган каракны бер нәрсә белмичә трамвайга ашыккан студент белән бутаулары мөмкин. Карчыкның олы улы үзенең күрсәтмәләрендә куган чакта каракны ниндидер бер вакытта күздән югалтып торуларын әйтә.

Декан үз студентына характеристиканы профессиональ төгәллек белән бирә. Шәкертенең еш кына пристаньга яки төзелешләргә эшкә җибәрүләрен сорап йөдәтүен дә искә ала. Профессор үзенең студентын яхшы белә, аның гаепсез булуына чын күңелдән ышана. Аның бу ышанычы эш белән яхшылап танышкач та какшамый, киресенчә, ныгый гына төшә. Профессор белән прокурор шактый озак сөйләшәләр, уйлашалар. Нәтиҗәдә мәсьәләнең томанлы ягы икесе өчен дә ачыклана.

Деканны озаткач, прокурор лейтенантны чакырып ала.

— Сез студентның гаепле булуына ышанасызмы?

— Йөз проценты белән.

— Ә мин аның йөз проценты белән гаепсез булуын исбат итә алам,— ди һәм ул профессор дәлилләрен аңа аңлатып бирә.

— Этнең студентка ташлануын да башкача аңлатырга була,— ди ул, сүзен дәвам итеп.— Ул, карак, һичшиксез, шушы кеше, дип уйлаган хуҗаның сизелер-сизелмәс кенә хәрәкәтенә, теләгенә буйсынып та студентка ташланырга мөмкин. Сез егеттә психик яктан бернинди кимчелек тә тапмадыгызмы?

— Юк, иптәш прокурор. Миңа калса, ул тулысынча сәламәт.

— Психик яктан сау-сәламәт икән, ни өчен әле биш ел җәфа чигеп укыганнан соң, соңгы имтиханны тапшырып, диплом алу урынына вак-төяк йорт әйбере урлап йөрергә тиеш? Ул мондый нәрсәне психик авыру булса гына эшли алыр иде. Сезнеңчә дә, минемчә дә, егет сәламәт, димәк, ул бернинди дә җинаять эшләмәгән. Кичекмәстән азат итегез үзен, гафу үтенегез һәм машина белән университетка илтеп куегыз. Имтиханын тапшырсын.

Биш көн вакыт узды. Милиция работникларына чын каракны табу өчен байтак кына көч салырга туры килде. Ул әкречелек белән шөгыльләнүче Гафаров дигән бәндә булып чыкты. Анда урланган әйберләр табылды һәм хуҗаларына кайтарып бирелде.

Студент бу хәбәрне, университетны тәмамлап, диплом алган шатлыклы минутта ишетте. Ул башыннан үткәннәр турында уйланып, җәйге нурлар сибелгән урам буйлап атлый. Кесәсендә — эшкә билгеләнү турындагы язу. Хәзер ул үзе тикшерүче. Тормыш юлында тагы да нинди хәлләргә очрамас әле! Юк, ул бер вакытта да гаепсез кешеләрне рухи рәнҗетүгә юл куймас...

* * *

— Ул тикшерүчене беләсеңме әллә? — дип сорадым мин, түземсезләнеп.

— Беләм шул,— дип елмаеп куйды сөйләүче.— Мин үзем идем ул.

— Ә профессор?

— Безнең Фәтхуллин Фидаи Нургалиевич.

«Безнең Фәтхуллин» белән мин икенче мәртәбә шулай «очраштым». Бу «очрашу»да, беренчесе кебек үк, миндә бик зур тәэсир калдырды....

Галиевне кем үтергән соң? Бу сорау өстендә озак кына баш ватарга туры килде. Әмма Фәтхуллинның элекке студенты дөрес җавапны тапмый калмады. Җинаятьчеләр бөтенләй башка кешеләр булып чыкты.

Шулай итеп, профессор Фәтхуллинның үзен күреп белмәсәм дә, ул тәрбияләгән белгечләр белән бер-бер артлы якынаеп таныша бардым. Казан юридициясе мәктәбенең дә традицияләре, эш стиле, күрсәткән хезмәтләре ачыклана барды. Бу мәктәпнең җитәкчесе Фидаи Фәтхуллин — татарлардан беренче юридик фәннәр докторы, беренче профессор — хокук белгече. Аны кем генә белми дә кем генә хөрмәтләми! Аның мәкаләләрен, китапларын кайсы гына юрист үзенә көндәлек кулланма итеп тотмый.

Әле Уфада чагымда ук хезмәттәшләр минем Казанга китәсемне ишетеп калганнар. Шуннан бирле ишек юлы да ябылмый башлады. Беренче булып Башкортстан прокурорының өлкән ярдәмчесе, юстициянең өлкән советнигы Зәфәр Нигъмәтуллин килеп керде:

— Безнең Фидаибызны күреп сәлам тапшыр! — диде ул.

Прокурор Заршат Еникеев, Калтасы районының халык судьясы Марат Маликов:

— Безнең исемнән аспирантура буенча гыйльми җитәкчебез Фәтхуллинның кулын кыс! — дип калды.

Уфаның Калинин районы прокуратурасы юристы Мөхтабәр Туктаров, Башкортстан Верховный суды председателе, юридик фәннәр кандидаты Шакир Вахитов, республика прокуроры Михаил Яковлев, Свердловск юридик институтының Уфа филиалында кафедра мөдире Зәфәр Кульбарисов — күпләрнең, бик күпләрнең әманәтләрен алып килергә туры килде Казанга.

Казан дәүләт университетының җинаять процесслары кафедрасына менә шушы әманәтләрне тапшырырга, Фәтхуллин белән танышырга, сөйләшергә дип килеп кердем мин.

— Профессор Фәтхуллин юк,— дип каршыладылар мине.— Ул СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалында конференциядә. «Владимир Ильич Ленин һәм Совет автономиясе» дигән темага доклад ясый.

Фидаи Нургалиевичның тагын бер ягы ачылды. Ул партиянең Татарстан өлкә комитетының иң актив лекторларыннан берсе. Икенче көнне профессор профсоюзлар өлкә комитетына киткән булып чыкты. Ул биредә президиум члены икән.

— Бүген Фәтхуллин булмас,— диделәр өченче тапкыр килүемдә дә.— Аны Казанның Совет районы партия комитетына чакырдылар, җәмәгать тәртибен саклауның торышын тикшерү өчен программа төзергә ярдәм итә.

— Университетның Гыйльми Советында...

— Докторлыкка диссертация яклау советында...

Фидаи Нургалиевич бу советларның да члены икән.

— Республика прокуратурасында...

— Республика Верховный судында...

— Аны Мәскәүгә чакырдылар...

Профессор Фәтхуллин Союзның һәм РСФСРның биш министрлыгының һәм учреждениесенең дә фәнни оешмалары члены.

Ниһаять, көтмәгәндә профессор үзе шалтыратты. Без университетта очраштык. Минем алдымда ачык йөзле, урта буйлы, яшь кенә чырайлы кеше. Профессор дип тә уйламассың. Ә чынында исә алдымда утыз тугыз яшьлек доктор, хокук фәннәре профессоры Фәтхуллин. Дулкынланып торган коңгырт чәч, кабынып китәргә әзер торган кара күзләр...

...Иске Шәйморза кешеләре элеккедән дә иртәрәк тора башладылар. Сугыш... Элекке Буденный районындагы кайчандыр гөрләп торган бу авыл хәзер бушап калгандай булды. Фронтка киткән ир-егетләр урынына балалар, үсмерләр басты. Җиен эш, кышын уку.

Нурзадә апа, башын калкытып, китапка кадалып утырган улына дәшә:

— Кайчан ятасың инде?

— Хәзер, әни,— ди Фидаи, китаптан аерылмыйча гына һәм укуын дәвам итә.

1947 ел. Уналты яшьлек Фидаи урта мәктәпне тәмамлады. Укытучылар Казан химия-технология институтына керергә тәкъдим иттеләр. Әмма документлар кире кайтты. 18 яше тулмаган үсмерләр югары уку йортына кабул ителми икән. Комсомолец җиң сызганып колхоз эшенә тотынды.

Бер көнне Фәтхуллиннарга иске танышлары килеп керде: район судьясы Шакир Фәтхетдинов белән район прокуроры Зөфәр Нигъмәтуллин. Күпне күргән Нургали агай янына алар еш кына килгәләп йөриләр, гражданнар сугышы турында, Буденный атлылары сафында үткән походлары турында тыңларга яраталар. Ә Нургали агайның сөйләр нәрсәләре күп.

Фидаи кунаклар белән исәнләште дә, олылар сүзенә комачауламас өчен, бер читкәрәк китте. Әмма бу юлы сүз сугыш турында түгел, ә Фидаиның язмышы турында барды.

Уналты яшьлек комсомолец икенче көнне район халык судында секретарь булып эшли башлады. Эш тынгысыз иде. Суд һәм милиция работниклары белән ерак авылларга командировкалар, тузанлы конторалардa өч-дүрт утыргычны тезеп эшләнгән «караватлар». Ә башта төрле уйлар, сораулар кайнаша. Алар тикшергән эшләр дә, кешеләр дә бер-берсенә охшамаган. һәр кемнең үз йөзе, үз сүзе.

Төннәрен протоколдагы юллар телгә килә шикелле. Суд хөкем ителүчегә дөрес карар чыгарды микән? һәрбер җинаятьне кодексларга сыйдырып бетереп буламы?

Җинаятьчелек белән көрәш чараларын һәм формаларын камилләштерү теләге аңарда, бәлки, шушындый төннәрдә тугандыр да.

Бер елдан соң Фидаи Фәтхуллин — суд башкаручысы. Ә тагын да бер елдан соң суд һәм милиция работниклары үзләренең комсомол секретарьларын, шул ук вакытта район үзешчән сәнгать түгәрәге җитәкчесе Фәтхуллинны Казан юридик институтына озаттылар.

Студент тормышы. Шау-шулы тулай торак, кайнар бәхәсләр, китапханәләр, спорт ярышлары. Фидаи группаның старостасы итеп сайлана...

Өченче курска җиткәч, сәләтле, тырыш студентны җинаять процесслары кафедрасы эшенә җәлеп иттеләр. Хәзер Фидаи үзенең максатына якын иде инде. Кеше язмышларын хәл итә торган хөкем үлчәве камилме? Хокук теорияләре һәр вакытта да тормыш таләпләренә җавап бирәме? Совет юстициясенең практик эшенә алар барысы да бердәй турылыклы хезмәт итәләрме? Хокук фәне белән суд практикасын бер-беренә тагын да якынайту өчен нәрсә эшләргә?

Университет аспиранты итеп кабул ителгән Фәтхуллин менә шушы сорауларның берсенә булса да җавап табу нияте белән гыйльми эшкә тотынды. Яшь коммунист бу киеренке елларда комсомол тормышында актив катнашырга да, агитпунктта эшләргә дә вакыт тапты.

Аспирантурадан соң Фәтхуллин Бөтенсоюз юридик институтының Иваново филиалында өлкән укытучы булып эшләде. Өч елдан соң галим Казанга кайтты. Иҗади эш еллары. Юстициянең төрле проблемаларына багышланган күп санлы мәкаләләр, монографияләр, популяр китаплар. 1967 елда докторлык диссертациясе яклау. Гади колхозчы улы, 36 яшендә, әйткәнебезчә, татарлар арасында беренче булып, юридик фәннәр докторы һәм хокук фәне профессоры дәрәҗәсенә ирешә. Ирексездән, Габдулла Тукайның әрнеп язган сүзләре искә төште: «Закон белгән юрист юк бездә, дип уйлау хата; хәтта печән, шалкан базарында закон сатканыбыз бардыр»...

Зур белгеч булып җитешкәнче Фәтхуллинга күп нәрсә кичерергә туры килде. Аспирантураны бетереп, диссертация якларга әзерләнгәндә генә инструкция таләпләре үзгәреп китте: эшләгән темаң буенча басылып чыккан мәкаләләрең булырга тиеш. Диссертациянең үзе турында да галимнәрнең фикерләре төрлечә булды: бераүләр авторны танылган авторитетлар белән исәпләшмәүдә гаепләделәр, икенчеләр гыйльми нәтиҗәләрнең чиктән тыш кыю булуын өшатмады.

— Үз сүзле булма, диссертацияне яңадан эшлә,— дип киңәш иттеләр өченчеләре.

Ләкин Фәтхуллин үз карашларын яклауны дәвам итте. Ниһаять, яңа рецензент тәгаенләнде. Юридик фәннәр докторы, профессор Михаил Александрович Чельцов турында Фәтхуллинның элек тә ишеткәне бар иде. Кыю, принципиаль һәм объектив галим буларак билгеле ул. Яңа хәбәр Фәтхуллинны бер яктан шатландырса, икенче яктан уйланырга мәҗбүр итте. Объектив, принципиаль булуы әйбәт, ярата Фидаи Нургалиевич андый кешеләрне. Ә менә аның күп кенә авторитетлы галимнәр белән исәпләшмәвенә ничек карар? Үзенең кайбер карашларына каршы чыгуны рецензент ничек кабул итәр?

Менә шундый борчулы уйлар белән алты ай вакыт узып китте. Әмма борчылуларны, шикләрне шатлык алыштырды. Ниһаять, кулда рецензия!

«...Күп кенә процессуаль мәсьәләләрне хәл итүдә авторның үз фикере бар, шуңа күрә хокук мәсьәләләрен аның практик яктан белүе турында нәтиҗә ясарга мөмкин дип исәплим,— дип яза рецензент.— Фәтхуллин хокук фәнендәге четерекле мәсьәләләрдән читләшми, гадиләштерү тенденциясенә каршы чыга... Гыйльми хезмәтләрнең барлык уңай якларын һәм юк дәрәҗәсендәге җитешсезлекләрен исәпкә алып, аны фәннәр кандидаты дәрәҗәсенә лаек дип табам»...

Яшь галимнең «Җинаять эше кузгату» дигән хезмәте 1961 елда аерым китап булып басылып чыкты. Хезмәт бөтен юристларның да игътибарын җәлеп итте. Парижда чыга торган бер журнал болай дип язды: «Бу хезмәт кодекстагы җинаять процессының башлангыч стадиясе бүлегенә бик файдалы аңлатма бирә. Жалобалар, эшләнгән һәм эшләнергә уйланылган җинаятьләр турындагы хәбәрләрне кабул итү органнарының функцияләрен билгеләүдә дә хезмәтнең әһәмияте гаять зур...»

Фәтхуллин турында сүз чыкканда: «Талантлы кеше»,— диләр. Талант, барыннан да элек, үз эшеңә мәхәббәт, үз эшеңә бирелгәнлектер ул. Шулар өстәвенә бүгенге һәм киләчәк тормыш алдында җаваплылык, һәр нәрсәне үзеңә кагылышлы итеп тою, һәрвакыт иң авыр, җаваплы урынга омтылу да кирәк. Гражданлык хисләре шуны таләп итә. Фәтхуллин өчен яшәүнең төп мәгънәсе шунда.

1965 елда Фидаи Фәтхуллинның юридик фәннәр докторы Н. В. Жогин белән бергәләп язылган икенче китабы дөньяга чыкты. Ул «Совет җинаятьчелек процессында әзерләнү тикшеренүләре» дип атала. Китап бик тиз арада таралып бетте. Бу хезмәткә карата төрле журналларда, шул исәптән чит илләрдә дә, махсус мәкаләләр багышланды. Шушы ук елда янә бер монография. «Гаепләү һәм хөкем карары» басылып чыкты. Бу Мари һәм Татарстан АССР юридик органнарының эш тәҗрибәсен өйрәнү нәтиҗәсе иде. Монография иң яхшы фәнни китаплар конкурсында беренче премиягә лаек дип табылды.

1966 елда тагын бер монография. «Гаепләү һәм суд барышында аны үзгәртү» дөньяга чыкты.

1970 ел. Ф. Н. Фәтхуллинның «Җинаять процессында гаепләү дәрәҗәсенең үзгәреше» дигән китабы Мәскәүдә басылып чыкты. «Гаепләү дәлилләре теориясенең гомуми мәсьәләләре» исемле монографиясе дә әзер инде.

Барын да исәпли китсәң, аның җитди гыйльми хезмәтләренең саны кырыктан артык. Шунысын да искә алыйк: боларның һәммәсе дә студентлар, аспирантлар белән алып барган эштән тыш башкарылган хезмәтләр.

Профессор Фидаи Фәтхуллин Бөтенсоюз югары аттестацион комиссиядә һәм юридик әдәбият нәшриятында штаттан тыш консультант. Бәхәсле диссертация, шикләрәк мәкалә булса — рецензентка.

Бер вакыт аңа калын кульъязма китерделәр. Адресаты: «Мәскәү, Югары аттестацион комиссия». Ул юридик фәннәр докторлыгына диссертация булып чыкты.

774 битгән тора! Авторы — күптәнге дус. Хезмәтне фәнни җитәкчеләр, аппонентлар, зур галимнәр укып, хуп күргәннәр. Тбилиси университетының Гыйльми Советы да автор диссертациясен яклаган икән инде. Галимнәр аңа фән докторы өчен бердәм тавыш биргәннәр. Ә Мәскәүдә диссертацияне Ф. Н. Фәтхуллинга күрсәтергә карар иткәннәр.

Кульязма белән җентекләп танышкач, Фидаи Нургалиевич бераз уйланып торды. Намус кушуына каршы килеп, башка галимнәрнең фикеренә кушылсаң, фәнгә зыян китерү була. Ә, киресенчә, күңелендәгеи язсаң, коллегаларыңның үпкәләве бар, диссертация авторы белән дуслыкның өзелүе дә мөмкин. Профессор, катгый карарга килеп, өстәл артына утырды.

«...Тышкы шомалык эчендә җитди хаталар һәм җитешсезлекләр яшеренеп ята. Алар диссертациянең гыйльми һәм практик әһәмиятен юкка чыгаралар...»

Мондый мисалларны күп китерергә була. Фәнгә яңалык өстәмәгән, ачыш китермәгән бер генә кульязма да Фәтхуллиннан хуплау таба алмый.

Фидаи Нургалиевич башкаларга гына түгел, үзенә карата да үтә таләпчән. Аның теоретик әһәмияте булмаган бер генә хезмәт тә язганы юк. Профессор иң катлаулы мәсьәләләрне дә практик эшкә анализ ясаганда хәл итә. Шуның өчен ул тормышны даими өйрәнә. Аны күп нәрсә дулкынландыра: студентның, тикшерүчеләрнең уңышсызлыкка очравы да, закон эшендәге хаталар да... Галимнең төп максаты — нинди генә очракта да Совет законнары бозылмасын, бер генә гаепсез кеше дә хөкемгә тарттырылмасын.

Фәтхуллин талантының тагын да бер ягы — ул үз тирәсенә өзлексез эзләнү, иҗат итү дәрте белән янган кешеләрне туплый, аларга юнәлеш күрсәтә. СССР Генеральный прокуроры урынбасары Н. В. Жогин, РСФСР прокуроры В. М. Блинов, Татарстан прокуроры И. Х. Хәмидуллин кебек бик күбәүләр Фәтхуллин киңәшләренә зур бәя бирәләр.

Профессор... Бу сүзне ишетү белән күз алдына ашын ашаган, яшен яшәгән карт образы килеп баса. Ә Фидаи Нургалиевичка әле кырык та тулмаган. Әмма гомер еллар үтүе белән генә түгел, шагыйрь әйткәнчә, эшләнгән эш белән билгеләнә. Ә Фәтхуллинның хезмәт җимешләре йөз яшәр кешеләр көнләшерлек.

Фидаи — үз-үзен аямаучы, фидакарь дигән сүз. Яшь галим үз исеменең мәгънәсен эш белән аклый. Фидакарь эзләнә, уйлана, иҗат итә.

## Хәсән Туфан

### Кара арыслан

Ирек юлы...
Юлайлар да янды,
Шамилләр дә ауды бу юлда.
Һәм сине дә
Илбасарлар чалды,
Илбасарлар суйды, Лумумба.

Иске таныш һәрбер континентка
Мондый каза, мондый кайгылар.
Кайгыларын эчкә йота-йота
«Хисап» көнен көтә андыйлар.

Калкыр көнең, хисаплашыр чорың
Житте инде, кара арыслан!
Дәгъваң булып калка, дәгъваң булып
Һәр суелган һәм бар асылган...

Биш мең еллык коллык чылбырларын
Беренче кат өзә алганны —
Ап-ак җанлы кара континентны
Каршы ала дөнья мәйданы.

### Кем көчлерәк

Нигә кердем, нигә күрдем шуны,
Нигә кирәк иде
Бу миңа? —
Иң борынгы бабай каршында мин
Басып торам менә... музейда.

Нәкъ горилла кебек — йонлы тәнле...
Тезгә житкән — озын, көчле кул.—
Сөяк кусәк белән
Бер манудa
Мамонтны да егар төсле ул.

Гажәпләнә
Һәм кызгана бугай,
Күзен алмый минем күзләрдә:
Әйтә кебек:
«Йөз мең ел эчендә
Минем токым ничек үзгәргән!
Четрекләнеп, көчсезләнеп беткән,
Ераклашкан минем дәвердән:
Заман сине — миңа бер ашарга
Чак житәрлек затка әвергән.
Ә көч культы — минем төп васыять
Яши барыбер сезнең йөрәктә,
«Кибернетик» этикагыз белән,
Әхлакыгыз белән бер рәттә!»

Әйе, бабай,
Жир йөзендә әле
Көч культлары һаман бар шул, бар:
«Кем көчлерәк булса — шул хаклы!» дип,
Негрларны изә янкилар,
«Кем көчлерәк илдә — шул яши!» дип,
Уйгурларны йота Маолар...
Ерткычлык бит, бабай, вандаллык ул
Кусәк белән көчле алулар...

Яшәү инде — иң чын могжизаны —
Якты акыл көчен тудырган! —
Еракта без — синең «васыять»тән,
Еракта без — кусәк чорыннан.

Безгә аны фикер даһилары,
Иҗат илчеләре китерде.
Һичбер кусәк вата алмый аны —
Гуманистик фикри Ирекне.

## Лирика һәм физика

Моңы юклар — укып кына узсын,
Моңы барлар — бераз уйласын:
Колгалиләр булган бу дөньяда
Ишмиләр дә нигә булмасын!?

Физик яктан
Чандыр Тукайлардан
Күп кат көчле яна ишмиләр,
Көпә-көндез алар, көпә-көндез,
Күрәсезме, әнә, нишлиләр...

Детонатор тыгып куеп алар
Әвәли дә нахак «шартлар»ны,
Сәгатьләргә карый-карый гына
Көтеп ята безнең шартлауны.

Шартламыйбыз ләкин, каушамыйбыз! —
Таян, йөрәк, ышан син миңа:
Детонатордагы «физика»ның
Ут шнурын кисә Лирика!

Шартламыйбыз! —
Һәрбер шельма ишми
Карый бирсен әйдә сәгатькә...
Колгалиләр булган мәйдан, әйе,
Ишмиләрсез булмый, әлбәттә.

## Сәлам әйтегез

Көннәр һаман җилле дә давыллый,
Урман шаулый, Идел монлана...
Бәхилләшкән сыман баш иям мин
Дулкынланган яшьлек дөньяма.

Үзем монда — Сездә, ял йортында,
Күңел ләкин, читтән, ерактан —
Кайларгадыр илткән юл чатыннан
Күз сала кук безнең бу чакка.

Хәлне сорап, җанны сыйпап китә
Уйга калган иске танышлар.
Сүзләрендә — серле саубуллашу,
Күзләрендә — яшерен сагышлар.

Нидер тоя күңел, нидер юрый.
Юраганы, бәлки, юш булыр:
Хушлашырбыз .. Бәлки бик озакка
Мин утырган урын буш булыр.

Кайчан булса исегезгә төшеп,
Безнең шушы — көзге җәебез,

Сездә берәр сагыну хисе туса,
Миннән аңа сәлам әйтегез.

Көннәр җилле, төннәр өермәле,
Урман шаулый, Идел шомлана...
Еракгагы юллар ташына басып,
Кул изим күк иркен дөньяма.

## Яп әле, яп

Утлы сүзләр, җырлар ялкынында
Кызган бүлмән бөркү булса да,
Яп әле, яп,— циклон килә бугай,—
Тәрәзәңне ябып куйсана.

Бу тормышта бары ышык кына,
Тынлык кына эзләп яшәгән
Гамьсез, мәнсез, денсез бөҗәкләргә
Ачык ласа утлы тәрәзән.

Ә бөҗәк ул — өскә, югарыга,
Дәрәҗәгә табан юл сала,
Йөзләренә синен, күзләреңә,
Йөрәгенә басып булса да.

Күз төшер дә тышка —
Әрсезләрдән,
Бөҗәкләрдән төшкән шәүләгә,
Яп сана, яп, ачык тәрәзәңне,
Утлы тәрәзәңне пәрдәлә.

## Митта-а!

Үзеңне күреп белмәсәм дә,
Чын туганым син, Туфан
*Васлей Митта.*

Еракмыни Казан Шупашкардан...
Янәшә дә безнең бусага.
Күрешмәдек, энем, тормышта без
Узган юллар бер үк булса да.

Ә йөрәктә
Сәламнәр дә сиңа,
Әйтер сер дә шактый күп иде.

Почтальон да бармый инде сиңа,
Телефон да, Митта, юк инде...

Тордым, бастым. Башны иеп, бәгырем,
Исән калган исемең алдына,
Һәм йөрәктә яткан сәламнәрне
Тапшырдым мин туган халкыңа,
Тапшырдым, Митта...

## Робагыйлар

●

— Нишлисең анда син, Җир улы?
— Мәңгелек галәмне күзлим мин,
Бу гаҗәп тылсымның — Акылның —
«Алла»ның бабасын эзлим мин.

●

Бир, мәңгелек, чиксез Вакытның
Миллиард елын гына бир миңа:
Аңның нинди Кодрәт икәнен
Күрсәтермен әле мин Сиңа!

●

Дөньяда бәндә күбәү дә,
Һәр кеше берәү генә:
Стандарт ачкыч ярамый
Һәр адәм йөрәгенә.

●

Үткәрсәң әгәр гомерне
Яктырып яна-яна,
Һәр көнең олы романның
Бер бите булып кала.

## Гомәр Бәширов

# БАРГАН САЕН ЮЛЛАР КҮҢЕЛЛЕРӘК

Шагыйрьләр хакында сүз чыкканда, гадәттә, поэзия өчен яши, диләр. Хәсән Туфанны исә мин ул үзе шигырь булып яши дияр идем. Чөнки Туфанны шигъриятән, шигырьне Туфаннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел. Ул шигъри образга, шигърият дөньясына чын күңелдән гашыйк кеше. Шигырьнең теләсә нинди киртәләрне җимерерлек тылсымлы көче барлыгына Туфан кебек чын күңелдән инанган башка кешене мин белмим. Шулай булганлыктан, кайвакытларны бу фани дөньяның көндәлек ыгы-зыгысыннан үзен бөтенләй азат итеп шигъри сәмаларда гына яшәү аның өчен иң гадәти хәл. Аның бу фидакарь мәхәббәте берьяклы гына түгел. Аның шундый чын һәм тирән мәхәббәтенә шигърият дөньясы да шундый ук инабәтлелек белән җавап бирә. Шигырь язу аның куанычы һәм юанычы гына түгел, бәлки яшәеш чыганагы, тормыш элексире. Мин хәтта поэзия Туфанны гомер буе яшәешнең һәр төрле кыенлыкларыннан, физик һәм мораль сырхаулардан саклап, аңа тормыш сикәлтәләреннән горур атлап узарга ярдәм иткән дип әйтер идем.

Кайчакларны төннәр буе тәрәзәсендә ут сүнми, төннәрә якты көнгә килеп ялгана. Шунда уйлыйсың: иксез-чиксез борчулы уйлар, чиге күренмәгән ваемнар белән төн буе баш ватып, эштән чыгып арыгандыр, йончыгандыр, дисең. Ләкин һәркайчан ялгышкан буласың. Озак та үтми, яшүсмерләрдәй җиңел атлап, биш бармагы белән чал чәчен аралап ул килеп чыга. Йөзендә шундый шатлык, әйтерсең, бөтен планетада аннан да бәхетлерәк беркем дә юк, әйтерсең, ул бу төндә бөтен кешелек дөньясына ярый торган бәхет ачкычы тапкан. «Нидән мондый мул шатлык?» дип сорауның хаҗәте дә юк, чөнки бөтен тормышыннан, елмайган күзләреннән үк күренеп тора: бу төндә һәйбәт шигырь туган!

— Укып карыйммы? — ди.

Укылганнан соң күп вакыт иң беренче соравы шул була:

— Әйтеп бирә алдыммы икән? Җан азыгы булырмы?

Кышкы төндә салкын карны шыгыр-шыгыр китереп, каенлыкның айлы юлында менә тагын бер ялгызы атлый. Халык күптән йоклый инде, эшләрен бетереп кайтканнар да кешеләр ял итә. Тик шагыйрьнең генә «эше бетмәгән», ул һаман уйлый, уйлана. Чөнки:

**Борчыла җан, әгәр безнең болыт**
**Чит илләргә чыгып китсә дә,**
**Чикләр артындагы тетеннәрдән**
**Янган китап исе килсә дә.**

Шагыйрь күңеле сизгер сейсмограф шикелле, тормыш сулышын, күңел тетрәнүләрен — һәммәсен сизеп тора, дулкынлана, борчыла, я дөньяга сыймастай зур куаныч кичерә. Озакмы, тизме, кайчандыр, чал акын думбырасын чиертеп үләң әйткәндәй, күңел кылларын чиертә-чиертә шигырь туа, җыр туа.

Төлке өне янында күзгә чалынган пар канат... Беренче карауга, нинди уйлар, нинди хисләр уятырга мөмкин бу күренеш? Бәлки, кызгандыруы, ерткычның комсызлыгына ачу һәм нәфрәт уятуы мөмкин. Әмма озак та үтми, күрше камышлыкта иптәшләреннән аерылып китми калган ялгыз аккошның зарлы тавышы колакка чалына. Шагыйрь күңелендә боларга чынбарлыкның башка драма һәм фаҗигаләре килеп өстәлә дә бөтен кешелек дөньясына матәм беркәнчеге япкан Бөек Ватан сугышы белән, аның миллионнар йөрәгенә салган тирән ярасы белән сискәндереп яңа шигырь туа:

**Кемне чакыра аккош төн катаl**
**Оскенцимда үтерелгән кыздан**
**Салдырылган ак күлмәк сыман**
**Җирдә нке ак канат ята...**
**Кемне чакыра аккош төн катаl**



*Б. Кербабаев, Х. Туфан, Х. Госман.*

Әдәбият белән аз-маз таныш булган кешеләрдә: «Кем ул Хәсән Туфан?» дигән сорауның туганы юк кебек. Чөнки аның кемлеген, әдәбиятта нинди урын тотуын халык белән тарих күптән ачыклады инде.

Хәсән Туфан поэзиягә аяк басуы белән үк яңа сүз әйтте. Ул үзенә кадәр булган зур осталарның берсенә дә охшамаган, халыкның революциядән соңгы уй-хисен чагылдырган талантлы яңа шигырь алып килде. Бу шагыйрь 1924 елда язылган беренче шигыреннән башлап безнең көннәргә кадәр ярты гасыр буе диярлек татар поэзиясенең иң алдынгы сафында атлады. Җиде-сигез йөз еллык бай тарихы, Тукайлары белән Такташлары булган талантлы зур әдәбиятта бу һич тә ансат эш түгел. Әгәр яшь галимнәребездән берсе: «М. Җәлил, Ф. Кәримдә генә түгел, Х. Туфанда да татар шагыйренең намусы, татар шигыренең көче, куәте сыналды», ди икән, ул моны чынбарлыкның үзенә таянып, бу чын хакыйкать булганга яза.

Туфан шигъри иҗатының беренче елларында ук әдәбиятка дөньяны ифрат дәрәҗәдә үзенчә күрүе, һич кетелмәгән, аның үзенә генә хас гаҗәп чагыштырулары, халык әкиятләрендәге сыман титан образлары белән килеп керде. Без ул әсәрләрне әле бүген дә поэтик табыш очраткандай рәхәтләнеп укыйбыз икән, бу үзе генә дә күп нәрсә әйтә. Мәсәлән, менә мондый шигырьне ничек онытырга мөмкин?

**Кыңгыр яткан Урал**
**Чилем тарта.**
**Чилем сабы — озын таш торба.**
**Билгә кат-кат рельсе билбау урап,**
**Күпер белән муенын каптырган.**

Бу — замана сулышы. Хәзер булса, бәлки ул бүтән образ табар иде. Әмма Туфанга кадәр пролетариатның шәһәрләе бер үзәге булган данлы Уралны, аның эшчәнлеген берәүнең дә бу кадәр җанлы һәм мәһабәт итеп күз алдына китереп бастырганы юк иде.

Барыр юлында гөлләр утыртып калдыргандай, шагыйрь иҗат гомере буе шулай, еллар күкрәгенә онытылмастай нәфис бизәкләр чигә-чигә, шигъри камиллекнең торган саен югарырак баскычларына менә барды.

**Дөнья мине.**
**Үзгәртте:**
**Еламаска өйрәтте.**
**Күлмәк җиңен ертасымы!**
**Бәйлисе бар**
**Йөрәкне.**

Тегесендә Уралның мәһабәтлегә сокландырган иде, монысында кеше рухының, үзенең хорлегә, кыенлыкларга баш имәстән, шыңшуларга, аһ-ваһларга юл куймастан, ир-егетләрчә нык торуы белән горурлануы нәкъ Туфанча күперенке, истә калырдай итеп бирелгән.

Әй, зәңгәр канатлы
Мәңгелек күбәләк!
Бу чиксез Галәмнең
Һәр юлы түгәрәк.
Төбе юк, яры юк,
Читә юк Галәмдә
Каядыр җитәргә
Теләсәң, әгәр дә,
Кешеңә таян, Җир:
Кодрәтең — кешеңдә!
Кешенең тормыш дип
Аталган эшендә!

Бу да шул ук Туфан. Әгәр дә бу юлы аңа җир шарының үзеннән дә өскәрәк, аннан да биеккәрәк «күтәрелергә» туры килгән икән, ул анда безнең замандашыбызның бөекләгән тагын да калкурак һәм күренеклерәк итеп тасвирлау өчен «менгән».

Шул рәвешчә, Хәсән Туфанның кеше дигән бөек затка мәхәббәте, замандашларыбызның мактаулы иҗади хезмәтенә чиксез ихтирамы Урал заводларында слесарь булып эшләгән яшьлек чорыннан чал чәчле мөхтәрәм өлкән шагыйрь вакытына кадәр бөтен иҗаты буенча матур аһәң булып яңгырап килә.

Әмма мин монда шагыйрьнең тагын бер шигыреннән биш кенә юл китермичә уза алмыйм. Чөнки, минем аңлавымча, Туфанның кешегә, димәк, аның аша бөтен тормышыбызга булган кайнар мәхәббәте бу шигырендә самими бер җылылык һәм горурлык хисе белән сугарылып, аеруча үтемле итеп әйтеп бирелгән. Менә ул:

Талантлы син, Кеше туганым,
Сәләтле син һәрбер иҗатка.
Дөнья дигән бөек китапка
Языла бара хезмәт юлларың,
Талантлы син, Кеше туганым.

Туфан шигырьләренең сүзгә тапкырлыгы һәм байлыгы, аларның тылсымлы тәэсир көче һәммәбезгә дә мәгълүм. Аларны укыганда, минемчә, берәү дә гамьсез, ваемсыз кала алмый. Туфан шигырьләрен укып бара торгач, күптән көтелгән куанычыңны ачкандай, кинәт гаҗәпкә каласың. Тукта, ничек болай булды соң әле бу? Гомер буе ишетеп килгән гап-гади сүзләр аның шигырендә гаҗәеп бер матур аһәң белән бөтенләй яңача яңгырыйлар түгелме соң? Әйтерсең, ул аларга тылсымлы әфсен өргән! Ул, мәсәлән, елаган сабыйны юатып һәм барчабызны да көнләштереп:

Яшьләрең юа лабаса
Күзеңнең зәңгәрләрен...—

дип әйтә ала.

Янсә аның шигырьләрендә сүз үз өстенә һич «авырсынмыйча» берьюлы икешәр «йөкләмә» күтәрә ала:

Килачәккә хатлар барып җитә,
Ә үткәнгә хатлар бармыйлар...—

дип яза ул.

Бу юлларны укуга Һади Такташның «Киләчәккә хатлар»ы искә төшә. Әмма шул ук вакытта монда бит Хәсәннең Такташка адресланган үз хаты турында да сүз бара.

Нинди дер аеруча затлы һәм купшы сүзләр эзләү белән мавыкмыйча, халык телендәге гади сүзләрдән укып туймастай ягымлы, «җанга якын» шигъри юллар тезеп бару, минемчә, Хәсәннең иң яраткан шөгыльләреннән берсе. Менә бу дүрт юлны, мәсәлән, рәхәтләнеп укыйсың.

**Синең бит тә бит, иркәм,**
**Ай битенә пар икән:**
**Ай — ни, ул — ни, диләр иде,**
**Халык сүзе хак икән.**

Монда шаярту да, сүз уйнату да бар. Икешәр, өчәр генә аваздан гыйбарәт булган бу «нәни» сүзләр шундый «тәмен» белеп, шундый нәфис бер нәкыш итеп чигелгәннәр ки, шагыйрьнең бу эше безнең элекке алтынчы һәм көмешче маһирларыбызның нечкә кул эшләренә охшап кала. Бу шигырь җәйге тын кичне күл өстендә ай нурлары уйнавын да күз алдына китерә.

Күрәсең, гади сүзләрдән мондый гүзәл юллар тудыру өчен сирәк очрый торган зур талант та, гомер буе һич тынгылык белмәстән, һаман эзләнү, өйрәнү дә, туган теленә кайнар мәхәббәт тә, ару-талуны белмәгән фидакарь хезмәт тә кирәктер. Бәхеткә каршы, Туфанда боларның һәммәсе дә җитәрлек.

Хөрмәтле өлкән шагыйребез Хәсән Туфанга җитмеш яшь... Шушыны әйтү белән үк «ничек, кай арада?» дигән кебегрәк төрле сораулар килеп туа. Әле күптән түгел генә Такташ белән алар икесе — буй-сыннары да, яшьләре дә бер чамадай булган җиту чәчле ике егет, берсе артыннан берсе сәхнәгә күтәрелеп, шигырь укыйлар иде. Әле күптән генәме Әхмәт Фәйзи, Фатих Кәрим, Муса Җәлил, Хәсән Туфан шигърият дигән шул ифрат авыр һәм мәшәкатьле йөкне җыйнаулашып төпкә җигелгән хәлдә янәшә тарталар иде. Әле күптән генәме...

Әмма табигатьнең берничек тә кире кагып һәм хәзергә әле һич тә үзгәртеп булмый торган үз кануннары бар. Шулай ул — җитмеш. Ләкин без моны узган гомерне юксыну, нәрсәгәдер офтану хисе белән искә алмыйбыз, һич юк. Хөрмәтле иптәшебезнең яше күпмегә җитүгә карамастан, һаман да элеккечә кайнар йөрәкле булып, бетмәс-төкәнмәс иҗат дәрте белән яшәве безне чиксез шатландыра.

Шул уңайдан, аңа мәдхия итеп түгел, бәлки җае чыкканда бу изге эше белән дә горурланып, тагын берничә сүз әйтәсе килә. Хәсән Туфан шигъриятә алмаш хәзерләүгә, яшь талантлар үстерүгә гомер буе барлык көчен һәм педагоглык сәләтен биреп килде. Бу хакта аның дәртле өндәү авазы моннан күп еллар элек үк ишетелгән иде.

**Безнең эздән**
**Безнең дәвам килә,**
**Яңа яшьлек килә яшәргә!..—**

дигән иде ул. Туфан монда да, иҗатындагы кебек үк, ярты-йортыга гына канәгать булмастан, яшьләр арасыннан әдәбиятта үз сүзен әйтердәй, вакыйга булырдай чын талантлар табарга тырыша.

Туфан каршында яшь шагыйрьнең талантлы яңа әсәре ул һич тә гади шигырь генә түгел, юк, ул сугыш вакытында зур шәһәр алу, уникаль җир асты байлыгын ачу, яисә айга очу кебек үк җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә торырга тиешле чиктән тыш җитди вакыйга. Үзенең талантлы шигыренә яшь шагыйрь, минемчә, хәтта үзе дә Туфан кебек үк чын күңелдән, аның кебек чиксез-чамасыз бер куану белән куана белми торгандыр. Яшьләрнең бер әйбәт шигырен тыңлау өчен үзенең кадерле вакытын, тансыклаган ялын, тынычлыгын, хәтта татлы йокысын фида итү Туфан өчен көн дә булып торган иң гадәти хәл. Ул күпме яшь талантка сәләтен ачарга булышты, үзенең йөрәк җылысын бүлеп биргәндәй, ничәмә-ничә яшь күңелдә иҗат чаткысы үрләтте!

Бу фидакарь мәхәббәтнең җимеше күз алдында. Туфан «фатихасы», аның ярдәме белән шигърият мәйданына күтәрелгән яшь көчләр остазларының якты еметен җиргә салмадылар.

Хәсән Туфан яше һәм әдәбиятта тоткан урыны белән генә түгел, бәлки ифрат катлаулы һәм гыйбрәтле тормыш мәктәбе узуы белән дә хәзерге әдип һәм шагыйрьләр арасында иң өлкәне. Ул Сәйфи Кудаш белән Беймбәт Майлинның «Галия» мәдрәсәсендә сабакташы һәм якын дусты, Һади Такташның яшьтәше һәм фикердәше, Муса Җәлил белән Фатих Кәримнең, Әхмәт Фәйзинең замандашы һәм иптәше, Сибгат Хәким белән Шәйхи Маннурның чордашы һәм каләмдәше. Кешелек тарихына яңа юл салган шушы давыллы ярты гасыр эчендә тормышында һәм иҗатында ниләр генә кичермәгән шагыйрь, нинди генә өермәләргә юлыкмаган! «И тормыш» исемле шигырендә язылганча, аның тормышка мөрәҗәгать итеп:

Йөрәкләрнең тирән эзе калган
Безнең сабыр, чандыр иңнәрдә:
Җилкәләрдә кичердек без сине
Күперләрең ватык җирләрдә,
Җилкәләрдә...—

дип әйтергә, һичшиксез, хакы бар!

Әмма яшәеш аны нинди генә сынауларга дучар итмәсен, тормыш диңгезе нинди генә дәһшәтле дулкыннарында чайкалдырмасын, Туфан һәрвакыт туган иленең һәм халкының намуслы һәм тугрылыклы улы, чорыбызның якты идеаллары өчен саф күңеле, зур таланты белән чын күңелдән көрәшүче үз шагыйре булып калды.

Күңелдә иң авыр
Сәальләр туганда,
Тик сиңа килəм мин
Киңәшләр сорарга...—

дип Ленинга мөрәҗәгать итә икән, партиясез өлкән шагыйрь телендә бу юллар аеруча эчкерсез һәм тирән мәгънәле булып ишетелә.

Хәсән Туфанның җитмеш еллык бәйрәм тантанасы татар әдәбиятында гына түгел, бәлки күп милләтле бөтен совет әдәбиятында онытылмаслык истәлек калдырырдай зур һәм шатлыклы вакыйга. Бу уңай белән без хөрмәтле өлкән иптәшебезне чын күңелдән тәбрик итеп, һәммәбезнең дә уртак фикерен чагылдыручы аның үз сүзләре белән бу мәкаләне тәмамларга телибез.

Без барасы юллар озын әле,
Без җитәсе кырлар бик ерак;
Барган саен юллар күңеллерәк.
Барган саен еллар җылырак.

## Тәлгат Галиуллин

# СҮЗ КУШАСЫ КИЛӘ ТАЛЛАРГА...

*Х. Туфан иҗатында табигать сурәтенең эволюциясе.*

Хәсән Туфан — үз укучысын күптән тапкан шагыйрь. Ул поэзиягә өермәле егерменче елларда килеп керә һәм шул чорда ук үз тавышы, үз шигъри интонациясе булган сүз остасы буларак танылa. «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Бибиеләр» шикелле эпик колачлы һәм киң сулышлы поэмалар язып, Туфан татар поэзиясен яңа тормыш материалы, үзенчәлекле характерлар белән баета.

Дәһшәтле егерменче еллардан соң байтак сулар акты, ил, халык тормышында олы вакыйгалар, фаҗигале һәм куанычлы, хәвефле һәм шатлыклы хәлләр булып узды, әдәбият яңа үрләр яулады, поэзиягә яшь талантлар өстәлеп торды. Бу еллар эчендә Туфан шигъриятe дә зур үзгәрешләр кичерде. Шагыйрьнең дөньяга карашы, тематик колачы киңәйде, шәхеснең мең тармаклы күңел кыллары белән бәйләнеш алымнары төрләнде. Туфанның хәзерге лирикасына чорның фәлсәфи һәм әхлакый асылын тоя белү, якты киләчәккә юл ярып баручы замандашыбызның рухи матурлыгын дәртләнеп җырлау, вакыйганы хис тирәнлеге белән үреп сурәтләү, тормышчан лиризм һәм шигъри нәфислек хас.



*Х. Туфан автограф бирә*

Татар поэзиясенең социалистик реализмга хәрәкәтен, хәзерге көндәге үсешен һәм киләчәген Хәсән Туфан исеменнән башка күз алдына китереп булмый. Әдәбиятка Туфан алып килгән геройның үсеш эволюциясен тирәнрәк өйрәнү галимнәребезне кызыклы ачышларга этәрер иде. Шагыйрьнең сурәтле фикерләү өлкәсендәге табышлары да үзенең өйрәнүчесен көтә. Шул мәсьәләләрне ачыкламыйча торып, әдипнең татар поэзиясе үсешендә тоткан урынын билгеләп булмаячак. Теләсә нинди шагыйрьнең көче, олылыгы конкрет мәсьәләләрне өйрәнгәндә ачыграк күренә. Нәкъ менә шуңа күрә, кабул ителгән тәртипләрдән беркадәр читенеп, традицион юбилей мәкаләсе урынына, укучыга Туфан иҗатының бик әһәмиятле бер проблемасына багышланган тикшеренү тәкъдим итәргә булдык.

Х. Госман, шагыйрьнең сугыштан соңгы иҗаты хакында сүз йөртеп, болай дип язган иде: «Хәсән Туфан үзенең бу чордагы иҗатында совет кешесе шәхесенең... чәчәк атуын җырлый дисәк, мөгаен, ялгышмабыз... Ул үзенең мәһабәт эшләре белән коммунизмга юл ярып бара. Шагыйрь аны кеше мөнәсәбәтләренең мәгълүм өч сферасы — җәмгыятькә, табигатькә, үз-үзенә мөнәсәбәтләре берлегендә күрсәтә»[1]. Чыннан да, Туфан иҗатында Кеше белән Табигать арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләсе, пейзаж лирикасы аерым урын тота. Табигать сурәте аның поэзиясендә гаҗәеп күп төрле функцияләрдә кулланыла, шагыйрьнең бөтен иҗатына гуманистик рух, җылы лиризм бирә. Шагыйрь табигать күренешләре аша үзенең дөньяга карашын, тормыш фәлсәфәсен чагылдыра, шәхес кичерешләрен үсештә, хәрәкәттә күрсәтүгә ирешә. Х. Туфан үз поэзиясендә табигатьнең мәңгелеген, бетмәстөкәнмәс матурлыгын, төсләр байлыгын ачып салырга омтыла. Ул табигатьтәге нәфислектә һәм гармониядә яңа җәмгыять белән бергә туачак матурлыкның, кешеләр арасындагы камил мөнәсәбәтләрнең чагылышын күрә, алар арасында якынлык таба.

Ни өчен Туфан иҗатында табигать образы шундый әһәмиятле урын тота соң?

Мәгълүм булганча, шагыйрьнең бала чагы Татарстанның мәһабәт урман-тугайлары, хәтфә болыннары кочагында үтә. Туган җир, туган табигать матурлыгы булачак шагыйрьнең дөньяга карашы, бигрәк тә эстетик зәвыгы формалашуга нык ярдәм итә. Шагыйрә йөрәкле әнисе аны матурлыкны аңларга өйрәтә. Бу хакта Туфан үзе түбәндәгечә сөйли:

[1] Х. Туфан. Сайланма әсәрләр. Казан. 1964 ел, 17 бит.

...Әни «минә йортка яки бәрәңге бакчасына бергә алып чыга да дөнья күрсәтеп йөри, кайткан яки киткән кыр казлары, торналар белән генә түгел, куаклар, үсемлекләр, җилләр, йолдызлар белән дә сөйләшә башлый иде...

Әни миндә табигатьтәге бар нәрсәнең җаны бар икән, чишмәләр генә түгел, йолдызлар да, җилләр дә сөйләшә икән, дигән «иман» тудырды»[1].

Яшьлек елларында Туфан Себер якларын йөреп чыга, Урал, Башкортстан табигате белән якыннан таныша. Бай һәм үзенчәлекле тормыш тәҗрибәсе аның иҗатына да тирән эз сала. Мәсәлән, егерменче елларда ул татар поэзиясенә Урал һәм Себернең үзенчәлекле табигате бизәкләрен алып килә, шул як пейзажын сынландыра, шул як табигате күренешләреннән чагыштырулар, метафоралар ясый.

Яшь шагыйрь образларның катлаулыларын, берсен-берсе кысрыклап килгәнен, күп төрле мәгънә белдергәнен яратып куллана. Шулар аша Туфан чорның өермәле романтикасын, омтылышлы рухын, ашкынулы идеалын чагылдырырга ниятли. Ул табигать сурәтләреннән «җил» һәм «буран» образларына аеруча еш мөрәҗәгать итә. Халык иҗатында мәхәббәт символы, йомышчы, мәңгелек юлчы буларак урнашып калган җил сурәте Туфанның «Еллар итәгендә», «Урал эскизлары» кебек әсәрләрендә үк очрый. Шагыйрь бу традицион образны бер урында метафора, эпитет буларак үстерсә («җил кешеләрнең эзен себерде», «күе җил»), икенче урында стихияле көчләрне символлаштыручы романтик сурәт буларак куллана («әй сез, бунтлар, җил-дуфанлы көннәр, өермәләр, утлар, вулканнар!»).

Егерменче елларда Хәсән Туфан табигатьнең башка күренеш-символларын да шундый ук стилистик һәм мәгънәви максатлардан чыгып үстерә. Әмма шулай да бу чорда шагыйрьнең палитрасында пейзаж зур урын тотмый әле. Табигать сурәте, кеше рухының олылыгын һәм кичерешләрә тирәнлеген күрсәтүдән бигрәк, вакыйганың иҗтимагый эчтәлеген ачуга юнәлтелә. Туфан тасвирлау чараларының турыдан-туры революцион көрәшкә, производствога, дәвер алып килгән яңалыкка барып тоташканнарын яратыбрак куллана.

Урал эшчеләренең революциягә хәрәкәтен, татарлар арасында сыйнфый аңның үсешен тасвирлаган уңышлы әсәрләрен биргәннән соң, Туфан утызынчы еллар башында ничектер тукталып кала. Авыр һәм катлаулы эзләнүләр аша, әдәби инерция көчен җиңә-җиңә, шагыйрь утызынчы елларның уртасында яңадан үз «көен» таба, кеше белән табигать арасындагы якынлык һәм каршылык, галәмнең, җәмгыятьнең бүгенгесе һәм киләчәге турында фәлсәфи уйланулар сөземтәсе булган шигъри этюдларын бирә башлый. Ул күләмле эпик формадан, эпик тасвирлау алымыннан читләшә, артык бизәкле образлардан, вакыты белән үзмаксат буларак туган метафоралардан баш тарта. Ана сөте белән күңеленә кереп калган туган табигать яме, яшьлек истәлекләре, Татарстан пейзажы өскә калкып чыга. «Ак каен», «Канатлар» шикелле әсәрләрен генә искә төшерик. Аларның үзәгендә инде, «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Урал эскизлары» әсәрләрендәге шикелле, катлаулы эпик характер ятмый, ә хис-кичереш хәрәкәте тора. Шагыйрь табигать сурәте, чынбарлык күренешләрен сынландыру аша шәхес рухына юл ала, иң матур уй-тойгыларын туган табигать күренешләренә ышанып тапшыра. Шул елларда табылган юнәлешне шагыйрь бүген дә дәвам иттерә, үстерә, гүзәл лирик әсәрләрен иҗат итә. «Узып барышлый», «Ташкент бакчаларында», «Каеннар сары иде», «Илдә ниләр бар икән», «Иртәләр җитте исә», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Каплан-Кырда», «Кәрван», «Овидий Назон», «Агыла да болыт агыла» шикелле күңел түрендә урын алган һәм теләсә нинди олы шагыйрьнең сайланмасын бизи алырлык шигырьләрне генә искә төшерик. Алар чорның тирән һәм гаять катлаулы фәлсәфи эчтәлеген, кешенең киеренке хисләрен ачып салалар, караңгылык белән яктылык, вәхшилек белән гуманизм, үлем белән үлемсезлек арасында барган мәңгелек тартышны яңача һәм сәнгатьчә нәфислек белән сурәтлиләр.

Туфан галәмнең, кешелек җәмгыятенең үсешендә, табигатьтәге мәңгелек хәрәкәттә, яңарыш процессында тирән эчке логика күрә. Шул логика буенча гуманизм, кешелеклелек һәрвакытта җиңүче булып чыга:

Галилейны, безнең Җәлилләрне
Хет ас, хет кис, алда, хәйләлә,—

---

[1] Х. Туфан. Сайланма әсәрләр. 6—7 битләр.

**Жир әйләнә барыбер, инквизитор!**
**Коммунизм ягына әйләнә!**

*(«Ә Жир барыбер әйләнә».)*

Шагыйрьнең табигать лирикасында да әһәмиятле һәм үзенчәлекле яңалык сыйфатлары беренәнә. Урал, Себер, тайга образлары янына дала, сәмум, чүл сурәтләре, дөнья, галәм, ерак мәңгелек шикелле символлар килеп өстәлә. Табигать хәзер Туфан өчен иҗтимагый идеяләрне укучыга җиткерү һәм стилистик төгәллеккә ирешү чарасы гына түгел. Ул — әдипнең юлдашы, дусты һәм якын киңәшчесе дә. Лирик герой чынбарлыктан үзенә иш, сердәш эзли, чәчәкләргә, талларга, чишмәләргә, йолдызларга, атомнарга мөрәҗәгать итә, сүз куша, алардан ярдәм, киңәш сорый. Бер шигырен ул «Сүз кушасы килә талларга...» дип атый...

Ләкин Туфан шәхес белән табигать арасындагы мөнәсәбәтне гадиләштереп, сентименталь-романтик идиллия төсендә генә тасвирлаудан ерак тора. Бакый чынбарлык, табигать гаять катлаулы, четерекле һәм каршылыклы. Шул нисбәттән «Каплан-Кырда», «Кәрван», «Кара-Ком ягында» шикелле әсәрләрне тагын бер кат укып карыйк...

Чүлләр аша үткәндә шагыйрь күзе акыл белән кыргый көчләр арасында гасырлар буенча барган тарихи көрәшнең җанлы эзләрен күрә. Адәм баласы элек-электән: «Дәрья тагын Каспийга койсын» дип, корылыкка каршы рәхимсез сугыш алып барган, «Каплан-Кырда» сөякләрен калдырган», «чүлләр бәрханы бай Багдадның данлы кәрванын күмеп киткән». Эре романтик штрихлар белән бирелгән тарихи көрәштән соң, лирик хис тагы да киеренкеләнә, шәхеснең катлаулы, тирән тойгылары алгы нәүбәткә чыга. Табигатьтәге кыргыйлык белән иҗтимагый явызлык арасында якынлык, уртаклык бар, ди шагыйрь. Табигатьнең тезгенсез көчләре, явызлык белән бәрелештә лирик геройның рухи тазалыгы, матурлыгы, туган иленә мәхәббәте бөтен күркәмлеге белән ялтырап ачылып китә. Төп фикерен укучысына тулырак җиткерү нияте белән шагыйрь куе эмоциональ буяуларга мөрәҗәгать итә, контрастлы чагыштыруларга, антитеза алымына өстенлек бирә («юлбасар күк усал сызгырып... сәмум килә чүлләрдән», «сулар кибә, үләннәр яна»).

Туфан табигать халәтенең төрле вакытларын, төрле чагылышларын тасвир үзәгенә алырга ярата. Бер урында ул кеше белән табигать арасындагы бәрелешне, көрәшне сурәтләсә, икенче урында галәмнең төп көчләре арасындагы дуслыкны, гармонияне, якынлыкны тасвирлый. Бу хакта Н. Юзиевнең кызыклы күзәтүе бар: «Шагыйрь,— дип яза тәнкыйтьче,— кешене табигатьтән аера торган каршылыкка караганда игътибарын аларны куша торган уртаклыкка, якынлыкка юнәлтә» [1].

«Сөйли торган материя» шигырендә әлеге якынлык һәм бердәмлек идеясе аеруча тирән һәм үзенчәлекле итеп бирелгән. Шагыйрь, романтик тасвир алымнарына таянып, төрле яссылыкларда яткан күренешләр, әйберләр, җан ияләре арасында аларны янәшә куярга мөмкинлек биргән эчке сәбәплелек бәйләнеше күрә:

**Мин — бу кырлар, сулар, җилләрдәге**
**Атомнарның иске туганы:**
**Материя мин, җаным,**
**Аның бары**
**Сөйли, җырлый, сагына торганы.**

«Кеше», «Прометей», «Үсәбезме, сеңелем?», «Гыйбрәт» шикелле лирик парчаларда табигать белән кеше арасындагы бәйләныш шулай ук үзенчәлекле поэтик форма аша бирелгән. Аларда шигъри шартлылык та бар, хәрәкәт кискенлеге һәм динамика да күзгә ташлана. «Гыйбрәт» шигыренең сюжет канвасы бик кызыклы. Туфан «чәчкәсе күплектән күрәм гөлемнең бөгелгәнен» дигән халык җырын эпиграф итеп ала да, шул тезисның дәресләгән тикшереп карарга була. Чыннан да, гөл ни өчен болай бөгелгән соң?

**— Сыгыласың, гөл, бөгеләсең,**
**Чәчкәң авыр, күрәсең!**
**Гөл шаярып сорау бирә:**
**— Кемне булса сөямсең!**

---

[1] Н. Юзиев. Традицияләр яңарганда. Казан. 1966. 65 бит.

Минем хәлне бер мәлне
Син дә белерсең әле:
Мәхәббәтең чәчәк атса,
Син дә бәгелерсең әле!

Бу лирик шаяруда табигать белән кеше арасындагы чик бөтенләй алып ташлана: гөл сөя-сөелә, шаярта, мәхәббәт сагышыннан сыгыла... Бу алым тормыш каршылыгын, яшәешнең катлаулы күренешләрен тирәнрәк күзалларга һәм табигать белән кеше, табигать сурәтчесе белән фикерләү арасындагы якынлыкны аңларга юл ача, татар шигъриятенең офыгын киңәйтеп җибәрә. Туфан романтизмының нигезендә дә табигатьне җанландыру ята.

Әлбәттә, табигать күренешләрен бу рәвешле сынландыру алымнарын поэзиягә бер Туфан гына алып кермәде. Сурәтле фикерләүнең бу ысуллары халык иҗатында, поэзиядә күптәннән яшәп килә. Кандалый, Тукай, Дәрдмәнд, Такташ ачышларын гына искә төшерик. Ләкин шагыйрь ирешелгәннәрне кабатлау юлына төшмәскә тырыша. Ул халык җырларында башлангыч хәлендә калган шигъри энҗеләрне, күзәнәкләрне табып ала да, аларны баетып, үстереп җибәрә. Бер мисал китерик. Халык лирикасында кешенең табигатькә мөрәҗәгате белән башланып киткән җырлар зур урын тота: «Сандугачым, әйт үземә, кайсы талга кунасың?»; «Сандугач, былбыл, ник сайрыйсың, үзәк өзелә синең тавышка»; «Аяз җилләр, каян истең, ничә сәхра үтә кичтең». Табигать лирик герой, аның кичерешләре белән тыңлаучы арасында, шулай әйтергә ярәса, арадашчы, элемтәче хезмәтен башкара. Әдәбият белемендә риторик янсә лирик эндәш дип аталган бу алым Туфан иҗатында еш табыла:

— Күтәрегез, гөлләр, башыгызны,
Ташлап җилгә кайгы-сагышны:
Сезгә, гөлләр, якын сердәш килә,
Каршылагыз якын танышны!..
*(«Овидий Назон».)*

Туфан иҗатында риторик эндәш фикер белән хис бердәмлегенә ирешү чарасы булып китә, экспрессив көчен, стилистик мөмкинлекләрен арттыра бара. Мәсәлән, еш кына табигать, чынбарлык үзе лирик геройга мөрәҗәгать итә. Романтик шартлылыкка, хыял уенына нигезләнгән бу метафорик алым кеше хисләрен тирәнрәк ачуга, шигырьне тыгызландыруга, ритмик иркенлеккә алып килә:

Гөлләр сорый миннән: «Нишләп, Туфан,
Уйга калдың әле син шулай!»
Белми гөлләр, уйга калып шулай
Гүзәллеккә сокланам бугай.
Яз эндәшә кебек бүген миңа:
«Нәрсә булды сиңа! Нишләдең!»
— Гүзәл син, яз! Сәҗдә кылып сиңа,
Тезләндерә әзер хисләрем!
*(«Гүзәл».)*

Бу төр шигырьләрдә сурәтләнгән табигать сынын лирик-риторик эндәшкә, эмоциональ-хисси яңгырашлылыкка генә кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Безнең алда, шартлы термин белән әйткәндә, «лирик драма» формасы ярылып ята. Табигатьне сынландыруның мондый катлаулы алымы утызынчы елларга, беренче чиратта, «Ак каен» шигыренә барып тоташа. Шагыйрь биредә туган табигать сурәтенә, реалистик шартлылык алымнарына таяна һәм шулар аша кеше белән табигать арасындагы рухи һәм физик бердәмлекне ачып салырга ниятли. Шигырьнең үзәгендә лирик киеренкелек белән драматизм ята.

Асучылар киткәч, сорый каен:
— Авыртмыймы муеның, Хәйбулла!
— Авыртуга түзәр идем, каен,
Тын алуы бигрәк авыр ла.
Билбау кыса, каен, сулышкайны,

Бушатсана шушы билбауны!
— Бушатыр да идем билбавыңны,
Мин каенда андый кул бармы!

Сугыштан соңгы елларда язылган «Чәчәк сибелә җилдә», «Тельманнар каны тамган камерада», «Ромашкалар», «Овидий Назон» шигырьләрендә Туфан «Ак каен» традициясенә әйләнеп кайта, яшьлектә табылган алымнарын үстерә, баета. Бу шигырьләрендә Туфан, фаҗиганең күзенә туры карап, чор драматизмын чагылдырырга, гасыр каршылыгы ачып бирергә омтыла. Шигъри форманың сәнгатьчә камиллеге, нечкә лиризм — табигатьтән, киеренкелек, кырыс драматизм тормышның үзеннән килә. «Ромашкалар» шигыре, мәсәлән, халыкның йөзләгән лирик җырлары үрнәгендә, табигать күренешен тасвирлау белән башланып китә:

Ромашкалар тирбәлә җилдә,
Бер күренеп, тагын күмелеп,
Йөгерә-йөгерә шаян нәниләр
Кырда качыш уйнаган кебек.

Алдагы юлларда табигать картинасы белән шәхес кичереше арасында уртаклык табыла, психологик күчеш барлыкка килә. Лирик герой, сөйгәненең мәхәббәтен, аны һаман да зарыгып көтүен белергә тели, сурәткә халык иҗатында туган ышануын китереп кертә. Ләкин «ярата-яратмый» уены гына лирик герой күңелендәге йөрәк өзгеч шомны, юксынуны баса алмый. Җилдә бер күренеп, бер күмелеп утырган шаян ромашкаларны кабер өстендә үскән резеда чәчәге алыштыра. Ромашка белән резеда чәчәгенең капма-каршы куелуы, яшәү белән үлем арасындагы тартышны гына символлаштырып калмый, кичереш киеренкелеген чагылдыра, рухи халәттә туган үзгәрешләрне исемли, кыскасы, психологик анализ чарасы булып килә.

Табигать сурәте, психологик анализ чарасы буларак, Туфан лирикасында күп төрле мәгънәви һәм стилистик функцияләрдә кулланыла. Шуларның берничәсен күрсәтеп үтик.

Элек кайгы-хәсрәтнең ни икәнен дә белмәгән сабый, сугышта әтисен югалткач, саргая, кибә, матурлыгын югалта. «Каеннар сары иде» шигырендә сүз әнә шул турыда бара. Шагыйрь чынбарлыктан да баланың кичерешләренә тиң сурәтләр таба: «Күз иде, җирнең шушындый күңелсез чагы иде, астралар, гөлләр кыраулы, каеннар сары иде...» Бу шигырьдә табигать образы, шәхеснең үкенечле хисләрен куертып, тыгызландырып җибәрсә дә, алар арасында әле турыдан-туры якынлык юк, янәшәлек бәйләнеше генә бар.

«Нишләтик сине йөрәк»нең лирик герое Нияз дошманны тар-мар итеп, ашкынып, үзенең сөйгәне Камәр янына кайта. Аның хәзер мәхәббәткә дә, бәхеткә дә тулы хакы бар. Ләкин тормыш драматизмы батырларны да кызганмый. Камәр Нияз кайтканчы мәңгелеккә табигать белән кушылган. Туфан героенын авыр, кайгылы хисләрен тышкы дөнья сурәтләре аша чагылдыру нияте белән, табигатькә Нияз күзләре белән карый:

Каеннар утыра зиратта
Траур кигән кебек.
Сиңсез дә монда ямансу,
Кит әле, дигән кебек.

Кеше хисләрен мондый ышандыру көче, диалектик эзлеклелек һәм нечкәлек белән зур талантка ия булган шагыйрьләр генә тасвирлый ала.

Табигать күренеше, психологик анализ, хисләр көрәшен, кичереш динамикасын чагылдыру алымы буларак, «Киек казлар» шигырендә аеруча уңышлы яңгырый. Кичерешенең сәдалеге һәм гаҗизлеге белән дә, халык җыры стиленә «тәкълит» итеп язылуы белән дә бу шигырь күңелгә бик тиз кереп урнаша. Ул җыр буларак та халык арасында киң таралды.

Туфан теманы эләктереп алуда халык сызган юлдан бара. Эчтәлекнең, үзәк мотивның халык җырына якынлыгы сурәт алымнарының, композиция элементларының да халык зәвыгына аһәңдәшлеген китереп чыгарган. Ләкин шагыйрь халыкны кабатламый. Туган илдән аерылу мотивы шигырьгә лирик геройның шәхси кичерешләрен алып керергә мөмкинлек бирә. Ул үзе белән кыр казлары арасында рухи якынлык күрә.



*Х. Туфан башкорт дуслары янында.*

Туфан табигать тормышын тирәнтен аңлый, аның халәтендәге кечкенә генә үзгәреш-яңарышны да күреп, сиземләп ала: яфрак лепердәвендә дә мәгънә күрә, агачлар, кошлар тормышында кеше язмышы белән уртак нигезләр табып, аны нечкә психологизм белән рәсемләп бирә. «Давылда» шигырендә ул табигатьнең көзге югалтулары турында сөйли. Ләкин көзге табигать туасы язлар өчен җирлек әзерләп калдыра: «Яфраклар көзге каеннан елаусыз аерылдылар: каенда дәвам итәргә бөреләр калдырдылар». Җилдә тибрәлеп, йокымсырап утырган нәни бөреләр — каенның сабыйлары — язлар килгәч, яңа тормышларын башлап җибәрерләр.

Туфан лирикасында табигать шигырьнең теләсә кайсы өлешенә килеп керә ала. Ул эпик тасвирга да, «мин»нең фәлсәфи уйлануларына да, «лирик стихия» белән дә кушылып китә. Кичерешбер табигатькә, бер лирик геройга борыла.

Шунсы үзенчәлекле, Туфан иҗатында туган җирнең, табигатьнең үзенә атап язылган шигырьләр очрамый диярлек. С. Хәким, мәсәлән, киресенчә, бу алымны бик яратып дәвам иттерә. «Туган як көе», «Туган җир», «Туган як», «Республикам минем», «Гөбенә буенда» кебек әсәрләрендә шагыйрь туган якның, билгеле бер төбәкнең үзенә «сүз катып», табигатьнең сынын халык күңеленә, зәвыгына якын буяуларда гәүдәләндерә.

Х. Туфан, сәнгатьчә идеал белән гадилек бердәмлегенә омтылып, эзләнүләрен төрле юнәлештә алып бара. Бер яктан, ул: «Кил әле, кил, үбим үзеңне бер! — яратам мин сине, и Җирем! Кочагыма минем сыймасаң да, җаныма бит сыясың минем»,— дип җир шарына, ерак Галактикага, мәңгелеккә мөрәҗәгать итә. Икенчедән, Туфан Җир шары, галәм кебек олы төшенчәләрне, бер бөтенне, аның ниндидер кисәге, гаять әһәмиятле өлеше аша чагылдырырга ярата. «Аралагыз мине, ак каеннар» исемле мәгълүм әсәрендә шагыйрь туып-үскән авылын, җирен сагынуын, шул юксынудан «газиз башкае» талуны әйтергә тели. Әмма шагыйрь туган якның үзенә түгел, ә аның күркенә — «яшел шәлле» ак каенга, миләшкә эндәшә:

> Арыды бугай сезне сагынып йөрәк,
> Арыды бугай газиз башкаем.
> Яшел шәлең белән күләгәләп,
> Яп иттер бер, сеңелем ак каен.

«Үзеңә бүләк итәсе иде» шигырендә Туфан туган авылы, туган ягы алдында үтәлмичә калган бурычы турында уйлана. Ләкин биредә дә ул метонимия алымына таяна, сурәтне тарайта бара һәм, үзе әйтмешли, «матдәнең җыры» — чәчәк белән сөйләшеп китә («Искә алып мине тагын, тиргиләрдер Кәрмәт гөлләре»). Чәчәкләр шагыйрьне тизрәк аңларлар, җиңелрәк гафу итәрләр шикелле. Ул гөлләрнең «уй-фикерләү рәве-

шенә» үтеп кирәргә, үзе турында нәрсә сөйләгәннәрен белергә тырыша. Аның өчен, ахыр чиктә, табигать фикере — халык фикере:

Нәрсә диләр икән ул чәчәкләр! —
Китте дә бу батты ди микән!..
Ә дөньяның мин күрмәгән төше,
Мин күрмәгән гөле күп икән...

Туфан үзенең иң матур хисләрен, тойгыларын гөл-чәчәк образларына ышанып тапшыра. Халык җырларында бөтен сылулыгы, гүзәллеге белән балкып утырган һәм, гасырлар сынавын үтеп, нәфисләгән, индивидуальләштерү көчен саклаган бу милли сурәтне хәзерге татар поэзиясендә аңардан да оста үстерүче шагыйрьне атавы кыен. Шигырь исемнәренә генә күз салыйк: «Чәчәк сибелә җилдә», «Чәчәкләр төсе калды», «Чәчәкләр», «Ромашкалар», «Гөлләр инде яфрак яралар», «Гөлләр исе калды кулымда», «Гүзәл» һ. б. Ул чәчәк артыннан чәчәкне, тәсбих төймәләрен тезгән шикелле, шигырьгә кертә бара.

Туфан төсләрне яхшы аера, күзгә бәрелеп торган ачык сурәтләрне ярата төшә. Аның лирикасын метафорадан башка күз алдына китерүе дә кыен. Чәчәк — табигатьтәге гармония билгесе. Шулай булгач, Туфан уенча, ул укучы белән шагыйрь, табигать белән кеше хисләре арасында арадашчы була ала. Икенчедән, чәчәк шагыйрьнең сурәтле фикерләвенә дә якын, аңа ачык төсле, «алтынсыман» бизәкле чагыштырулар, метафоралар ясау мөмкинлеген бирә.

Табигать күренешләренең гади атамалары булып йөргән исемнәр, халык җырындагы кебек үк, Туфан шигыренә килеп кергәч тә, эмоциональ төсмер алып, шигъри фикерләү бизәге булып китәләр. Ул ай, сандугач, таң, аккош, җил шикелле традицион сурәтләрне яратып куллана. Ләкин аларны, әлбәттә, традицион мәгънәдә генә алмый. Шигырьнең эчке структурасына, кичереш дулкынына яраштырып, ул укучыга электән таныш образларны бөтенләй көтелмәгән юнәлештә үстереп җибәрә: өлгене халык җырыннан ала да аңлы рәвештә фольклорда кабул ителгән схеманы җимерә.

...Шул рәвешле, табигать күренешләре Туфанның ярты гасырлык иҗаты дәвамында гаять зур үзгәрешләр кичерә. Егерменче елларда шагыйрь табигатькә күбрәк идеологик һәм стилистик максатлардан чыгып мөрәҗәгать итә. Алдагы ун-унбиш ел эчендә табигатьнең кулланыш сферасы да, мәгънәсе дә, функциясе дә үзгәрә, киңәя. Ул шагыйрьнең юлдашына, киңәшчесенә, якын кешесенә әверелә, үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне аңларга булыша, аның дөньяга карашына, фикерләвенә, шигъри күременә тирән йогынты ясый. Кыскасы, табигать образы иҗтимагый-фәлсәфи һәм тарихи максатларга буйсындырыла. Туфанның хәзерге лирикасында туган табигать күренешләре психологик анализ чарасы, шигырьне нәфисләү алымы буларак кулланыла. Утызынчы-кырыгынчы елларда шагыйрь еш кына табигатьнең үзен аңларга омтылса, хәзер ул чынбарлык күренешләре аша кеше рухының олылыгын, катлаулы кичерешләрен «материальләштереп» сурәтләргә тырыша.

Туфан поэзиясе туктаусыз үсеп-үзгәреп торса да, ул үзенең төп сыйфатларын саклый. Шулар арасында иң мөһиме — туган табигатькә, аның билгеле бер символларына, лирик сурәтләренә чиксез мәхәббәт. Туфан поэзиясе халыкка шул сыйфаты белән якын да. Әлбәттә, бу катлаулы проблеманы бер мәкаләдә генә тулы хәл итү мөмкин түгел. Шуның өстенә без Туфанның иң соңгы елларда язылган әсәрләренә кагылмадык, шигъри «гөнаһларына» да аерым тукталмадык. Тукай, Җәлилләрнең музыкаль иҗекләрендә тәрбияләнгән укучы Туфан лирикасында «чатак» рифмаларны да, шигырьне «төртеп торган» прозаизм элементларын да җиңел күрә ала. Билгеле бер дата, бәйрәм уңае белән язылган әсәрләре дә, эмоциональ тәэсир көчләре, лирик киеренкелекләре буенча, тормыш тәҗрибәсе сөземтәсе буларак, күңел тирәнлекләреннән күтәрелгән шигырьләреннән түбән торалар. Кызганычка каршы, шагыйрь соңгы елларда андый әсәрләрне дә аз язмады.

Ләкин Туфанның татар шигъриятенә алып килгән ачышлары аны һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзиләр белән бер рәткә куйды. Туган табигать, туган җир матурлыгын, «Табигатьнең патшасы» — кешене олы итеп җырлый белүе шагыйрьгә уңыш һәм дан алып килде. Туган ил тойгысы — туган җир, туган табигать тойгысыннан башлана. Туган табигатькә мәхәббәт хисе — патриотизмның конкрет чагылышы. Шул ноктадан килеп караганда, Туфан иҗаты — иң югары бәягә лаеклы шигърият.

## Рувим Моран

# ТУФАН МОГҖИЗАСЫ

Сезнең Туфан белән бергә Казан урамнарына чыгып йөргәнегез бар микән? Чыкканыгыз булса, ун адым да китеп өлгермәссез:

— Исәнмесез, Хәсән абый! — дигән сүзне ишетерсез. Болар шагыйрьнең якын дуслары, кордашлары, каләмдәшләре генә түгел,— яшьләр, үсмер егетләр-кызлар. Бу кешеләрнең күпчелеге шагыйрьне яратканга, хөрмәт иткәнгә исәнләшеп китәләр. Аларның шагыйрь белән якыннан торып бер авыз сүз сөйләшкәннәре дә юктыр, бәлки. Чал чәчле шагыйрьнең бөтенләй чит кешеләрне очратканда да акыллы һәм шул ук вакытта сабыйларча эчкерсез елмаюы бу яшьләрнең сокланулы күз карашында чагыла кебек.

Шагыйрь күңеленең әнә шулай һәр кеше күңеле, халык күңеле һәм табигать җаны белән дә кушыла алу мизгелен, уртаклык табуы могҗизасын ничек аңлатырга соң? Минемчә, бу сыйфат Туфан өчен поэзиянең бары тик шигырь юллары, рифмалар гына булмавы, үзен бөтен терекләкнең атомнары белән кардәш, бертуган итеп тоюыннан киләдер. Мәсәлән, ул миләүшә чәчкәсенә эндәшеп болай ди:

> — Мин — бу кырлар, сулар, җилләрдәге
> Атомнарның иске туганы:
> Материя мин, җаным,
> Аның бары
> Сөйли, җырлый, сагына торганы.

Аны күргәч, далада үсеп утырган миләүшә чәчкәсенең, Казан урамында очраган бер кыз шикелле, шагыйрь белән исәнләшүенә, күкчәчәк (василек) Туфанның энесе икәнлеккә, экватордагы бананнарның Татарстандагы каеннардан көнләшүенә, талларның татарча сөйләшә белүләренә ышанасың. Чөнки Туфанның табигатькә мөнәсәбәте бөтенләй үзенә бер төрле. Дипломатия теле белән әйткәндә, бу мөнәсәбәт үзара хөрмәт итешүгә нигезләнгән. Ул үзенең өзелеп сөйгән гөлләре-чәчкәләре, үсемлекләре белән генә түгел, тирә-юньдәге бөтен тере җан иясе белән уртак тел таба ала. Хәтта ул үз әгъзалары белән дә аерым бер җан иясе кебек итеп сөйләшә.

Ә үзенең йөрәге турында: «Кырык бердән дә ашкан эсселектә кочегар күк эшли йөрәгем»,— ди ул. Йөрәк белән акыл гынамы соң! Аңа үзе язган шигырь юллары да җанлы бер нәрсә кебек тоела. «Матур әдәбият» нәшриятында шагыйрьнең «Совет поэзиясе китапханәсе» өчен әзерләнгән сайланма шигырьләре җыентыгы тикшерелгән чакта Туфан миңа: «Әгәр кайбер яраткан шигырьләрем, ятим бала кебек моңаеп, китапка керә алмыйча, «ишек артында» калалар икән, мин нишли алам соң? Аларны ничек тә юатырга тырышырмын инде...»,— дип язган иде.

Туфан поэзиясенең материя белән катнашып яшәве Җир тирәсе белән генә дә чикләнеп калмый. Яктысын һәм җылысын галәмгә, әллә кайдагы ерак йолдызларга таратып янып яткан төнге учак белән сөйләшкәндә ул алар белән кайчан да булса «мәңгелекнең берәр почмагында» очрашасына ышана.

Мин еш кына инде җитмешкә җиткән дустымның күңеле һаман яшь булуы, рухи куәте картаймавының сере әнә шунда түгел микән? — дип тә уйлыйм. Чөнки материя эр-яңадан тумый, юкка да чыкмый, бары тик икенче рәвешкә генә керә.

Туфан бөтен йөрәген, иҗат ялкынын үзе өчен кадерле булган туган теленә һәм туган халкына багышлаган. Татар мәдәниятенең шатлыгы да, кайгысы да аның үз шатлыгы, үз кайгысы кебек. Бүгенге Татарстанның иң зур шагыйре Хәсән Туфанны аның егерменче еллардан бирле сүрелмичә сакланып килгән революцион рухы белән тирән милли тойгының берләштерелүе тудырган.

> ...Иң ахыргы көнемә тикле
> Чәчләр әле тагын агарыр,
> Йөрәк ләкин яшәрә барыр.



*Х. Туфан каләмдәш дуслары янында.*

Менә мин «әдәби портрет» стиленә дә күчеп киттем бугай инде. Югыйсә фәкать шагыйрь дустым турында, миңа Туфан белән бергә эшләве — аның шигырьләрен русчага тәрҗемә итүе рәхәт икәнлеге, аның кеше буларак кайбер «сәер гадәтләре» турында гына язмакчы идем. Хәсән Туфан — шагыйрьлек сыйфатлары кешелек сыйфатларыннан аерылмый торган бер шәхес ул. Аның яшәү җаен белеп бетермәве, талымсыз булуы Туфан белән аралашкан һәркемгә мәгълүм. Ул көннәр-төннәр буе кәгазь битләрен вак кына гарәп хәрефләре белән сырлап язып утыра. Яшел кара белән чуарлап бетергән бу кәгазьләрнең рәтен бары тик ул үзе генә белә. Аның кәгазьләре арасыннан тәрҗемә итү өчен дип бирәр шигырен табып алуы бик мәшәкатьле эш. Бу яктан Туфанның рус шагыйре Хлебников белән күп кенә уртаклыклары бар. Хлебников безнең гасырның башларында Казан университетында укыган. Ул үзенең бүлмәсендәге бөтен мебельне чыгарып, бер карават белән өстәл генә калдырган, ә тәрәзәләренә чыпта корып куйган. Хлебников үзенең кульъязмаларын капчыкка, мендәр тышларына тутыра торган булган һәм юл йөргәндә байтагын югалтып бетергән.

Аның каравы, Маяковский әйтмешли, «аның башы көн-төн поэзия белән генә мәшгуль булган». Бу сүзләр безнең Хәсәнгә дә бик туры килә...

Унбиш еллык дуслык дәверендә кайвакыт безнең аңлашып бетмәгән, фикерләребез кушылып җитмәгән чаклар да булгандыр. Иҗади дуслыкны һәм тәрҗемә эшен яшәвенең максаты итеп караганда, Туфанның дусты була алу һәм аның шигырьләрен тәрҗемә итү җиңел эш түгел. (Сүз уңаеннан әйткәндә, Сибгат Хәким белән дә шулай: минем йөрәгемнең икенче яртысы аңа бирелгән). Әмма зур шагыйрь, зур кеше белән аралашу шатлыгы барысын да йола. Без бергә эшләгәндә бер-беребезне ярты сүздән дә аңлыйбыз. Вакыт-вакыт бәхәсләшеп тә китәбез һәм нәтиҗәдә тәрҗемә оригиналның бөтен яхшы якларын алып, аңа кайтадан тәэсир ясый — оригиналның ачылып җитмәгән мәгънәләрен ача торган бердәнбер юлын табабыз. Мәсәлән, «Мегезендә чылбыр өзеге» дигән шигырендә Туфан туган Казаныннан еракта кышкы бер төнне, сагынудан чылбырын өзеп, шагыйрь янына хәл белергә килгән «Прометей» исемле үгез турында яза. Оригиналда үгезнең абзарын ватып, көрткә-буранга бата-чума килүе турында гына әйтелә. Мин бу хәлнең ничегрәк булуын күз алдына китердем дә:

**«Хлев разломал и отправился прямо**
**На огонек, мимо силосной ямы»,—**

дип тәрҗемә иттем. Туфан:

— Каян беләдең син аны? Ул чыннан силос базы яныннан узып килә бит! — дип гаҗәпләнә калды.

Бу мисалны мин үземнең «зирәклегем»не күрсәтү өчен китермим. Шагыйрь белән тәрҗемәченең озын гомерле дуслыгы текстны гына түгел, авторның бөтен эчке тормышын аңларга, оригинал белән тәрҗемәдәге поэтик детальләрнең эмоциональ тәңгәллегенә китерә димәкче булам.

Мин Тукайның (татар җырларын башкару турында әйтелгән булса да) түбәндәге сүзләрен гел исемдә тотам: «Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек шуның безнең күңелгә охшарына күңел ышанмый. Көебезнең алтынын кояр шикелле»,— ди ул.

Мин һәрвакыт Туфан поэзиясенең алтын-энҗеләрен коймаска-югалтмаска тырышам. Шуңа ирешкәнлегемне күргәч, үземнең дә Хәсән Туфанның мактаулы исеме янында якынрак торуымны тоям. Миңа шуннан зуррак бүләк кирәкми дә.

## Сибгат Хәким

•

Төнге ике. Өстәл, кәгазь, кара.
Яз, дим, үземә, нигә тукталдың?
Яз, язмау бит оят тәрәзәдә
Уты янган чакта Туфанның.

Ярышырга калгач, ярышырга,
Шигырьләрдән алкыш көнелдә...
Төнге ике... Тик ике ут яна
Тын урманда, Аккош күлендә.

Сөйләшәләр безнең тәрәзәләр,
Ни турыда икән ымнары?
Туфанны моң баскан, пәрдә аша
Кар өстенә төшкән моңнары.

Алмагачка кәгазь тартма элгән,
Песнәкләргә анда җимнәре.
Йөрәгендә песнәкләрдән башлап
Бу тормышның кары, җилләре...

Бер-бер артлы сүнә безнең утлар,
Сөенәм, ярый күрдек бу таңны,
Сөенәм, әле Пушкиннарымнан тыш
Тукайлы бу дөнья, Туфанлы.

1970

## Сәйфи Кудаш

# ЯРТЫ ГАСЫРДАН СОҢ...

### ИСТӘЛЕК

**«Булыр баланың буыны иртә ныгый».**

*Картлар сүзе.*

Минем өстәлемдә кечкенә бер фоторәсем тора. Бу рәсемне мин үзләрен бу кеше белән якын таныш, хәтта дус санап йөргән берничә замандашыма күрсәтеп караганым бар. Ләкин аларның берсе дә аны танымадылар. Ә менә шул кеше белән «Галия» мәдрәсәсендә бер кыш бер класста шәрик булып сабак укыган һәм азактан Башкорт дәүләт университетының доценты булган тел галиме Әхтәм Мансуровка күрсәткәч, ул шатлыклы тавыш белән:

— Кара әле, кемне күрәм, менә бит ул безнең Хәсән Туфан! 1916 елда бөтенләй бер үсмер генә булган икән ләбаса. Ә без синең белән ул чакта мыек чыккан һәм солдатка каралган егетләр идек бит инде. Кая, бир әле,— дип рәсемне миннән алган һәм артындагы язуны укый башлаган иде.

Әйтергә генә ансат. Бу рәсемгә төшкән көн белән аның турында шулай сүз алып барган көн арасында ярты гасырдан артык бер аралык сузылып ята. Галимҗан абзый Ибраһимовчарак итеп әйткән чакта, илле ел ул тарих өчен бер адымга да тулар-тулмас кына бер ара. Ә менә кеше гомере өчен, аркылысын-буен бергә кушып чутлаган чакта, ярыйсы гына бер хикәя тәшкил итә. Үзегезгә мәгълүм, аркаулыгын һәм буйлыгын суда чылатып тукылган берничә йөз сәхифәлек бер роман укуга караганда, йөрәк каны белән язылган илле битлек хикәя укуны артыграк күрәсең бит...

Мин бу рәсемне Әхтәм Мансуровка, алдан уйланган план буенча, шул хакта һәм аңа бәйләнешле вакыйгалар турында сүз кузгатыр өчен күрсәтмәдем, әлбәттә. Бәлки, бөтенләй икенче бер нәрсәне эзләп, папкалар актарган вакытта, абайламыйча, бер конвертны идәнгә төшердем. Менә шул вакыт конверттан, хәзер дә паспортларга ябыштырыла торган зурлыктагы бик күп фоторәсемнәр коелды. Без, үзебез эзли торган нәрсәне бөтенләй онытып, шулар белән мавыгып киттек. Чөнки бу конвертта, моннан ярты гасыр элек, үзебез белән «Галия»дә бергә укыган байтак сабакташларыбызның миңа истәлек итеп биргән рәсемнәре саклана иде. Шуларны күрү белән, безнең игътибарыбыз һәм әңгәмәбез үзеннән-үзе шул заманга табан каерылып кайтты да китте. Без, һәрбер шәригебезнең рәсемен кулга алып, аларның үзебездә һәм мәдрәсә тормышында калдырган истәлекләрен хәтерләдек.

Әлбәттә, кешеләр үзләренең характерлары белән бик үзенчәлекле булган кебек, аларның үзендә калдырган хатирәләре дә бик төрлечә була. Берәүләр, хәтердә сакланмый торган шигырьләр кебек, аерылгач та онытылганнар. Икенчеләр, начар шигырьләрдә булган уңышлы строфалар һәм сүзләр кебек, анда-санда гына хәтергә төшеп куялар. Ә өченчеләр инде, Тукайның «Туган тел» исемле шигыре сыман, синең йөрәгеңә кереп утырганнар да тамыр җибәргәннәр. Син аларны үзеңнән аралап та, аерып та ала алмыйсың хәзер...

Мин бүген, менә шушы юлларны язар өчен кулыма каләм алганга чаклы, гадәтемчә, иртә үк тордым да, ашык-пошык киенеп, чыгып киттем. Врачлар миңа хәзер экрен хәрәкәтләнергә һәм йөрергә кушалар. Ә мин, әтисенең сүзен тыңлама-



*С. Хәким, С. Кудаш, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, Ә. Еники.*

ган тискәре малай кебек, үземне өкрен йөрергә гадәтләндерә алмыйм. Бүген дә, шулай, дәрескә соңга калмас өчен, һичбер нәрсәгә игътибар итмичә мәктәпкә чапкан бала сыман, элекке Уфимская урам буенча алга ашыктым.

Ләкин мин бүген, 1970 елның август аенда, хәзерге Чернышевская урамының асфальт түшәлгән тротуары буйлап, Мәҗит Гафури исемендәге 15 нче урта мәктәпкә карый китеп барсам да, уйларым, әллә кайчангы, 1916 елдагы оңгырлы-чоңгырлы Уфимская урамының тузаннарында ауныйлар иде инде.

Элекке атаклы «Галия» мәдрәсәсенең бинасына урнашкан татар мәктәбенә без бу исемне 1940 елда Гафуриga 50 ел тулу уңае белән биргән идек. Мәктәпкә Чернышевская урамы ягыннан керә торган ишекнең бер ягына Мәҗит Гафури, икенче ягына Галимҗан Ибраһимовның бер вакыт шушы бинадагы «Галия» мәдрәсәсендә укулары турында язылган мемориаль такталар урнаштырылган. Ул такталарны мин бу бинага үзем куештым. Аларга язылган сүзләрне, сабак тәкърарлаган бала кебек, әллә ничә кабат укыганым бар. Минем өчен генә түгел, бәлки бик күп замандашларым һәм бөтен татар халкы өчен тарихи һәм кадерле булган бу бинаны мин ел саен берничә тапкыр зиярәт итәмен.

Әгәр дә бер галим татар, башкорт, казакъ, кыргыз, үзбәк, чиркәс, төркмән һәм адыгәй халыкларының мәдәни-әдәби үсешендә әзме-күпме мирас һәм иҗтимагый хәрәкәтендә эз калдырган М. Гафури, Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, Ш. Әхмәдиев, С. Атнагулов, Г. Нигъмәти, З. Ярмәки, С. Габәши, И. Башмаков, Ш. Бабич, Б. Майлин, Х. Кәрим, Х. Туфан, Г. Ходаяров, Ш. Фидаи һәм башка бик күпләрнең биографияләрен язар өчен кулына каләм ала икән, ул инде бу бинаның исемен телгә алмыйча уза алмаячак. Шуңа күрә дә без Уфага ел саен я Казагыстан, я Үзбәкстан, я Кыргызстан һәм Кавказдан, элек шул бинадагы мәдрәсәдә укыган теге яки бу билгеле кешенең юлы буйлап эзтабарлар килеп торуга һичбер гаҗәпләнмибез.

Октябрь революциясенә чаклы һәм революция елларында шушы мәдрәсәдә укып, Совет власте шартларында партия, дәүләт җитәкчесе, фән-гыйлем, әдәбият-сәнгать эшлеклесе булып җитешкән кешеләрнең һәммәсе турында да бу бинага мемориаль такталар куя торган булсак, әлбәттә, бу бина, татар-башкорт хатыннарының көмеш тәңкәләр тезеп бизәгән элекке бишмәтләре кыяфәтенә керер һәм, тышкы ягы белән дә, дөньяда тиңдәше булмаган бер музейга әйләнер иде.

Патша хөкүмәте, бу мәдрәсәне яптырыр өчен, барлык чараларны күреп караган. Петербургтан махсус комиссия җибәреп тә тикшерткән. Эчке эшләр министры Столыпинның әмере белән полиция департаменты мәдрәсә өстеннән, ачык һәм яшерен рәвештә, өзлексез күзәтү алып барган. Әллә ничә тапкыр тентү ясаган. Провокаторлар һәм шымчылар аның тирәсендә йөреп, әллә ничә пар чабата туздырганнар. Болай эш барып чыкмагач, Бабич язган Газазиль һәм Иблисләр, мәдрәсәнең җитәкчеләрен үзара талаштырып һәм котыртып, Уфаның зур байларын аңа акчалата ярдәм бирүдән туктаттыралар. Ләкин мәдрәсә барыбер ябылмый һәм таралмый, чөнки, Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән әйтсәк, мәгърифәтчеләрнең пәһлеваннарча тырышлыклары бушка китмәгән. Байлар ташлап чыккан мәдрәсә 1919 елда колчаклылар яндырып киткәнгә чаклы, бөтен халык ярдәме белән, үз эшен дәвам итте. Уфа губержандарм идарәсенең полиция департаментына биргән мәгълүматына караганда, алар бу мәдрәсәне «Халык» университеты тибындагы уку йорты» дип танырга мәҗбүр булганнар.

Бүген мин хәзер 70 яшен тутырган һәм «Тукай биргән эстафетаны» югалтмыйча катлаулы һәм авыр язмыш юлы узган, яшьлек һәм картлык дустым Хәсән Туфанның моннан 55 ел элек менә шушы бинада калган эзләрен эзләп килдем. Үземне-үзем онытып, мәдрәсә бинасын берничә кабат әйләнеп чыктым да, ишеккә күтәрелә торган баскыч алдында тынлыкка чумып һәм сабырсызлык белән басып калдым. Шул ара да булмады, кемдер, гаҗәп бер нәфислек белән шыңгырдатып, мандолина уйнап җибәрде. Бу тылсымлы тавыштан мин, кинәт сискәнеп киттем дә, ялт итеп, тәрәзәгә күтәрелеп карадым. Әйе, уң яктагы кечкенә бүлмәдә уйныйлар. Таныш тәрәзә һәм таныш бүлмә... Ул бүлмәдә мин бер кыш яшәдем. Шул бүлмәдә мин Бабич белән Туфанның мандолинада уйнауларына сихерләнеп, хәйран калып, әллә ничә тапкыр утырганым бар!.. Әллә аскы каттагы ашханәдә Бабич тиздән булачак җыр, музыка һәм шигырь кичәсенә репетиция үткәрә микән? Заманында бу бинада фәкать Шәйхзадә Бабич, Хәсән Туфан һәм Һади Сәфәргалиевләр генә шулай зәвыклы итеп, оста уйный торганнар иде бит...

Менә мандолинаның сихерле аһәңе иртәнге тынлыкның төпсез тирәнлегенә чәлтерәп түгелеп китте... Мин аны тотарга өлгерә алмый калган бер кеше хәлендә торып калдым. Тик Фәридә Кудашеваның тавышы яңгырагач кына, Уфа радиосының иртәнге концерты башланганлыгын һәм мандолинада мәшһүр Исмәгыйль Илалов уйнаганлыгын белеп, тыела алмыйча көлеп куйдым.

Бу бинаның өченче катында, уң як почмакта, ике яклап кояш карый торган иң зур һәм якты бер бүлмә бар. Без Хәсән белән менә шушы бүлмәдә таныштык һәм бер кыш бергә укыдык. Шуның өстенә мәдрәсәдә була торган барлык ачык һәм яшерен җыелышлар шушы бүлмәдә уздырыла торган иде. Әдәбият кичәләре уздырган чакта без шушы бүлмәне сәхнәләштерә торган идек. Шушы бүлмәдә мин, башлап Галимҗан Ибраһимовның беренче лекциясен тыңлау белән, сабак укый башладым. Шушы бүлмәдә мин беренче тапкыр М. Гафури, С. Рәмиев һәм Ш. Бабичның сөйләвен күрдем.

1915 елда мин бирегә беренче тапкыр килеп кергән чакта мәдрәсәдә укулар күптән башланган, сабакташ шәрикләр үзара танышып һәм үзләшеп беткәннәр иде инде. Шул сәбәпле миңа иң артта буш калган парталарның берсенә урнашырга һәм шәрикләр белән уку барышындагы шартларда танышып бетәргә туры килде. Шуның өчен язын Кустанай юлында танышкан казакъ дусларым Бейимбәт Майлин белән Габдрахман Мостафиннардан башка биредәге барлык кешеләр дә чит һәм ят иделәр әле миңа. Шуңа күрә дә үзләре сүзгә бик һәвәс һәм илгизәк булмасалар да, бу ике казакъ егете мине ялгызлыктан аралаучы һәм шәкертләр гаиләсенә бәйләп җибәрүче дуслар булдылар.

Бу икенче хәзерлек классында минем игътибарымны башлап үзенә җәлеп иткән кешеләр: күпчелеге мыеклы егетләрдән торган шәкертләр арасындагы өч үсмер булды. Алдагы парталарга утырып алган һәм үзләрен кайсыбер мыеклы кешеләргә караганда да иркенрәк тота торган бу «малайлар», тәүге карашта, миндә сәеррәк бер тәэсир калдырган һәм: «Бу көзге чебешләр шпорлы әтәчләр арасына иртәрәк килеп кергәннәр түгелме соң?» — дигән сыманрак бер уй тудырган иде. Ләкин, мәдрәсә тормышына тирәнрәк керә барган һәм классташлар белән



*Х. Туфан, С. Кудаш һәм Әхтәм Мансуров.*

якынрак аралашкан саен, бу сәер тәэсоратлар бик тиз арада үзеннән-үзе юкка чыкты. Инде мин Хәсән Туфан, Хәмзә Шәфиев һәм Әмин Вәлиев дигән шул өч үсмерне генә түгел, бәлки класстагы барлык шәкертләрнең дә исемнәрен белеп беттем.

Бер көнне миңа Хәсән белән кул кысышып көрәшергә туры килде. Нигәдер, яшенә һәм гәүдәсенә караганда зуррак та, көчлерәк тә төсле булып тоелды аның кулы. Бу хакта Әхтәм Мансуровка әйткән идем, ул елмайды да:

— Син аның яшенә карама, ул бит Уралдан килгән шахтер. Бакыр казып ныгыган куллы ул,— диде.

Күп тә үтмәде, мәдрәсәдә әдәбият кичәсе булды. Бер карагагнда, теге үсмер малайлар кыллы оркестрда мандолина уйныйлар. Икенче карасаң, хорда җырлыйлар. Ә Хәмзә белән Әмин сәхнәдә алмашлап шигырь сөйлиләр. Хәсәннең мандолина уйнавы башлап менә шушы кичәдә минем һушыма китте. Мин, оркестр башкарган беренче көйне тыңлау белән үк, уйнаучыларның осталыклары бер төсле түгел икәнлеген аңладым. Кайбер уйнаучылар оркестрның башкару сыйфатының дәрәҗәсен төшерәләр. Ә икенчеләре, киресенчә, кулларына үзләре хуҗа булып, кылга сизгер чиртү һәм бармакларны төгәл басып, зәвык белән, музыкаль грамоталы итеп уйнау сәбәпле, башкарылуның сыйфатын яхшыртып, уенның уңышын тәэмин итәләр. Хәсәннең уйнавы оркестрда менә шундый кылларның берсе иде. Аның бармаклары, арканда аяк очлары белән оста йөрүчеләр кебек, кылларга бик дөрес басалар. Мидиатор тоткан кулы гаҗәп бер сизгерлек һәм саклык белән хәрәкәтләнә. Шул сәбәпле кыллар табигый, аһәң белән, нәфис шыңгырыйлар. Шуңа күрә көйне йотлыгып тыңлыйсың. Шушы музыкаль сизгерлек аркасында Хәсән көйләрне иң югары ноталардан өздереп уйный ала иде. Минемчә, аның шигырьдәге үзенчәлеге дә менә шуннан ук килә булса кирәк. Хәзер мин, күп еллардан соң да, берәрсенең мандолинада зәвык белән уйнавын ишетсәм, колакларымда Хәсән чирткән кылларның моңнары чыңлап киткәндәй була.

Шуның өстенә алларында Хәсән торган бу үсмерләр мәдрәсәнең эчке һәм тышкы сәясәтләрен бик яхшы аңлап, шәкертләрнең актив хәрәкәтендә чарлана башлаган чая егетләр булып чыктылар.

Бу мәдрәсәдә, заманында Галимҗан Ибраһимов, Шәһит Әхмәдиев һәм Булат Салиев кебек хөр фикерле бунтарь шәкертләр башлап җибәреп, аннан соң тради-

циягә әйләнгән атнага бер тапкыр яшерен җыелыш уздыру гадәте бар икән. Ул җыелыш ял көне алдыннан, атнакич белән уздырыла. Җыелышларның көн тәртибенә күп төрле мәсьәләләр куела иде. Һәр мәсьәлә буенча төп докладчылар билгеләнә. Фикер алышу һәм бәхәсләшүгә теләгән һәр кеше катнаша ала. Җыелыш булачак көнне мәдрәсәдә чит кешеләрнең барлыгы-юклыгы тикшерелә. Урамнан һәм йорттан мәдрәсәгә керелә торган ишекләр бикләнә. Урам ишеге төбенә эчке яктан сакчы куела. Җыелыш бара торган бүлмә тәрәзәләренә одеял корыла. Бу саклык чаралары, әлбәттә, көн тәртибенә куелган мәсьәләләрнең нindилегенә карап эшләнә һәм күреләләр. Мәсәлән, беренче бөтен дөнья сугышы дәвам иткән чакта, бу сугышка мөнәсәбәт билгеләү мәсьәләсе буенча булган бер яшерен җыелыш, бүгенге кебек, минем хәтеремдә. Минем әлеге өч үсмер шәригемнең солдатка каралу еллары әле ерак һәм, әгәр дә үзләре ирекле рәвештә китмәсәләр, аларның бу сугышка катнашу ихтималы да юк иде. Ләкин, шулай булуга да карамастан, алар инде, җыелыш барган бүлмәнең алгы парталарының берсендә утыралар иде. Бу җыелыш та, гадәттәгечә, шау-шулы булды. Докладчы да, сөйләүчеләр дә бу сугышны дөньяга хакимлек итүче зур империалистик дәүләтләренең үзара, колониаль максатлардан чыгып, базар өчен кан түгү мәйданы итеп таптылар. Шуңа күрә дә сугышка ярдәм итмәскә, ничек кенә булса да солдатка бармаска дигән фикергә килделәр.

Яшүсмер Хәсәннең үзен зурларча тотуын хәтерләткән икенче бер вакыйганы алырга мөмкин. Икенче яктан бу вакыйга, әгәр дә шәкерт демократиясе үз сүзендә хаклы булса, мәдрәсә җитәкчелеге алар таләбе белән хисаплашмыйча булдыра алмаганлыгын раслый торган бер дәлил дә иде. Безнең класска, болай карап торуга өсте-башы бик заманача, төскә-килбәткә дә ямьсез булмаган бер укытучы дәрескә керә башлады. Төркиядән йөреп кайткан һәм коры кием калыбы гына булган бу кыланчык надан кеше беренче дәрестә үк бездә начар тәэсир калдырды. Аның бүлмәдән чыгып китүе булды, хәтта аз сүзле, сабыр табигатьле Әхмәт Габдуллин кафедрага менеп алды да теге хәлфә төсле кыланырга керешге. Башкалар шаркылдап көлделәр.

Шуңа күрә дә дини дәресләрнең берсен укыта торган бу хәлфәнең безгә икенче тапкыр керүе тагын да күңелсезрәк үтте. Күрәсең, кайбер шәкертләр алдан ук сөйләшеп куйганнардыр инде, теге хәлфә өченче тапкыр дәрескә керер вакыт якынлаша башлагач, кыю һәм туры сүзле Фатих Зәйни алга чыгып басты да:

— Егетләр, бу саламторхан белән нигә вакыт әрәм итәбез? Күренеп тора, аның укыткан дәресе дә, үзе дә безгә ошамый бит. Нишлибез бу бәндә белән? — диде.

— Нишлибез, имеш, тотабыз да класстан куып чыгарабыз,— диде Хәсән моңа каршы.

— Ничек куабыз?

— Просто, кергәч каршылап аякка басмыйбыз. Баш күтәреп карамыйбыз. Сорау бирсә, эндәшмибез. Шуннан соң аңа кергән ишектән кире чыгып китүдән башка эш калмый,— диде Хәсән, үз тәкъдимен эшкә ашыруның юлын ачыклап.

Без шулай эшләдек тә. Хәлфә дәреслек китабын култык астына кыстырып килеп керде. Без аякка басмадык. Ул кукраеп кафедрага менеп утырды да:

— Әфәнделәр, безнең дәрес кайда тукталып калган иде әле? — дип сорады. Җавап бирүче булмады.

— Димәк, укырга теләмисез? — дип сораган иде, без алдан куелган тәртипне бозып, күтәрелеп карамыйча гына, бер тавыштан:

— Юк! — дидек.

Укытучы тасыр-тосыр килеп класстан чыгып киткәч, шаулашып көлеп җибәрдек. Без хәлфә мәдрәсәнең мөдирен алып керер дә тавыш чыгарыр дип көткән һәм җавап та әзерләп куйган идек. Ләкин хәлфә класска кабат аяк басмады. Шуннан соң мәдрәсәдә бөтенләй күзгә дә күренмәде. Кич белән безнең класска:

— Әшегез хөрт егетләр. Сез куып чыгарган теге туң кәбестә күчәне назир булмәсендә «Кодурый»ны кочаклап һәм сезне Зыяга әләкләп утыра. Ләкин курыкмагыз. Андый надан хәлфәләрнең каргышларын алла барыбер кабул итмәячәк. Бик шәп иткәнсез. Башкаларга сабак һәм гыйбрәт булыр. Шәкерт йөрәгенең

чүп-чар тутыра торган кәрзинкә түгел икәнен аңларга күптән вакыт инде. Мәдрәсәнең иң зур стажлы шәкертләре исеменнән сезне тәбрикләргә керdem. Яшәсен тутыккан богаулардан азат булган хөр көнел! — дип шаулап Шәйхзадә Бабич килеп керде.

Без аның бу сүзләрен кул чабып каршы алдык. Ләкин ул, уң кулын күтәреп, безгә шауламаска ишарә ясады да туп-туры Хәсән янына барды һәм аның белән нәрсә турындадыр үзара пышылдашып алдылар. Шуннан соң Бабич, минем кебек, арттагы парталарның берсендә утырган Бейимбәт Майлин белән Габдрахман Мостафин янына килде һәм, казакъчалап саулык сорашкач, мандолина уйнарга өйрәнүнең барышын белеште. Тегеләр эшнең канәгатьләнерлек түгеллеген әйтеп, өйрәтүче юклыктан зарлана башлаганнар иде, Бабич, башын чайкап алды да, кыяфәтен җитдиләтеп:

— Нәрсә сез, җолдастар, чыннан сөйләшәсезме, әллә, безнең халык әйткәндәй: «Биисе килмәгәннең көе килмәгән» дигән сыман кыланып утырасызмы әллә? — дип, тегеләрнең күзләренә тозырaеп карады. Болай да оялчан булган Бейимбәт белән Габдрахман уңайсызланып киттеләр. Бейимбәт акланырга ашыккан кебек:

— Җок, шынын айтамыз. Өйрәтүше таба алмай җедәп отырмыз,— дигән иде, Бабич партадан сикереп торды да:

— Нәгып өйрәтүше табылмасын, кем сезнең үтенечегезне кире какты? Үзегезнең классыгызда гына бер оркестр оештырырлык мандолина уйнаучы бар. Сезнең, казакъчалап әйткән чакта, мандолинаны былбыл кебек соңкылдатушы, моң фәрештәсе булган шәригегез Хәсән үзе генә ни тора! Ул бит сезне бер ай эчендә болай гына түгел, Гата Исхаковның ноталары буенча өйрәнеп, Абай көйләреннән концерт бирерлек музыкантлар ясап чыгарачак,— дип тегеләрнең озын чәчле башларыннан алмаш-тилмәш сыйпап куйды.

Аннан соң ул Хәсән янына килде һәм башта аның алдында ачык хәлендә яткан «Яңа әдәбият» хрестоматиясына күз салды да:

— Нәрсә, Сәгыйт Вәлиевнең атмаган таңын аттырып утырасыңмы? — Яхшы ятла, булмаса Галимҗан хәлфә үзеңнең колагыңны тартыр. Ул бик тәләпчән укытучы һәм тезгенне кыска тота торган кеше. Менә син казакъ даласының шул ике бөркетен мандолинада уйнарга өйрәт. Бу бурычны мин сиңа түгәрәк исеменнән йөкләтәм. Алар гаҗәйбелмахлукат кебек тылсымлы бер мандолина сатып алганнар. Кулга тоту белән шыңгырап китә. Әгәр дә тыңламасаң, теге, үзегез класстан куып чыгарган хәлфә кебек итеп, музыка түгәрәгеннән куам да чыгарам. Булдымы? — дип сорады. Бабичка каршы мөлаем елмаеп утырган Хәсән ягымлы тавыш белән:

— Булды,— дигән иде, ул теге казакъ егетләренә карап:

— Ишеттегезме? Иртәгәдән җиң сызганып, казакъның Кормангазы, Биржан, Абай һәм Җәяү-Муса кебек барлык музыка тәңреләренең рухларына сыенып, эшкә башлагыз! Хәзер йокларга звонок булачак. Барыгызга да тыныч йокы! Төшләрегезгә матур кызлар керсен! — диде дә, кергәндәге кебек үк, шаяра-шаяра чыгып та китте.

Бабичның шулай «кыздырып» һәм боерыклар биреп йөрүенең сәбәпләре шул кичне миңа тагын да ныграк аңлашылды. Чөнки ул мәдрәсәдәге «Милли көй, сәхнә һәм музыка түгәрәге»нең җитәкчесе. 1906 елда Галимҗан Ибраһимов нигезен салган мәдрәсә матбугатының дәвамы буларак, татар телендә чыга торган кульъязма «Парлак» журналының редакторы. Түгәрәкнең хоры, кыллы оркестры бар. Бабич менә шул һәвәскәрләр хәрәкәтенең оештыручысы һәм аңа җан өреп торучысы икән. Ә безнең сабакташыбыз Хәсән шул хәрәкәтнең иң актив бер кешесе һәм Бабичның ярдәмчесе булып чыкты.

Бабичны бүген безнең класска кереп һәм шулай шаулап йөрергә мәҗбүр иткән нәрсә тели дә мин үзем шул хәрәкәтнең актив бер кешесе булып әверелү барышында тагын да ачыграк аңладым. Бу мәдрәсәдә Россиядә яшәүче сигез халыкның аңлы яшьләре укый иде. Шулар арасында татар һәм башкортлардан кала казакъ шәкертләре күпчелек тәшкил иттеләр. Алар мәдрәсәнең үзешчәнлек хәрәкәтенә актив катнаштылар. «Садак» журналын дәвам иттерәләр. Әдәбият

кичәләрендә казакъ акыннарының үләңнәрен һәм әсәрләрен укыйлар. Аерым шәкертләр, дала моңнарын аңкытып, думбыра чиртәләр һәм җырлыйлар. Хәтта Мостафа исемле бер шәкерт татар телендәге пьесаларны сәхнәләштерүгә дә катнаша иде. Ләкин казакъ халкының әдәбиятын, җыр һәм музыка байлыгын бик яхшы белгән Шәйхзадә Бабичны казакъ шәкертләренең шушы активлыгы гына канәгатьләндермәгән. Бер көнне, ятакларның берсендә, казакъ шәкертләре думбыра чиртеп һәм үләң әйтеп күңел ачып утыралар икән. Шул вакыт Бабич килеп кергән дә казакъ түгәрәгенең ул чактагы җитәкчесе Ногман Манаевка:

— Минем башка яңа бер уй килде бит әле. Ни өчен без аерым казакъ хоры һәм оркестры оештырмыйбыз? — дигән. Бабичның бу сораулы мөрәҗәгатеннән канәгатьләнеп елмайган Ногман:

— Бу хакта без Беймбәт Майлин белән дә уйлашканыбыз бар. Ләкин мәдрәсәдә казакъларның өч думбырадан башка музыка кораллары юк. Казакъ шәкертләре мандолина уйный белмиләр. Белә дигәннәре дә бала-чага гына. Хор оештырырга мөмкин. Матур гына тавышлы егетләр бар. Оркестр оештырыр өчен иң элек казакъ шәкертләреннән мандолина алдырырга һәм аларны уйнарга өйрәтергә кирәк, дигәч, Бабич куанып:

— Алай булса сез кесәләре мөмкинлек биргән барлык шәкертләрдән дә мандолина алдырыгыз. Уйнарга өйрәтүне оештыру эшләрен мин үз өстемә алам. Килештекме? — дип Ногманның кулын кыскан.

Менә шуннан соң казакъ шәкертләре хор оештыру эшенә керешкәннәр. Беймбәт белән Габдрахман да, агасы җибәргән 70 сум акчага, Бабич сокланып мактый торган тылсымлы мандолинаны сатып алган икән. Бабич безнең класска кереп чыккан көннән соң, Хәсән Беймбәт белән Габдрахманны, ә Әмин Галиев Җиһангали Теләпбиргәневны мандолина уйнарга өйрәтә башладылар.

Хәзерге киңлек һәм биеклектә торып, бүгенге яктылык һәм ачыклыктан чыгып караган чакта, әлбәттә, югарыда мин сөйләгән хәлләр бик алай искитәрлек нәрсәләр түгел кебегрәк булып та күренергә мөмкин. Мин дә аларны кемне булса да шаккатырыр өчен язмыйм. Бәлки социалистик революция тудырган бәрәкәтле шартларда зур шагыйрь булып җитешкән бер замандашымның, элекке патша Россиясендә, өзлексез полиция күзәтүе астында яшәгән, ярым дини бер мәдрәсәдә узган шәкертлек елларына күз ташлап кына үттем.

Кичә 15 нче мәктәптән кайтканда мин Башкорт дәүләт университеты алдында җыелышып торган яшьләргә сокланып һәм шатланып уздым. Элек дәүләт хисабына үз телендә башлангыч мәктәбе дә булмаган халыкларның балалары — Бабич, Туфан һәм Ивановларның туганнары укырга килгән хәзер бу университетка. Бабич һәм Туфаннар бу бәхеттән мәхрүм иделәр бит. Шуңа күрә дә мин Туфанны Петербург яки Казан университетының студенты итеп яза алмадым. Ләкин моны мин хәзер горурланып та әйтәм.

Хәсән «Галия»гә Урал эшчеләре арасыннан килде һәм үз кул көче белән тапкан акчаны түләп укыды. Биредә ул Россияне халыклар төрмәсенә әйләндергән патша самодержавиесен җимерергә кирәклеген башлап аңлады. Аны ничек аудару турында исә аңа Уралда Данил агайлар төшендерделәр. Биредә ул Тукайның Пушкин белән Лермонтовны, Гафурины, Крыловны, Галимҗанның Горькины яратканлыкларын белде. Биредә Галимҗаннан тел осталыгына, Бабичтан поэтик-музыкаль зәвыкка өйрәнде дә, эшче халкы турында җырлар өчен кире Уралга кайтты.

Хәсән шуннан киткән ел белән беренче шигырен язарга кулына каләм алган еллар арасында илебез, халкыбыз һәм аерым кешеләр башыннан гаять зур, берен-нән-бере катлаулы, бай вакыйгалар һәм сынаулар узды. Ике революцияне һәм гражданнар сугышын эченә алган бу елларны Хәсән Уралда, Хабуллар һәм Минаплар белән бергә, заводта, Данил агай җитәкчелегендә, Совет властен ныгытуда катнашты.

Казандагы дусларым бервакыт миңа Хәсән Туфаннан автобиография яздыра алмауларыннан зарланганнар иде. Ләкин моңа минем артык исем китмәде. Чөнки ул үз остазларыбыз бу мәсьәләдә бик тыйнак булуларын белә. Тукай мәрхүм, мәсәлән, нәширләр бик сорап йөдәткәч кенә, балалык еллары турындагы «Исемдә

калганнар»ны язып бирергә мәҗбүр булган. Гафури, безнең бик үтенеп соравыбыз буенча, автобиографиясен язар өчен өч тапкыр кулына каләм алып карады. Ләкин өч очракта да гомеренең соңгы еллары хакында язып бетермичә китте. Әгәр дә яла ягучылар шул чаклы үзәгенә үтмәгән булсалар, Галимҗан Ибраһимов та үзе үлгәннән соң дөнья күргән мәгълүм автобиографиясен язмаган булыр иде. Фатих Әмирханның шаярып язган тәрҗемәи хәле юмористик бер хикәя булып кына калды. Сергей Есенин исә, автобиографиясен язган чакта, шигырь яза башлаган елга чаклы булган гомер юлын язгач: «Автобиографиямнең калган ягын шигырьләремнән укыгыз», дип нокта куйган.

Безнең Хәсән Туфан да, бәлки, шул караштан чыгып эш итә торгандыр. Минемчә, чын һәм самими лирик шагыйрьнең автобиографиясе, чыннан да, аның лирикасындадыр.

* * *

Хәсән белән без «Галия» мәдрәсәсендә Галимҗан Ибраһимовтан сокланып дәрес укыган, Шәйхзадә Бабичның әдәбият-музыка түгәрәгендә поэзия белән сихерләнгән һәм М. Гафури, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй кебек ул заманның атаклы шагыйрьләренең шигырь укуларын тыңлау һәм кулларын кысу бәхетенә ирешкән елларда аралашып дуслаштык. Бу вакытта мин дә, поэзия мәйданында әле абына-сөртенә, ат уйната башлаган идем. Хәсән үзенең йөрәге, характеры белән шул чакта ук шагыйрь иде. Тик әле ул йөрәгендәге шигъри хисләрне безгә музыка аркылы гына җиткерә иде. Ләкин яз көне күкрәп яуган тәүге яңгырдан соң шытып, көчле омтылыш белән җир өстенә дәррәү калкып чыккан көчле үсентеләр кебек, Хәсән йөрәгендә яралган бу шигъри орлыклар да шул көннәрдә үк инде бәреп чыга, җайлап кына аны рухландыра башлаганнар иде. Мәсәлән, 1917 елның 27 гыйнварында югарыда әйтелгән рәсемен миңа истәлек итеп бирде. Аның рәсеме артына язылган: «...Рухым зинданының бер кыйсьме булган шушы рәсемемне хатирә өчен тәкъдим итәмен», дигән сүзләрен укыгач, сискәнеп киткән идем мин шул чакта. Бу сүзләр миңа ул чакта ук, җирнең кайсыдыр бер читендә яткан зилзилә оеткысы, үзенең барлыгын белдереп, бер тапкыр тетрәтеп, ухылдап куйган шикелле булып тоелган иде. Шул сүзләр язылуга җиде ел үткәч мин «Х. Туфан» имзасы белән басылган үзенчәлекле һәм барган саен көчәя, дулкынландыра барган шигырьләрне укып сихерләнә башладым. Бу шигырьләр үзләренең темалары, формалары һәм сулышлары белән хәтта Такташка караганда да күп яңа иделәр. Бер елдан соң бу яшь шагыйрь, һич көтмәгәндә, икенче бер башлап язучы булган Сәгыйть Агиш артыннан миңа сәлам әйтеп җибәрде. Мәнә шуннан соң гына мин бу яшь шагыйрьнең моннан ун ел элек сабакташ һәм табакташ яшьлек дустым Хәсән икәнлеген белдем. Шул минут Хәсәннең үземә истәлек итеп биргән рәсеме хәтеремә килеп төште. Шул вакыт мин эчемнән: «Димәк, теге йөрәккә сыймаслык бер хәлгә килеп җиткән вулкан, әдәбият мәйданына яңа шигырь туфаны булып бәреп чыккан икән», дип уйладым. Ул шагыйрь — минем моннан унбиш ел элек, Бабич әйткәнчә, моң фәрештәсе булган мандолина остасы, сабакташым, унбиш яшьлек Хәсәнем, ә бүгенге атаклы шагыйрь Хәсән Туфан иде.

Мәхмүт Нигъмәтҗанов

# ЯҢА ТОРМЫШ ҖЫРЧЫСЫ

1905 елгы рус революциясенең шифалы җилләре тәэсирендә татар халкының профессиональ театры барлыкка килә. Музыка сәнгатебез дә үзенең тәүге адымнарын шул ук театр стеналары эчендә атлый. З. Яруллин, Ф. Латыйпов, С. Габәши кебек һәвәскәр музыкантлар даирәсе киңәя, аларның эшчәнлеге торган саен профессиональрәк төс ала бара. Татар музыка сәнгате тарихындагы беренче иҗат үрнәкләре булып шуларның әсәрләре санала. Татар халкының мәшһүр композиторы Салих Сәйдәшев тә үзенең музыкаль биографиясен «Сәйяр» труппасы каршындагы инструменталь ансамбльдә башлый.

Булачак композитор заманы өчен укымышлы гына саналган һәм татар халкының мәдәни әһелләре белән аралашып яшәгән гаиләдә үсә. Малайның шактый иртә ачылган музыкаль сәләте бәрәкәтле туфракка эләгә. Салихның гармун һәм пианино белән мавыгуын, бераз соңрак һәвәскәр ансамбльләрдә катнашып йөрүләрен хуплап каршы алалар. Аны халык музыканты З. Яруллин һәм Казан музыка училищесының танылган педагоглары укыта. Халык музыка коралларында оста уйнарга өйрәнгән яшь малай халыкның музыкаль традицияләрен һәм милли башкару үзенчәлекләрен үзләштерә, Казан шәһәренең бай музыкаль тормышы, музыка училищесы педагогларыннан дәресләр алу гүзәллеккә сизгер һәм тәэсирләнүчән егетнең карашлар даирәсен киңәйтә, ниһаять, артистлар, язучылар, үз чорының башка алдынгы кешеләре белән аралашып яшәү яшь музыкантның иҗтимагый фикер үсешенә дә уңай йогынты ясый. Унҗиде яшьлек Салих Сәйдәшев, Бөек Октябрь революциясе булу белән, яшь Совет иленең давыллы, революцион энтузиазм белән тулы мәдәни тормышына актив төстә катнашып киткән икән, бу очраклы хәл түгел. Аның тормышындагы аерым фактларга игътибар итү дә җитә: мәгариф бүлегенең кушуы буенча Буада хор оештыру, ирекле төстә Кызыл Армиягә язылу, анда капельмейстер булу, татар драма театрының музыка бүлегенә җитәкчелек итү h. б., h. б. Татар совет культурасын төзи башлауның беренче көннәреннән ук күптөрле иҗтимагый эшчәнлек С. Сәйдәшевнең бөтен иҗат биографиясенә тирән эз сала, аңарда сәнгатьнең иҗтимагый әһәмиятен һәм художникның халык алдындагы җаваплылыгын аңлау хисе тәрбияли. Әгәр С. Сәйдәшев иҗатында революцион оптимизм һәм яктылык хисе, олы һәм тирән мәгънәсендәге пафос, гражданлык хисе көчле икән, бу шулай ук очраклы нәрсә түгел.

1922 елда Татарстан халык мәгариф комиссариаты чакыруы буенча Казанга кайтуга Салих Сәйдәшевнең иҗат эшчәнлегендә яңа этап башлана. Ул татар театрында бара торган спектакльләргә көйләр яза, күренекле татар драматурглары белән берлектә, музыкаль драмалар иҗат итә. Аның музыкаль драмаларын халык татар совет музыка

сәнгате үсеше тарихындагы зур вакыйга буларак бәяли һәм искиткеч җылы каршы ала.



Без теге яки бу халыктагы үзенчәлекле милли сәнгать әсәрләренә еш кына механик төстә якын килергә, аларны ниндидер гомуми стандарт үлчәү таяклары белән үлчәргә гадәтләнгәнбез. Мондый алым һәр очракта да урынлымы икән?.. Татар милли музыка сәнгате өчен характерлы булган музыкаль драмаларны алыйк. С. Сәйдәшевнең музыкаль драмаларында, бигрәк тә «Наемщик»та, опера жанры белән уртак әйберләр күп. Биредә музыкаль драматургиянең классик формалары һәм элементлары халык музыкасы традицияләре белән органик берләшә, операдагы кебек үк, ария, дуэт, балет номерлары зур урын тота, оркестрга киң урын бирелгән... Әмма музыкаль драмаларны операга бару юлындагы гадәти бер адым, түбәнге баскыч дип кенә бәяләргә ярамый, аларга без барыннан да бигрәк милли музыкаль театр тудыру мәсьәләсен үзенчәлекле төстә хәл итүнең бер чагылышы дип карарга тиешбез. Музыкаль драма татар совет культурасының үсеш тарихындагы табигый күренеш буларак туа, милли театрның һәм музыканың иң яхшы традицияләрен ул үзенә сеңдерә, шулай ук башка халыкларның казанышларын иҗади үзләштерү җирлегендә барлыкка килә. Шуңа профессиональ милли музыканың төп стиль сызыклары Сәйдәшев иҗатында аеруча тулы ачыклана. Аның профессиональ татар музыкасына нигез салучы буларак төп роле дә шуның белән аңлатыла.

С. Сәйдәшевнең 20 еллар иҗаты яшь композиторлар эшчәнлегенә һәм татар музыка сәнгатендәге күп жанрларның формалашуына хәлиткеч йогынты ясый. Бу йогынты сәхнә әсәрләренең, аеруча опера һәм балет жанрының үсешендә нык сизелә. Композиторның спектакльләргә язган музыкасында саф инструменталь өзекләр дә шактый гына. Алар милли симфоник музыка сәнгатенең алга таба үсеше өчен җирлек булып исәпләнәләр.

Үз иҗат гомеренең соңгы көннәренә кадәр Салих Сәйдәшев театр өчен музыка яза. Дөрес, аның спектакльләргә язган музыкасында да төрле темаларга караган, төрле эчтәлекле җырлар шактый гына. Шулай да композиторның махсус җырлары аерым игътибарга лаек. Алар С. Сәйдәшев мирасының зур бер өлешен тәшкил итәләр һәм бүген дә тулы канлы тормыш белән яшиләр. Иҗтимагый тормышның мөһим мәсьәләләрен чагылдырган җырлар композиторның 40—50 еллар иҗатында төп урынны били. Сугыштан соңгы елларда да Сәйдәшев балаларга һәм яшьләргә багышланган менә дигән җырлар иҗат итә.

Композиторның халык язмышы һәм тормыш белән тыгыз бәйләнеше, аның гражданлык һәм патриотизм хисләре, аеруча калку булып, нәкъ менә җырларында чагыла. Моңа ышану өчен, аның Кызыл Армия бәйрәме, Татарстан бәйрәме һәм Октябрь революциясе кебек гомум халык тантаналарына багышлап язылган җыр һәм маршларына мөрәҗәгать итү дә җитә. Хикмәт әлеге җыр-маршларның теге яки бу бәйрәмгә карата махсус язылуларында гына түгел. Иң мөһиме һәм хәлиткече шунда, алар чын йөрәктән, ихлас күңелдән язылганнар. Аларның күбесе («Совет Армиясе маршы», «Совет яшьләре җыры», «Дуслык турында җыр», «Без — төзүчеләр», «Совет Татарстаны» һәм башкалар) тикмәгә генә бүген дә шулай заманча һәм актуаль яңгы-

рамый. Шулай итеп, Салих Сәйдәшев музыка сәнгатебез тарихына көн кадагына суга торган массовый характердагы патриотик җырлар иҗат итүче булып та кереп калды.

Композиторның яшьлек дәрте һәм шатлык хисләре белән тулы чын мәгънәсендәге милли җырлары социализм төзүче совет кешеләренең тормышчан рухын чагылдыра. Мәшһүр «Совет Армиясе маршы» — патриотик лириканың иң гүзәл сәхифәләреннән санала.

Әмма югары гражданлык хисе, урыны-урыны белән хәтта плакатчарак яңгыраган әсәрләр композиторга тирән һәм эчкерсез хисле лирик булып калырга комачауламый. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, гражданлык хисе һәм лиризм һич тә бер-берсенә каршы килми, алар композиторның киң иҗат диапазонлы һәм рухи йөзенең эмоциональ киеренке булуы хакында сөйлиләр. Башкача булуы мөмкин дә түгел. Чөнки сәнгать төрләре арасыннан үтә лиригы саналган музыка үз иҗатчысыннан искиткеч көчле юмартлыгы, кешеләргә тирән мәхәббәт белән карауны сорый. Шулай булганда гына ул киң халык массаларының идея-эмоциональ аңын һәм рухын били ала. Әмма С. Сәйдәшев лирикасына җылаклык, күз яше сыгу ят. Ул я максатка омтылышлы һәм якты («Сандугач»), я ихлас характерда һәм тирән хисле («Җырларым», «Майсәрә җыры»), я булмаса эпик һәм кырыс аһәңле («Кара урман») әсәрләр иҗат итә, ә еш кына аның җырлары эмоциональ кичерешнең күптөрле халәтен үсештә чагылдыралар.

Салих Сәйдәшев нинди генә жанр һәм формаларга мөрәҗәгать итмәсен, чын мәгънәсендәге җылы лирика аның бөтен иҗаты аша сузыла. Бу нәрсә музыка сәнгатенең нәкъ менә лирик стихиядә көчле булуы белән генә аңлатылмый, ә композитор талантының беренче карашка никадәр генә төрле-төрле булып күренмәсен, асылда бөрыбер лирик булып калуыннан килә.

Салих Сәйдәшев музыкасының шундый киң танылуының һәм халык арасында популярлыгының сере нәрсәдә соң? Аның иҗатының тормышчанлыгы каян килә? Моның сәбәбе композиторның тормыштагы үз иҗтимагый урынын дөрес аңлап, актуаль иҗади мәсьәләләргә игътибар итүендә генә түгел. Бу иҗат өчен чыганак кына әле. Ул сорауларга кыскача гына түбәндәгечә җавап бирергә мөмкин. Сәйдәшев музыкасының көче: аның халыкчанлыгында, партиялелегендә һәм үзенчәлекле талантында.

Иң элек Сәйдәшев музыкасының халыкчан нигездә булуына, халык традицияләре белән тирәнтен бәйле булуына басым ясап әйтергә кирәк. Халыкчан булу өчен Сәйдәшев халыктагы нинди дер стиль алымнарын кабатламый, бала чактан ук халыкның милли моңнары аның канына сеңгән. Шуңа күрә дә ул, экзотизмга бирелмичә яки халыкка хас үзенчәлекләрне бозмыйча, традицияләрне бик иркен һәм иҗади файдалана белә. Шуңа күрә ул, фольклорга якын образларны тудырганда да, халыктагы мелодияләрне кабатламый, ә үзенең оригиналь әсәрләрен иҗат итә, шул ук вакытта алар чын-чынлап халыкчан булып яңгырыйлар. Сәйдәшев фольклорга өстән генә мөрәҗәгать итми, ул аның рухына, халыкның музыкаль фикерләвенә турылыклы. Шуның белән бәйле рәвештә, композиторның мелизматикага — татар халкының сузынкы җырларындагы әһәмиятле алымга гаять кыю мөнәсәбәтен әйтеп үтәргә кирәк. Фольклордагы мелизмнарының заманы өчен әһәмиятен һәм шул ук вакытта чикләнмәгән булуын дөрес аңлаган хәлдә, ул аларны кабатлаудан ерак тора. Чөнки алар аның музыкасына хас якты, революцион рухка каршы килерләр иде. Ул мелизмнарны интим лирик музыкаль образлар тудырганда, әсәренең тәгәл жанрына, эмоциональ рухына туры китереп, аларны үзенең мелодик стиленә буйсындыра, файдалана. Композитор, халык алымнарын файдаланганда, аның традицион формасын тамырдан үзгәртә. Аның иҗади тәҗрибәсе хәзерге буын композиторлары өчен дә бик гыйбрәтле.

Халык җырларының төрле жанрларындагы стиль үзенчәлекләрен композиторның ничек файдалануына күз төшерик. Менә берничә факт.

Композитор халык җырларына хас сузынкы, моңлы, хәрәкәтчән өлешләрне аралаштыру алымын гаять төрлечә куллана. (Мәсәлән, «Кара урман», «Печәнчеләр җыры», «Гөлйөзем ариясе» һ. б.лар). Шулай ук ул халык музыкасындагы аеруча традицион үзенчәлекләргә бик сизгер мөрәҗәгать итә. Борынгы җырлар өчен типик булган көйләр — Әхмәт Фәйзи сүзләренә язылган «Уянсыннар кырлар» җырында,

«Батырҗан ариясендә, «Наемщик» музыкаль драмасындагы балетның беренче өлешендә, Әхмәт Ерикәй сүзләренә язылган «Кыюсыз егет» җырында һ. б. әсәрләрдә — аеруча үткен һәм оста файдаланылган. Әлбәттә, моңа композитор теоретик анализ юлы белән түгел, ә иҗади интуиция һәм халык музыкасы рухын дөрес итеп тою юлы белән ирешә. Сәйдәшев, көйләрне шул рәвештәге трактовкасы белән, пентатониканың теоретик проблемаларын чишәргә юл күрсәтә, көйләр барлыкка килүнең борынгы формаларының тормышчанлыгын исбат итә.

Сәйдәшев әсәрләрендәге пластик һәм һәрвакыт төгәл мелодиканың халык моңнары һәм алардагы ритмика белән бәйләнешенә күз салу игътибарга лаек. Татар теле сөйләменең үзенчәлекләренә, татар шигыренең ритмикасына гаять сизгер караш композиторның барлык вокаль әсәрләре өчен уртак. Менә шуңа күрә дә аның җырлары халыкның үзенеке булып әверелде, шуңа күрә дә ул музыка язган җырның һәр сүзе тыңлаучының йөрәгенә керeп урнаша. Композитор музыка ритмикасын җыр текстындагы сүзләргә буйсындыра.

Әмма С. Сәйдәшев иҗатындагы новаторлыкның бүтән композиторларга охшарга тырышу яки новаторлык хакына новатор булып кыланырга омтылу белән һич тә уртаклыгы юк.

Сәйдәшевнең казанышы шунда: ул үзенең музыкасында үз заманына аваздаш рухи омтылышларны чагылдыра алды.

Ә аның музыкаль стилендәге новаторлык нәрсәдә соң? Иң элек шунда: ул милли музыкаль традицияләр белән тыгыз бәйле, егерменче — утызынчы еллардагы совет җырлары белән аваздаш, революцион җырларга хас рух белән сугарылган татар массовой җырларын иҗат итте. Аларның стиль сызыкларына игътибар итик. Совет Армиясе, яшьләр, дуслык турындагы җырларында аның чынбарлыкка аваздаш булган энергияле марш интонацияләре яңгырый. Алар актив ритмикалы, динамик һәм ачык гармонияле. Сәйдәшевнең мондый җырларында мажор һәм минор закончалыгы хакимлек итә, мелодик үсешне үзенә буйсындыра. Әлбәттә, аларның эмоциональ омтылышы, мелодик энергиясе пентатоника рамкалары белән генә чикләнеп калмый, композитор хроматизмнарны, мелодик минорны да кыю куллана. (Мәсәлән, «Совет Армиясе турында җыр».) Шуңарга карамастан, Сәйдәшев музыкасы чын-чынлап милли музыка булып кала бирә. Нинди генә жанрга мөрәҗәгать итмәсен, Сәйдәшев — беренче юл салучы, яңа профессиональ культура тудыручы. Беренче татар вальсын, беренче арияләрне һәм дөнья музыка классикасыннан килә торган башка формаларны ул иҗат итте. Шунысы мөһим: композиторның беренче тәҗрибәләре тарихи факт булып кына калмады, алар хәзерге көндә дә яшиләр, бүгенге тыңлаучыларны да тирәнтен дулкынландыралар.

Аның халыкның милли моңы белән сугарылган музыкасы башка милләт тыңлаучыларының да күңеленә якын. Татар музыкасы тарихында Салих Сәйдәшевнең урынын билгеләгәндә, бөек Тукай мирасы искә төшә. Хикмәт күпмедер дәрәҗәдә аларның тормыш юллары охшаш булуда гына да түгел. Хикмәт алар иҗатындагы хис һәм идеяләр уртаклыгында. Аларның һәр кайсы гомер буе халык иҗатына таянып иҗат итте, аларның һәр кайсы гомер буе халык идеалларына турылыклы булып калды.

Татар совет культурасы тарихында Салих Сәйдәшев иҗатының әһәмияте әйтеп бетергесез. Аның музыкасы — халык тормышының сәнгатьчә сурәтләнгән елъязмасы, яңа тормыш төзүче халык психологиясенең иҗтимагый чагылышы. Ул музыка хәзер дә коммунизм төзүче халкыбызга хезмәт итә, яшьләребездә югары этик идеаллар, эстетик зәвык тәрбияли, массаларны яңа җиңүләргә рухландыра.

## Җәүдәт Фәйзи

# ОНЫТЫЛМАС ИПТӘШ

Мөгаен, талантлар элек тә туып торгандыр. Әмма алар, канат җилпергә дә өлгермәгән кош балалары кебек, патша Россиясендәге сәмруг кошның комсыз тырнакларына эләгеп, югала барганнар. Безнең профессиональ музыка сәнгатебезгә нигез салырга тиешле композитор әлеге сәмруг кош картаеп хәлсезләнгән бер чорда дөньяга килә — татар халкының һәм Салих Сәйдәшевнең үзенең бәхете әнә шунда. Бөек Октябрь аны һәлакәттән саклап кала, аңа һәм аның кебек талантларга очарлык көч бирә, гүзәллек дөньясына юл ача.

Салихның балалык чоры һәм яшьлек еллары сихри музыка моңнарын тыңлап үзә. Чәчәкләрдән бал җыйган бал корты кебек, ул халык музыкасының бөтен гүзәллеген һәм нәфислеген үзенә сеңдереп үсә. Беренче укытучысы З. Яруллин, О. Радзевич һәм А. Литвинов кебек тәҗрибәле тәрбиячеләр аңа дөрес юнәлеш бирәләр, музыка сәнгатенең олы юлына чыгарга булышалар.

Музыка аның тормышының төп максатына әйләнә. Хәтта, гражданнар сугышы башланып, өстенә кызылармеец шинеле киеп алгач та ул музыкадан аерылмый. Күпмедер вакыт Оренбург Шәрык музыка мәктәбендә эшләп алу да ярап куя: биредә ул музыкаль әсәрләрне оркестрга салырга өйрәнә, дирижерлык һөнәренең нечкәлекләрен үзләштерә. Тик болар әле чын иҗат эшенә хәзерлек чоры гына була. Чын иҗат үзе исә 1922 елда Казанга кайткач башлана.

Казанда С. Сәйдәшевне Татар академия театрына чакыралар һәм сәхнәдә бара торган спектакльләрне музыка белән тәэмин итү эшен тапшыралар. Бирегә килүгә, ул артык зур булмаган оркестр оештырып җибәрә, үзе үк аңа дирижерлык итә, оркестр белән башкару өчен популяр халык җырларын эшкәртә. Билгеле, ризасызлык белдерүчеләр, безгә гармун белән скрипка җиткән диючеләр дә табыла. Әмма күпчелек С. Сәйдәшевнең бу яңа адымын зур мәдәни вакыйга буларак каршылый.

Акрынлап спектакльләргә ул үзе иҗат иткән көйләрне кертә башлый. Нәфис мелодияле, халыкча җылы язылган әлеге әсәрләр шунда ук күтәреп алына һәм халык арасына тарала. Музыка татар театрындагы спектакльләрнең төп компонентына әйләнә. Драматурглар, аеруча К. Тинчурин һәм Т. Гыйззәт, үзләренең күпчелек әсәрләрен Салих Сәйдәшев музыкасына исәпләп язалар. Мәшһүр композиторның «Галиябану» һәм «Сүнгән йолдызлар» спектакльләренә язган увертюралары татар музыка сәнгатендәге беренче симфоник әсәрләр булып исәпләнә. «Зәңгәр шәл» һәм «Наемщик» татар совет театр сәнгатендәге яңа жанрның — музыкаль драмалар жанрының юлбашы булып санала. Әлеге әсәрләре һәм данлы «Совет Армиясе маршы» белән Салих Сәйдәшев үз иҗат эшчәнлегенең иң югары баскычына күтәрелә.

Әсәрләрен ул бары тик аңа хас «яңа телдә» иҗат итә. Традицион пентатоник ладны диатоникага кадәр киңәйтеп, С. Сәйдәшев яңача яңгырашлы көйләр язуга ирешә. Аның тарафыннан көйгә кертелгән кыска секундлы интонацияләр әле бүген дә заманча яңгырый. Бу — композиторның халык музыкасына новаторларча якын килүе нәтиҗәсе иде. Үз иҗатында ул халык җырларының алдынгы традицияләренә таяна һәм, культурабыз тарихында беренчеләрдән булып, татар музыкасының да интернациональ рухта үсәргә тиешлеген исбатлый.

Үз иҗатында Салих Сәйдәшев бары халык җырлары һәм аларның традицион форма кысалары белән генә чикләнеп калмый. Ул рус һәм дөнья классиклары иҗатын өйрәнә. Бизе һәм Верди аның иң яраткан композиторлары була. Аларның опера жанры өлкәсендәге ачышлары аны үзенә аеруча нык җәлеп итә. Бу нәрсә Сәйдәшевнең композитор буларак фикерләү үзенчәлегенә дә тәэсирсез калмый, билгеле. Ул иҗат иткән музыкаль әсәрләрдә увертюра, ария, хор һәм биюләр кебек опера элементларының күп очравы нәкъ әнә шул хакта сөйли.

Салих Сәйдәшев оркестр өчен иҗат итүче композитор иде. Зур күләмле симфоник әсәрләр тудырып калдырырга өлгермәсә дә, күпчелек әйберләрен ул оркестр белән башкару өчен язды. Әгәр беренче тәҗрибәләрен һәм балаларга багышланган

ирларын исәпләм[illegible] я оркестрда башкару, я булмаса
кестрга ияреп җырлау өчен язылган. Күпчелек әсәрләренең полифоник фактурада
луы, ихтимал, шуның белән аңлатыладыр. Салих Сәйдәшев бик сирәк очракларда
на аккордлы-гармоник тасвирга мөрәҗәгать итә. Аның әсәрләрен өстән-өстән генә
зәтеп чыгу да шуны раслый.

Композиторның иҗат процессы ифрат үзенчәлекле иде. Үзенең күпчелек җырла-
ын ул Р. Кушловская, Г. Кайбицкая, С. Садыйкова, С. Айдаров, Ф. Маннапов кебек
шкаручыларның иҗади мөмкинлекләрен күздә тотып язды. Җырларын тәмам
җкәртеп җиткергәнче, композитор һәрвакыт алар белән киңәшә. Җырчыларның
иңәш һәм тәкъдимнәре булса, рәхәтләнеп кабул итә. Башкаручылар ул язган җыр яки
онияларне өйрәнгән арада үзе аларны оркестрга сала тора. Бу эшне дә ул партиту-
здан түгел, ә оркестр инструментлары өчен аерым партияләр язудан башлый.
ълеге бик үк гадәти булмаган эшне ул беренинди кочәнүсез һәм ифрат җиңел
башкара. Чөнки табигать аңа искиткеч камил музыкаль сәләт биргән. Кагыйдә була-
рак, җырның ярдәмче партиясе дә оркестрда башкару өчен языла. Бу янгыраш буен-
ча гына җырлаучы артистларга булышу йөзеннән шулай эшләнә. Салих Сәйдәшев
җатындагы мондый эш алымы, берьяктан, вакыт тарлыгы белән аңлатылса, икенче
яктан, аңа партитура язып утыруның артык хаҗәте дә булмый, искиткеч яхшы музы-
каль хәтерле булганга, ул оркестр белән күңелдән дирижерлык итә. Тик аеруча катл-
аулы һәм зур күләмле әсәрләрне башкарганда гына партитурадан файдалана.

Кагыйдә буенча, аның әсәрләренең партитурасы аерым инструментлар өчен ком-
позиторның үз кулы белән язылган партияләрдән оеша. Бу эшне исә аның оркестрын-
а эшләүче музыкантлар: скрипкачы Йосыпов һәм Яушевлар, кайчандыр «Шаляпинның
зенә уйнаган» атаклы волторнист Глазырин башкара. С. Сәйдәшев архивында автор-
ың үз кулы белән язылган партитураларның бөтенләй очрамавы шуның белән
ңлатылса кирәк.

Әле үзе исән вакытта ук С. Сәйдәшев халыкның тирән ихтирамын һәм мәхәббәтен
азанып өлгерде. Ул искиткеч популяр композитор иде. Аның исеме, республика чик-
ләрен үтеп чыгып, ерakларга таралды. Тукай шигърияте кебек үк, Салих Сәйдәшевнең
шчәнлеге дә Үзбәкстан һәм Казагыстан, шулай ук киң илебезнең башка төбәкләрен-
дә яшәүче яшьләр иҗатына көчле йогынты ясады. Аның исеме Украина совет музы-
касына нигез салучы Лысенко, әзербәйҗанлы Гаджибеков, рус совет музыкасының
мәшһүр вәкиле Дунаевскийлар белән бергә йөртелергә лаеклы.

Салих Сәйдәшев мирасына тарихи яктан якын килеп бәя биргәндә шуны исtә
тотарга кирәк: профессиональ татар музыкасына нигез салучы бу композитор үз
иҗатын театр дирижеры һәм андагы спектакльләргә музыка язучы буларак башлап
җибәрә. Беренче дирижер буларак, ул театрдагы музыкантларны үз тирәсенә туплый.
Үзе искитмәле сәләтле булганга, ул башкаручыларның аз гына ялгышын да шунда ук
тотып ала. Аның шул таләпчәнлеген яхшы белгәнгә, артистлар да, музыкантлар да үтә
игътибарлы булырга тырышалар. Оркестрдагы музыкантлар, авторның үзе кебек үк,
партияләрен еш кына яттан башкаралар. Бәлки нәкъ менә шуның өчендер дә заманы
өчен шактый катлаулы саналган «Эшче» һәм «Сания» опералары белән дирижерлык
итүне авторлары Салих Сәйдәшевка ышанып тапшыралар. Ул хәтта Мендельсонның
скрипка һәм оркестр өчен язылган атаклы концертыннан да куркып калмый...

Әмма Салих Сәйдәшевнең дирижерлык эшчәнлеге никадәр генә мактауга лаек
булмасын, аның композитор буларак эшчәнлеге чагыштыргысыз өстен тора. Компо-
зитор үз әсәрләрен чорның реаль мөмкинлекләрен нык истә тотып яза. Аңа үз әсәр-
ләрен башкаручыларның музыкаль-техник һәм вокаль мөмкинлекләре белән сана-
шырга туры килә. Ул заманда иҗади планнарын тормышка ашырырга хәзерге кебек
мөмкинлекләр дә булмый. Шуңа да карамастан, ул бүгенге көндә дә заманча яңгы-
рый торган дистәләрчә әсәрләр язып калдыра алган.

Салих Сәйдәшев — чын мәгънәсендә халыкчан композитор. Аның язганы аңа чын-
барлыктан, бүгенге заманнан аерылгысыз. Салих Сәйдәшев татар музыка сәнгатендә
һәрвакыт искиткеч фигура булып калачак. Профессиональ татар музыка сәнгатенә
нигез салучы буларак, ул бөтен совет сәнгатенең дә горурлыгы. Аның иҗат мирасы
милли мәдәниятебезнең алтын фондын тәшкил итә. Аны саклау, өйрәнү һәм пропаган-
далау — композиторларыбызның һәм музыка белгечләребезнең җаваплы бурычы.

Земфира Сәйдәшева

# ҖЫРЛАР ОСТАСЫ

Җырларым, сез шытып йөрәгемдә,
Ил кырында чәчәк атыгыз!
Күпме булса сездә көч һәм ялкын,
Шулкадәрле җирдә хакыгыз!

Салих Сәйдәшевнең үләр алдыннан иҗат итеп калдырган соңгы җыры патриот шагыйребезнең шушы сүзләренә язылган. Һәм бу бер дә гаҗәп хәл түгел. Шагыйрь Муса Җәлил кебек үк, Салих Сәйдәшев тә иҗат гомеренең зур өлешен татар халкының җыр жанрын үстерүгә багышлый. Совет чынбарлыгының рухына туры килгән, татар халкының яңа уй-хисләрен чагылдырган, яшьләребезнең тормышында булып узган кискен үзгәреш, тамырдан борылыш моментларын гәүдәләндергән яңа эчтәлекле җырларны башлап ул иҗат итә.

Билгеле булганча, С. Сәйдәшев татар театрына эшкә килүгә андагы спектакльләрдә музыканың роле нык арта. Башта композитор халык көйләреннән файдалана. 1926 елда «Зәңгәр шәл»не куйганда гына беренче мәртәбә ул үзе язган көйләр яңгырый. Һәм алар тиз арада популярлык казаналар, спектакльдән тыш та башкарыла башлыйлар.

Салих Сәйдәшев язган беренче җырларның спектакльләргә бәйле булуы аларның тематикасына да билгеле бер эз сала. Алар татар театры репертуарындагы нигездә лирик эчтәлекле пьесаларга язылган җырлар булалар. Шушы нәрсә әле 20 елларның урталарында ук татар совет җыр сәнгатендә яңа жанрның — гражданлык лирикасының тууына этәргеч ясый[1]. Сүз К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» пьесасындагы кызлар хоры һәм Ф. Бурнашның «Хөсәен Морза» әсәреннән Бибисара җырлары хакында бара. Аларның халык җырларына якын гади һәм ягымлы көйләре тыңлаучылар күңеленә бик тә хуш килә, шуңа күрә әлеге әсәрләрне республиканың барлык почмакларында күтәреп алалар.

Әгәр хәзер генә телгә алынган җырларда, нечкәлек, сагышлырак һәм моңсурак аһәңнәр өстенлек итсә, шуннан соң иҗат ителгән әсәрләрдә лирик кичерешләр башкачарак төсмер ала. «Сандугач» исемле көйдә, шулай ук К. Тинчуринның «Ил» драмасына язылган «Ал чәчәкләр» җырында, мәсәлән, сагыш-моңсулыкның инде эзе дә юк, аларда якты һәм шатлыклы мәхәббәт хисләре хакимлек итә. Бу көйләрнең текстлары халык җырлары стилендә эшләнгән: һәртөрле чагыштырулар һәм параллелизмнар, традицион эпитетлар аларда тулып ята. Аларның мелодиясендә кыска шәһәр көйләренә хас традицияләрне файдаланып, С. Сәйдәшев тә шул ук юлдан бара. Шуның белән бергә композитор «Сандугач» җырының көенә кызыклы үзгәреш тә кертә. Әгәр аның кушымтасы сүз төзелеше ягыннан шактый ук традицион характерда булса, җырның көендә халык музыкасы өчен ятрак тоелган ачык яңгырашлы колоратуралар файдаланыла, алар әсәрнең гомуми яңгырашына дәрт һәм шатлык авазлары өстиләр. С. Сәйдәшев ачкан бу яңалыкны соңыннан җыр жанры өлкәсендә эшләүче башка композиторлар (М. Мозаффаров, Л. Хәмиди һ. б.) күтәреп ала.

Салих Сәйдәшев иҗат иткән җырларда хезмәт темасы да шактый киң чагылыш таба. К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Ил» пьесаларыннан Булат һәм чалгычылар җыры, Т. Гыйззәтнең «Наемщигы»ннан Батырҗан җыры әнә шундыйлар. Әлеге җырлар үңае белән композитор иҗатына хас тагын бер үзенчәлеккә тукталып узасы килә. Һәркемгә мәгълүм булганча, «Зәңгәр шәл» спектаклендә татар халкының революциягә хәтле

[1] Билгеле булганча, рус совет җыр сәнгатендә мондый эчтәлекле җырлар бары 30 елларның урталарыннан гына киң иҗат ителә башлый.

тормышы сурәтләнә. Әсәрнең гомуми эчтәлегенә бәйле рәвештә, Булат та шахтерларның авыр һәм газаплы хезмәте хакында җырлый. Ә композитор, тота да, әлеге сүзләргә марш характерындагы көй яза. Сәер кебек. Ләкин моңа әллә ни гаҗәпләнмәскә кирәк: чөнки С. Сәйдәшев спектакльләрдәге вакыйгаларга сукырларча иярәп бармый. Ул ерак киләчәккә карый, аны яңа тормыш вакыйгалары күбрәк дулкынландыра. Бәлки, композиторның 20 елларда ук иҗат иткән әсәрләренең озак гомерле булуларының сере нәкъ менә шундадыр. Калган ике көйдә хезмәт процессы турыдан-туры үзе сурәтләнә: җырлар йорт салу күренешендә («Наемщик») һәм печән чапканда («Ил») башкарылалар. Текст һәм музыка язучы авторлар каршына яңа, авыр бер мәсьәлә килеп баса: татар музыка сәнгате өчен бик үк гадәти булмаган бу теманы ничек һәм нинди чаралар ярдәмендә тормышка ашырырга?. Чөнки Казан татарларының революциягә кадәрге музыкаль фольклорында турыдан-туры хезмәт процессын тасвирлаган җырлар бөтенләй диярлек булмый. Безнең авторлар әлеге теманы чишүнең яңача алымнарын табалар, хезмәт картиналарын коры сурәтләү белән генә чикләнмичә, аның бөеклеген, хезмәт кешеләренең күтәренке хисләрен чагылдырырга омтылалар һәм шуңа ирешәләр дә. Заманы өчен бу әлеге теманы новаторларча хәл итүнең матур үрнәге була.

«Зәңгәр шәл» пьесасыннан Булатның икенче җыры борынгы озын көйләр стилендә язылган. Халык арасында ул күбрәк «Кара урман» исеме белән йөри.

Татар халкының авыз иҗаты әсәрләрендә качкыннар хакында шактый күп сөйләнә. Җәбер-золымга түзә алмый, урманнарда качып яшәргә мәҗбүр булган әлеге кешеләрнең кыю гамәлләре, фольклорчы И. Надиров сүзләре белән әйткәндә, «кайсы яктандыр крестьян бунтларына аваздаш. Аларда социаль каршылык ачык төсмерләнә»[1]. Әлеге социаль протест мотивы Салих Сәйдәшев иҗат иткән көйдә дә сизелә. Шуның белән бергә, композитор мәсьәләгә новаторларча якын килә. Барлык тасвир чараларын ул шигъри тексттагы образларны ачуга буйсындыра. Билгеле булганча, җырның тексты шактый хәрәкәтчән: салмак кына башланган җыр кушымтада әкренләп героик яңгыраш белән алмашына. Музыка әзлекле төстә текст артыннан бара, нәтиҗәдә тексттагы һәр фраза үзенә хас интонацион характеристика ала. Шул рәвешчә, «Кара урман»ның шомлы, дәһшәтле сүзләре аның көенә дә билгеле бер эз сала, аңа шомлы тәэсир бирә. Сүзләрнең мәгънәсе куәтләнгән саен, көй үсә, көчәя бара. Ниһаять, «Ирек даулый качкын егетләргә» дигән соңгы фраза бөтен көчкә яңгырый. Салмак башланган эпик җыр кушымтада сугышчан, хәрәкәтчән төс ала, һәм ул качкыннарның көрәшкә чакыручан көчле рухын чагылдыра:

> **Кара урман төсле шаулый-шаулый,**
> **Дошманнарның кенен тен итәргә...**

Баштагы алмашынучан үлчәм биредә тигез, кискен хәрәкәтләр белән алмашына. Шулай марш характерындагы пунктирлы ритмика халык җыры рухында язылган әсәргә героик характер бирә.

Егерменче елларда яңа тормыш төзүче яшьләргә багышланган җырларга ихтыяҗ көчәя. Һәм бу өлкәдә дә башлап Салих Сәйдәшев активлык күрсәтә. 1929 елда Г. Кутуй сүзләренә ул язган «Студентлар маршы» татар совет музыка сәнгатендә әлеге темага караган әсәрләрнең беренче үрнәге булып санала. Г. Минскийның «Шлем» әсәрендәге «Кызылармеецлар җыры»н да шикләнми шушы ук төркемгә кертергә мөмкин. Бу җырлар ифрат бәхетле язмышлы булып чыктылар, менә 40 ел инде алар халык теленнән төшми. Сугыштан соңгы елларда аларның беренчесе «Совет яшьләре җыры» (Ә. Исхак сүзләре), икенчесе «Совет армиясе җыры» (Ә. Фәйзи сүзләре) дип йөртелә башлады.

30 еллар татар совет музыка культурасы тарихына профессиональ музыка сәнгатебезнең гөрләп чәчәк аткан чоры булып кереп калыр. Нәкъ шушы елларда беренче уңышлы опералар барлыкка килә, симфонияләр, хор өчен әсәрләр языла. Татар совет җыр сәнгате дә үз үсешендә яңа баскычка күтәрелә. Бу өлкәдә М. Мозаффаров,

[1] Татар халык җырлары. Казан. 1963 ел. 18 бит.

Ф. Яруллин, Н. Жиһанов, Л. Хәмиди, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, А. Ключарев кебек сәләтле яшьләр нәтиҗәле эшчәнлек күрсәтә башлый. Әмма бу чорда да Салих Сәйдәшев иҗаты нык аерылып тора. Чорның характерлы сыйфатларын барыннан да тулырак нәкъ менә ул чагылдыра, яшьлек җырчысы, яңа тормышны данлаучы булып һаман да нәкъ менә ул кала. К. Тинчуринның «Кандыр буе» пьесасыннан «Без кабызган утлар»ны һәм «Фәридә җыры»н алыгыз, ул иҗат иткән дистәләрчә башка җырларны искә төшерегез. Күпме яктылык, тормыш муллыгы һәм яшәү шатлыгы аларда!

Бөек Ватан сугышы еллары С. Сәйдәшев иҗатын яңа темалар һәм яңа аһәңнәр белән баета. Элек аның өчен бик үк хас булмаган кырыс, саран авазлар өстенлек ала. Сугыштан соңгы елларда, җырчы композитор буларак, Салих Сәйдәшев яңадан туа дияргә мөмкин. Бу елларда аның иҗатында спектакльләр белән бәйләнмәгән мөстәкыйль җырлар барлыкка килә («Халисә», «Дуслык турында җыр», «Яшьлек җырым син» һ. б.). Шул ук вакытта ул спектакльләргә музыка язуын да дәвам иттерә.

...Салих Сәйдәшевнең җыр сәнгате өлкәсендәге эшчәнлеге гаять дәрәҗәдә кызыклы һәм гыйбрәтле. Аның иҗаты белән җыр сәнгатебез бик нык баеп, төрләнәнеп калды. Ул татар совет җырларының интонацион төзелешен күп елларга алга билгеләде, үзеннән соң киләчәк җырчы композиторлар иҗатына көчле йогынты ясады. 20 елларда ук С. Сәйдәшев ачкан төрле интонацион табышлар, төрле жанрлар татар совет җыр сәнгатендә дистә еллар буе яшәп килде, аларның байтагы бүген дә өстенлек итә.

Бүгенге көндә җыр жанрында барлык композиторларыбыз диярлек эшли, бу өлкәдә һәрберсенең үз почеркы, үз юлы бар. Әмма татар профессиональ музыкасына нигез салучының традицияләре һәм васыятьләре халкыбызның музыкаль культурасында бүген дә яши һәм киләчәктә дә яшәр.



## Нәҗибә Әминова

*Мин 1945 елда Башкортстанның Кушнаренко районы Әхмәт авылында туганмын.*

*Урта мәктәптән соң Уфа университетының филология факультетына укырга кердем. Аны тәмамлап, менә бер ел инде, Бүздәк районында укытучы булып эшлим.*

*Ләкин кайда гына барсам да, ниләр генә эшләсәм дә, һәрвакыт күңел шигырь белән яшәр кебек.*

●

*Укытучым Җәлил ага Киекбаевка*

Типте йөрәк...
Бүген соңгы тапкыр типте,
Китте кеше,
Мәңге кайтмас өчен китте...
Китте кеше —
Йөрәкләрдә кайгы калды.
...Димәк, кеше
Шатлык булып яши алды.

●

Чәчләремдә, әнкәй, кулын тоеп,
Таң белән үк ачтым күземне.
Карадым...
Юк, ләкин баш очымда,
Күрмәдем мин таныш йөзеңне.

Тәрәзәдән кергән йомшак җилләр
Сөеп үткән икән чәчемнән,
Тирә-юньгә әнием карашыдай
Җылы кояш нуры чәчелгән.

Аяз күкле яңа туган көн бит,
Нинди тыныч тора ул көлеп!
...Күзләремне ачтым — баш очымда
Әнкәм басып тора дип белеп.

●

Керфекләрең чыланмаган,
Күңелең ташып тулмаган,
Әле ләйсән сибелмәгән,
Язгы күкрәү булмаган.

Керфегеңә чык тамчысы
Кунар бер, кунар әле,
Йөрәгеңә язгы ташкын
Тулар бер, тулар әле,
Кояшлы яңгыр шикелле
Күңнәрең туар әле.

●

Сөйдем сине
Куанычтан
Яшьләрем түгелгәнче,
Таныш булмаган сагышлар
Йөрәгемне телгәнче.

Сөйдем сине
Хисләр тоташ
Ялкынга тиңләшкәнче,
Маңгай чәченә кагылган
Җилләрдән көнләшкәнче...

●

Айлы бер төн,
Әбкәм өе.
Мендәремдә бер учма нур.
Пәрдә ачып тышка карыйм —
Ай нурында урам матур!

Покла, әбкәй,
Ник шикләнеп миннән
Тамак кырасың син?
Миңа айлы урам матур,
Ә мендәрдә тик учма нур...
Соң бит белеп торасың син...

●

Буй-сыннарың шул булса да,
Үзгәргән киемнәрең...
Елмайсам да елмаймадың,
Моңсу итте кемнәрең?

Ал чәчәк тулы аланга
Килгән чакларың кая?..
Көләч гөлләр көнләшерлек
Көлгән чакларың кая?..

Ак чәчәкле ситсы күлмәк
Кигән чакларың кая?
Син онытсаң да, онытмам,
Дигән чакларың кая?

Мина монсу —
Куктән кояш
Карый җиргә тып-тыныч.
Мина монсу —
Исә җилләр,
Хәтта җилләр тып-тыныч.
Мина монсу —
Дулкыннар да
ярны
Тып-тыныч таба...
...Янымда син...
Ә бит йөрәк,
Йөрәк тып-тыныч кага,
Гомер тып-тыныч ага...

●

Мин башканы сөйгән идем,
Син дә бүтәнне кебек...
Мин елмаеп карыйм сина,
Син дә торасың көлеп...

— Бир кулыңны,
Киттек! — дисен,—
Сина да... барыберме?..
Юк!
Мин һаман аны сөям,
Син дә бит...
бары берне.

●

Бар авыр сүз кадалганы
Йөрәгемә ут шикелле,
Күкрәгемне ачу-нәфрәт
Көйдергәне ут шикелле;

Һәм нахакны күтәрмичә
Күңел сынып калган да бар.
Юк, дөреслек кенә түгел,
Ялган да бар, яман да бар.

●

Җәйдә телим кояш көлүен,
Кышның телим кышча килүен.
Уртачасын сөймим дию...
Тынлык икән —
Булсын тып-тыныч.
Давыл икән —
Хәтта куркыныч.
Янгыр!
Яусаң, җирне нык чылат,
Үтмә, үтмә
Бары тамчылап.
...Уртачасын сөймим дию,
Уртачасы юк бит сөюнең.

●

Зәңгәр күктә нурлар бии —
Кояш көлә!
— Каплап алам кояшны! — дип,
Болыт килә.

Кояш нурын сүндердем, дип,
Китте болыт.
...Нурлар бии —
Кояш калды
Кояш булып.

●

Ерактан ук балкып тора
Караңгыда чаткы да,
Әмма нурлы йолдызны да
Күреп булмый яктыда.

●

Гөлләр башын түбән игән,
Нигә моңсулар икән?
Таҗларын чыклар юганмы,
Нигә дымсулар икән?

...Карашың җиргә төбәлгән,
Ник әле сагышларың?
Керфегеңдә тамчылар бар,
Юдың кем ялгышларын?..

## Этюд

Килде давыл,
Камышларны
Таптап үтте дулкыннар.
Шашып-шашып,
Тын ярларны
Кочып үпте дулкыннар.

Давыл үтте,
Күлнең яше
Калды тышта түгелеп...
Камышлар күлгә төбәлде,
Сагышлардан бөгелеп...

**Павел Дегтяров**

# РЕВОЛЮЦИЯ СОЛДАТЫ

I



Юк, Шәех Кәримов география укытучысы да, тарих укытучысы да түгел. Әмма ул Татарстан белән Украинаның үткәнен һәм бүгенгесен искиткеч яхшы белә. Шулай да, бу ике тугандаш республика турында сөйләгәндә, ул кайсы ягы беләндер укытучыны хәтерләтә. Аның иркен квартирасында һәрвакыт Татарстан һәм Украина карталары эленеп тора. Сыңар кулына тоткан күрсәткеч таягы белән ул әледән-әле шушы республикаларның шәһәр һәм авылларын төртеп күрсәтә. Менә монда, Галициядә,— ди Шәех Кәримович,— егерменче елда татар хәрби частьлары сугышты. Беренче Атлы армия белән бергә алар Көнбатыш Украина хезмәт ияләренә азатлык һәм ирек алып килделәр... Ә менә монда, Львов шәһәренең үзәгендә, атаклы Дан калкулыгы. Анда кырык дүртенче елда бу борынгы шәһәр өстенә азатлык байрагы элгән безнең сугышчыларыбызның гәүдәләре күмелгән... Брода шәһәре янында исә минем туган ягымнан — Әлмәттән башлана торган «Дуслык» трассасының нефть эшкәртү станциясе урнашкан...

Аннан соң ул Казаннан, Мөслимнән һәм Татарстанның башка районнарыннан килгән яңа газеталарны күрсәтә. Мин үзенең һәм бөтен гаиләсенең язмышын Украина белән бәйләгән Кәримовны йотылып тыңлыйм, уем белән ул узган тормыш юлы буйлап узам. Шул чакта минем күңелемдә олы җанлы интернационалист, ялкынлы патриот, коммунист һәм революция солдаты Шәех Кәримов турында башкаларга да сөйләп теләге уяна.

I

— Боже, царя храни...

Тантаналы гыйбадәт ахырында әйтелә торган бу сүзләр Кәримовның башында күп төрле уйлар кузгатты. «Вольно!», «Таралырга!» командалары инде күптән бирелгән булса да, ул әле һаман солдат итекләре таптап шомарткан мәйданда басып тора иде.

Әйе, әлеге поп үзенең килеш-килбәте белән аңа Бакалыдагы нәкъ шундый икенче бер попны хәтерләтте. Басынкы гәүдә, туктаусыз хәмер чөмерүдән кызарган битләр, сытылган мүк җиләге буяп куйгандай кызыл борын. Чыннан да шул попмы бу, әллә игезәкләрме алар?

Подпоручик Кәримов, баскан урыныннан кузгалырга базмыйча, ерактагы истәлекләр иркенә бирелде.

Җиргә иңә төшкән тәбәнәк өйләре белән таралып утырган Уразмәт авылы Уфа губернасының Минзәлә өязендәге (хәзерге Мөслим районындагы) башка авыллардан

бер нәрсәсе белән дә аерылмый. Анда да ачлык һәм ярлылык, караңгылык һәм газап-җәфа чигү.

Кәрим картның шыксыз тормышы да нәкъ авылдашларыныкы төсле. Итле ашны аның гаиләсендә бары тик олы бәйрәмнәрдә генә күрәләр.

Бу гаиләнең бердәнбер байлыгы — биш малай һәм биш кыз. Аларның барысын да җыеп кырга алып чыксаң, анда агач сукага борылырга да урын калмый. Бер кишәрлек җиргә чәчкән игенең белән шушы чаклы ишле җанны асрап кара әле син!

Уразмәт авылында гомер кичергән татар, башкорт, чуваш һәм рус хезмәт ияләре әнә шулай ачлы-туклы яшиләр, очын очка көч-хәл белән ялгап баралар. Әмма аларның күбесе күңел төшенкелегенә бирелми. Алдагы өметенә ышанып яшәүче Кәрим, бер рус белешенең киңәшен тотып, улы Шәехне рус мәктәбенә укырга бирә.

— Без ни өчен ярлы? Чөнки надан без,— ди Кәрим Шәехкә.— Бар, улым, аң-белем ал, кояшка үрлә. Картлык көнемдә бәлки минем дә тормышымны җылытырсың.

Шулай итеп, Шәех Бакалыдагы рус мәктәбенә укырга керә. Һәм шунда 1911 елда мәктәп попы белән каршылыкка очрый. Менә хәзерерактагы Волынь мәйданында басып торганда аның күз алдына ирексездән әнә шул поп килеп басты. Уразмәттә вакытта ук инде Шәех әтисенең мулладан: «Ни өчен минем балаларымның ашарларына хәтта бер сынык икмәкләре дә юк, ә бай балалары бал-май эчендә йөзәләр?» — дип соравына каршы мулланың һәрвакыт бер үк сүзләр белән җавап бирүен еш ишетә иде.

— Алланың теләге шундый. Аның каравы теге дөньяда син үзең дә, балаларың да оҗмахның иң түрендә булачаксыз.

Кызыл борынлы кәрлә поп та туйганчы ашарлык ризыклары булмаудан зарланган укучыларны шул ук сүзләр белән юатырга тырыша.

— Ач тору һәм салкыннарда туңу — сезнең өлешегезгә тигән зур бәхет ул, чөнки хода дөньялыкта газап чиккән кешеләргә, үлгәч, алар үзләре теләгән бөтен рәхәтлекләрне бирермен, дигән.

Мулла һәм поп әйткән сүзләр Шәехне уйланырга мәҗбүр итте. Аларның берсе ислам, икенчесе христиан динен якласалар да, асылда бер үк нәрсә турында сөйлиләр, бер үк нәрсәне алга сөрәләр, җирдәге гаделсезлек белән килешеп, язмышка буйсынып яшәргә өндиләр. Малайның күңелендә попка карата ачу хисе кабарды. Һәм ул алла законнарын өйрәнү дәресендә аңа җавап бирүдән баш тартырга карар итте — класс журналында Кәримов фамилиясе белән рәттән юан каләм белән куелган «икеле» билгесе барлыкка килде.

Моның өчен Шәех поптан үч алырга ниятләде. Үзенең ике иптәше белән бергәләп, ул мәктәп өйалдысының сайгакларын сүтеп куйды. Кичке гыйбадәткә ашыгучы поп аның тозагына эләгеп егылды һәм борынын җимерде.

Укучыларны кулга алдылар. Полицейский аларга, бу эштә гаепле кешене тапканчыга кадәр, ашарларына су белән ипидән башка ризык бирелмәячәге турында кисәтте. Шунда Шәех:

— Иданне мин сүттем һәм моны мин берүзем эшләдем,— диде, алга чыгып.

Аны полиция участогына алып киттеләр. Тик озак тотмадылар, чыгардылар. Ләкин мәктәптән аны кудылар...

Һәм менә хәзер Кәримов «данлыклы» патша сугышчыларының җиңү хөрмәтенә кыска буйлы поп тантаналы гыйбадәт укыган мәйдан уртасында басып тора. Бу ике поп — авыл һәм полк попы — бер-берләренә никадәр охшаганнар! Аның бусы да нәкъ тегесе сөйләгән сүзләрне сөйли торгандыр, мөгаен...

— Әйе, син менә дигән батыр! — диде аңа теге вакытта әтисенең рус танышы, мәктәптән куылган Шәех үз авылларына кайткач.— Поптан бик дөрес үч алгансың, ә бөтен гаепне өстеңә алып, тагын да яхшырак эшләгәнсең!

Үзенең соңгы өмете — улларының берсен генә булса да кеше итү ышанычы сүнә баруын күргән Кәрим карт, бер сүз дә дәшмичә, тирән кайгыга батты: инде хәзер нишләргә?..

Бер-берләренә ярдәм кулларын сузарга күнеккән киң күңелле кешеләр Шәехне күрше авылга, Морзахан Солтановка җибәрделәр. Милләте белән татар булса да, бусы да тархан-дворян һәм сәүдәгәр, патша властьларының ышанычлы ялчысы. Пристань һәм кибетләр, күн һәм мех эшкәртү предприятиеләре — бөтенесе дә аныкы.

— Белемле кешеләр бик кирәк миңа,— диде ул малайга.— Алар белән табыш ясавы җиңелрәк...

Табыш, әлбәттә, Солтанов кесәсен калынайта. Ә аның яшь кассир-хисапчысы бары тик чит кеше малына гына исәп-хисап ясый. Һәркемнең үз эше, үз юлы.

Шәех Кәримов дәрестән дә үз юлы белән китте. Һәм бу юл аны 1911 елда РСДРП сафларына алып килде. Большевиклар партиясе программасы белән аны мулла Харрас Дусмин таныштырды. Әйе, мулла. Дин хезмәтчесе булып ул партия кушуы буенча эшли иде.

Нибары берничә класс белеме булган Шәех Кәримовка ленинизм әлифбасын өйрәнер өчен бик зур тырышлык кирәк булды. Кичләрен һәм төннәрен хуҗаның майланып беткән исәп-хисап кенәгәләрен бер читкә этәреп, яшереп куелган җирдән ул Харрас Дусмин биргән брошюраны алып утыра торган булып китте. Үзен беркайчан да күрмәгән, ләкин аның өчен иң кадерле булган укытучы бу брошюрада Кәримовка эксплуатациянең катлаулы исәпләре, Морзахан Солтановның һәм шуның кебек башкаларның табыш алу чыганаклары хакында аңлата икән.

Бай хисапчысы бик күп таңнарын патша цензурасы тарафыннан тыелган әдәби һәм политик әсәрләр укып каршылый. Йокысыз төннәр аның көчен киметми, киресенчә, аңа яңадан-яңа энергия бирә. Ничек шушы кадәр ачык һәм ышандырырлык итеп яза бу Ленин! Әйтерсең, гомер буе Татарстанда, Шәехнең туган җирендә яшәгән...

Солтанов үзенең хисапчы-кассирыннан зарланмый. Чөнки Кәримов аның исәп-хисап эшләрен төгәл итеп, җиренә җиткереп башкара. Аннан соң Шәехка бит ул хезмәт хакын да тиешлесеннән азрак түли. Ләкин полиция егет белән поп арасында булган вакыйганы һич тә онытырга җыенмый. Ул вакыйга булып узганнан соң, властьлар, яше җитмәгәнлектән, Шәех белән исәп-хисапны өзәргә кыюлык итмәсәләр дә, аның артыннан күзәтчелекне бер генә минутка да туктатмыйлар. Моны һәр даим сизеп яшәгән Кәримов көтмәгәндә кеше күзеннән югала. Ләкин аңа озак яшеренеп ятарга туры килми: ышанычлы дип саналган дуслары сатлык җан булып чыгалар. Полиция Кәримовның эзенә төшә... Шул вакытта беренче бөтендөнья сугышы башланып китә. Кәримов, партиядәш дусларының киңәше буенча, үзе теләп армиягә китәргә ризалык ала. Большевиклар солдатлар арасында үз кешеләренең мөмкин кадәр күбрәк булуын телиләр.

...Подпоручик Кәримов һаман әле баскан урыныннан кузгалмый. Подпоручик... Башта ул рядовой солдат булып сугыша. Аннан кече унтер-офицер, унтер-офицер, подпрапорщик, прапорщик дәрәҗәсенә күтәрелә. Ниһаять, аңа подпоручик исеме бирәләр. Бу хакта ишеткән полк офицерлары кинаяле сүзләр катыш үзара елмаешып куялар:

— Сәнәктән кәрәк булган нәрсә...

Өреп кабартылган күркәләр! Алар әллә Кәримовка югары хәрби чин кирәк дип уйлыйлармы икән?! Ул һәрвакыт окопташлары белән бергә булучы, хәрби хезмәтнең барлык авырлыкларын алар белән бергә кичерүне үзенең изге бурычы итеп саный. Солдатлар аның батырлыгы, гадилеге белән горурланалар:

— Лачын! Курку белмәс бөркет!

Бу сүзләрне Кәримов кан коюлы сугышларда кичергән чиксез авырлыклар өчен иң зур бүләк итеп кабул итә. Югарыда да Кәримовның батырлыкларын күрми кала алмыйлар. Аның күкрәгенә бер-бер артлы дүртенче, өченче, икенче һәм беренче дәрәҗә Георгий тәреләре тезелә. Георгий кавалерының тулы бантын тагып йөргән большевик-офицерның нинди уйлар белән янганлыгын, аның нәрсәләр турында хыялланганын белсәләр икән?! Ләкин бу хакта аның бары тик иң якын дуслары гына белә. Аларның теләк-омтылышлары уртак: «Сугышны тизрәк туктатырга! Штыкларны патшаның үзенә һәм аның ялчыларына каршы борырга!»

...Менә хәзер, 1916 елның җәйге бу көнендә, Шәех Кәримовның күз алдында — якында гына агып яткан Стоход елгасы, Көнчыгыш Галиция, Көнбатыш Украина. Ул шушы җирләрдә яшәүче үзе кебек гади кешеләрнең язмышлары турында уйлана. Монда да халык ул туып-үскән җирләрдәге шикелле үк газап-михнәт чигеп, ачлы-туклы яшәп көн итә. Бу соң кайчанга кадәр шулай дәвам итәр икән? Кешеләрнең тормыш күген каплап йөзгән кургаш кебек бу авыр болытлар кайчан таралыр икән дә, ул болытлар астыннан кайчан кояш көлеп карар икән?..

Ул көннең инде ерак түгеллеген Кәримов әле ачык кына белми иде...

1943 елның 18 январе. Ул көнне, Бөек Октябрь революциясенең бишеге — Ленин шәһәрен чолгап алган дошманның уналты ай буена дәвам иткән блокадасын тулысынча җимереп, Ладога ярлары буенда Ленинград һәм Волхов фронтлары сугышчылары бергә килеп кушылдылар. Башка барлык сугышчылар кебек үк, капитан Кәримов та, шатлыклы очрашу билгесе итеп, уң кулындагы автоматын югары күтәрде.

— Пароль?

— Җиңү.

— Отзыв?

— Үлем фашизмга!

Дистәләрчә сугышларда катнашкан, туган Ватаны өчен күп тапкырлар канын койган куркусыз командир бу минутта үзенең иптәшләренә күз яшьләрен күрсәтүдән оялмады. Аның җил ашаган битләре буйлап көмештәй берчекләр тәгәрәде. Ләкин бу бик-бик кыска вакытлы күренеш иде. Берничә минуттан полк командиры ярдәмчесе капитан Кәримовның боерыклар биргән тавышы ишетелә иде инде:

— Батареяларның сугышчан комплексларын тулыландырырга! Күпме патрон һәм граната калганлыгын яңадан бер тапкыр барларга!

Җиңү белән рухланган полк Ленинградтан көньякка, Мга ягына омтылды.

Тирә-якта гитлерчыларның үле гәүдәләре, яндырылган танк һәм машиналары аунап ята. Үзенең полкы белән көньякка атлап барганда Кәримов сугышчан юлын тагын бер тапкыр уеннан кичерде. Гражданнар сугышыннан соң хәрби форманы аңа утыз тугызынчы ел башында — фин кампаниясе башлангач кияргә туры килде. Фин сугышы беткәч, Шәех Кәримов өендә өч кенә ай торды һәм... яңадан армия, яңадан сугыш — Бөек Ватан сугышы башланып китте.

Танкларга каршы ата торган артиллерия полкы командиры ярдәмчесе капитан Кәримов 1942 елның җәендә Сталинград фронты гаскәрләре составында оборона сугышларында катнашты. Ул генерал Чуйковның трактор заводы районында, Иделнең уң як ярындагы плацдармда оборона тоткан легендар 62 нче армиясе сафларында сугышты. Фронтның шушы участогын әйтеп үтү үзе генә дә Сталинград сугышында катнашкан Кәримовның сугышчан батырлыгы турында күп нәрсә сөйли.

Сталинград фронты белән чагыштырганда яңа фронтның беренче карашка Шәех Кәримовка бернинди дә уртаклыгы юктыр кебек күренде. Сазлыклар һәм урманнар... Чолганышта калган шәһәргә көнен һәм төнен сугыш кораллары, азык-төлек һәм ягулык ташу өчен хезмәт итүче тар гына коридор булып сузылган Ладога күле... Зур шәһәрне һәм гаскәрләрне барлык кирәк-яраклар белән тәэмин итү өчен бу тар коридор, әлбәттә, һич кенә дә җитәрлек түгел.

Әйе, Кәримовка монда Сталинградны бик аз нәрсә хәтерләтте. Урам сугышлары урынына монда артиллерия дуэльләре хакимлек итә. Тик шулай да бу фронтларның һәр икесенә уртак бернәрсә — Совет сугышчыларының дошманны җиңүгә булган какшамас ышанычы хас иде.

Ленин шәһәре... Ул моннан берничә дистә километр гынаераклыкта. Вакыт-вакыт Шәех Кәримов хәтта аның һәркемне сокландырган һәйкәлләрен, күккә ашкан манараларын күргәндәй була.

Ленин шәһәре... Онытылмас унҗиденче елның ноябрендә партия чакыруы буенча большевик-подпоручик Шәех Кәримов үзенең ротасын нәкъ шул шәһәргә алып килгән иде. Ә ул менә болай булды...

1916 елның җәендә Кәримов Стоход янындагы сугышларда каты яраланды. Дәвалануырга аны Рязань шәһәренә озаттылар. Госпитальдән ул запастагы полкка эләкте. Бу вакытта инде 1917 елның ахырлары якынлашып килә иде. Менә шул көннәрнең беренче телеграф ленталарында яшен тизлеге белән «Патша власте төшерелде!» дигән сүзләр кабынды.

— Башлана! — дип кычкырып җибәрде Кәримов, шатлыгын яшерә алмыйча. Бу көнне ул гарнизон буенча дежурлык итә иде. Әлеге хәбәрне бөтенләй башкача кабул иткән гарнизон начальнигы генерал Макаров аны үз янына чакыртып алды.

— Подпоручик, һич кичекмәстән гарнизон частьларын аякка бастырырга! — дип

өмер бирле ул, кырыс кына.— Безнең данлыклы сугышчыларыбыз, бер кешедәй булып, патшаны яклау өчен изге көрәшкә күтәрелергә тиеш. Хәрәкәт итегез!

Ләкин подпоручик китәргә ашыкмады. Бераз уйланып торганнан соң, ул тыныч тавыш белән ашыкмыйча гына җавап кайтарды:

— Солдатлар сезне якламаячаклар, генерал. Аларга кан эчкеч патша һәм кан коюлы сугыш кирәк түгел... Гарнизонны күтәрергә киңәш итмәс идем мин сезгә...

Моннан бер көн элек булса, Макаров һич тә икеләнмичә бунтарь подпоручикны кулга алырга һәм судка бирергә боерган булыр иде. Ләкин бүген моны эшләргә ярамаганлыгын ул ачык төшенде. Кәримовны ул тизрәк икенче бер запас полкка озату чарасын күрде. Ләкин большевик-подпоручик анда да озак тормады. Монархист рухлы офицерлар Кәримовның «Рязань тарихы»н бик яхшы беләләр, аның һәр адымын күзәтеп торалар иде. Һәм офицерлар өчен уздырылган җыелышларның берсендә кемдер патшага озын гомер теләгән җырны җырларга тәкъдим иткәч, Кәримов демонстратив рәвештә баш тартты.

— Стенага терәргә!

Бу хөкемнән аны бары тик Георгий тәреләре генә коткарып калды. Нәрсә әйтсәң дә, ул бит аларның барлык дәрәҗәләре белән дә бүләкләнгән кыю офицер. Аны штрафниклар ротасына җибәрделәр. Кәримов солдатлар арасында тиз арада үз кеше булып китте. Сугышчылар аңа үзләрен борчыган иң-иң мөһим сораулар белән әледән-әле мөрәҗәгать итәләр иде:

— Бу сугышның берәр чиге булырмы?

— Патша төшерелде, шулай булгач, ни өчен офицерлар һаман солдатларны кыйныйлар?

— Халык революциясе дип сөйлиләр, ә власть башында әле дә булса фабрикантлар һәм помещиклар утыра...

Кәримов тормышның үзе тарафыннан куелган әнә шуңа охшашлы дистәләрчә сорауларның һәркайсына булдыра алган кадәр ачык һәм тулы итеп җавап бирергә тырышты.

Рота яшь кымыз кебек кайный. Моны гарнизон башлыклары да сизәләр. Кәримовка ярдәмче итеп алар алпавыт улы, карадан да кара фикерле монархист Ивановны билгеләделәр. Ротаны Мурманск тимер юлы төзелешенә — Кандалакша шәһәренә озатырга боерык бирелде.

Ерак төньяк портында, бигрәк тә Кәримов ротасы килеп урнашкан тимер юл станциясендә, көчле большевистик оешма үзенең эшчәнлеген киң җәелдергән иде. Бу оешма белән кассир Кулиш җитәкчелек итә. Кәримов аның белән бик тиз танышып алды. Тимер юлчы — большевиклар җитәкчесе Шәех Кәримовны партия алып бара торган көрәш курсы һәм ил тормышындагы яңалыклар белән таныштырып, бик күп төннәрен аның белән бергә үткәрде. Кулишның чыгышларында «Ленин позициясе», «Ленин платформасы» дигән сүзләр әледән-әле кабатлана иде. Аннан ишеткән яңалыкларны Кәримов төкми-чәчми үзенең солдатларына җиткерә барды, илдә революцион вакыйгаларның үскәннән-үсә баруы турында сөйләде.

Октябрь ахырында Кулиш ашыгыч рәвештә Кәримовны үзенә чакыртты.

— Ротаң белән синең Петроградка килеп җитүеңне сорыйлар,— диде ул аңа, сынаулы караш ташлап.

— Петроградка? Ни өчен? Кем сорый?

— Әйе, Петроградка. Ленин һәм партия сорый. Ә ни өчен икәнлеген анда баргач әйтерләр.

Берничә сәгатьтән рота вагоннарга төялде. Вакытлы хөкүмәтнең җирле властьлары большевистик рухтагы солдатларны Петроградка җибәрмәс өчен төрле комачаулыклар тудырырга тырышып карадылар. Ләкин солдатларга тимер юлчы дуслары ярдәмгә килде. Көндез алар составны запас юлга кертеп тордылар һәм, властьларга сиздермичә, төнлә Питерга озаттылар.

Һәм, ниһаять, менә ул Питер! Рота, 5 ноябрьдә поездддан төшеп, Смольныйга, Петроград Советы каршындагы Хәрби-революцион комитетка, үзенең делегатларын җибәрде. Делегатлар аннан тирән дулкынлану белән кайттылар.

— Смольныйда безне искиткеч җылы каршыладылар,— диделәр алар Кәримовка.— Петроградка без бик вакытлы килеп җиткәнбез...

Шулай итеп, Кәримов үзенең ротасы белән тарихи вакыйгалар эченә кереп китте. Ротага Невский проспекты буйлап патрульлек итү бурычы йөкләнде.

Проспектны халык ташкыны күмгән. Урам буйлап иңнәренә мылтыклар аскан кызылгвардиячеләр атлый. Кышкы сарай ягына карап, юнкерлар уза.

Кәримов ротасы 7 ноябрь көнен нәкъ әнә шунда — Невский проспектында каршылады. Солдатлар Ленинның Смольныйга килгәнен беләләр иде инде. Яңа гына язылган һәм басылып чыккан «Россия гражданнарына!» мөрәҗәгате кулдан-кулга күчеп йөри: «Вакытлы хөкүмәт төшерелде... Яшәсен эшчеләр, солдат һәм крестьяннар революциясе!..»

Кешелек тарихында яңа эра — коммунизм эрасы башланганлыгын хәбәр итеп, «Аврора» залпы яңгырады. Революцион көчләр төнлә штурм белән Кышкы сарайны алдылар.

Кызылгвардиячеләр белән бергә Кәримов ротасы солдатлары да ак офицерлардан Нева аша салынган күперләрне, дәүләт биналарын тартып алышуда, юнкерлар училищеларын чолгап алуда катнаштылар.

Сигезенче ноябрьда рота Невский буйлап патрульлек итүен дәвам итте. Шул вакыт көтмәгәндә кайсыдыр йортның түбәсеннән аткан пулемет тавышы ишетелде. Аягы яраланган командир җиргә ауды. Күп кан агудан ул аңын югалтты. Кәримов ярaлыларны дәваланырга алып баручы поездда гына исенә килде. Урыныннан сикереп торырга теләде, ләкин аягының авыртуына түзә алмыйча, яңадан чалкан егылды. Шәфкать туташы аңа катгый рәвештә:

— Тыныч кына ятыгыз,— диде.— Без Астраханьга барабыз.

— Ә миңа Питер кирәк, аңлыйсыңмы, Питер кирәк! Анда Ленин, анда революция...

Шәфкать туташы җылы сүзләр белән юатырга ашыкты:

— Революция җиңде. Аның белән Ленин үзе җитәкчелек итә... Ә сезгә дулкынланырга һич тә ярамый. Сезне катлаулы операция көтә...

Башына ак косынка бәйләгән бу фәрештәгә күңелендәге уйларны ничек итеп аңлатырга соң?! Ә бит аңа хәзер, менә шушы минутта Петроградта булу никадәр кирәк иде! Анда ул Ленин белән очрашып, аңа туган халкы турында, үзе һәм солдат дуслары турында сөйләргә теләгән иде. Ә бу ак халатлы кызның үз сиксәне сиксән:

— Тыныч кына ятыгыз!..

Революция давылы белән актарылган Петроградта Шәех Кәримовка нибары өч кенә тәүлек булырга туры килде. Аның каравы нинди генә тәүлекләр әле! Һәр сәгате дистәләрчә елларга тиң иде ул тәүлекләрнең. Петроград — Октябрь — Ленин...

...Тормышта шулай килеп чыкты: революциядән соң Кәримовка Октябрь шәһәрендә булырга һәм Ленин белән очрашырга насыйп булмады. Менә хәзер, егерме биш елдан артык вакыт үткәннән соң, ул, Кызыл Армия сугышчысы, изге җиребездән фашист этләрне куа, Ленинград блокадасын өзүдә катнаша. Аның бөтен көчен җыеп:— Мәңге яшәячәксең син, Ленинград! — дип кычкырасы килә. Ләкин ул кычкырмый, бары тик оборонадан һөҗүмгә күчү өчен кирәкле кыска-кыска командалар гына бирә. Аннан соң яңадан штаб белән бергә атлый. Салмак адымнар белән атлап барганда аны кабат истәлекләр чолгап ала. Ул истәлекләр, кино кадрларын хәтерләтеп, бер-берләрен алыштыра торалар.

...Ярасы төзәлгәннән соң Кәримовны Астраханьнан Уфага җибәрәләр. Биредә аны марксистик түгәрәк буенча таныш дусты каршы ала:

— Исәнме, батыр!

— Саумы, дустым! — ди Кәримов, аны кочаклап һәм шатлыгын уртаклашырга ашыга.— Ниһаять, безнең күптәнге хыялыбыз тормышка ашты бит!..

1918 елның 2 февралендә Шәех Кәримов, үзе теләп, халык байлыгын, халык милкәтен саклау отрядына языла. Озак та үтми, аны 9 нчы кызылгвардия отрядының начальнигы итеп билгелиләр. Отряд составында нибары унсигез кеше, ә аңа йөкләтелгән эшнең иге-чиге юк. Отрядка, барыннан да элек, Златоуст өязе территориясендә Совет власте урнаштыру һәм аны ныгыту бурычы тапшырылган. Төп терәк — халык белән тыгыз элемтәдә булуда. Отряд алдына куелган иң мөһим бурычларның берсе — икмәкне реквизицияләү һәм аны Петроградка, Мәскәүгә озату. Революциянең ахыргача җиңеп чыгуын теләгән ярлылар үзләренең соңгы килограмм ашлыкларына кадәр китереп тапшыралар, ә байлар һәм кулаклар икмәкне яшерәләр, черетәләр, яндыра-

лар. Шәех — сугышчы да, агитатор да. Аның коралы — мылтык һәм большевистик сүз.

Шул ук елның җәендә чехлар корпусы советларга каршы баш күтәрә. Ә көзен Уфа директориясе — «Вакытлы Бөтенроссия хөкүмәте» төзелә. Ул властьны Антанта ялчысы — хәрби диктатор адмирал Колчакка тапшыра. Революциянең язмышы кыл өстендә кала. Кәримов үзенең отряды белән Масагут авылы янында акчехларга каршы сугышка керә. Көчләр тигез түгел. Ләкин, тиешле дәрәҗәдә коралланмаган булуларына да карамастан, кызылгвардиячеләр чит ил оккупантларын тар-мар итәләр. Бу бәрелеш вакытында Кәримов яңадан каты яралана.

Совет властен саклап калу өчен башланып киткән гражданнар сугышы һәм партизаннар көрәше җәелгәннән-җәелә бара. Ярасы төзәлгәннән соң, Шәех Кәримов, акчехларга билгеле булмаган сукмаклар буйлап, Бакалыга юл тота. Бирегә ул нәкъ кирәкле моментка — 2 нче партизан отряды төзелгән вакытка килеп җитә. Татар, башкорт һәм руслардан бу отрядка 280 ләп сугышчы туплана. Җәяүлеләр, атлылар... Аларның күбесе — элекке солдатлар.

Отряд командиры итеп И. И. Пазухин, аның урынбасары итеп Шәех Кәримов һәм Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты вәкиле итеп И. С. Кожевников раслана. Төзелеп бетү белән отряд акчехларга һәм Колчак гаскәрләренә каршы һөҗүмгә ташлана.

...Кәримовлар гаиләсендә кунакта булганда, күп санлы фоторәсемнәр арасында мине шактый олы яшьтәге өч кешенең бергәләшеп төшкән рәсеме үзенә җәлеп итте.

— Бу — Иван Рагулин, бусы — Иван Лобанов, ә менә монысы мин булам,— дип аңлатып бирде миңа Кәримов.— Әлеге рәсемгә без 1957 елда, Башкортстанда Совет власте урнаштырылуга кырык ел тулу көнен бәйрәм итү өчен Бакалыга килгәч төшкән идек. Ул бәйрәмгә безне, элекке партизаннарны, партия район комитеты чакырды. Бәйрәмгә илебезнең төрле почмакларында яшәүче иптәшләр килде. Алар арасында 2 нче партизан отряды полк итеп үзгәртелгәч, өченче батальон белән командалык иткән Рагулин һәм пулемет командасы начальнигы итеп билгеләнгән Лобанов та бар иде.

Кәримов нәрсәнедер хәтеренә төшергәндәй, сөйләвеннән беравык туктап торды һәм сүзен дәвам итте:

— Ул вакытта, 1957 елда дип әйтүем, мин үзебезнең Татарстанда, Бөгелмәдә яши идем. Бакалыга узып барышлый Иван Рагулин Бөгелмәгә сугыла һәм минем шунда яшәвемне ишетә.

Кыскасы, Рагулин безнең йортны эзләп тапты. Ләкин башта ул мине танымады: Кырык өченең апрелендә, Ленинград фронтында мин сул кулымны югалттым... Бакалыга без бергә киттек һәм анда Лобановны очраттык. Анда безгә Башкортстан республикасы Верховный Советы Президиумының Мактау грамоталарын тапшырдылар... Озакламый Рагулин вафат булды, Лобанов бүгенге көндә Бакалыда яши.

Саргая төшкән фоторәсемнән һәм аның иясе сөйләгәннәрдән мин әнә шулар хакында белдем.

...Сугышта юлны сайлап алмыйлар, аны язмыш үзе сала, диләр. Анысы ничектер, әмма Шәех Кәримовның сугышчан юлы бик күп тапкырлар Украина җирләре буйлап үтә. Беренче бөтендөнья сугышында ул Волынь һәм Стоход елгасы тирәләрендә сугышып йөри. 1918 елның ноябрендә ул хезмәт иткән полк немец гаскәрләренә һәм Петлюра директориясенә каршы көрәшү өчен Украинага җибәрелә. Татар сугышчылары, полк байрагын биек күтәреп, Донбассның күп кенә шәһәр һәм авылларын дошманнан азат итү өчен бөркетләрчә сугышалар. Шундый сугышларның берсендә Шәех Кәримов тагын яралана. Сугышчыларына аның тәнендә инде пуля һәм туп кыйпылчыклары тишкәләр урын да калмагандыр кебек тоела. Ә ул һаман да көрәшнең иң кызган участокларына омтыла, йөрәге аны революцион антына турылыклы булып калырга чакыра.

Курск госпиталеннән чыкканнан соң, Шәех Кәримов — татар-башкорт батальоны командиры. Ул көннәрдә Михаил Васильевич Фрунзе җитәкчелегендәге Көнчыгыш фронт гаскәрләре тарафыннан Колчакның удар армиясен тар-мар итү башлана. Кәримов батальоны, Колчак гаскәрләрен Чиләбегә кадәр куганнан соң, Бәләбәйгә борыла һәм Рәҗәпов командалык иткән Татбригада составына кушыла.

Кызыл Армия Колчакны тар-мар итеп бетергәндә, Кәримов инде 204 нче татар полкы белән командалык итә. Полк, кара көзгын булып илнең азатлыгын буарга килгән барон Врангельгә каршы сугышу өчен, Көньяк фронтка күчерелә. Татарстан һәм Украинаның азатлыгы өчен яңадан кан коюлы сугышлар башланып китә.

Перекопка бәреп керү өчен зур әһәмияткә ия булган Софиевка янындагы сугыш Кәримовның беркайчан да хәтереннән чыкмас.

Һөҗүмгә күчәр алдыннан бирегә Көньяк фронтның Революцион Советы члены Бела Кун килә. Ул Кызыл Армиянең совет җиреннән чит ил интервентларын һәм контрреволюцион гаскәрләрне куып чыгаруны тәмамлау алдында торуы хакында ялкынланып сөйли.

Митингтан соң һөҗүмгә ташлангач, кызылармеецлар полк командиры Шәех Кәримовның иң алгы рәттән атлавын күрәләр. Акларның каршылыгы көчле, әмма һөҗүм итүчеләрне бернәрсә дә туктата алмый.

— Ленин! Советлар! Ура!

Кәримов җиргә ничек ауганын үзе дә тоймый кала. Башта ул ялгыш абынып кына егылдым дип уйлый. Яраланган командирны сугышчылар күтәреп торгызалар.

Егерме беренче елны ул армиядән демобилизацияләнә. Башта җинаятьчеләрне эзләүчеләр группасында, аннан кооперациядә һәм халык судьясы булып эшли. Салкын окопларда яткан солдатларның татлы хыяллары матур чынбарлыкка әверелә бара. Ләкин, халкыбыз һәм илебез яңа шатлык һәм бәхеткә карап атлаганда, кинәт дәһшәтле сугыш башланып китә. Һәм 1943 елның 13 апрелендә Кәримовны яңадан дошман пулясы эзләп таба. Бу ярасын ул моңарчы алган барлык яраларыннан да авыррак кичерә. Монысында Кәримов бер кулын гомерлеккә югалта.

III

Шәмсия һәм Шәех Кәримовларның гаилә корып бергә тора башлауларына узган елның 19 октябрендә нәкъ илле ел тулды. Бу олы бәйрәмгә Мәскәүдән уллары Саша, Вова һәм кияве белән бергәләп кызлары Флора кайтып төште. Табын янында аларның һәркайсы тәбрикләү тостлары күтәрделәр.

— Алтын туй хөрмәтенә! Бриллиант туегызны да күрергә насыйп булсын өчен!

Алар 1919 елның көзендә танышалар. Ул чакта Шәехка егерме дүрт, кызга унтугыз яшь була. Бөтендөнья һәм гражданнар сугышының ут-ялкыннарын кичкән бу егетне Шәмсия беренче тапкыр Уфа урамы буйлап ат өстендә чабып узганда күреп кала. Ә соңыннан юллар аларны бер-берсе белән якыннан һәм кабат аерылмаслык итеп очраштыралар.

Шәмсия башта батальон, аннан соң полк санитаркасы булып хезмәт итә. Шәех кайда, ул да шунда — сугышчыларга кичектергесез ярдәм кирәк булган урыннарда була. Перекопка якынлашып килгәндә, Врангель тубының кыйпылчыгы иреп аяктан еккач, Шәмсия аны иңнәрендә сугыш кырыннан алып чыга.

Тыныч елларда да ул Шәехнең иң ышанычлы, иң тыйнак дусты булып кала. Гражданнар сугышы тәмамлангач, Шәмсия милициядә һәм халык судларында эшли, үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештыра, актив җәмәгать эшлеклесе буларак, төрле урыннарда күп санлы чыгышлар ясый.

Әйе, ирле-хатынлы Кәримовларның көрәше, тынгысыз тормыш юлыннан бергәләшеп атлый башлауларына ярты гасыр. Аларның кызлары да үзләренең барлык көчләрен һәм эшләрен илгә багышлаган кыю көрәшчеләр, чын патриотлар булып үстеләр. Флора Бөек Ватан сугышы елларында фронтның иң куркыныч участокларында беренче класслы радистка булып хезмәт итә. Аның кызы Александра И. М. Губкин исемендәге Мәскәү нефть институтын тәмамлый. Кәримовның олы кызы Әлфия дә инде күп еллардан бирле нефть промышленностенда эшли. Дөресен генә әйткәндә, Кәримовларның Львовка күчеп килүләренә дә Әлфия сәбәпче була. Уфа нефть институтының өченче курсын тәмамлагач, 1945 елда аңа Львов шәһәренә күчәргә тәкъдим итәләр. Көнбатыш Украинада нефть промышленносте кызу темплар белән үсә башлаган чор була бу. Шәмсия ханым юлга җыенган кызы белән ялгыз калып бик озак сөйләшә, аңа үзенең киңәшләрен бирә:

— Ерак җирләргә китәм дип бер дә борчылма, кызым. Ул яклар безгә туган ягыбыз шикелле кадерле. Украинаның азатлыгы, бәхетле киләчәге өчен әтиең анда әллә ничә тапкыр утка керде. Ул җирләрдә миңа да булырга туры килде. Украина безнең икенче туган җиребез ул. Аның лаеклы кызы булырга тырыш.

Әлфия Кәримова менә егерме елдан артык инде Львовта эшли, хәзерге көндә ул нефть-химия промышленностеның дәүләт фәнни-тикшерену һәм проектлаштыру институты баш инженеры. Аның үзенә тапшырылган бу җаваплы эшне ничек башкаруы турында СССР Верховный Советы Президиумының «Почет билгесе» ордены белән бүләкләү турындагы 1966 елның 28 май Указы ачык сөйли.

Кәримовларның барысы да, Әлфия исә бигрәк тә, «Дуслык» нефть үткәргеченең Львов җире аша узуына куанып бетә алмыйлар. Чөнки «Дуслык»ның юлы Әлфиянең әти-әнисе туып-үскән яклардан башланып китә бит һәм ул үзе дә нефтьче.

Шәех Кәримович кызы Әлфиянең «Дуслык» нефть үткәргече турында сөйләвен йотылып тыңлый һәм зур горурлану белән үзе дә сүзгә кушыла:

— Безнең Татарстан җире — дуслыкка ныклы нигез салынган җир ул.

Аннан соң ул сугыштан соңгы елларны, көл һәм җимерекләр эченнән яңа калкынып килгән Львов шәһәрен искә төшерә. Ул вакытта Казаннан бирегә нефть һәм газ промышленносте предприятиеләре өчен дистәләрчә төрдәге машиналар һәм приборлар җибәрелә. Аннан килгән йөзләрчә осталар украин егетләрен һәм кызларын бик күп төрле һөнәрләргә өйрәтәләр. Ә хәзерге көндә Львовтан автобуслар һәм телевизорлар, инструментлар һәм электр лампочкалары төялгән поездлар көнчыгышка агыла.

...Үзенең үткән һәм бүгенге тормышы турында сөйләгәндә, Шәех Кәримов әле Татарстанны, әле Львовны телгә ала. Мондый чакта миңа ул Украинага Татарстан җиреннән килгән тулы хокуклы илче-вәкилне хәтерләтә.

Менә ул яңадан стенага эленгән карталар янына килә. Ул карталар Украина һәм Татарстан республикаларының көннән-көн үсә, күтәрелә, чәчәк ата баруын чагылдырган шартлы билгеләр белән чуарланган.

— Минем якташларым быел Татарстан Автономияле Социалистик республикасы төзелүгә илле ел тулуны бәйрәм иттеләр. Бу чор эчендә Татарстан тормышында булган үзгәрешләрне санап чыгу өчен генә дә әллә никадәр вакыт кирәк булган булыр иде!..— ди ул.

Украина һәм Татарстан карталары эленеп торган стена буенда зур өстәл. Аның өстендә күп санлы фоторәсемнәр. Ул фотолар Шәех Кәримовның данлы тормыш юлын чагылдыралар.

Вакытлар узу белән саргая төшкән фоталарның кайберләрендә без аны гражданнар сугышында итеп күрәбез. Рус, украин, татар, башкорт, чуваш, удмурт һәм мордва туганнары белән бергә ул ил бәхете, халык азатлыгы өчен барган изге көрәшнең уртасында кайный... Менә — Бөек Ватан сугышы елларында төшкән фоторәсемнәр, сугышчан орденнар һәм медальләр. Шунда ук — революция казанышларын яклап калуда һәм гражданнар сугышы чорында актив катнашкан өчен Бөек Октябрьның 50 еллык юбилее уңае белән бүләкләнгән Кызыл Байрак һәм Ленинград блокадасын өзү өчен барган сугышларда күрсәткән батырлыгы өчен бирелгән Кызыл Йолдыз орденнары... Революциянең тугрылыклы солдаты, бүгенге көндә персональ пенсионер Шәех Кәримов алган сугышчан бүләкләрне саный башласаң, алар дистәдән артып китә.

Өстәлдә Казаннан килгән газета-журналлар, көрәштәш дуслары язган хатлар ята. Аларда бүгенге һәм киләчәк тормышыбыз өчен гражданнар һәм Ватан сугышы кырларында үз-үзләрен аямыйча көрәшкән ил батырларының якты хыяллары тормышка ашуы гәүдәләнә.

**Сабырхан Асанов,**

казакъ шагыйре

# КАЗАН УТЛАРЫ

*Советлар Союзының барлык язучылары кебек, мин дә юлбашчыбызның гасырлык юбилеен иҗади хәзерлек белән каршыларга теләдем. Шул уңай белән Ленин эзләреннән Ульяновск, Казан, Куйбышев, Мәскәү, Ленинград һәм Лейпциг (ГДР) шәһәрләрендә булып, шактый күп материал җыйдым. Шуның нәтиҗәсе буларак, «Ленинга барганда» исемле шигырьләр җыентыгы төзелде. Китаптагы бер циклым «Казан утлары» дип атала. Ул Ильичның Казан чоры тормышын чагылдыруга багышланган.*

*«Казан утлары» журналы укучылары игътибарына шул циклдан берничә шигыремне тәкъдим итәм.*

## Актлар залында

Ил кайгыда.
Көн дә бүген
Каш-кабагын җыерган...
Актлар залында шаулап
Студентлар җыелган.
Чал галимнәр, профессорлар
Аптырап, шашып калган...
Кайберләренең йөрәге
Шактый ук ярсып алган.
«Нәрсә белән бетәр соң бу?!»
Ә көрәш кызды гына.
Бераз басты шул көрәшнең
Иң алгы сызыгына.
Кулында аның кепкасы,
Йомарланган шактый ул.
Үзе кыя бөркетедәй
Һава ярып атлый ул.
Төркем сискәнеп читенде —
Ак сөякләр төркеме.
Давылдан коты алынып,
Курәсең, ул өркеде.
Өркеде, трибун егеткә
Нәфрәтле караш ташлап.
Яшь бөркет кучә һөҗүмгә,
Ялкынлы сүзен башлап:
— «Шушымыни яшьлек яме?
Белем алу шушымы?
Бар хокукыңны тышаулап,
Җибәрәләр һушыңны.
Бавырда таш ята сыман,
Кайгыдан күкрәк чатный.
Җылау-сыкраудан ни файда?
Аннардан ирек артмый.
Алар төпчергә күп алмый
Төшендә күргәнне дә,
Алар хәтта гаеплиләр
Шаярып көлгәнне дә.
Йотардай булып текәлә
Сиңа жандарм күзләре...
Кайда гына карасаң да
Шымчы-шпик эзләре...
Хуш күрми һич күнелебез
Мондагы тәртипләрне.
Артык түзәр хәл калмады —
Долой бөтен чикләүне!»
Сходкада шулай егет
Давылланды, яшьнәде!
«Дөрес сөйли Ульянов!» — дип,
Актовый зал яшьләре
Аның һәрбер әйткән сүзен
Факел итеп күтәрде.
Тирән йокысыннан Ильич
Уятты бик күпләрне.
Мин үземне алар белән
Бергә сыман хис иттем.
Гуя мин яшь Ульяновның
Үз тавышын ишеттем.

## Комлев урамы, 15 нче йорт

Йөрәк жырдан ташып тибә,
Тибә чаптар ат сыман...
Казанның нәни бер өе
Гажәп кунакчыл, туган.
Бар йөрәгем белән тойдым
Анын дуслык жылысын...
Үзе кечкенә булса да,
Йөрдем анда көнозын.
Мена алдымда карт ана,
Көмешләнгән чәчләре...
Керфек очларыннан тама
Мөлдерәмә яшьләре.
Юк, яшь кенә баса алмый
Анын бәгырь ярасын...

Камауда интектерәләр
Анын сөйгән баласын.
Ул көн, кояш тотылгандай,
Карангы булган, салкын.
Киткән улкае ананын
Даулап хакыйкать хакын.
Киткән декабрь төнендә,
Курыкмыйча суыктан,
Төрмәгә, кырыс сөргенгә
Киткән ул шушы йорттан.
Син, йорт, нәни... ә шулай да,
Жаны кебек ананын,
Үзенә тартып торасын
Күнелен кин даланын.

## Казан—Кокушкино юлында

Кин асфальт юл бормаланып
Сузыла еракларга.
Яшь чагында юлбашчыбыз
Сөрелгән бу якларга.
Эш юклыктан йөрмим лә мин,
Башымда — изге уйлар...
Автобус көтеп тормадым,
Жәяү киттем юл буйлап.
Ленин күнледәй саф иртә.
Үрләр аша юл уза.

Карурманнар татарлардай
Мина дус кулы суза...
Бу жирләрне күрмәс идем,
Белмәс идем гомергә...
Шушы юлдан яшь Ульянов
Әйдәлгән шул сөргенгә.
Әйтерсен, ул һаман бара...
Куып житеп дәшәм күк...
Халкы өчен күпме газап
Чиккән Ильич яшьтән үк.

## Казан утлары

Теллэрдән күчә телләргә
Тукай, Жәлил жырлары.
Идел өстендә тирбәлә
Кичке Казан нурлары.
Идел буенда үземне
Бик әйбәт хис итәм мин.
Аз ут белән килгән идем,
Күп ут белән китәм мин.
Яр кырында зур-зур йортлар
Басып тора уйланып...

Аларнын тәрәзләренә
Йолдыз элгән Ульянов.
Шунадыр шул кич булса да
Көндәй якты урамнар.
Яшь Володя арабызда
Пәри кебек, туганнар.
Яна сәфәргә чакырып,
Гөрли Казан портлары...
Идел өстендә тирбәлә
Кичке Казан утлары.

МӘХМҮТ ХӨСӘЕН
тәржемәләре.

## Нияз Хәкимуллин



### АЛЬПИНИСТ ЯЗМАЛАРЫ



Безнең машиналар Алтай өлкәсендәге Катанда авылына килеп кергәндә кояшлы һәм эссе июнь көне кичкә авышкан иде инде. Без илнең төрле шәһәрләреннән — Свердловскидан, Ленинградтан, Мәскәүдән, Новосибирскидан — җыелган кешеләр. Ә мин Казаннан. Без бүген, Бийскидан чыгып, 550 километр юл үттек. Көн озын машинада дыңгырдап килү шактый йончыткан булса да, иптәшләрнең сер бирәселәре килми: барысы да шаярышкан булалар. Биш йөз илле километр түгел, биш километр үткән кебек тә булмады әле бу дип, чамадан арттырып җибәрүчеләр дә бар арада. Дөрес, алар барысы да юл йәреп күнегеп беткән кешеләр. Ләкин, ничек кенә булмасын, ярты мең чакрым сикәлтәле юл үтү үзенекен итми каламы соң? Башта шулай мактанышкан булсалар да, иптәшләрнең күбесе аннан-моннан гына тамак ялгап алдылар да, авыл мәктәбе бакчасындагы каеннар төбенә таралышып, үзләренең йокы капчыкларына кереп чуму ягын карадылар. Уен түгел бит: иртәгә иртүк торып, без бу авылдан җәяүләп авыр походка — Үзәк Алтайның кеше аягы бик сирәк баскан районына юл тотарга тиешбез...

Без торып походка әзерләнә башлаганда кояш яңа чыгып кына килә иде әле. Ә ерак походка әзерләнү бик җаваплы эш ул. Юлда андый-мондый хәл килеп чыкмасын өчен, барысын да бик җентекләп тикшерергә, һәр нәрсәне хаҗәте чыкканда ансат кына табып алырлык итеп үз урынына куярга кирәк. Кием-салымны, альпинизм кирәк-яракларын, азык-төлекне яхшылап капчыкларга тутыру, әйтергә ансат кына булса да, зур тәҗрибә сорый торган эш. Дөрес, безнең арада барысы да поход хәстәрләре белән таныш: кимендә ике-өч тапкыр мондый походларда булган кешеләр. Ләкин һәр походның үз мәшәкате бар аның. Ә завхозның эше аеруча күп. Ул атлар аркасына асып алып барылачак йөкләрне урнаштыру белән мәшгуль. Завхоз һәркайсы

25—30 килограммлы төенчекләрнең кайсында нәрсә төрелгәнлеген, ул төенчекләрнең кайсы нинди ат аркасына асылган булуын белеп торырга тиеш. Ялгышмас өчен ул аларның һәркайсын номерлап үз блокнатына язып бара. Завхозыбыз Сергей Георгиевич Успенскийга ул яктан һич тә тел тидерерлек түгел. Бу эштә инде күп еллардан бирле эшләп килүче, зур тәҗрибәле кеше ул. Үз гомерендә бик күп экспедиция хуҗалыклары белән җитәкчелек иткән. Памир, Тянь-шань тауларына менүче альпинистларны озаткан. Ә хәзер менә безне Алтай тауларына озатырга җыена. «Син аны җиде төн уртасында уятып, аптечка яки рация кайда дип сорасаң, секунд эчендә һич тә ялгышмыйча әйтә дә бирә»,— ди аның турында безнең экспедиция җитәкчесе Казакова Елена Алексеевна. Елена Алексеевна үзе дә тауларда бик күп йөргән, ул — атказанган спорт мастеры. Шактый олы яшьтә булса да, әле һаман яшьләрчә җитез, егәрле. Андый кешеләр белән теләсә нинди кыен юлга чыгарга була...



*Мәкаләнең авторы Н. Хәкимуллин.*

Ниһаять, барлык төенчекләр дә төйнәлеп бетте. Инде аларны ат аркаларына гына асасы калган иде. Ләкин бу эш шактый мәшәкатьле булып чыкты. Без, экспедиция членнары, биштәр асып йөрергә өйрәнгән булсак та, безнең кирәк-яракларны алып барырга тиешле атларның мондый хикмәт белән беренче генә мәртәбә очрашулары икән ләбаса. Алар төенчекләрне аркаларына астырырга һич кенә дә теләмиләр: тибенәләр, үз-үзләрен аямыйча сикерәләр. Хәтта тәҗрибәле кәрванчылар да җайларына төшә алмый байтак азапланды ул көнне. Бары тик берничә атны «бракка» чыгарып, алар урынына башкаларын алып килгәннән соң гына, ниһаять, өзерлек эшләре тәмамланды һәм ун алты кешедән, кырык биш аттан торган безнең кәрван юлга чыкты.

Безне алты кәрванчы озата бара. Алар барысы да Алтайны бик яхшы белә торган, заманында яшь Совет иленең дошманнары белән сугышып йөргән тәҗрибәле партизаннар.

Урман сукмагы тар булганлыктан, кәрван шактый озынга сузылып бара. Куе үлән баскан йомшак сукмак буйлап җай гына атлый торгач, кәрван киң һәм тиз агышлы Кураган елгасына килеп төртелде. Без шул елганы аркылы чыгарга тиеш. Күперфәлән юк, кичү өчен сайрак һәм таррак урынны эзләргә кирәк. Ике кәрванчы, безне калдырып торып, разведка ясап килгәннән соң, кәрван тагын кузгалып китте. Елга буйлап өскә таба бер-ике километр баргач, әлегә кәрванчылар сайлаган урында кичү башланды. Башта елганы «разведчиклар» үзләре кичте. Күбекләнеп актарылып аккан Кураганның аргы ягына чыккач, кул болгап безгә дә кичәргә мөмкин икәнлеген аңлаттылар. Сакланып кына кәрван да суга керде. Ярдан караганда әллә ни куркыныч булып тоелмаса да, эченә кергәч елга шактый хәвефле булып чыкты. Менә-менә агым син атланган атны этеп егар да агызып алып китәр төсле.

Күңел юкка гына шикләнмәгән икән: йөк аскан атларның берсе елганың яртысын узгач нәрсәгәдер сөртенде дә көчле агым аны шундук бөтереп алып, агызып китте. Без нишләргә дә белмичә аптырап калдык. Хәер, аптырамасаң да берни эшләрлек түгел: без үзебез дә су уртасында, үзебезнең атларның да шундый ук хәлгә төшүләре бик мөмкин. Ләкин безнең кәрванчылардан инде аргы якка чыккан ике Егор — Кураганны моңарчы да берничә мәртәбә кичкәннәре булган кешеләр — күп уйлап тормадылар, атның ага башлавын күрүгә икесе дә берьюлы суга сикерде һәм, тиз-тиз

йөзеп, агып бара торган атны куып та җиттеләр. Агым аларны да әләктереп алып бәтерә башлады. Хәзер инде ат кайсы да, Егорлар кайсы икәнлеген аерып та булмый башлады һәм мин, алар анда ни кылмак булалар икән соң дип, гаҗәпсенеп калган идем. Ләкин бер-ике минут үтүгә барысы да ачыкланды: алтайлылар ат өстендәге йөкләрне кисү белән мәшгуль булганнар икән. Төенчекләре агып китКәч, ат җиңеләеп калды һәм сикереп торды да аягы тимәгән җирдә йөзеп, тигән җирдә йөреп ярга чыкты. Шулай итеп, экспедициянең шактый азык-төлеге акса акты, әмма Егорлар атны коткарып калды...

Тауларда йөри белү — бик зур һөнәр. Иң әйбәт карталар, иң яхшы компаслар да кайчакта бер тәҗрибәле кеше янында берни тормый. Безнең озатучыбыз Андриан Тимофеевич Архипов Алтай якларын үзенең биш бармагы кебек белүче кеше иде. Инде җитмештән узса да, һәр эштә яшьләрдән калышмый торган уртача буйлы, таза гәүдәле ул карт тегенди-мондый гына озатучы түгел. Аның атасы да озатучы булган һәм заманында Алтайны өйрәнүче атаклы галим В. В. Сапожниковка юл күрсәтеп йөргән. Озын саргылт сакаллы, йомшак тавышлы, башына иске фетр эшләпә кигән ул карт безнең өчен бик тә кадерле кеше булып чыкты: кәрванны башлап ул алып барды һәм иң читен урыннарда да ни эшләргә, кайдан барырга икәнен ул искәртеп торды.

Ә юлда кыенлыклар бик күп очрады безгә. Моңарчы кеше аягы бөтенләй диярлек басмаган урман араларыннан, як-ягы биек кыялар белән уратып алынган тарлавыклардан мөмкин кадәр тизрәк һәм юл язмыйча үтәр өчен шактый зур тәҗрибә һәм акыл кирәк лабаса!..

Безне барыннан да бигрәк таң калдырганы кыялар арасындагы тарлавыклар булды. Нинди генә үләннәр һәм чәчәкләр үсми анда. Ә ул чәчәкләрнең исләре! Мин андый хуш исне бүтән беркайда да татыганым юк иде әле. Аның шунысы бик гаҗәп: синең як-ягыңда текә, ялангач һәм гомергә дә үлән үсми торган, башлары болытлардан ашкан кыя-таш бит! Һәм менә шул кыялар арасындагы тарлавыкларда искиткеч матур чәчәкләр, үләннәр, агачлар. Ә һавасының сафлыгын әйтеп тә торасы юк инде.

Ләкин Алтайдагы барлык тарлавыклар да шулай мул үсемлекле һәм шулай матур түгел. Мәңге кояш төшми һәм берниндн үсемлек тә үсми торган шәп-шәрә тарлавыклар да бар анда. Андый тарлавыкларны үткәндә күңелләргә шом төшеп, тәннәр чымырдап куя...

Әнә шундый тарлавыкларның берсен үткәннән ары безнең кәрван тауга күтәрелде дә Каир һәм Бортулдак дип аталган тарлавыклар арасындагы коточкыч тирән упкын буена килеп терәлде. Аргут упкыны дип аталган атаклы упкын икән ул. Төбенә карасаң — башлар әйләнә. Шулай булмый хәле дә юк: тирәнлеге ике километр чамасы аның, ә төбендә тирә-якны шаулатып Аргут елгасы агып ята. Мондый урыннан кечү турында уйларга да ярамый иде, әлбәттә. Һәм безнең кәрван Аргут упкыны кырые буйлап Иедыгем үзәнлегенә таба юл тотты...

Иедыгем — агачларга һәм үләннәргә бай шактый матур үзәнлек. Ә бара торгач безнең каршыдагы урманнар бик нык куерып тоташ стенага әйләнде. Аркаларындагы йөкләре агачларга кысылып, атлар тукталып кала башлады. Кәрванны туктатып, аларны юллап алырга туры килгәнлектән, алга бару бик нык акрынайды. Агачлар артык куе булып, кояш төшмәгәнлектән болай да тынчу, юеш урман һавасы без сазлыклы урыннардан бара башлагач тагын да ныграк тынчулана төште...

Шулай шактый зур мәшәкатьләр белән бара торгач, кәрван мин моңарчы беркайда да күрмәгән шомлы һәм гаҗәеп урманга килеп керде. Хикмәт шунда, ул урмандагы агачлар барысы да кап-кара баганалардан гыйбарәт. Чын баганалардан аермалары бары тик шунда гына, аларның очларында ботаклар бар. Ләкин аларның бер бөртек тә ылыслары юк. Алар да кап-кара. Бу — урман янгыны булган җир. Ут ул агачларның сагызлы кабыкларын һәм ылысларын гына ялап үткән, ә кәүсәләре шул килеш утырып калган. Бу — үле урман, күңелдә кызгану хисе уята торган шомлы урман. Шуңа күрә ул урыннарны тизрәк үтеп китәсе килә. Уннарча чакрымга сузылган шул үле урман эченнән баргач, без мүкләр һәм вак-төяк агачлар гына үсеп утырган сазлы болынлыкка килеп кердек. Ярый әле бу сазлык булган, югыйсә янгын тагын да еракарак китәсе икән. Сазлыктан бару шулай ук кыен булса да, әнә шул уй күңелне күтәреп җибәрә...



*Иптәшләр алдагы маршрутны ачыклый.*

Аннары тагын урманга килеп керәбез. Монысы алда очраганнарыннан да куерак. Монда инде кысылган атларны чыгарып баргандагы кебек кенә түгел, монда юлның һәр метрын диярлек агачларны балта һәм пычкы белән кисеп салып барырга туры килә. Шунлыктан әллә ни үрчетеп булмый: көненә дүрт-биш чакрым җир үтсәң дә шөкер итәсең. Ахырдан без, атларны калдырып, җәяүләп кенә китәргә булдык. Атлар аркасындагы йөкләрне биштәр итеп үз җилкәләребезгә астык та юлыбызны дәвам иттек. Хәер, бераз сабыр итсәк тә ярыйсы булган икән булуын: атларны калдырганнан соң күп тә бармадык — ачыклык башланды. Ләкин кеше әүлия түгел шул, алда ни буласын белеп тора алмый.

Ниһаять, без Иедыгем тарлавыгыннан ике километр ярым биеклектә урнашкан тау болынлыкларын үткәч, барлык үсемлеге бары тик мүктән генә гыйбарәт булган тау тундрасы башланды. Тагын бераз күтәрелгәч исә, мүкләр дә бетеп, без Мең су[1] бозлыгына килеп җиттек. Мең су — Алтай тауларындагы иң зур бозлык. Аның буе унбер чакрымга сузылган. Көн инде кичегеп бара иде, шунлыктан без бозда ятканчы җирдә ятыйк әле дип, ул көнне юлыбызны бүтән дәвам итмәдек, палаткаларыбызны Мең су буена кордык та кунарга тукталдык.

Ә иртән Мең су бозлыгы буйлап өскә күтәрелә башладык. Мин алда искә алып киткән галим В. В. Сапожников заманында бу бозлыкны боз диңгезе дип атавы белән бик хаклы булган икән. Ул бозлыкның өсте, чыннан да, катып калган диңгез дулкыннарын хәтерләтеп тора. Юлыбызда зур-зур бозлык тегермәннәре бик еш очрый. Алары — башта боз өстеннән агып барып, аннары кинәт боз ярыкларына бик хәтәр шаулап агып торучы, тегермән тавышларын хәтерләтә торган бозлык елгалары. Ул елгалар шуңа алай бик нык дөберди, чөнки тиз агучы су үзе белән зур-зур ташларны иртеп алып төшә. Ә ул ташлар «таш өстәлләр» җимерелүдән барлыкка килә. «Өстәл» дигәне менә болай: бозлык эрегәндә кайчандыр тау башларыннан тәгәрәп төшкән ташлар яткан урыннары акрынрак эри һәм шуның нәтиҗәсендә таш астындагы боз калкып, өстәлне хәтерләтеп тора. Ләкин ул өстәлләр дә мәңгелек түгел, вакытлары җиткәч, алар да эреп җимерелеп төшәләр дә су белән агып китеп әлеге «тегермәннәрне» әйләндерәләр.

---

[1] Бик күп елгалар шул бозлыктан агып төшкәнгә шулай аталган булса кирәк.— Н. Х.

Мең су бозлыгы ничектер ике басмалы баскычны хәтерләтә. Аның беренче басмасы, ягъни әлеге боз диңгезенә охшаган урыннары киң һәм сөзәгрәк, ә икенче басмасы тар, ләкин бик текә. Әгәр ул урында боз булмыйча су булган булса, анда бик зур һәм дөньяда тиңе булмаган биек шарлавык булган булыр иде. (Икенче баскычның биеклеге 300 метр.) Хәер, ул хәзер дә шарлавык инде, әмма аннан су түгел, бәлки боз агып тора. Аерма бары тик шунда гына.

Беренче баскычтан без чагыштырмача җиңел күтәрелдек. Инде менә икенчесенә менә башларга тиешбез. Ул бозлыкка менәр алдыннан мин көндәлегемә менә шушы юлларны язып куйганмын: «Мең су боз шарлавыгы. Шарлавыкта кеше егылып төшеп китәрдәй ярыклар бик күп. Борынгыдан калган җимерек патша сарайларын хәтерләтеп торган төрле биеклектәге боз баганалары да күп, аларның да безнең өстебезгә авып төшүләре бик ихтимал. Шарлавык шактый хәрәкәтчән булырга тиеш — әледән-әле боз ишелгән тавышлар ишетелеп тора...»

Ә бозлыкның башына менгәч көндәлеккә менә болай дип язганмын: «Теге 300 метрлы «басмадан» күтәрелгәндә боз ярыкларына таеп төшүчеләребез дә булды, ләкин, бер-беребезне бауга бәйләп барганлыктан, беркем дә алай зур бәхетсезлеккә юлыкмады. Төбе күренми торган боз ярыклары өстендәге кар күперләрен үткәндә күз аллары караңгыланып китә иде. Әмма әлеге дә баягы шул бау белән бер-беребезне бәйләү монда да безгә бик зур ярдәм итте һәм рухи көч бирде. Бүген без бөтенләй ял итмичә эшләдек. Әйе, эшләдек, чөнки бу шарлавыкның һәр метрын боз чабып, баскыч ясап үтәргә туры килде. Кайткач иптәшләргә сөйләсәң ышанмаслар да әле: ун сәгатькә нибары өч йөз метр гына ара үттегезмени дип, көләргә тотынырлар. Ә без менә монда ул араны бик тиз, бер көн эчендә үттек дип сөенешеп утырабыз. Сөенерсең, абзыкаем. Андый-мондый көтелмәгән берәр нәрсә килеп чыгып, ярты юлда туктап калсаң да берни эшли алмас идек бит!..»

Мең су шарлавыгының өстенә менгәч шактый еракка сузылган тигезлек — боз кырлары башланды. Ә алардан арырак тагын таулар, боз белән капланган текә таулар китә. Әлеге тигез боз кырында палаткалар корып төн үткәргәннән соң, иртүк торып, тагын юлыбызны дәвам итәбез. Төшкә таба кояш яктысында күзләрне камаштырып ялтыраган боз кырын үтеп, тагын тауга күтәрелә башлыйбыз. Хәзер инде, аяк астында тайгак боз түгел, бәлки ап-ак кар шыгырдый. Бу — Алтай тауларының иң биек ноктасы булган Белуха тавы итәге. Без шул Белуханың түбәсенә менәргә тиешбез. Тездән кар ерып барсак та, бөтенебезнең дә кәефе яхшы. Көләбез, шаян сүзләр сөйләшеп киләбез. Ялга тукталган вакытларда аска карап табигатьнең шушылай киң, иркен һәм матур булуына сокланып утырабыз, мәңгелек кар фонында фотога төшәбез. Һава саф, салкынча, сулап туймалы түгел. Ә бит хәзер, менә шушы минутларда, Алтай далаларында түзеп булмаслык дәрәҗәдә эссе һәм бөркүдер.

Ләкин таулардагы һава торышы иркә кызларның холкы кебек бик тиз үзгәрүчән була икән. Миллиардларча бәләкәй лампалар сыман булып кояшта ялтырап яткан кар бөртекләре кинәт кенә «сүнеп» китте дә шул арада каяндыр соры болытлар килеп чыгып, бөтен дөньяны каплап алды. Аннары ишелеп кар яварга тотынды. Без хәзер кар болыты эчендә. Бер-беребезне күздән югалтмас өчен, тотынышып дип әйтерлек барырга туры килә. Карява башлауга бер-ике минут үтүгә яшен яшьни башлады. Ялт та йолт, ялт та йолт килеп, яшен шарлары безнең тирәдән туктаусыз үтеп тора. Алар шулкадәр якын безгә — кулыңны сузсаң тотып алып булыр төсле. Без хәзер бик куркыныч хәлдә. Тау яшене уен эш түгел, сугып үтерүе дә бик мөмкин. Шуңа күрә барыбыз да биштәрләребезне салып, аларны тиз генә карга күмеп куябыз: биштәрләрдә калай консерва банкалары бар, ә яшен андый калайларга «сугып» уйнарга яратучан ярата.

Хәзер инде алга бару һич тә мөмкин түгел, кар көчәйгәннән көчәя бара, дөньяны тоташ караңгылык чорный һәм без, палаткалар корып, тукталырга мәҗбүр булабыз. Дүрт кешелек палаткага бишәү урнашабыз. Башкача һич тә сыеп булмагач, башлыаяклы ятарга туры килә. Хәер, монысына үзебез гаепле, чөнки, күтәреп барырга җиңелрәк булсын дип, бүтән палаткаларны тауга алмаган идек. Тыгыз булса да түзәргә туры килә, ә тышта җил котыра, буран дулый. Кар тузаннары хәтта палатка тукымасы аркылы да үтеп керә. Палатка бөтенләй үк җимерелеп төшмәсен өчен, аның түбәсенә өелгән карны әледән-әлә кагып торырга туры килә...

Төн үтеп таң аткач та буран басылмады. Киресенчә, тагын да ныграк дулый башлады. Шуңа күрә көнне без әлеге кысан палаткада үткәрдек. Һич кичектергесез очракларда гына чыгып керергә кирәк булганда да ишегеп кар баскан палатканың авызын кул белән көрәп азапланырга туры килде...

Без монда унберенче августта туктаган идек. Бүген унөченче август. Палатканы кар инде бөтенләй күмеп үк киткән, шунлыктан һава тынчу, сулыш алуы читен. Җитмәсә иркенләп сузылып ятарга да мөмкинлек юк, ян башлары авыртып бетте инде.

— Кар явуы басыла төште бугай,— ди башын палатка ишегенә таба куеп яткан Арсен.

Куанышып, барыбыз да палаткадан чыгабыз. Буран бөтенләй үк тукталмаган булса да, томан бераз тарала төшкән, көн ачылыбрак киткән кебек. Юлыбызны дәвам итмәкче булып, палатканы җыябыз, биштәрләребезне аркаларыбызга асабыз. Ләкин кузгалып китүебезгә ярты сәгать үтми, тагын кар бураны күтәрелә. Җил дә кинәт көчәеп китә. Салкын битләрне өтеп-өтеп ала.



*Тиздән — Белуха түбәсе.*

Ә без акрын гына баруыбызны дәвам итәбез. Аннары аякларыбыз туңа башлый һәм без, тәмам өшеп калудан шикләнеп, тукталабыз да тагын палатка корып, аның «өлысына» сыенабыз.

— Минем аякларым берни дә тоймый,— дип сукрана Анект.

— Минекеләр дә шулайрак шул,— ди Володя да, аңа кушылып.

— Соң ни пычагыма болай бөкшәешеп утырасыз алай булгач? — ди аларга Арсен, шактый ачулы итеп. Тизрәк ботинкаларыгызны салыгыз да спирт белән аякларыгызны угыгыз!

Аякларын салсалар, тегеләрнең икесенең дә бармаклары өшегән икән. Бераз угач, Володяның өшүе кайтып, бармаклары кызарып китте, ә Анектныкылар һаман апак килеш торалар иде әле. Хәзер Елена Алексеевна да аңа ярдәм итә башлады. Ул гел шулай, үз әниебез шикелле, һәркайсыбызга якын, үз итеп карый. Ләкин ул да безнең белән бергә килгән, арыган кеше бит.

— Ничек син оялмыйча олы кешегә удырып торасың, үзең ышкырга ярамыймыни? — дип мин Анектны ачуланып алдым.

Анект кинәт кенә әнөнә килгәндәй уңайсызланып куйды. Аннары аягын үзе ышкырга тотынды. Күренеп тора, ул бик нык арыган иде. Шуңа күрә аңа катырак бәрелүем өчен минем үземә дә ничектер уңайсыз булып китте.

Без шулай һәркайсыбыз үз эше белән мәшгуль булып торган арада кинәт күрше палаткадан:

— Малайлар, тизрәк ярдәм итә күрегез! — дигән хәвефле тавыш ишетелде. Палаткабыздан башларыбызны тыгып карасак, исебез китте: таудан ишелеп төшкән кар күршеләребезнең палаткасын бөтенләй күмеп киткән иде. Тиз генә чыгып, аларны казып алырга туры килде. Ә җилнең һәм буранның һич тә туктар чамасы күренми иде әле. Без барыбыз да баштанаяк карга буялып беткәнбез, үзебез туңабыз — төшләребез төшкә тими. Сакал-мыекларыбызга, керфекләребезгә шулай ук кар бозланып каткан. Август уртасында без нәкъ кыш бабай шикелле булып йөрибез. Үпкәләр урын юк, чөнки монда без үз теләгебез белән чыккан кешеләр...

Унбишенче август төнендә дә без һаман шул урында палаткаларыбызда ята идек әле. Кар бөтенләй басып китә башлагач, төнге сәгать бердә торып палатка тирәсен бераз рәткә китереп кергән идек. Ә буранның һаман туктар исәбе юк иде әле. Ләкин тауда һава тиз үзгәрүчән шул.

Иртән безне йокыдан Елена Алексеевнаның:

— Ура! Торыгыз, егетләр, безнең урамга да бәйрәм килгән! — дип кычкырган шатлыклы тавышы уятты.

Без шатланышып палаткадан чыкканда буран чыннан да тынып калган һәм көн матур, кояшлы иде. Күктә болытның әсәре дә юк, хәтта бездән шактый еракта булган Монголия җирләренә кадәр аермачык булып күренә иде. Бозланып каткан карларыннан чистартып, палатканы төрәбез, биштәрләребезне аркаларыбызга асабыз да тагын тауга күтәрелүебезне дәвам итәбез. Ә күрше палаткадагылар, шуннан ары бара алмыйча, кире төшеп китәләр, чөнки аларның юлга алган ризыклары саеккан иде. (Саекса да гаеп түгел, чөнки без биш көн кар астында ятсак та, ашамыйча гына ятмадык бит.)

Күтәрелү хәзер тагын да кыенлаша төште: атнага якын ишелеп яуган кар тирән һәм бик йомшак, аяклар бот тиңентен бата. Ә кар астында тайгак боз. Шуңлыктан бик сакланып, һәр адымны иплән кенә басып барырга туры килә. Акрынлап булса да, штурмны дәвам итәбез. Кинәт иксез-чиксез кар диңгезе өстендә ниндидер эзләр күренә башлый. Әллә бездән алда нинди дә булса башка партия белән чыккан альпинистлар үтте микән дип, шунда ашыгабыз. Юк, альпинистлар эзе түгел, Алтай хуҗасы — аю эзе икән ул. Безгә генә түгел, аюга да тауга менү шактый кыенга туры килә икән: әнә ул, аяклары таеп киткәнлектән, текәрәк урыннарда шуып-шуып кире төшкән, боздагы ярыкларны әйләнеп үткән.

Текә кыя буендагы тигезрәк урынга ялга туктыйбыз. Гел кар ерып килгәнлектән, ботинкаларыбыз, чалбарларыбыз һәм бияләйләребез манма су булган. Аркаларыбыздан пар чыгып тора. Каршыбыздагы текә кыяга күтәрелү җиңел булмаячагын алдан ук сизеп торабыз. Ахырдан ике төркемгә бүленеп күтәрелеп карарга кирәк дигән нәтиҗәгә киләбез. Анект, Володя һәм мин бер бауга бәйләнеп, ә Арсен белән Елена Алексеевна икенче бауга бәйләнеп китәләр. Безнең бәйләм алдан кузгала. Кар шундый ярмалы: баскан саен ишелә дә төшә, ишелә дә төшә. Бер адым алга атлап, ике адым артка шуа башлагач, карны көрәп, бозга баскычлар ясап менәргә туры килә. Һәркем мөмкин кадәр азрак сөйләшергә тырыша: көч кимрәк сарыф ителсен. Бик кирәк булган очракларда бер ике сүз белән генә үзара аңлашабыз.

Менгән саен кыя текәләнә бара. Шулай да тауның түбәсе күренә башлады инде. Тау түбәсендә җил шактый көчле булса кирәк — карны себергәне күренеп тора. Әгәр шушыннан берәребезнең аягы таеп китсә — харап. Ул чакта безнең бөтен хезмәтебез юкка чыгачак. Шуңа күрә һәркем аеруча сак булырга тырыша...

Ниһаять, бөтен авырлыклар артта калды. Без Алтай тауларының иң биек ноктасы булган Белуха түбәсендә. Бездән өстә бары тик зәп-зәңгәр күк йөзе дә, шул күктә акрын гына йөзеп баручы ике-өч болыт кисәге генә. Хәзер без иң тантаналы минутлар кичерәбез: үзебезгә кадәр бу тауга менгән кешеләр калдырган билгене эзлибез. Озак та үтми, Володя куанып кычкырып җибәрә:

— Килегез, таптым! Менә ул тимер банка!

Ашыгып һәм дулкынланып банканы ачабыз. Банка эченнән саргайган һәм бик пөхтәләп төрелгән кәгазь килеп чыга. Аны сүтеп укыганнан соң бу тауга менгән кешеләрнең исемнәрен һәм аларның кайчан монда булганлыкларын беләбез. Кәгазь утыз җиденче елда язылган. Аңа дүрт кеше исем-фамилияләрен язып куйганнар. Димәк, бу ноктага шул елдан бирле кеше аягы басмаган. Үз чиратыбызда, без дә бу тауга кайчан менүебезне һәм исем-фамилияләребезне язып, шул ук банка эченә тыгып куябыз. Безнең бу язуыбыз горур Белуха түбәсендә тагын ничә ел сакланыр икән? Бездән соң монда тагын кемнәр күтәрелер икән? Без аларны белмибез. Ләкин шунысы бәхәссез: кемнәр генә менсә дә, алар да нәкъ менә безнең кебек куанышачаклар һәм онытылмас тантаналы минутлар кичерәчәкләр.

Бер тапкыр да коры җиргә басмыйча, гел кар һәм боз арасында көн күреп йөрүебезгә инде ун көн булды. Андый-мондый хәвеф-хәтәр булмаса да, шактый йончылдык инде без. Ләкин әле юлның иң кыены алда: таудан төшү аңа күтәрелүгә

карaганда күп тапкыр кыенрак бит. Без менгән юлдан түгел, бәлки тауның аргы сыртыннан төшәргә тиешбез. Маршрутыбыз шундый, ә алдан билгеләнгән маршрутны альпинистлар беркайчан да бозарга тиеш түгел.

Төшәр өчен уңайрак урын эзли башлыйбыз. Үзара уйлашканнан соң башта тауның боз ярыгына төшеп кыяга аяк басарга, аннары шул бер километр чамасындагы текә кыя буйлап түбән төшәргә булдык.

— Таптым! — диде Арсен, боз ярыгының бездән арырак бер җиренә туктап.— Шушыннан да яхшырак урын булмас шикелле.

Тиз-тиз генә аның янына киләбез. Бу урында ярык чыннан да киң һәм тирән — утыз метр чамасы. Ә төбендә шәрә кыя ташлары күренеп тора. Моннан төшәргә мөмкин, тик бер шарт белән: бауга бәйләнеп кенә. Ләкин менә бауны кая бәйләргә соң? Боз кисkeчне карга кагып бауның башын шуңа бәйләп калдырыр идек тә — кар бик тирән һәм бик ярмалы, боз кискечне тотып торырлык түгел. Безнең бары тик бер генә чарабыз кала: кайсыбызга булса да монда өстә калып, иптәшләр ярыкка төшкәндә бауны тотып торырга туры киләчәк. Беренче кешене төшерү ансат булачак, чөнки өстә калган дүртебез бауны бик ышанычлы тотачакбыз. Икенче, өченче булып төшүчеләргә дә артык мәшәкатьле булмаячак. Ә менә дүртенче кеше төшкәндә исә өстә беребез генә калачак һәм аңа бауны тотып тору кыенга туры киләчәк. Ә иң четерекле мәсьәлә шул: соңгы кешебезнең бавын кем тотып торыр?..



*Төшү менүдән дә кыенрак.*

Тәвәккәлләп иң алдан мин төшеп китәм. Ярыкның стеналары шоп-шома, бер дә тотынырлык урыны юк. Тегеләр өстән бауны акрынлап җибәрә торалар, мин һаман төшә барам. Ниһаять, минем аяк кыя ташына тия һәм өстәгеләргә булды дип кычкырам. Ә кыя шундый текә — карасаң башлар әйләнерлек. Шуңа күрә мин аска карамаска тырышам. Һәм иплән кенә кыяга ыргак кагып, үземне шуңа бау белән бәйләп куям да минем арттан төшеп килүче иптәшне көтә башлыйм. Әнә аның зәңгәр штурмовка кигән аяклары, аркасындагы биштәре һәм гәүдәсе һаман саен миңа якынлаша бара. Ләкин үзен танып булмый әле — йөзе күренми... Әһә, таныдым, Анект икән. Ниһаять, ул да минем янга килеп төшә. Хәзер без икәү инде. Күңел күтәрелеп китә һәм мин аңа үзен бәйләп куяр өчен кыяга ыргак кагарга булышам. Аннары өченче кешенең төшеп килүе күренә башлый. Ләкин ярты юлга җиткәч, ул нигәдер тукталып кала.

— Кем ул, ник туктадың анда? — дип сорыйм мин, борчылып.

— Бу мин идем дә, ләкин страховка бавы нәрсәгәдер эләкте әле монда,— дип җавап бирә хатын-кыз тавышы. Димәк, Елена Алексеевна икән.

Без нишләргә дә белми торган арада Елена Алексеевна үзе асылган бауга тотынып өскә үрмәли башлый. Бер-ике метр шулай күтәрелгәч, ярыкка кысылган җиреннән страховка бавын ычкындыра да, өстәгеләргә тагын үзен төшерә башларга куша. Без, аның чагыштырмача ансат котылуына куанышып, җиңел сулап куябыз. Дүртенче булып Володя төшә.

Хәзер Арсен өстә ялгызы гына калды. Ул ничек төшәр икән? Барыбыз да дулкынланабыз.

— Ашыкмагыз,— ди Елена Алексеевна,— хәзер барысын да аңларсыз. Ул запас бауның очын өстән салынып торган бауның башына бәйли дә Арсенга аларны тартып

алырга куша. Шулай итеп, аның кулында хәзер алтмыш метрлы бау. Без хәзер нишләр икән инде дип торганда, ул өстә сөңге сыман булып калкып торган зур гына боз кыясы башына бавын ыргыта да бау шул кыяга эленеп кала. Хәзер эшнең асылы безгә дә аңлашыла башлый: ул кыяга кидерелгән бауның бер ягына тотыначак, ә без, икенче ягыннан тотып, бауны акрын-акрын җибәрә торачакбыз. Ягъни без аны астан тотып төшерергә тиеш булабыз? Шунысы гаҗәп, аны төшерү без уйлаганнан күп мәртәбә ышанычлырак та, ансатрак та булып чыга. Бауны чишеп, өстәге боз кыясыннан тартып алганнан соң, сөяп куйган кебек текә кыя стенасы буйлап ничек төшү турында киңәшләшеп алабыз да эшкә керешәбез. Юк, кыя никадәр генә текә булмасын, ул безне куркытмый инде. Чөнки монда, бердән, бозга тотынгандагы кебек, куллар туңмый, икенчедән, кыяга ыргак кагып, бауга бәйләнеп төшәргә була. Шуның өстенә кыяда басып торыр өчен ярык һәм чыгып торган «кәрнизләр» дә байтак күренә. Шулай да бу эш җиңел түгел. Бик сакланып эш итәргә һәм каушамаска кирәк...

Ни тырышсак та, ул көнне кыядан төшеп җитә алмадык. Кунарга туры киләчәк. Ләкин ничек кунарга соң! Палатка кору турында уйларга да ярамый — аны корырлык тигез урын юк. Инде тәмам күз бәйләнеп барганда кыяның зуррак булып чыгып торган бер җирендә тукталдык та, шунда ыргаклар кагып, бау белән бәйләнеп, кыя стенасына сөялеп кенә йокларга мәҗбүр булдык.

Без уянганда таң сызылып кына килә иде әле. Соңгы ризыгыбызны — бер банка шпрот консервасын — бишкә бүлеп капкалап алдык та тагын төшә башладык. Кыя итәге якынайган саен күңелләребез күтәрелә барды һәм, ниһаять, без аякларыбызда нык басып торырлык хәвефсез җиргә төшеп җиттек. Тукталып тормастан, кыя итәгендәге бозлыкны үтеп, яшел мүкләр белән капланган тау болынлыгына бардык та, биштәрләребезне салып ташлап, башта куанышып бер-беребезне җиңү белән котладык, аннары бераз ял итәргә утырдык.

**Светлана Червонная,**
сәнгать фәннәре кандидаты

# СӘНГАТЬЧӘ НӘФИСЛЕК ӨЧЕН

Быел яз Казанда Татарстан театр рәссамнарының чираттагы күргәзмәсе ачылды. Башта ул театраль-декорация сәнгатендә милли татар драматургиясе образларын яктыртуга багышланган мөстәкыйль экспозиция итеп эшләнгән иде. Соңыннан В. И. Ленинның тууына 100 ел һәм Татарстан АССРның 50 еллыгы уңае белән ачылган республика юбилей күргәзмәсенең аерым бер бүлеге булып китте. Театр рәссамнарының мондый күргәзмәләре, яхшы традициягә әверелеп, менә инде 20 ел буена даими күрсәтелеп килләләр.

Әлеге күргәзмәнең үзенчәлекләре нәрсәдә соң?

Беренчедән, театр рәссамнарының иҗатын тулы итеп, йомгаклап күрсәтүдә. Тегә яки бу рәссамның очраклы сайланган бер-ике эше генә түгел, ә соңгы еллардагы барлык әһәмиятле хезмәтләре куелу аның иҗатын күпкырлы һәм тулы итеп күзалларга, иҗади үзенчәлекләрен, эзләнүләрен тоярга мөмкинлек бирә.

Икенчедән, театраль-декорация сәнгатенең милли татар драматургиясенә мөнәсәбәтен басым ясап, ассызыклап күрсәтүдә. Дөрес, республика юбилей күргәзмәсенең аерым бер бүлегенә әйләндерелгәч, бу экспозициягә классик рус, совет һәм чит ил драматургиясе һәм операсына ясалган декорация эскизлары да өстәлде. Әмма күргәзмәнең әүвәлге тематик планы бозылмады: татар драматургиясе өстенлек итеп калды. Күргәзмә шунысы белән кызыклы да иде. Бер үк популяр спектакльгә төрле рәссамнар ясаган декорацияләрне күрү театраль-декорация сәнгатенең күп төрле алымнары һәм мөмкинлекләре белән танышырга ярдәм итте. Мәсәлән, Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе Ә. Тумашев, Э. Гельмс, П. Сперанский декорацияләре аша гаҗәеп төрле интерпретацияләрдә күз алдына килә; Н. Исәнбәтнең «Муллакур Вахитов» драмасындагы мәгълүм күренеш — юлдагы броненосец Э. Гельмс сурәтләвендә бер төрле, В. Никитин сурәтләвендә икенче төрле эмоциональ яңгыраш таба. Иң мөһиме шунда, хәзерге татар театраль-декорация сәнгатенең милли үзенчәлекләре спектакльнең әдәби-драматургик яки музыкаль җирлеге, режиссурасы, актерларның башкару осталыгы белән бер бөтен бәйләнештә формалашып үсә. Рәссамнарның татар драматургиясе әсәрләренә шулай игътибар итүләре милли тойгылар байлыгын тулырак ачарга мөмкинлек бирә, рәссамга халык тормышына тирәнрәк үтеп керергә, аның социалистик идеалын ачыграк күрергә ярдәм итә.

Казан сәхнәләре ветераны, өлкән рәссам П. Т. Сперанский гомеренең соңгы көннәренә кадәр татар театры өчен эшләп килде. Күргәзмәдә аның Н. Җиһановның «Качкын», «Алтынчәч», «Җәлил» операларына, Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясенә, Р. Гобәйдуллинның «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» балетына

эшләнгән декорация эскизлары куелган иде. П. Сперанский хезмәтләре М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры тарихында гына якты сәхифә булып калмады. Хәзер инде күпләр хәтерләмиләрдер дә, Сперанский безнең гасыр башында оешкан беренче татар профессиональ театры — «Сәйяр»ның тәүге художнигы иде. Ул революциягә кадәрле үк хәзер инде классикага әверелгән пьесаларга — Г. Камалның «Беренче театр», «Банкрот» пьесаларына декорацияләр ясады. Татарстан АССРда социалистик культура төзелешенең беренче елларыннан Сперанский Үрнәк татар театрында (1920—1922) эшләде, аннары унҗиде ел буе (1922—1939) Татар дәүләт академия театрының баш художнигы булды. Ул анда дистәләрчә спектакльләрне җиһазлады. Сперанский татар милләте тарихын, халыкның тормыш-көнкүрешен, сәнгатен искиткеч яхшы белә һәм аларны бөтен матурлыгы белән сәхнәдә тудырырга омтыла иде. Архитектураны яхшы белгәнлектән, ул сәхнә декорацияләрендәге архитектура стильләрен гаҗәеп тирән тоя, эскизлар язу белән генә чикләнми, үз декорацияләрен дә сәхнәдә кора иде.

Әйе, П. Т. Сперанский үзенең озын гомерендә бик күп эшләде. Рәссамның үлеменнән соң алты ел үткәч, күргәзмәгә куелган эскизларына карыйсың да, ирексездән: шушы берничә опера һәм балетка эшләгән декорацияләре белән генә дә ул Татарстанның театраль-декорация сәнгатендә якты эз калдырып, тарихка зур оста булып кереп калыр иде, дип уйлыйсың.

Н. Җиһановның «Алтынчәч»енә ясаган декорациясендә Сперанский операның фольклор һәм тарихи байлыгын гаҗәп оста итеп тасвирлап биргән. Бигрәк тә финал уңышлы. Кояш белән өретелгән якты, алтын шәһәр образының гүзәл күренеше хорның «Алтын кояш нурларында, ямьле Идел буйларында» дигән тантаналы, көчле яңгырашы белән гаять тәңгәл килә. Рәссам либреттодагы: «Еракта Казан крепосте күренә»,— дигән кыска гына аңлатмага искиткеч тирән эчтәлек салган. Ул, шәһәр стенасын һәм манараларны якынайтып, аларны фәнни төгәллек белән башкарган, иске Казан крепостена җан өргән. 16 гасырда «Казан ханлыгы турында әкият»не язган рус авторы сокланып:

**Бөек шәһәр стеналарының**
**Искиткеч гүзәллеген күрде ул.**
**. . . . . . . . . . . . . . . .**
**Әй Казан көчле крепость шәһәре...**
**Имән агачыннан коелган,— дигән.**

Рәссам әнә шул «искиткеч гүзәллекне» сурәтли алган, крепость стеналарын, сак манараларын тигез итеп туплап биргән; урта гасырның шулкадәр матур һәм шәфкатьсез шәһәре өстендә ул һич нәрсә белән чагыштырмаслык кызыл күк йөзе балкыткан.

Сперанскийның «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» спектакленә ясаган декорация эскизлары да зур уңыш. Тукай әсәрләрен иллюстрацияләгән бер генә рәссам да әле Кабан күле янындагы күренешне шулай якты һәм матур итеп сурәтли алмаган иде. Яки печән базары күренешен алыйк. Кибетләре, рәт-рәт тезелеп киткән сату өстәлләре, чуар вывескалары белән сурәтләп, Сперанский Тукайның: «Иртә белән кайнамакта бу базар»,— дигән шаян юлларын җанландырып күз алдына бастыра. Сперанский үз эшендә театр декорацияләренең үзенчәлеген бер генә минутка да онытмый, аларның төрле төсләр яктылыгындагы матурлыгын, күләмлелеген нечкә тоя, сәхнәнең мөмкинлекләреннән тулы файдалана. Хәтта эскизларында ук ул аларның театр дөньясына караганлыкларын аерым бер зәвык белән күрсәтә белә: шәһәр пейзажын бай, кызыл яки яшел пәрдә белән каймалап ала, шулай итеп рәсемнәренең сәхнә өчен иҗатланганлыгын билгели, композициягә төгәллек бирә, ә бөтен образга бары тик сәхнәдә генә мөмкин була торган үзгәрешләрнең матурлыгын сала.

Узган ел 30 еллыгын билгеләп үткән Татар опера һәм балет театры сәхнәсендәге рәсем сәнгатенең П. Сперанский һәм М. Абдуллин нигез салган яхшы традицияләрен театрның хәзерге баш художнигы Әнвәр Нагаев уңышлы дәвам итә. Күргәзмәгә аның Н. Җиһановның «Илдар» операсына эшләгән декорация эскизлары куелган иде. Рәссам бу эскизларда спектакльнең музыкасы һәм драматургиясенә хас героик һәм драматик башлангычны эзлекле рәвештә үстерә бара. Үз композицияләрендә ул сугыш китергән афәтләрне, авышкан телеграф баганалары белән янып яткан җирне (I һәм IV картиналар), җир йөзенә иңгән шомлы салкын зәңгәр төнне сурәтли. Нагаев декорацияләрендә

романтик күтәренкелек һәм патетика, детальләрнең конкретлыгы ачык күренә, сәхнәдәге геройның тирә-юнендәге әйберләр тәфсилләп, нәфис эшләнәләр. (Блиндаж күренеше шундый.)

З. Хәбибуллинның «Раушан»ына декорация эскизларында Нагаев күңелле музыкаль әкиятнең якты колоритын, матурлыгын яратып тасвирлый. Төнге күктәге түгәрәк алсу ай, тавык тәпиләрендәге йорт, сихерле имән, кызыл учак — болар һәркайсы мавыктыргыч, кызык, гаҗәп һәм бераз куркыныч. Чын әкиятләрдә шулай булырга тиеш тә бит.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры М. Җәлил исемендәге татар опера һәм балет театрыннан бермә-бер әлкәнрәк: ул инде җиденче дистәгә аяк басты. Бу театрның декорация сәнгате дә зур тәҗрибәле, «стажлы». Биредә П. Беньковның нәфис, ягымлы буяулар белән эшләнгән декорацияләре М. Фәйзинең «Галиябану», Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә», К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» спектакльләренә ямь биреп тордылар. Биредә 1922 елда К. Гоццины «Принцесса Турандот» спектакленә беренче мәртәбә татар рәссамы Усман Арсланов декорацияләр әзерләде. Биредә гомерләре иртә өзелгән рәссамнар Мортаза Абдуллин, Ренат Һибәтуллиннарның иң яхшы декорацияләре иҗат ителде.

Хәзер бу театрның традицияләрен М. Сутюшев белән Ә. Тумашев уңышлы дәвам иттерәләр.

Әнәс Тумашевның декорация эскизлары күргәзмәдә гаять бай һәм күп иде. Алар Т. Гыйззәтнең «Чаткылар», Х. Сәлимҗановның Г. Ибраһимов повесте буенча эшләнгән «Татар хатыны ниләр күрми», Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә», М. Лермонтовның «Маскарад», К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр», С. Җамалның «Фатима Сабри» һ. б. спектакльләргә эшләнгәннәр.

Шик юк, Ә. Тумашев иҗатында татар театр рәсем сәнгате һәрвакыт үсештә: лирик тирәнлек, нечкә шигърият, бай колорит, халыкка якын һәм аңлаешлы тормыш дөреслеге буларак күз алдына килә. Тумашев эскизлары әдәби әсәрнең образлары белән һәрвакыт аваздашлар. Рәссам аерым сәхнә күренешләрен иллюстрацияләүдән бигрәк, аларны тулыландыра, яңа буяулар белән баета, үзәк мотивларны аңларга ярдәм итә.

Бигрәк тә Тумашевның романтик характердагы пьесалар өчен эшләнгән эскизлары үзенчәлекле. Ул аларда бөтен иҗатына хас эмоциональлеккә ирешә. М. Лермонтовның «Маскарад» исемле романтик драмасы да шул чорның конкрет-тарихи, көнкүреш вакыйгалары аша түгел, ә эмоциональ кичерешләргә корып җиһазланган.

Гуашь белән язылган күләмле рәсемнәрдә («Нинаның йокы бүлмәсе», «Бал. Уеннар йорты» һ. б.) буяуларда чагылдырылган төрле тойгылар, геройларның төрле лирик темалары — ягымлылык һәм шәфкатьсезлек, сафлык һәм мәкерлелек темалары музыкаль аһәңнәр кебек бертуктаусыз алышынып торалар.

Алтынсу-яшел төсләрдә бирелгән бал күренеше аеруча әйбәт: биредә һәрнәрсәдән салкын бөрки, һәрнәрсә үтәдән-үтә күренә, чыдамсыз, тиз уалучан. Вальс тавышлары шул төсләр белән бергә үрелеп ниндидер борчулы киеренкелек, нәрсәнедер шомланып көтү тойгысы уяталар. Рәссам, яктылык һәм төсләрне алыштырып, сәхнәне әле зәңгәр, әле сирень төсенә, әле шәмәхәгә, әле әфлисун төсенә күмә: тамашачыларга драмадагы вакыйгаларга тәңгәл матур буяулар сюитасы тәкъдим итә.

Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә»се өчен декорация эскизлары да шул ук принципта эшләнгәннәр. Баз-зиндан, әкиятләр иле Гөлстан, җәйге тәхет залы, кышкы тәхет залы, хан кызының зиннәтле бүлмәсе, төнге җәза күренешендәге шәһәр мәйданы... Бу картиналар җиһазларга ярлы, аларда артык бер әйбер дә юк, барысы да төсләр гаммасына корылган. Менә әкияти атаудагы чәчәкләр һәм яфраклар көзге күе кызгылт ялкын белән яналар, бөтен сәхнә җете кызылда коена. Җәза күренешендә салкын зәңгәрлектә төн куера, сакчы кулындагы факел ут һәм кара төтен белән күк йөзен каплап, төтәп яна. Шәрыкча көймәләп ясалган түбә-түшәм силуэты спектакльнең буеннан буена барлык күренешләрне берләштереп килә. Ул бер китапның матур миниатюр бизәге шикелле.

Романтик рәссам Тумашев шул ук вакытта декорацияләрендә һәрвакыт анык бер җирлектән аерылмый, тормыш-көнкүрешне яхшы белүен, туган җир пейзажын сурәтләү осталыгын күрсәтә, сәхнәдә реаль тормыштан образлар тудыра.

Мәнә Т. Гыйззәтнең «Чаткылар»ындагы иске татар авылы күренеше. Җиргә иңгән ярлы өйләр, бер якка кыйшайган сарай, череп беткән салам түбәләр. Бу тәссез, моңсу деньяя иркен күк йөзе белән бер дә ятышмый. Алсудан сарыга, сарыдан аксыл зәңгәрсуга сиздерми күчүче төсмерләр кичке шәфәкъне матур да, шомлы да итеп сурәтлиләр. Биредә өмет һәм сагыш төсмерләнә шикелле. Шул ук спектакльнең икенче бер күренешендә алтынсу һәм кызыл төсләр белән эшләнгән яхшы җиһазлы, җылы, пөхтә бай йорты бирелә. Йортның түбәсе кисеп алынган кебек. Аның артында еракта кырткә чумган салам түбәләре белән авыл җәйрәп ята. Тәнге салкын зәңгәр күк йөзенә күкшелләнеп ялгыз мәчет манарасы сузыла. Рәссамның бу алымы сәхнәдәге вакыйганы ике төрле лирик планда үстерергә ярдәм итә: зиннәтле келәмнәр түшәлгән җылы, рәхәт йорттан канәгатьлек һәм байлык аңкып тора, ләкин бирелгәге вакыйгалар ярлы авылның шомлылыгын, ятимлеген, нәрсәдер кетеп ятканын сәнгатьчә калкуландырып күрсәтә.

Тумашев иҗатында тарихи темалар белән мавыгу безнең көннәр драматургиясендәге заманчалыкка омтылу белән үрелеп килә. Рәссам Сәхиб Җамалның «Фатима Сабри» әсәрен бик яхшы декорацияләр белән бизәгән. Хәзерге гарәп шәһәре, реклама утлары, җиңел архитектур бизәкләр иркенлек һәм нәфислек тойгысы уяталар.

Яки К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романы буенча эшләнгән «Сәүбановлар» постановкасының оформлениесен карыйк. Тумашев крестьян йортын традицион стильдә, татар халык иҗаты стиленә зур игътибар биреп эшләгән. Ярлылар тормышының кырыс һәм драматик асылын гаять оста күрсәтә алган. Шулар белән үк янәшә Р. Ишморатның «Сәрле моң»ына ясалган декорацияләр. Болары инде җирнең ягымлы яшел төсләре, алтынсу күк йөзе, көмеш сыман каеннары белән бәхетле тыныч тормышның лирик күренеше булып кабул ителә.

Казан — театраль шәһәр. Аның гаять үзенчәлекле опера һәм академия театрлары белән янәшә әле бит атаклы рус театры да бар. Мин В. И. Качалов исемендәге Дәүләт зур драма театрын әйтәм.

Күргәзмәдә бу театрның ветеран рәссамы В. С. Никитинның кызыклы эшләре куелган иде. Никитин биредә 1937 елдан бирле эшләп килә. Поповның «Гаилә», Кронфельд һәм Компанецларның «Лейпциг — 33», Достоевскийның «Җинаять һәм җәза», Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов» кебек әсәрләренә декорация эскизлары белән Никитин үзенең вак кына детальләрне дә тәфсилләп төгәл эшләүче, таләпчән рәссам икәнен күрсәтте. Шулкадәр төгәл, һәр вак-төягенә кадәр җиренә җиткереп ясалган шул нәфис детальләрдән искиткеч җиңел, бер бөтен матур декорация туа. Бу җәһәттән аның «Мулланур Вахитов» драмасында дача күренеше игътибарга лаеклы — уенчыктай итеп эшләнгән аерым кисәкләр бергә туплангач, юка челтәр бизәкләре кебек график камиллеккә ирешәләр.

Качалов театрының декорация сәнгате тарихында Э. Гельмс аерым бер урын тота. Күргәзмәдә аның иҗаты шактый тулы яктыртылган иде. Иҗат интересларының гаҗәеп төрлелеге һәм зур эшчәнлеге, гомуми югары культурасы һәм профессиональ әзерлеге, хәзерге совет һәм чит ил театрын яхшы аңлавы, модага белеп иярә белүе һәм театраль фикерләвенең үткенлеге Гельмсны күптән инде республиканың популяр һәм сәләтле театр рәссамнарыннан итеп танытты. Гельмс Качалов театрында бүгенге совет сәнгатенә хас театраль формалар эзли: җиңеләйтелгән, динамик, һәрвакыт төрле-төрле, шартлылыклардан тайпылмаучан декорацияләр әзерли. Мисалга В. Маяковскийның «Мунча» спектакленә ясаган декорацияләрен («Вакыт машинасы» һ. б.) күрсәтергә мөмкин. Алар җиңел, график төгәл, фантастик конструкцияләрдә бирелгәннәр.

Гельмсның төп юнәлеше көлке-сатирик пландагы спектакльләргә декорацияләр ясауда. Бу рәссам көлке ситуацияләрне нечкә тоя, гротеск һәм шаржны яхшы аңлый, аның эскизлары күңелле, мәзәк, кетелмәгән үткен алымнарга бай. Моны без Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетына эшләгән декорация эскизларында аеруча ачык күрдек. (Гельмс Качалов театрыннан тыш Казандагы һәм Казаннан читтәге башка театрлар өчен дә эшли.) Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясенә финалны Гельмс әле моңа кадәр бер рәссам да тоймаган үткен юмор белән чишкән. Күргәзмәдә Ә. Тумашевның да шул ук финалга ясаган эскизы бар иде, анда без шатлыклы бәйрәм күренешен — дөртле һәм күңелле сабантуйны, якты зәңгәр күк йөзен, әкияти гаскәрнең хәрби бай-

ракларын хәтерләткән чигүле сөлгеләр бәйләнгән колгаларны күрәбез. Гельмста исә бөтенләй башка күренеш: беседкалар, таганнар, лареклар белән чуарландырылган шәһәр бакчасы мавыктыргыч, мәзәк рәсем итеп, үтә күренүчән салкын яшел төстәге акварельдә бирелгән.

Бер үк вакытта Гельмс кискен драматик киеренкелеккә корылган спектакльләрне дә Татарстан театр рәссамнары арасында иң оста җиһазлаучы. Ул спектакльләрнең трагик интонацияләрен йомшартмыйча, аларны тагын да көчәйтеп күрсәтә белә. Моны М. Булгаковның «Качу» пьесасында беренче пәрдәгә ясалган эскизларда, Р. Ишморатның «Үлемсез җыр» драмасын искиткеч бер бөтен кырыслык белән җиһазлауда да күреп була. «Үлемсез җыр». Төрмә камераларының күкшел юешлеге, концлагерьларның чәнечкеле тимер чыбыклары шулкадәр ышандыру көченә ия, син аларны чынлап күрә, тоя башлыйсың. Фашист тиранлыгының явызлыгы, дәһшәте тетрәндерә сине. Бу спектакльнең Алмашев бүлмәсендәге күренеш бигрәк тә тәэсирле эшләнгән. Ул сорыкөрән төсләрдә, анда бер яктылык әсәре юк, һава җитми, нәкъ таш капчык инде. Бүлмәдәге һәр деталь: кара мундирлы эсэсчы утырган биек готик кресло да, Алмашевның шәрык, мөселман стилен дәгъва итүче кызыл тахта-сәкесе дә, тимер кулына «Идел-Урал штаты» картасы тоткан килбәтсез рыцарь сыны да гаҗәеп фаш итү көченә ия. Кыю шартлылык, күпертеп күрсәтү пьесаның эчтәлеген тагын да тирәнрәк аңларга ярдәм итә. һәм шуның белән аклана да.

Татарстан театраль-декорация сәнгатенең үсеш дәрәҗәсе бәхәссез. Без моны театр, телевидение рәссамнарының, ниһаять, костюм осталарының иҗатындагы үзенчәлекләрдән ачык күрәбез. Костюмнар әзерләүдә сәләтле рәссам Л. Сперанскаяның иҗаты игътибарга лаеклы. Күргәзмәгә ул «Печән базары, яхут Яңа Кисекбаш» спектакленә эшләнгән костюм эскизларын куйган. Яхшы зәвык белән, бераз стильләштереп эшләнгән ул костюмнар әйбәт тәэзир калдыралар.

Яшь рәссам Л. Насыйров, Татар дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбле өчен эшләнгән искиткеч матур костюм эскизлары белән катнашып, күргәзмәне баеткан. Бу рәссам югары зәвыклы, халык иҗатының башлангыч чыганакларын тирән тоя, милли сәнгать традицияләрен әйбәт белә. Аңа гармония һәм колорит яңгыраш, рәсемнәрнең нәфислеге, милли бизәкләр салуда күпкырлылык хас. Л. Насыйровның таланты тагын бер өлкәдә ачык чагыла. Ул да булса театр плакаты сәнгате. Яшь рәссамның плакатлары декоратив, күзгә ташланучан, буяуларга бай, сурәтләр һәм хәрефләр бик үзенчәлекле.

Усман Абдулловның телевизион спектакльләргә ясаган эскизлары да кызыклы гына. Мәсәлән, «Салих Сәйдәшев музыкасы» дигән фильм-концертны ул бик яхшы иллюстрацияләгән. Телевидениенең спецификасына ярашлы график төгәллек, кыскалык, пөхтәлек, күләгәләр бирә белү хас бу рәссамга.

Тулаем алганда, республиканың театраль-декорация сәнгате үсешендәге бәхәссез уңышларны билгеләп, кайбер борчый торган кимчелекле якларга да тукталып үтик. Әле кайвакыт тупас, примитив, сәхнәдә аның ни өчен кирәклеге хакында уйламыйча, иҗат ялкыны салмыйча гына эшләнгән декорацияләр дә очраштыргалый. Алар, кызганычка каршы, спектакльләрдә дә күренгәли һәм сайлап алуда таләпчән, кырыс булган әлеге күргәзмәгә дә килеп кергәннәр. Мәсәлән, Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсына А. Чудаков эшләгән декорация эскизлары шундыйлардан. Алар артык чуар, төсләре күңелгә ятмый.

Яшь рәссамнар пассивлык күрсәтәләр. Ел саен дистәләрчә кызлар һәм егетләр Казан художество училищесының театраль-декорация бүлеген тәмамлап чыгалар, ләкин соңгы елларда шуларның бик азы гына иҗат активлыгы күрсәтте, театр сәхнәсенә һәм күргәзмәгә лаеклы әсәрләр тудырды.

Социалистик реализм принципларына нигезләнгән татар театр декорация сәнгатенең төп үсеш юлларыннан читкә тайпылу очраклары да юк түгел. Формаль эзләнүләр белән мавыгу, сәхнәдә «шаккатыризм», спектакльнең образлылыгына битараф карау, аерым алганда, Минзәлә театры рәссамы А. Яһудин иҗатында нык сизелә.

Кайбер көчле һәм талантлы рәссамнарның да вакыт-вакыт тынычланып, үз-үзләреннән канәгать булып, артык эзләнеп тормыйча гына иҗат итүләре шулай ук күңелне борчый. Тумашев та кайвакыт үз-үзен кабатлый башлый, мизансценаларны сүлпән һәм

бер төрле кора. Әйтергә кирәк, Гельмсның графика белән артык мавыгуы сизелә, коры, җансыз декорацияләр ясап ташлый, ашыга, теге яки бу күренешләргә игътибарсызлык күрсәтә дә, спектакль бертигез стильдә килеп чыкмый; Сутюшев исә эскизларын әпен-төпен генә эшли, ә бит театр рәссамы үз иҗатында сәхнәдә декорация коруны сәнгатьчә матур эшләнгән эскизлары белән раслап барырга тиеш.

Тартыр атка күбрәк төялә, ди борынгы татар мәкале. Татар театраль-декорация сәнгате күпне «тарта» ала, аның үсеше өчен Совет Татарстанында барлык шартлар да тудырылган. Бу өлкәдә бай традиция бар, даими рәвештә яңа кадрлар әзерләнеп тора, һәрвакыт алышынып торучы бай репертуарлы зур шәһәр театрларында иҗади тормыш кайный, һәм, иң мөһиме — татар халкының театрга, тамашага булган күптәнге олы мәхәббәте бар.

Димәк, театр рәссамнарына таләп тә зур булырга тиеш. Чөнки республика театр культурасының һәрьяклап үсеше аларның иҗатына да бәйле. Хезмәт ияләрен эстетик тәрбияләүдә театрның роле турында бөек Тукай:

**Халыкка дәрсе гыйбрәттер театр,**
**Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.**
**. . . . . . . . . . . . . .**
**Вәләкин шарты бар: яхшы төзелсә,**
**Әгәр һиммәт агачыннан өзелсә.**
**Ул алма мөтдәте тулганда пешкәч,**
**Кызаргач һәм матур булгач, җитешкәч,**

дип юкка гына әйтмәгәндер.

# *БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР*

**Т. КАМАЛИЕВ.** **Сезгә генә сөйлим. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970**

**Син бит безгә әти урынына,**
**Бер үзең син бөтен дөньяга.**
**Айлар, еллар, шулай гомер буе**
**Безнең өчен тагын кем яна!**

Кешелекнең сөекле юлбашчысы бөек Ильичка карата тирән мәхәббәт хисләре белән сугарылган бу шигъри юллар яшь шагыйрь Тәүфикъ Камалиевның «Бер үзең» исемле шигыреннән алынды. Аның күптән түгел басылып чыккан «Сезгә генә сөйлим» дигән яңа җыентыгы әнә шул шигырь белән ачыла. Шигырьдә дөнья халыкларының, даһи Ленин биреп калдырган җиңелмәс байрак астына тупланып, көрәшә-көрәшә, якты киләчәккә горур карап барулары турында сөйләнә. Нибары 12 юлдан торган әлеге шигырьне укыгач, яшь әдипнә теге яки бу фикерне кыска һәм җыйнак итеп әйтеп бирә алу сәләте барлыгын күрәсең. Дөрестән дә, Тәүфикъ үзенең иҗатында «кыскалыкта — осталык» дигән принциптан чыгып эш итә. Шуңа күрә аның шигырьләре укучыны ялыктырмый, бер кат уку белән күңелгә кереп кала. Менә бер мисал. Җыентыкта «...нең бер сүзе» исемле дүртьюллык шигырь бар. Автор анда болай ди:

**И бар да соң инде шигъри йортлар!**
**Тик минеке генә — алачык.**
**Ә шулай да, ачып бер кергәчтен,**
**Нидер сора, нидер ала чык...**

Шагыйрьнең «Сезгә генә сөйлим» җыентыгыннан, үзебезнең күңелебезгә салып, без «Чакырды, дәште», «Гыйльфан абзый», «Кунакка кем ишек ачмас», «Кайчан гына сүз кушсам да», «Утлар сүнгәч», «Иске эзгә төштем», «Насыйп микән», «Кем юатыр», «Ындырда... каравылда», «Район гостиницасында» шикелле матур-матур шигырьләр алып чыгабыз. Ул шигырьләрдә бер-берләре белән соңгы сыныкларын бүлешергә әзер торган гади кешеләрнең олы җанлылыгы, күңел яктылыгы чагыла. Ә менә «Чишмә», «Юкка», «Шик», «Һаман шул көе», «Һаман нидер көтәсең», «Күгәрченкәй, күгәрченкәй» һәм «Елмаюың» шигырьләрен автор үзенең шигъри алачыгына бераз ашыгыбрак керткән. Аларын хәзергә алачыкның теге ягында калдырып торганда да бик яраган булыр иде. Бу шигырьләр я ахырынача эшләнеп җитмәгәннәр, я булмаса шагыйрь аларда башкалар тарафыннан инде күптән әйтелгән, һәркемгә таныш фикерләрне кабатлый.

Тәүфикъ Камалиев — үз-үзенә карата таләпчән, эзләнүчән шагыйрь. Яңа җыентыгындагы кайбер шигырьләрендә аның тагын бер ягы белән ачыла баруын сизенергә мөмкин. Моңарчы нигездә лирик шигырьләр язган Тәүфикъның «Штрафның төрлесе бар», «Бер шабашникның сөйләгәннәре», «Алтын таңкә», «Кемнәрең бар» һ. б. шигырьләре юмористик рухта язылганнар. Киләчәктә бу жанрга ешрак мөрәҗәгать итсә, аның иҗаты, һичшиксез, тагын да тулылана, байый төшәр иде.

Яшь шагыйрь тәрҗемә өлкәсендә дә үзенең каләм көчен сынап карарга тырыша. Бу җыентыкта без аның тәрҗемәсендә бирелгән балкар шагыйре, дәүләт премиясе лауреаты Кайсын Кулиевның беричә шигыре белән танышабыз. Шигырьләрдә әйтелгән төп фикергә, аларның рухына хыйлаф кылмыйча эшләнгән әлеге тәрҗемәләр Тәүфикъ Камалиевның бу өлкәдә дә уңышка ирешәчәгенә өмет уята.

«Сезгә генә сөйлим» җыентыгы яшь әдипнең каләме шигырьдән шигырьгә, җыентыктан җыентыкка үткенләнә, камилләшә баруы турында сөйли.

**М. ӘГЪЛӘМОВ.** **Кыңгырау. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970**

Бер-берләренең үкчәләренә баса-баса, поэзиябезгә яңа, талантлы яшь көчләр килә. Алар арасында без матбугатта үзенең тавышын көннән-көн ныграк ишеттерә барган

Мөдәррис Әгъләмовны да күрәбез. Аның шигырьләренә үткәннәргә карап уйлану, бүгенге көннең шатлык-кайгыларын лирик геройның хис һәм тойгылары аша ачып бирергә, кешеләрнең эчке дөньяларына үтеп керергә омтылу хас. Моның шулай икәнлеген яшь шагыйрьнең быел Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Кыңгырау» исемле беренче җыентыгы шактый нигезле итеп дәлилли. Бу җыентыкка кергән шигырьләрне укып чыккач, Мөдәррисне барыннан да элек, ил язмышы, җир язмышы кызыксындыра, дигән нәтиҗәгә киләсең. Җыентыкта аның «Уфа юлы» дигән шигыре бар. Бу шигырендә автор патша заманнарыннан калган авыр истәлекләргә, почта атлары чабып үтсә, «колак салып авыл тыңлап калган» шомлы көннәргә мөрәҗәгать итә.

Ак патшаның кара хатларын да
Китергән ул почта атлары...
Авыр яраларын ачкан сыман,
Ачкан хаты илнең картлары,—

ди ул, патша тырнагы астында сыкранып яшәгән халыкның авыр язмышы өчен ачынып. Әмма халык йөрәгендәге иске яраларны янадан ачып күрсәтү яшь шагыйрь өчен үзмаксат түгел. Бу хакта искә алу ана Ленин гасырында яшәүче халкыбызның, бөтен буйга басып, үз тормышына үзе хуҗа булып яшәвен раслау өчен кирәк.

Мөдәррис Әгъләмовның ата-анага, өлкәннәргә багышлап язылган шигырьләре укучыда безне җиргә бүләк иткән һәм тәрбияләп үстергән иң кадерле кешеләргә карата тирән мәхәббәт хисе уята. «Әнигә», «Балам, бәгырем, диеп», «Оекбаш», «Канат» һ. б. шигырьләрдә бу тема аеруча киң яктыртыла. «Әнигә» шигырендә, мәсәлән, чәчләре иртә агарган аналарның авыр сугыш елларында кичергән михнәт-газаплары, кайгы-хәсрәтләре гәүдәләнә:

Сезнең гомерләрне искә алсам,
Янып китәр кебек камыллар...
Көлтә кебек кысып буганга тик
Бүселмичә торды кайгылар.

Җыентыкта яшь әдипнең дуслык, яшьлек-мәхәббәт темаларына багышланып язган шигырьләренә дә шактый киң урын бирелгән. «Сөн ага», «Чабаталар сатып яшәсәк тә» шигырьләрен укыганда, ир-егетләрә «сугышта бер тапкыр, тынычта мең тапкыр» сыналган ике дус халыкның — татар һәм башкорт халыкларының аерылгысыз дуслыгын, якынлыгын тоясың. «Юлдашым», «Тулай торак», «Авылларга чыкты көз кереп», «Соклану» шигырьләрендә исә матур хыяллар, олы теләкләр белән янып яшәүче яшьләребезнең якты омтылышлары чагыла.

Мөдәррис Әгъләмов күп яза. Аның һәркемнең күңелен дулкынландырырлык матур-матур шигырьләре вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле басылып тора. Әмма әнә шул әйбәт шигырьләрнең күбесе авторның беренче китабына кертелмәгән. Аның каравы яшь шагыйрьнең һәм эчтәлеге, һәм поэтик эшләнеше ягыннан шактый йомшак булган «Олылык», «Тулай торак коридоры», «Исемнәр», «Кош», «Каен суы дәште ана язын», «Сылу белән сөйләшү» кебек шигырьләре җыентыкта байтак урын били. Алдагы җыентыкларын матбугатка чыгарырга әзерләгәндә анда керәчәк шигырьләрен сайлауга автор игътибарлырак, таләпчәнрәк булсын иде дияse килә.

**Э. МӨЭМИНОВА. Бүләгем. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970**

Энже Мөэминова укучыларга үзенең вакытлы матбугат битләрендә әледән-әле басылып килә торган һәм аерым җыентыклар булып чыккан шигырьләре, поэмалары аша таныш. Поэзия сөюче дуслары хөкеменә шагыйрә быел үзенең яңа китабын — «Бүләгем» исемле җыентыгын тапшырды. Бу җыентыкка тупланган шигырьләрендә ул бүгенге көн өчен актуаль булган төрле темаларга мөрәҗәгать итә. «Россия тудырды Ильичны», «Мәхәббәте белән терелтә» һәм «Чын ярату белән яратам» шигырьләрендә автор бөек Ленинның һаман да «барлык тереләрдән тере» икәнлеген үзенчә әйтеп бирергә омтыла. Халыкның үз Ильичын беркайчан да үлемгә бирмәячәген тасвирлап язылган «Мәхәббәте белән терелтә» шигыре менә мондый юллар белән тәмамлана:

Гасыр буе халык үз Ленинын
Үзе өчен шулай
Мәхәббәте белән терелтә!

Энже Мөэминова иҗатында туган җирнең күркәмлеге, совет халыкларының олы дуслыгы, яшьләребезнең мораль сафлыгы, тигез мәхәббәткә нигезләнеп корылган семьяларның матурлыгы турындагы шигырьләр шактый киң урын алып тора. Аларның кайберләре «Бүләгем» җыентыгына да кер-

телгән. «Гел янәшә», «Мин — юлаучы», «Янар вулкан кебек», «Син һәм мин», «Нигә шулай», «Каен кызы», «Лампа яктысы» шигырьләрен укыганда лирик геройның эчкерсез хисләргә ия булган олы җанлы кеше икәнлеген тоясың. Эшләгән эшләре, дөньяга карашы, башкаларга карата булган мөнәсәбәте белән ул сине күп нәрсәләр турында уйланырга, үзеңнең үткән юлыңа тагын бер тапкыр борылып карарга мәҗбүр итә.

Менә гаҗәп! —
Баскан җирдән китеп булмый,
Китеп булмый —
Баскан урыным магнитланган!
Туган җиргә,
торган җиргә,
үскән җиргә
Мәхәббәтем мине шулай
бәйләп куйган! —

ди шагыйрә «Мин — юлаучы!» шигырендә. Бу юлларны аның белән бергә син дә кабатлыйсың, син дә күңеленә салып куясың.

Безнең әдәбиятта укытучылар һәм мәктәп тормышына багышланып язылган чәчмә әсәрләр дә, шигырьләр дә юк диярлек дәрәҗәдә аз. Профессиясе буенча укытучы буларак, Энже Мөэминова үзенә якыннан таныш булган әлеге теманы, әлбәттә, читләтеп үтә алмый. «Синең бәхет җинел бәхет түгел», «Борчылма син, әнкәй!», «Онытмадым» һ. б. кайбер шигырьләрендә без шагыйрәнең бу юнәлештә шактый кыю адымнар ясавын күрәбез.

Җыентыгы «Әйтегезче шуны, аналар», «Чагыштыру», «Сез тоярсыз кайту шатлыгын» дигән шигырьләрендә автор җирдә һәркемгә тормыш бүләк иткән аналарның тирән кичерешләрен, шатлык һәм борчуларын, балаларының аларга карата булган мөнәсәбәтләрен тасвирлый. Ләкин бу шигырьләрнең беренчесендә шагыйрә тел өстендә җитәрлек дәрәҗәдә эшләп җиткермәгән. Шигырьдә куллану өчен гомумән уңышлы булмаган «ләкин», «чөнки» кебек сүзләрнең беричә урында кабатлануы гына да моны бик ачык раслый. Шуна ук охшашлы кимчелекләрне башка кайбер шигырьләрдә дә еш очратырга мөмкин. Киләчәктә шагыйрә үз шигырьләренең техник эшләнешләренә дә игътибарлырак булсын иде. Укучы бит үзенә бүләккә тәкъдим ителгән әсәрләрнең барлык яктан да ахырынача төгәл эшләнеп беткән булуын таләп итә.

**Р. РӘХИМОВ. Туган җирем. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты. 1970**

Эсселектән үләннәр көйрәгән җәйге челлә көннәр. Бөтен табигать зарыгып яңгыр көтә. Ләкин күктә бер генә болыт әсәре дә күренми. Игеннәрнең язмышы өчен борчылып, йокысын һәм ашын онытккан авыл кешесенең җаны тыныч түгел. Менә-менә ниндидер могҗиза туачагына өмет баглагандай, үзенең күз карашын ул чалт аяз күккә төбәгән. Ә күк йөзендә һаман да берниндн үзгәреш юк. Игенченең йөзе кырыслана, борчылуы тагын да арта төшә.

Бәгыремә үтте корылык,
Сусызлыкта көйгән утыз көнем
Ярты гомеремә торырлык,—

ди ул, авыр сулап. Яшь шагыйрь Ринат Рәхимовның «Туган җирем» исемле яңа җыентыгын ачып җибәргән «Бәгыремә үтте корылык» шигыре әнә шулай башланып китә.

Ринат — авылда туып, шунда җир сукалап үскән егет. Безне туендырган туфракка, игенченең якты өмете булып шыткан уҗымнарга мәхәббәте аны басу-кырларга өзелмәс җепләр белән бәйли. Агроном профессиясенә ия булган Ринат Рәхимов хәзерге вакытта колхоз председателе булып эшли. Авыл кешеләре белән даими аралашып, аларның уй-теләкләре белән янып яшәү шагыйрьнең иҗатына да нәтиҗәле йогынты ясый. Аның күпчелек шигырьләренә җир язмышы өчен борчылу, илгә байлык-муллык бирү өчен үз-үзләрен аямыйча көрәшүче колхоз эшчәннәренең фидакарь хезмәтен олылау хас. «Иртә карлар — иртә чал төсе» шигырендә, мәсәлән, кыш иртә килеп, басу бәрәңгесе кар астында калыр дип, төн йокыларын оныткан агрономның кичерешләре чагыла:

Кар астында калса бәрәнге дип,
Ярылырга йөрәк җитеште...
Иртә карлар эрүен эреде дә,
Тик шул таңда чәчкә чал төште.

Яшь әдипнең «Һәрбер кырның була үз тургае», «Туган нигеземә мин йорт салдым», «Чапкан аттай ярсып типкән йөрәк», «Офыклардан күңелем киңәйгәндәй», «Якты өлгеләр», «Сабан туйда мәйданнарга чыктым», «Кырым минем» кебек шигырьләрендә дә тынгысыз авыл кешесенең хис-тойгылары чагыла. Җыентыкта халыклар дуслыгы те-

масына багышланып язылган шигырьләр белән дә танышырга мөмкин. «Ташкент ярасы» һәм «Мари җире хатирәсе» шигырьләре әнә шундый әсәрләр рәтенә керә. «Кәче крестьяннарының М. И. Калининга ике соравы» шигырендә автор Бөтенсоюз старостасының гадилеген, чабаталы татар крестьяннары белән уртак тел табып, ихлас күңелдән сөйләшүен укучыны ышандырырлык поэтик детальләр ярдәмендә күрсәтә алган.

Лирик шагыйрьгә хас булганча, Ринат Рәхимов үзенең шигырьләрен җиңел тел белән, җыйнак һәм аңлаешлы итеп язарга тырыша. Шуңа күрә аның һәрбер шигыре диярлек күңелгә тиз кереп урнаша, анда тасвирланган вакыйганы яки күренешне күз алдына бик җиңел китереп бастыра. «Кошлар телен белгән әнием бар» шигырендә без онытылгысыз әкият көйләп бишек тирбәткән киң күңелле ана белән очрашсак, «Үзебезнең авыл карчыгы» шигырендә «бәбкәләрен тилгәннәрдән саклап», шуның белән үзен юатып, узган яу кырыннан кайтмый калган биш улын онытып торгандай булган түзем карчыкны күрәбез. Шагыйрьнең симпатиясе һәрвакыт әнә шундый гади кешеләр ягында.

**Карт кешегә җылы күбрәк кирәк,**
**Син еш-рак елмай картларга.**
**Болай да бит бик еш моңаялар**
**Матур гына яшәр чакларда,—**

ди ул «Үзебезнең авыл карчыгы» шигырендә. Җыентыкның соңгы бүлегендәге «Иманнар» шигыре дә үзенең бөтен гомерен җир яме, халык бәхете өчен багышлаган эчкерсез һәм гадел кеше турында язылган.

Соңгы вакытта безнең поэзиябездә еш кына дүртьюллык яки сигезьюллык шигырьләргә мөрәҗәгать итү күзгә ташлана. Ринат Рәхимовның әлеге җыентыгында да дүртьюллык шигырьләрдән үрнәкләр бирелгән. Шагыйрь аларны «Җир ярасы» исемле гомуми баш астына туплап, «Туфрак-һава, җир-су язмышы турында уйланулар» дип атаган. Ләкин, ике-өч дүртьюллыкны искә алмаганда, бу циклга кергән шигырьләр җыентыктагы башка шигырьләрдән кайтыш язылганнар. Аларда Ринатның үзенә генә хас булган поэтик фикерләвен тоюы бик авыр. Ул шигырьләрне укучыга тәкъдим итми торганда да шагыйрь берни дә оттырмаган булыр иде. Ә гомумән җыентык күңелдә җылы тәэсир калдыра һәм Ринат Рәхимовның иҗатына карата булган өмет-ышанычны тагын да арттыра төшә.

**Гөлшат Зәйнашева**

## Конфет

Борын-борын заманда...
Юк ла, бүген — Казанда,
Бер танышларга кердем,
Конфет хәтле кыз күрдем!
Әллә чын, әллә ялган —
Бичара үсми калган!..
Кайгыра әниләре,
Кайгыра әбиләре;
Ник кызыбыз үсми, дип,
Бишектән дә төшми, дип,
Бакчага да йөрми, дип,
Бер нәрсә дә белми, дип...
Ничек укыр мәктәптә,
Пөри дә алмас хәтта!
Конфет хәтле диярләр,
Уч төбендә чөярләр!..
Ник үсмәгән дисезме?
Белергә телисезме?..
Көн-төн конфет сорый ул,
Ә бирмәсәң, җылый ул,
Ашый ул бары конфет,
Иртә конфет, кич конфет,
Бер түгел, унбиш конфет,
Бәрәңге һәм ипи ул
Хәтта авыз итми ул,
Ашамый ул күмәч тә,
Кача күмәч күргәч тә,
Яратмый ул аш һәм ит,
Суыра ул гел конфет,
Эчми ул катык һәм сөт,
Сорый конфет та конфет!
Һаман шулай яшәгәч,
Конфет кына ашагач,
Үсмәгән, гел үсмәгән,
Бишегеннән төшмәгән,
Кечерәя барган, ди,
Конфет хәтле калган, ди!..



# Корбан исемле малай



Иртә торган акырган,
Кич ятканда бакырган.
Туганнан бирле шулай
Җылак булган, ди, Корбан.
Җылак булып үскән ул,
Бәгырьләргә төшкән ул,
Тәпи йөри башлау белән,
Сугышып баш тишкән ул.
Әтисен тыңламаган,
Әнисен санламаган,
Игътибарсыз укыган,
Дәресен аңламаган.
Кызларны кыерсыткан,
Чәч толымнарын тарткан,
Малайларга бик ямьсез
Кушаматлар да таккан.
Уйныйк дисәң, бу Корбан
Уйнамаган, котырган,
Дуслары ни әйтсә дә



Сугышырга тотынган.
Көннәрдән бер көн шулай
Тупас телле бу малай
Урам аша чыкканда
Очраткан, ди, бер бабай.
Бабайга юл бирмәгән,
Өстәвенә тиргәгән —
Кычкырган тупас малай...
Аптырап калган бабай.
Ләкин шунысы чын микән;
Бабай тылсымчы икән,
Малайны кызык иткән,
Авызын бозып киткән:
Авыз, ди, хәзер кыек,
Үскән, ди, бик зур мыек.
Тупас кылану кая —
Сөйләшәлмый, ди, кыеп!..

## Әхмәт Рәшитов

### Шаян такмаклар

Горсоветта эшләр ходта,
Карарлар шап языла;
Башта урам асфальтлана
Аннан чокыр казыла.

Кибеткә барыр идем,
Перчатка алыр идем,—
Прилавка асларына
Яшерен юл салыр идем.

Аракы сөйгән берәүне
Җыелышта «кистеләр».
Шуннан соң барып өенә
Самогонын эчтеләр.

Телеграмма суккан идем
«Юлым уң булды!» диеп;
Өйдәгеләргә килгән ул:
«Улыгыз үлде...» диеп.

Быткомбинат керем юа,
Быткомбинат киптерә —
Кызылын да, зәңгәрен дә
Соргылт төсле иттерә.

Мунчаларга барыйм дисәм,
Яна йөрәк ялкыны:
Бер көнне булмый кайнар су,
Икенче көн — салкыны.

...Барча гаеп иләрен
Җыйнап аласы иде,
Кычыткан себерке белән
Шәпләп чабасы иде.

### Әсмабикә «дәвасы»

Әсмабикә абыстайның
Теше сызлый башлады.
Үрле-кырлы сикерсә дә,
Доктор-фәлән дәшмәде.

Ишетте, Арча ягында
Өшкерүче бар, имеш,
Ул өшкерсә, бетә, имеш,
Барлык сызлау, барлык шеш.

Абыстай төенчек кыстырып
Шул тарафка атлады,
Атлады, авызы эченнән
Догасын кабатлады.

«Лә иләһе илә лаһе...»
Баруга эше «пеште»;
Өшкерүче әзерләгән
Әрекмән суын эчте.

...Бер атна йөри абыстай,
Басылмый теш, сызлый теш.
Өстәвенә, атлаганда
Богыр-богыр килә эч.

Тагын китте Әсмабикә
Өшкерүче янына.
«Тешем, эчем авырта», ди,
«Карачы», дип ялына.

Бу юлы аңа бирелде
Күмердән куган нәрсә:
Кайтуга башка сукты шул —
Абыстай тагын хаста...

Им-томчыга йөри-йөри
Бер чиргә бишне алды.
Күпме сәдакалар салды
Һәм... гарип булып калды.

# Иван Законов

*Иван Законов — үзенең күпчелек әсәрләрен «Крокодил» журналы битләрендә һәм «Крокодил китапханәсе» исемле сериядә чыккан китапларда бастырып танылган рус шагыйрьләренең берсе. Ул күбесенчә сюжетлы сатирик шигырьләр, фельетоннар, юморескалар, пародияләр, көлке куплетлар яза. Казакъ, башкорт, осетин, мордва, чуваш әдәбиятларының күбесенчә сатирик һәм юмористик пландагы иң яхшы әсәрләрен русчага тәрҗемә итеп аерым китаплар чыгарды. 1970 елда аның тәрҗемәсендә «Татар елмаюлары» («Татарские улыбки») дигән шундый ук калын китап Казанда чыкты. Шагыйрь хәзер дә безнең сатирабызны бик тырышып тәрҗемә итә. Бәйрәм ашы кара-каршы дигәндәй, үз чиратларында безнең авторларыбыз да Иван Законовның кайбер әсәрләрен татарчага тәрҗемә иттеләр һәм итәләр. Түбәндә сез шуларның кайберләрен укырсыз.*

## Тәэсирле лекция

— «Гаилә һәм сөю» дигән
Лекция була икән,
Киттек, җаным, тыңлап карыйк.
— Мин риза, киттек, иркәм!

Бәлки кызык сүз сөйләрләр,
Шуннан көлеп кайтырбыз.
Бәлки ялгыш яшибездер —
Шуны белеп кайтырбыз!

...Киттеләр. Колхоз клубы
Туп-тулы, гөрләп тора,
Трибунада житди лектор
Су эчеп, тирләп тора:

«Гаилә кору йоласы
Пәйгамбәрләрдин калган —
Яһүд патшасы Соломон
Җиде йөз хатын алган!

Төрек солтаны Сөләйман
Барысыннан да уздырган:
Аның хәрәмсараенда
Һәкъ җиде мең кыз торган.

Ә Распутин... ә Распутин
Кыланмаган ни генә!
Мәгъшукаларын санап та
Чыгалмаган чигенә!

Ир — ир инде ул, иптәшләр,
Тик кенә тормас инде...
Ну, хатын-кыз да тикмәгә
Тамагын кырмас инде!

Әйтик, менә, Клеопатра!..
Юлий Цезарь нишләгән? —
Шул Мисыр хатынын сөеп
Харап булган, пешмәгән...

Ә тегә? Әйттем бит, юкка
Тамагын кырмас, диеп.
Берәү сөйгәч шул житте, дип,
Тик кенә тормас, диеп.

Күпме ирне харап иткән
Шушы Мисыр кәнтәе!
Тагын искә алып үтик
Падиша-әбекәйне...»

...Лекция тыңларга килгән
Ир тик кенә тормады —
Каш сикертте, гашыйк итте.
Янда гына утырган бер
Бибиклеопатраны!

Хатыны сизде:
— Месткомга
Явить итәм, эт! — диде.
Өйдә бәләк белән ярды
Ирен — Цезаретдинне...

Зөлфәт тәржемәсе

## Ишәк хөкеме

Дүрткүз котырды:
Һөжүм кылды Кәжә тәкәсенә,
Тиде бит тәмам теңкәсенә.
Ә тегесе,
Кире кагып этнең һөжүмен,
Батырды корсагына очлы мөгезен...
Кәжә тәкәсенең эше
Тапшырылды дисең кемгә?
Ишәк хөкеменә!
— Син,— диде Ишәк,—
Анларга тиеш идең үзең:
Очлыдыр һәм озындыр мөгезең.
Әгәр дә төптән уйлап карасаң,
Һөжүмнән саклану чарасын
Арттырып җибәргәнсең чамасыз —
Котыла алмассың каты җәзасыз!
— Сез аек фикер йөртегез:
Котырган Дүрткүз
Әгәр бугаздан алган булса мине?
Ишәк:

— Анысы анын,— диде,—
Башка мәсьәлә.
Ягъни мәсәлән,
Һәркем беләː
Җәза алыр иде
Җинаятенә күрә.
— Ә миңа ул җәзадан ни файда?
— Һемм... синең акылың кайда?
Син бит үлгән булыр идең күптән,
Шуның белән эшең дә беткән!

## Бюрократик мәзәк

Жалоба укый Сәйфетдин:
«Мондый гына нәрсәләрне
Ерып чыгар зам Гайфетдин —
Ул хәл итсен мәсьәләне...»
Кыза Гайфи, туза Гайфи:
«Тамыры,— ди,— моның тирән.
Курьер аша жалобаны
Пом Зәйнигә мин илттерәм».
Зәйни эшнең җитдилеген
Тиз төшенде, ялкынланды.
Кнопкага үрелде дә
Секретарен дәшеп алды:
«Мә, тиз житкер Шәймигә син!
Монда булса бер аягың,
Икенчесе анда булсын...»
...Һәм жалоба нәкъ бер айга
Кереп ятты зур тартмага —
Чөнки Шәйми ялда иде.
Кайтты Шәйми, әйтте Шәйми:
«Ул жалоба кайда?» — диде.
Җилле тота, баш шәп эшли,
Кулларына күз нярми.
«Синең эшең икән бу,— ди,—
Әйләндерче яле, Ярми!
Ярми яхшы әйләндерәː
Сызгалый да асларына,
Җәһәт кенә олактыра
Жалобаны... авторына!

**Марс Шабаев тәрҗемәләре**

## Рәхәтләндерү

Яна бер цикл
шигыреңне уку
Зур рәхәт булды,
талантлы дустым.
Исеме үк — алтын:
«Юкә янында...»
Кайлардан алып
шундыйны куштың?!.
Нәтиҗәм шундыйː
музыка дисәк,
Син бит Феттан да
көчлерәк, дустым.
Юк, алдап әйтмим...
Ә хискә килсәк,
Син Есениннан
хислерәк, дустым...
Сүзең — хәзинә!
шуңа да сине
Без, шагыйрь халкы,
бик якын иттек.

— Ә нишләп әле
монда торабыз,
Әйдә, алтыным,
буфетка киттек.
— Мәкалә язам
калын журналга
Барчасын әйтеп
иң рәсми тостә.
— Бу уңай белән
дәшми калалмыйм!
Буфетчы, безгә
йөзәрне өстә!
— Синдә зур талант.
Кыю эшлисең,
Сине тик шулай
диеп йөрибез.
— Официант кайда?
Безгә тиз генә
Йөзәрне өстәп
шашлык бирегез.

— Фикерең уткен,
формаң искиткеч
— Әйдә, алтыным,
коньяк эчик без!
— Лирикада син —
бердәнберебез!
— Официант! Безгә
шампань бирегез
— Кара нинди шәп:
«Юкә янында
Бер күрү белән
яраттым сине!»

— Алло! Официант!
Ике тавык бир
Һәм йөзәр грамм...
ярамый кимe!..
— Мин рәхәт күрәм
тик сине укып.
Петр...аркамы син?
Әллә... Хайям...мы?
Булды бер шагыйрь,
шундый мактауның
Сүзенә никтер
чынлап таянды.

## Битлек

Елмаеп каршы алыр да
Әйтер: «Уз әйдә, утыр!»
Уйлар: «Мин игътибарсыз дип
Әйтүче кеше юктыр».
Ләкин алай диюче юк,
Чөнки ул андый түгел.
Ялган битлек белән каплап
Үз үзен алдый күңел.
Кыланыр ул юмарт булып
Алтын тау вәгъдә итәр.
Ә биргәне — кукиш булыр
Көннәрне алдап үтәр.
Бар аның урынбасары,
Ярдәмче бар штатта.
Үзенә әйтә: «Юлга чык,
Бер районда эш тап та!»
Һәм менә китеп бара ул,
Командировка кулда.

Янәсе, массалар белән
Элемтә тота ул да.
Ә баргач нишли дисезме?
Аулда йөреп ял итә.
Бер әшнә белән утырып
Бөтен эшен хәл итә.
Типтереп бии белә ул,
Ә җыры: «Шаулый камыш...»
Шундыйны бер күргән идем,
Бар минем андый таныш.
Үзенә кирәк чараның
Чарасын күрә белер,
Шул чара өчен мал эзләп
Кесәгә керә белер.
Ә аның башына сугу,
Битлеген йөртү кирәк.
Кесәгә кул тыгып түгел,
Йөк тартып йөртү кирәк.

Зәки Нури тәрҗемәләре

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## БАШКАЛАДА СӨЙЛӘШҮ

Мәскәүдә РСФСР язучылар союзының сентябрь башларында үткәрелгән идарә утырышында Сибгат Хәкимнең поэмалары тикшерелде. Алим Кешоков җитәкчелегендә уздырылган бу утырышка шагыйрьнең «Дуга» һәм «Васыять» поэмалары гына куелган булса да, сүз аның барлык иҗаты турында барды.

Фикер алышуларда язучылардан Рафаэль Мостафин, Михаил Львов, Иван Рыжиков, Ахияр Хәкимов, Ренат Харисов, Җәмил Мостафин, Георгий Ладонщиков, Гариф Ахунов һәм «Балалар әдәбияты» нәшриятының СССР халыклары әдәбияты редакциясе җитәкчесе Галия ханым Кәримова һ. б. катнашты. Алар, татар совет поэзиясендә утыз елдан артык эшләгән шагыйрьнең иҗатына анализ ясап, аның халыкчан булуын, гражданлык хисләрен, тормыш һәм көрәш фәлсәфәсен тирән чагылдыруын әйттеләр. Тормышның конкрет детальләреннән туган шигырьләрнең зур фикерләр алып килүен шагыйрьнең осталыгы дип билгеләделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР НӨКИСТӘ

13—18 сентябрьдә татар шагыйрьләре Х. Туфан, Р. Фәйзуллин Үзбәкстан ССРның Каракалпак автономияле республикасында булдылар. Алар Татарстан вәкилләре сыйфатында Каракалпак язучыларының Нөкис (Нукус) шәһәрендә уздырылган VI съезды эшендә катнаштылар, чыгышлар ясадылар. Шулай ук Каракалпак совет поэзиясе ветераны С. Нурумбетовка 70 яшь тулуга багышланган тантаналы кичәдә дә катнаштылар.

## ЭШЧЕ ОБРАЗЫ ТУРЫНДА

Әлмәттә «Татар әдәбиятында эшче образы» дигән темага киңәшмә булды. Татар язучыларының әсәрләрендәге эшче образларына анализлар белән тәнкыйтьчеләрдән Т. Галиуллин, Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин һәм Флүн Мусин докладлар ясадылар.

Татнефть берләшмәсе, Түбән Кама химкомбинаты һәм Чаллы автозаводы җитәкчеләре Татарстанда киң колач белән алып барыла торган зур төзелешләр турында сөйләделәр. Киңәшмәдә Мәскәүдән әдәби газеталарның сотрудниклары һәм башкала нәшриятлары вәкилләре дә катнашты.

## ҖӘЙГЕ ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР

СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының этнография группасы сотрудниклары 1971 елдан башлап «Татар халкының этнографик атласы» дигән зур һәм мөһим темага керешәчәкләр. Берничә томнан торачак бу фәнни хезмәткә материал туплау инде башланды дияргә дә ярый. «Атлас» өчен төп чыганак булып илебезнең төрле өлкә һәм республика музейларында сакланган этнографик коллекцияләр хезмәт итә. Шуның өчен быелгы экспедиция сезонында институтның бер төркем этнографлары (Мөхәмедова Р. Г. — җитәкче, Сафин Ф. Ш. — лаборант, Бекташова З. — рәссам, Козина С. — фотограф) Горький һәм Касыйм шәһәр музей коллекцияләрен өйрәнү өстендә эшләделәр. Нәтиҗәдә институтның этнография фонды байтак яңа материал, бигрәк тә кием-салымга караган музей коллекцияләренең фотокопияләры, акварель рәсемнәр, сызымнар белән баетылды.

Ю. Г. Мөхәметшин җитәкчелегендәге икенче отряд Актаныш һәм Минзәлә районнарының Түбән Кама ГЭСы суы зонасына керүче, шушы 3—4 ел эчендә күчереләчәк татар авылларында этнографик материал җыйнады. Авылларның йорт төзелешләре, аларның архитектура һәм декоратив үзенчәлекләре, халыкта сакланган борынгы кием-салымнар, бизәнү әйберләре, авыл хуҗалыгы кораллары һ. б. ш. фиксацияләнде. Бу әйберләрнең фотолары, рә-



*Борынгы татар халкының кием үрнәкләре.*

семнәре, алар турында алынган мәгълүматлар этнографик атлас өчен материал булып хезмәт итәләр.

Алдагы елларда институтның этнографик экспедицияләре тагы да киңрәк территориядә һәм зуррак күләмдә алып барылачак.

Шул ук институтның фольклор секторы быел Төмән өлкәсендә яшәүче татарлар арасына экспедиция оештырды. Себер татарларының авыз иҗаты һәм музыкаль фольклорын туплауның берничә еллык программасын башлап җибәрү иде бу.

Шушы елның июнь-июль айларында филология фәннәре кандидаты Флора Әхметова җитәкчелегендәге экспедиция Төмән һәм Тубыл төбәгендәге күп кенә авылларны йөреп чыкты. Экспедиция җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Хуҗиәхмәт Мәхмүтов белән бергә, Тубыл районының Хуҗайлан, Бәйек, Үләртеш, Кызылбай, Күкрәнде, Комрау авылларында, институт фәнни хезмәткәре Нәгыйм Ибраһимов Вагай районының Карагай, Танбурьян, Көлгешле, Ишаер һәм Убы авылларында, институт хезмәткәре Нурмөхәммәт Хисамов һәм пединститут студенткасы Илсөя Һадиева Төмән районының Ямбай, Турай, Каскара авылларында, Тубыл районының Сатылган, Олы һәм Кече Юршак авылларында булдылар.

Экспедиция нәтиҗәсендә бай гына фольклор материалы тупланды. Язып алынган әсәрләр арасында йола фольклоры, борынгы җырлар, бәетләр, әкиятләр, мәкальләр, табышмаклар, риваятьләр, борынгы «Козы-Керпеш һәм Баян-Сылу» («Күзикә») дастанының өзекләр, «Кияү тиясәү» такмаклары бар.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ МУЗЕЕ

Казандагы А. М. Горький музее сотрудниклары татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышлап, Кырлайда музей оештыралар.

Алар Габдулла Тукай турында күп еллар буе материаллар тупладылар, хәзер бөек шагыйрьнең халык кулында саклануы мөмкин булган кулъязмаларын, китапларын, фоторәсемнәрен, шәхси әйберләрен эзләү һәм туплау эшенә керештеләр.

## ФАТИХ КӘРИМ МУЗЕЕ

Башкортстан АССРның Бишбүләк районында тагын бер музей төзелде. Гүзәл шигырьләре белән халкыбызны әсир иткән фронтовик шагыйрь Фатих Кәримнең туган җире Аит авылында шагыйрьнең музее ачылды. Бирегә шагыйрьнең кулъязмалары, китаплары, фоторәсемнәре, шәхси әйберләре, каләмдәш дусларының китаплары куелды. Музейга шагыйрьнең авылдашлары, мәктәп укучылары, замандашлары бик еш киләләр.

## ЯЗУЧЫЛАР ОЧРАШЫ

Август аенда башкалабызның Измайловский паркында Госман Бакиров татар хезмәт ияләре белән очрашты. Язучы аларны татар әдәбияты яңалыклары белән таныштырды, хәзерге көндә аларның нинди әсәрләр иҗат итүе турында сөйләде, үз әсәрләреннән өзекләр укыды.

* * *

Тукай премиясе лауреаты, композитор Заһид Хәбибуллин, язучылардан Ләбибә Ихсанова, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һәм Мәхмүт Хәсәновлар Азнакай колхоз-

ларында әдәби-музыкаль кичәләр уткәрделәр. Район газетасы каршындагы яшь язучылар түгәрәгендә булып, андагы яшь каләмнәр белән очраштылар, аларның шигырь һәм хикәяләренә җентекле анализ ясадылар.

Сентябрь башларында шул ук группа Киров өлкәсенең В. Поляна районында һәм Татарстанның Кукмара районнарында завод эшчеләре, колхозчылар, мәктәп укучылары белән очрашулар уткәрделәр. Кичәләрдә тыңлаучыларны әдәбият, музыка өлкәсендәге яңалыклар белән таныштырдылар. Үз әсәрләреннән өзекләр укыдылар. Композитор Заһит Хәбибуллин музыка ничек туа дигән темага күңелле әңгәмәләр уткәрде, үз әсәрләрен скрипкада уйнап күрсәтте. Бу очрашуларда Алабугада яшәүче прозаик Эдуард Касыймов та катнашты.

* * *

Шагыйрь Радиф Гатауллин, драматург Рәйсә Ишморатова һәм нәфис сүз остасы Рафаэль Галиев Сарман районы колхозларында колхозчылар белән очрашып, аларга татар әдәбияты яңалыкларын сөйләделәр. Шигырьләр, хикәяләр укыдылар.

## ДРАМАТУРГНЫ ИСКӘ АЛУ

Драматург Тажи Гыйззәтнең тууына 75 ел тулу уңае белән Казан шәһәренең Совет районы культура сараенда әдәби кичә уткәрелде. Кичәдә драматургның тормыш юлы һәм иҗаты турында сәнгать фәннәре кандидаты, язучы Баян Гыйззәт сөйләде. Язучы Габдрахман Минскийның истәлекләрен кичәдә утыручылар зур кызыксыну белән тыңладылар. Ахырдан Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары драматургның «Чаткылар» һәм «Кыю кызлар» дигән әсәрләреннән өзекләр күрсәттеләр.

## ХАЛЫК МӘХӘББӘТЕ

Заһид Хәбибуллин татар музыка сәнгатен баетуда озак еллар эшләгән композитор. Аның чын халыкчан моңнарын, балалар өчен язган «Раушан» балетын, инструменталь әсәрләрен яхшы беләләр. Сентябрь аенда композиторга 60 яшь тулды. Шул уңай белән Татарстан Верховный Совет Президиумы Заһид Хәбибуллинның музыка өлкәсендә күрсәткән зур хезмәтләрен искә алып, аңа Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исем бирде.

## ЯШЬ ХУДОЖНИКЛАР КҮРГӘЗМӘСЕ

Мәскәүдә «Юность» журналы редакциясе каршында республикабыз яшь художникларының күргәзмәсе ачылды. Бу күргәзмәгә Илдар Әхмәдиевның татар китапларына ясалган иллюстрацияләре, карикатуралары, Чехословакиядә сәяхәт иткән вакытта ясаган рәсемнәре, Тавил Хаҗиәхмәтовның «Халык әйтсә хак әйтә» дигән темага гравюралары, балалар китапларына иллюстрацияләре, Илдар Зариповның әсәрләре, Вацлав Зелинскийның сугышка каршы көрәш темасына эшләнгән гравюралары, китап иллюстрацияләре һәм Виктор Федоровның живопись, графика һәм портретлары куелды.

Бу күргәзмәне Татарстан художниклар союзы белән «Юность» редакциясе бергәләп оештырды.

## «ИДЕЛ» АНСАМБЛЕ БАШКОРТСТАНДА

Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Илһам Шакиров Башкортстан шәһәрләрендә гастрольдә булды. Ул «Идел» инструменталь ансамбле белән бергә татар халкының борынгы озын көйләрен, композиторларыбызның татар совет шагыйрьләре сүзләренә язылган җырларын башкарды.

Илһам Шакиров чыгышларын тамашачылар һәркайда алкышлап кабул иттеләр.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлегендә отчет-сайлау җыелышы булып узды. Бүлекнең җаваплы секретаре Р. Фәйзуллин бүлек бюросының соңгы ике елдагы эше турында отчет-хисап докладыбелән чыгыш ясады. Ул шушы чорда бүлек әдипләре иҗат иткән проза, поэзия, драма әсәрләренә анализ ясады, язучыларның тормыш белән бәйләнешләре ныгуын, иҗади географияләре киңәюен, СССР язучылар союзы члены булган иптәшләрнең сан ягыннан да үсүен билгеләп үтте. «Иң куанычлысы,— диде докладчы,— талантлы яшь прозаиклар, шагыйрьләр, драматурглар килә. Алар шушында туып үскән, җирле тормышны, кешеләрне яхшы беләләр. Киләчәктә алардан камил һәм колачлы әсәрләр көтәргә тулы хакыбыз бар». Фикер алышуларда Р. Төхфәтуллин, Г. Афзал, М. Хәсәнов, Э. Касыймов, С. Сөләймано-

ва, Ш. Бикчурин, М. Газизов, С. Кальметов, Ю. Эминев, Г. Рахим иптәшләр катнашты. Чыгыш ясаучыларның фикерләрен куәтләп, Казаннан килгән, язучылар союзының идарә членнары С. Хәким, Г. Ахунов иптәшләр дә бүлек бюросының эшенә югары бәя бирделәр. Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре итеп яңадан Р. Фәйзуллин сайланды.

* * *

Сентябрь башында Әлмәт шагыйре Ә. Маликов Сахалин партия өлкә комитеты чакыруы буенча командировкада йөреп кайтты. Сахалин агавын япон империалистларыннан азат итүгә 25 ел тулуга багышланган тантанада булды, хезмәт ияләре алдында уздырылган кичәләрдә чыгышлар ясады.

## ЮБИЛЕЙ ЕЛЫ ГАСТРОЛЬЛӘРЕ

В. И. Ленинның тууына 100 һәм Татарстанның төзелүенә 50 ел тулу уңае белән республикабыз театрлары бай репертуар булдырдылар. Август, сентябрь айларында алар, илебезнең калаларында, республикабыз районнарында чыгышлар ясап, хезмәт ияләрен үзләренең иҗатлары белән таныштырдылар.

Галиәскәр Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры коллективы, җәй айларында Мәскәүдә чыгышлар ясаганнан соң өч бригадага бүленеп, Татарстанның Азнакай, Бөгелмә, Саба, Кукмара, Балтач, Октябрь районнарында гастрольләрдә булды. М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры коллективы Кавказ шәһәрләрендә, Качалов исемендәге Зур драма театры Горький һәм Ижевск шәһәрләрендә спектакльләр күрсәттеләр.

Казан дәүләт курчак театры коллективының татар группасы Ульяновск, Пенза өлкәләрендә, республикабызның Алексеевск, Куйбышев, Октябрь районнарында булды, рус группасы исә Башкортстан тамашачылары белән очрашты.

Минзәлә драма театры коллективының беренче бригадасы сентябрь аенда Үзбәкстан шәһәрләрендә, икенче бригадасы Мөслим, Азнакай районнарында яңа сезон спектакльләрен күрсәттеләр.

Әлмәт драма театры да, ике төркемгә бүленеп, сентябрь аенда Башкортстан һәм Татарстан районнарында гастрольләрдә булды.

Театрларның спектакльләре һәркайда зур уңыш белән барды. Алар театр сәнгатебезнең шактый зур югарылыкта булуын күрсәттеләр.

## КАЗАНДА БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР

Сентябрь аенда М. Н. Ермолова исемендәге Мәскәү театры Казанда спектакльләр бирде. Башкала театрының гастрольләре Борис Лавреньевның совет әдәбиятының алтын фондына кергән әсәре — «Разлом» белән ачылды.

Бу театр коллективында кинофильмнар аша халкыбызга яхшы таныш булган артистлар да күп иде. Алар шәһәребезнең кинозалларында, колхоз һәм совхоз клубларында күп санлы тамашачылар белән очраштылар. Студентлар, театр училищесы укучылары, партия активы белән бергә үткәрелгән кичәләр дә бик җанлы үттеләр. Шәһәребез халкы башкала театрын яратып карады һәм тагын килүләрен үтенде.

## ТАТАР АРТИСТЛАРЫ ӘФГАНСТАНДА

Сентябрь аенда Мәскәү, Үзбәкстан, Таҗикстан, Әрмәнстан һәм Әзербайҗан артистларыннан торган бер төркем Әфганстанда чыгышлар ясадылар. Совет артистлары составында Татарстаннан республикабызның атказанган артистлары Фәйтүнә Абдуллина, Әнвәр Латыйповлар да бар иде.

Концертлар һәркайда зур уңышлар белән барды, Әфганстан матбугаты Совет артистларының осталыгына югары бәя бирде.

# 1970 ЕЛДА ЖУРНАЛ БИТЛӘРЕНДӘ БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР

## В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ


*Владимир Ильич Ленинның туына 100 ел тулу турында коммунистлар һәм эшчеләр партияләре киңәшмәсе мөрәҗәгате. № 4.*

*Владимир Ильич Ленинның туына 100 ел тулуга карата Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты тезисларыннан. № 4.*


### *Ленин — бөек якташыбыз*


С. Баттал. **Безне саклаган.** Шигырь. № 4.

Безнең лениниана. **Бәләкәй рецензияләр.** № 4.

Н. Дәүли. **Ленин турында уйлар.** Шигырь. № 4.

А. Костин, И. Моратов, А. Мөслимов. **Киң фарватерга чыкканда.** Мәкалә. № 4.

Р. Мостафин. **Минем горурлыгым.** Мәкалә. № 4.

А. Мөслимов. **Соңгы юлга.** Очерк. № 4.

А. Мөслимов. **Ильич урнәгендә.** Интервью. № 4.

Ф. Насыйров. **Ленинга хат җибәрик!** Репортаж. № 4.

И. Низамов. **Сагындым мин Иделне!** Публицистик мәкалә. № 4.

З. Нури. **Ленинга — чәчәкләр.** Репортаж. № 1.

З. Нури. **Йөрәккә якын җирләрдә.** Шигъри этюдлар. № 4.

Ә. Рәшитов. **Иптәш Ленинга хат.** Шигырь. № 3.

С. Сабиров. **Ул көннәрдә.** Очерк. № 4.

Ф. Табеев. **Юл башы.** Мәкалә. № 2.

**Татар әдипләренең Ленин турындагы фикерләре.** № 4.

А. Хәрәвиев. **Ягулык фронтында.** Мәкалә. № 4.

М. Хәсәнов. **Ленин тәгълиматы һәм татар халкының иҗтимагый-политик фикер тарихын өйрәнү мәсьәләләре.** Мәкалә. № 4.

С. Шакир. **Смольныйда.** Очерк. № 2.

С. Шакир. **Онытылмас хатирә.** Очерк. № 4.


### *Төрле илләрдән, төрле телләрдән*


Х. Алимҗан. **Онытылмас көн.** Шигырь. № 1.

Ж. Бриер. **Ленинга сәлам.** Шигырьдән өзек. № 2.

Г. Гараи. **Разливтагы исемсез кеше.** Шигырь. № 1.

С. Дангулов. **Изге теләк.** Әсәрдән өзек. № 3.

В. Диев. **Мәңге тере образ.** Мәкалә. № 2.

Л. Дмитерко. **Ленин җирләрне яраткан.** Шигырь. № 3.

М. Зощенко. **Ленин турында хикәяләр.** № 1.

С. Каляев. **Ленинны җырлыйм.** Шигырь. № 4.

Э. Каррера Герра. **Эшче иртәсе.** Шигырь. № 4.

Н. Крупская. **Ильичка нинди әдәби әсәрләр ошый иде.** Истәлек. № 4.

Ленин матбугатта. Мәкалә. № 4.
М. Львов. Якташ. Шигырь. № 4.
Ю. Мацявичюс. Аның исеме. Шигырь. № 3.
Б. Молоку. Ильичка. Шигырь. № 4.
Л. Радищев. Бер кечкенә эш. Хикәя. № 4.
Э. Ромеро. Ленин. Шигырь. № 4.
Н. Саба. Син яшисең шәрык йөрәгендә. Шигырь. № 3.
Д. Соколов. Дус. Хикәя. № 3.
К. Эренженов. Ленинда кунакта. Шигырь. № 1.
Р. эш-Шәһал. Ленин турында поэма. № 2.

## ТАТАРСТАН АССРга 50 ЕЛ

Автономиябез тарихы. Календарь битләреннән. № 6.
Н. Арсланов. Үз илем, үз республикам. Шигырь. № 6.
Г. Билалов. Татарстанны индустрияләштерү процессында пролетар интернационализм. Мәкалә. № 2.
Т. Галиуллин. Азатлык һәм гуманизм поэзиясе. Мәкалә. № 3.
Р. Гатауллин. Халкым уллары. Шигырь. № 6.
Б. Гыйззәтуллин. Республикабызның культура үсеше. Интервью. № 5.
Р. Гәрәй. Казаным. Шигырь. № 6.
Ф. Ибраһимова. Балалар әдәбияты, аның уңышлары. Мәкалә. № 1.
Г. Кашшаф. Аның идеяләре белән рухланып. Публицистик мәкалә. № 6.
Ф. Минушев. Игенче хезмәте. Интервью. № 6.
М. Мәхмүтов. Мәгърифәт нуры. Интервью. № 2.
И. Мөхетдинов. Иң мөһим бурычларның берсе. Интервью. № 6.
З. Нури. Ирек мәйданы. Шигырьдән өзек. № 6.
З. Сәйдәшева. Татар халкының революцион җырлары. Мәкалә. № 4.
Х. Туфан. Татарстан итеп күтәрдең. Шигырь. № 6.
Г. Усманов. Кем идек без һәм кем булдык. Мәкалә. № 6.
Ф. Хәкимова. Игелекле эшебез. Интервью. № 6.
М. Шабаев. Июнь иле. Шигырь. № 6.
М. Әгъләмов. Минем офыгым. Шигырь. № 6.

*Тукай премиясе лауреатлары. № 7.*
*Җәлил премиясе лауреатлары. № 7*

## БӨЕК ҖИҢҮГӘ 25 ЕЛ

А. Айнетдинов. Хөрмәт белән телгә алабыз. Мәкалә. № 5.
Г. Бакир. Җиңү сәгате сукканда. Истәлек. № 5.
Генераллар сөйли. № 5.
Н. Дәүли. Фронттан кайталмасам... Шигырь. № 5.
М. Мазунов. Хәтерлим аның зәңгәр күзләрен. Шигырь. № 5.
Ә. Маликов. Бу гасырның корыч давыллары. Хаклы идең... Шигырьләр. № 5.
Маршаллар сүзе. № 5.
З. Нури. Күңел дәфтәреннән. Шигырьләр. № 5.
М. Садри. Ут эчендә очрашулар. Хәрби хәбәрче язмалары. № 5—6.
Фронттан хатлар. № 5.
Н. Шевченко. Ул — матросовлар сафында. Очерк. № 5.
И. Эренбург. Татарлар. № 5.
Г. Әпсәләмов. Ватан кайда да бер генә. № 5.

## ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕ

И. Абдуллин. **Арыш сохарие. Юлларыңа чыгам ел саен. Аппендицит. Якасыннан алып булмый.** Хикәяләр. № 9.

Я. Винецкий. **Пушкин һәм Мәрьям.** Повесть. Русчадан В. Нуруллин тәрҗемәсе. № 2.

А. Гыйләҗев. **Урамнар артында яшел болын.** Роман. Ахыры. № 1.

Н. Дәүли. **Ату.** Хикәя. № 2.

Ә. Еники. **Картлар. Курай.** Хикәяләр. № 12.

М. Зарипов. **Соңгы вахта.** Хикәя. № 2.

М. Зарипов. **Вакытсыз туй.** Хикәя. № 10.

Р. Зыятдинов. **Бер телем икмәк.** Хикәя. № 5.

Д. Зөбәерова. **Дустым авазы.** Повесть. № 6.

Б. Камалов. **Күршеләр.** Повесть. № 2.

Э. Касыймов. **Сорбонна профессоры.** Повесть. № 4.

Г. Мөхәммәтшин. **Йөрәктәге эзләр.** Повесть. № 3—6.

И. Низамов. **Җилкәне киерелгән көймә.** Хикәя. № 6.

И. Нуруллин. **Хәсрәт бакчасы.** Хикәя. № 4.

В. Нуруллин. **Күпер чыкканда.** Повесть. № 7—8.

М. Рафиков. **Ишгилде.** Этюдлар. № 8.

Ш. Рәкыйпов. **Таңнар һаман матурмы!** Повесть. № 11—12.

С. Сабиров. **Хәтәр сәфәр.** Хикәя. № 6.

Ж. Тәрҗеманов. **Лобачевский һәм Хәлфин.** Романнан өзек. № 7.

Р. Төхфәтуллин. **Җиләкле аланнар.** Истәлек-хикәяләр. № 9.

Н. Фәттах. **Этил суы ака торур.** Тарихи роман. № 8—12.

Ф. Хөсни. **Өзелгән җыр.** Хикәя. № 11.

Ә. Шәмин. **Алтын медальон.** Хикәя. № 8.

## ПОЭЗИЯ ӘСӘРЛӘРЕ

Н. Арсланов. **Шагыйрьгә. Бер мизгелдә... Мамай курган. Аһ орабыз... Атлантида. Мин газазил булып баш күтәрдем. Кайгыдан да... Шагыйрь җаны. Төнге шигырь. Йорт казлары. Палубада.** Шигырьләр. № 5.

Н. Арсланов. **Казагыстан — туган ягым.** Поэма һәм шигырьләр. № 9.

Ә. Атнабаев. **Шатлыкларым, кайгыларым.** Шигырьләр. № 2.

Г. Афзал. **Гомер китабы. Тирәк. Уйландыра торган чак. Рәсүл Гамзатовтан. Яхшы.** Шигырьләр. № 7.

Ә. Баянов. **Сәяхәтнамә.** Кама этюдлары. № 10.

К. Булатова. **Туган җиремә. «Кеше бул», диеп. Син юк идең... Кайчан гына...** Шигырьләр. № 12.

Р. Вәлиев. **Аппассионата. Вакыт. Мизгел. Мәхәббәт.** Шигырьләр. № 8.

Ш. Галиев. **Үзем... Сынатма. Бер мең дүрт йөз унсигез көн... Нюра. Хәтимә апа. Ул фронтка... Музейда булган хәл. Карт карга. Карыйм да... Мәхәббәт һәм биография. Мәңгелектән... Сез тарихның... Тел очында... Көлмәк эченә... Район газетасында... Күптән яши... Кайнар кеше... «Уф-алла»ны... Үстерим дисең... Биш ел буе... Ай-һай... Шактый еллар...** Шигырьләр. № 7.

Р. Гатауллин. **Төрле дәфтәрләрдән.** Шигырьләр. № 1.

Р. Гатауллин. **Зур темага эскизлар.** Шигырьләр. № 4.

Рәшит Гатауллин. **Мин бәхетнең... Мин бу җирдә... Әллә ни әйтермен... Күктә йолдыз...** Шигырьләр. № 5.

Р. Гәрәй. **Туган якта. Ык өстендә йөзгән көймәләр. Безнең язмыш — туган ил язмышы. Урман йоклый. Казлар каурый койган көннәрдә. Сагынуларым чиктән ашканда. Кабынып яшә. Күңелем минем һаман окопта.** Шигырьләр. № 10.

С. Гәрәева. **Күк күз.** Шигырь. № 10.

Ә. Давыдов. **Иптәш секретарь. Бик борчылган... Совет халкым... Без бу урамнарны... Мәхәббәтнең... Уздылар... Бу дөньяның... Бөтен язган...** Шигырьләр. **№ 8.**

Н. Дәүли. **Рәхмәт сезгә, хатын-кызлар. Айга карап уйлаганда. Дусларыма.** Шигырьләр. **№ 11.**

Р. Закиров. **Сагынып... Киткәндә. Сәяхәтче карт.** Шигырьләр. **№ 5.**

Зөлфәт. **Очыш. Шаулый хәтер... Челдерәү. Болын. Кирәкми! Мәңгелек. Мизгел. Синнән ерakta. Таныш кышны сагыну. Без гениме!** Шигырьләр. **№ 7.**

Ә. Исхак. **Төрле ел шигырьләре.** Шигырьләр. **№ 11.**

С. Кудаш. **Ленин белән киңәш итәмен... Кышкы тылсым. Сагыну. Китәләр... Онытма. Юк, әзләмим. Кил әле...** Шигырьләр. **№ 11.**

Г. Латыйп. **Ленинизм таңы. Россиянең... Килдем мин... Чехов каены. Аргы очка таба... Шуларның берсе мин булырмын...** Шигырьләр. **№ 8.**

Н. Мадъяров. **Нинди язмыш... Тартар җыры... Кайчакта... Яшьлек безне... Җәй буенча... Кояшка...** Шигырьләр. **№ 7.**

Ш. Маннур. **Ник онытылмый.** Шигырь. **№ 5.**

З. Мансур. **Чыклы иртә.** Шигъри романнан өзекләр. **№ 5.**

Р. Мингалимов. **Минем дәүләт.** Поэма. **№ 4.**

Э. Мостафин. **Язмыш тәрәзәсе. Көймә. Кичә... Яралардан... Кайт, диярсең!** Шигырьләр. **№ 7.**

К. Мостафин. **Батырны... Тиен. Июнь төннәрендә... Кое.** Шигырьләр. **№ 9.**

Ш. Мөхмүдов. **Дөнья шул ул... Мәңгелек сәфәр. Кояшка. Чирек гасыр... Төнге уникe. Бик күп нәрсәләр... Диңгез буенда уйланулар. Эз. Стәрле юлы.** Шигырьләр. **№ 9.**

З. Мөҗитов. **Йөрәкне син... Илдә тормыш... Нием бар... Бу ни... Кояш кына... Сугылма, җил...:** Шигырьләр. **№ 11.**

З. Насыйбуллин. **Исем турында баллада. Канәгать. Урал. Этюд.** Шигырьләр. **№ 9.**

Н. Нәҗми. **Шагыйрьләр.** Шигырьләр. **№ 10.**

Р. Риян. **Еракларданкиләм. Салчы сүзе. Иртәнге музыка.** Шигырьләр. **№ 6.**

Г. Рәхим. **Туган як иманнарена. Тегермән. Шобагалар. Күзләреңне кара димәдем...** Шигырьләр. **№ 1.**

Г. Рәхим. **Бәхетем... Хыялый тебәктә. Урамнар артында... Кыр юлларын. Ут һәм су. Бу язны. Сагышны... Исемеңне бик еш...** Шигырьләр. **№ 12.**

Ө. Рәшитов. **Буыннар эстафетасы.** Поэма. **№ 6.**

Ә. Синегулов. **Кеше эзли. Яңгырда калган... Йөрәкнең.** Шигырьләр. **№ 12.**

Д. Сирай. **Буразна. Җир катысы. Болын. Тиргәмәсеннәр... Яра.** Шигырьләр. **№ 10.**

М. Сиражи. **Сукыр. Йолдызлы төн... Пар эз.** Шигырьләр. **№ 11.**

Б. Сөләйманов. **Синең моңнарың. Ак таңнарым... Әгәр егет... Буровойдан... Торозодон... Аучымы... Кезге урманда.** Шигырьләр. **№ 2.**

С. Сөләйманова. **Фал китабы.** Поэма. **№ 3.**

Х. Туфан. **Могикан. Әй!! Ник. Алар өчен дә. Хисләр утын... Робагыйлар.** Поэма һәм шигырьләр. **№ 2.**

Х. Туфан. **Кара арыслан.** Кем көчлерәк. **Лирика** һәм **физика. Сәлам әйтегез. Яп әле, яп. Мит а-а! Робагыйлар.** Шигырьләр. **№ 12.**

Е. Уткин. **Куеп иңне иңгә.** Атакага йөрде «Шүрәле». Шигырьләр. **№ 12.**

Р. Фәйзуллин. **Эшең юк... Хорлектән башлана... Дөньяда... Зур кеше.... Яудауларны... Кадер... Хак сүз... Әти эшләгән... Йөгереп уйнап... Бәлки син... Күктә — яшен... Этюд.** Шигырьләр. **№ 3.**

Т. Фәттах. **Сөләйманның беренче җыры. Нигә өрттым... Китәм. Зәңгәр күзләр.** Шигырьләр. **№ 9.**

Р. Харисов. **Синең йөрәк тә типсен!** Шигырьләр. **№ 2.**

Г. Хуҗиев. **Салават күпере.** Поэмадан өзек. **№ 11.**

С. Хәким. **Васыятьләр.** Поэма. **№ 1.**

Ф. Чанышева. **Акыл-киңәш сорап... Кар естендә... Яшьтәшемә.** Шигырьләр. **№ 10.**

Л. Шакирҗанова. Юри генә. Бар әле. Яшел урам. Сине көтәм. Әле яз... Нигә!.. Шигырьләр. № 5.

Ф. Шиһапова. Шундый бер моң... Соң аңладым... Шигырьләр. № 11.

Ф. Шәфигуллин. Ышанмагыз, авылдашлар. Йолдыз. Этюд. Миләш. Өмет. Тенге смена. Шигырьләр. № 7.

Ф. Яруллин. Кичтән юллар... Бер начарлык... Күккә менеп...: Кайчакта кеше...: Шигырьләр. № 10.

Рәшит Әхмәтҗанов. Шагыйрьләр. Баш сөягең... Көз. Күгемне ятим... Еракераклардан. Карт монологы. Артта—үлем, алда тормыш... Куркыныч булса... Шигырьләр. № 11.

Х. Әюпов. Урман. Карлар эреп... Язгы яңгыр... Шигырьләр. № 12.

Н. Әминова. Типте йөрәк... Чәчләремдә... Керфекләрең чыланмаган... Сөйдем сине... Айлы бер төн... Буй-сыннарың... Миңа моңсу... Мин башканы... Бер авыр сүз...: Җәйдә телим... Зәңгәр күктә... Ерактан ук... Гөлләр башын... Этюд. Шигырьләр. № 12.

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Р. Ишморатова. Яшьлек канат җәйгәндә. Пьеса. № 3.

С. Кальметов. Китап сатучы. Скетч. № 11.

С. Шәкүров. Мәхәббәт газабы. Пьеса. № 10.

## ДУСЛАР ИҖАТЫ

С. Асанов. Актлар залында. Комлев урамы, 15 йорт. Казан — Кокушкино юлында. Казан утлары. Шигырьләр. № 12.

Н. Байтирәков. Зифа сынлы... Юлыңа кызлар юлыкса... Шигырьләр. № 8.

Ф. Васильев. Дөм караңгы... Урманнарда. Яз килүгә. Шигырьләр. № 8.

Э. Гюнтер. Бары бер сүз. Шигырь. № 9.

В. Давыдов-Анатри. Рәхмәт сүзе. Балачак. Шигырьләр. № 10.

Ф. Ермаков. Бүгенге удмурд әдәбияты. Мәкалә. № 8.

К. Иванов. Тимер талкы. Баллада. № 5.

И. Йосыпов. Тукайга. Шигырь. № 4.

А. Клабуков-Багай. Ленин янына бару. Баллада. № 8.

Г. Красильников. Тугандаш халыкләр семьясында. Мәкалә. № 8.

М. Львов. Шагыйрьләр. Апрель аенда. Сыйфатлар. Дуслар юлга дәшә. Салават былбыллары. Шигырьләр. № 6.

С. Мәүленов. Нурлы яңгыр, җылы җил. Агыш. Тукай кабере янында. Кабан күле буенда. Казанның нәкъ уртасында. Татар кызы Галиябану. Галиябану, аман тор. Оялаган өй алдында. Син күрмәдең әле. Шигырьләр. № 6.

Г. Орлов. Бергә атлап... Шыта да... Көзгедәй төз юл. Шигырьләр. № 10.

С. Самсонов. Туган көнемне мин белмим. Повестьтан өзек. № 8.

М. Сениэль. Ана җыры. Яр буенда. Шигырьләр. № 10.

А. Талвир. Пиньпи. Хикәя. № 10.

М. Уйп. Безне кем таныштырды. Тып-тын иде. Шигырьләр. № 10.

Н. Хайтов. Хикмәтле хикәяләр. № 1.

П. Хузангай. Йөрәк җыры. Шигырь. № 10.

В. Щекачев. Аучылар. Кара төндә. Шигырьләр. № 1.

М. Юхма. Кояшлы чигү. Хикәя. № 10.

Р. Яшин. Икмәк турында җыр. Нарат. Шигырьләр. № 8.

## ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Ә. Баянов. Үкенечкә. Мәхәббәт корбаны. Әтәчләр сугышы. Баганалар. Шигырьләр. № 7.

И. Законов. Тәэсирле лекция. Ишәк хөкеме. Бюрократик мәзәк. Рәхәтләндерү. Битлек. Шигырьләр. № 12.

Р. Исаев. **Алма бабай. Үз башына төшсә.** Хикәяләр. № 11.

Т. Миннуллин. **Гомердә булмаганны...** Комедия. № 9.

В. Монасыпов. **Ньютон биномы. Шәмси каләше.** Юморескалар. № 6.

Г. Насыйров. **Бик нәни дүрт хикәя.** № 6.

З. Нури. **Көлке шигырьләр.** № 10.

Г. Рәхим. **Муенымнан... Ачуланган минутта. Борын-борынгыдан.** Шигырьләр. № 8.

Ә. Рәшитов. **Шаян такмаклар. Әсмабикә «дәвасы».** Шигырьләр. № 12.

С. Сабиров. **Сихер зәхмәте.** Яман төер. Хикәяләр. № 2.

Х. Сарьян. **Финал.** Хикәя. № 1.

И. Туктар. **Җөмләләр.** № 8.

И. Туктар. **Җөмләләр.** № 11.

Р. Фәизов. **Кыбырсык һабил.** Хикәя. № 2.

Р. Фәизов. **Соңгы батыр.** Хикәя. № 4.

Р. Фәизов. **Могҗиза. Күгәрчен Фазыл.** Хикәяләр. № 7.

Ф. Хөсни. **Кара кофе.** Хикәя. № 3.

Дусларча шаярулар. № 6, 10.

## БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Ш. Галиев. **Төньяктагы дустыма хат. Чар.** Кем белә! **Кыспа. Акбай белән Аккай.** Шигырьләр. № 5.

З. Гомәрова. **Нигә Вәли тиз үсми.** Күңелем. **Чыланудан качалар. Укып бир. Табышмак.** Шигырьләр. № 7.

Г. Зәйнашева. **Конфет. Корбан исемле малай.** Шигырьләр. № 12.

Р. Тимершин. **Беренче кар. Тере алма.** Сикәлтә. Флюгер. **Белеп торам. Үкенеч. Кызыгалардыр әле. Көз.** Шигырьләр. № 9.

## ХАЛЫК ИҖАТЫ

К. Дәүләтшин. **Фольклорда стихияле материализм.** № 5.

Р. Мөхәммәтҗанов. **Башкортстан татарлары җырлый.** № 1.

Ф. Әхмәтова. **Керәшен йолалары.** № 7.

## ОЧЕРК. ПУБЛИЦИСТИКА

Г. Ахунов, М. Зарипов. **Тормыш китабы.** № 4.

Г. Ахунов, М. Зарипов. **Татарстан — туган йортыбыз.** № 7.

Р. Гарәфетдинов. **Өч революция бөркете.** № 11.

В. Гудкова. **«Җай килү»нең сере.** № 7.

П. Дегтярев. **Революция солдаты.** № 12.

В. Исхаков. **Алтмыш дүртенче кавалер.** № 11.

Н. Ихсанов. **Батыр эштә беленер.** № 2.

М. Насыйбуллин. **Фидакарь Фидан.** № 12.

Ф. Насыйров. **Барысы да хәтердә.** № 3.

С. Рафиков. **Таш билге.** № 9.

И. Салахов. **Сикәлтәле сукмаклардан.** № 7.

Т. Сәгыйтов. **Тормыштагы эзләр.** № 11.

А. Сәләхетдинов. **Рәшә диңгезендә ак кораб. Баш конструктор.** № 10.

Г. Фәйзрахманов. **Пирамидалар илендә.** № 7.

М. Хөснимәрдәнов. **Бәхет үз кулыбызда.** № 3.

Ф. Хәмидуллин. **1918—1919 елларда Казанда культура хәрәкәте.** № 11.

М. Хәсәнов. **Исәнме, кошем!** № 6.

Н. Хәкимуллин. **Алтай тауларында.** № 12.

З. Шәфигуллин. **Авыл — шәһәр эзеннән.** № 7.

## СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Й. Вәлитова. Җырдай матур гомер. № 11.
Д. Гыймранова. Тыңгысыз кеше. № 10.
Г. Зәйнашева. Кәкүк. № 3.
Г. Зәйнашева. Сандугач. № 8.

## ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

К. Богданов. Габдулла абыйның соңгы күрүем. № 10.
Ә. Кайбышев. Казанда беренче татар спектакльләре. № 7.
З. Кәримова. Нәриман Нәриманов белән очрашу. № 3.
Х. Маннан. Ул минем остазым иде. № 9.
К. Мостакаев. Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан белән күрешү. № 8.
О. Полетаев. Революция баһадирлары. № 11.
Ә. Усманов. Партизан учаклары. № 6.

## ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ ҺӘМ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ш. Галиев. Гражданин нәни буламы, яки 437 сорауга җавап турында. № 9.
Х. Госман. Тарихчанлык принципбын үзләштерү юлында. № 7.
И. Иялова. Яңа үрләргә карап. № 7.
М. Мәһдиев. Профессор Гайнуллин һәм татар филологиясе. № 11.
Г. Рамазанов. Чын шигърият илендә. № 8.
Р. Сибәгатев. Тәрҗемәгә ике караш. № 7.
Г. Халит. Киләчәккә карап. № 3.
Г. Халит. Керәшче әдип портреты. № 11.
Г. Хантемирова. Тәрҗемәдә милли үзенчәлекләрне саклау. № 11.
Х. Хәйри. Роман һәм аның герое. № 2.
С. Шәйдуллин. Тутыкмас корал. № 10.
А. Әхмәдуллин. Драматургиябезнең кайбер тенденцияләре. № 6.

## ӘДӘБИЯТ ҺӘМ МӘДӘНИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Ф. Вәлиев. Борынгы архитектурабыз. № 1.
Давыллы елларда туган дуслык. № 8.
М. Госманов. Тарихтагы тирән эзләрдән. № 5.
Й. Исәнбәт. Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә. № 3.
Ә. Кәримуллин. Тормышка ашмаган проектлар. № 7.
З. Максудова. Шагыйрь Вәлиулла Чүпрәле. № 8.
Л. Небенцаль. Муса Җәлилнең көрәштәше. № 2.
Э. Сәгыйдова. Тукайның ике җыентыгы. № 1.
Ж. Фәйзи. Халык җәүһәрләре. № 1.
Р. Фәхретдинов. Болгар шәһәрләре. № 2.
В. Хаков. Әдәби тел хәзинәсенең кыйммәтле истәлеге. № 3.
Г. Әпсәләмов. Шагыйрьнең тагын бер рәсеме. № 1.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. Батуллин. Хыял дөньясында. № 7.
Г. Билалов. Ленин нурлары яктылыгында. № 9.
М. Госманов. Сүзлекләр тарихыннан. № 10.

Р. Лотфуллин. Гел кояшка карап. № 9.
М. Маннурова. Хәрби мемуарлар. № 2.
Р. Мостафин. Чорның шигъри шаһадәтнамәсе. № 5.
З. Рәмиев. Тормышның үзеннән. № 10.
П. Старостин. Туган ягыбызның ерак үткәне. № 7.
Ф. Фасеев. Котеп алынган сүзлек. № 8.
Р. Хәйретдинов. Данлы көннәр елъязмасы. № 5.
Ф. Шәфигуллин. Шифалы яңгыр. № 1.
Ф. Яруллин. Үткән каләм. № 9.
Ф. Әгъзәмов. Кешелекле солдатлар. № 2.

Бәләкәй рецензияләр. № 2, 4, 5, 6, 7, 8, 9, 11, 12.

## ӘДӘБИ-МӘДӘНИ БӘЙРӘМНӘР

### М. МАКСУДНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

А. Шамов. Зур тормыш. № 1.

### Җ. ФӘЙЗИГӘ 60 ЯШЬ

З. Хәйруллина. Көрәш һәм җиңү җырлары. № 1.

### Х. ХӘЙРИГӘ 60 ЯШЬ

Ф. Мусин. Алгы сафта. № 2.

### З. ХӘБИБУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

М. Җиһаншина. Нурлы җырлар остасы. № 10.

### Х. ТУФАНГА 70 ЯШЬ

Г. Бәширов. Барган саен юллар киңәлләрәк. № 12.
Т. Галиуллин. Сүз куәсы кипә талларга. № 12.
С. Кудаш. Ярты гасырдан соң... № 12.
Р. Моран. Туфан могҗизасы. № 12.
С. Хәким. Төнге ике... Шигырь. № 12.

### С. СӘЙДӘШЕВНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

М. Нигъмәтҗанов. Яңа тормыш җырчысы. № 12.
З. Сәйдәшева. Җырлар остасы. № 12.
Җ. Фәйзи. Онытылмас иптәш. № 12.

### БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Гомәр Гали. № 6.
Н. Гайнуллин. В. М. Бахметьев. № 8.
Халикъ Садри. № 8.
Ш. Садретдинов. С. Рәмиев. № 2.
Х. Хисмәтуллин. Фатих Кәрим. № 3.

## АЛАР БЕЗДӘ БУЛГАННАР

В. Климентовский. А. Н. Радищев. № 6.
В. Климентовский. Г. Р. Державин. № 8.
В. Климентовский. С. Т. Аксаков. № 11.

## ТӨРЛЕСЕННӘН

С. Алишев. Крестьяннар сугышында татарлар. №
Безнең сафка. № 4.
П. Савельев. Муса исеме алар телендә. № 8.
Г. Саттаров. Татарстан районнары һәм район үзәкләренең исемнәре. № 9.
С. Червонная. Куанычлы күренеш. № 4.
С. Червонная. Сәнгатьчә нәфислек өчен. № 12.
А. Шамов. Дустым турында. № 5.

## УКУЧЫЛАР СҮЗЕ

Х. Алмаева. Тәрҗемәләр әйбәтрәк булсын. № 9.
Һ. Афзалова. «Урамнар артында яшел болын». № 9.
С. Хәйретдинов. «Гыйльмениса» повесте. № 3.

## ҖЫРЛАР

НӘСИМӘ. З. Хәбибуллин музыкасы. Н. Арсланов сүзләре. № 3.
ТАТАРСТАНЫМ МИНЕМ. М. Яруллин музыкасы. Р. Харисов сүзләре. № 6.
АЛМАГӨЛ. Х. Вәлиуллин музыкасы. Г. Әпсәләмов сүзләре. № 8.
БӨДРӘ ТАЛ. Татар халык көе. № 10.

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—12.

*Хөрмәтле иптәшләр!*

«Казан утлары» журналына язылу дәвам итә.
Һәр айның 20 сенә кадәр сез алдагы айлар өчен журналга языла аласыз.

Безнең журналга бернинди чикләүсез һәм илебездәге теләсә кайсы элемтә бүлегендә язылырга мөмкин. Аңа язылу шартлары «Союзпечать»ләрдәге газета-журналлар каталогында күрсәтелгән. «Казан утлары» ул каталогка 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ